КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Бүреләр улавын ишетәм якыннан... *Шигырьләр.* ....................3
Зөлфәт ХӘКИМ. Серле тәңкә. *Роман.* ....................8
Равил РАХМАНИ. Кабынырга җитә сыңар чаткы... *Шигырьләр.* ....................69
Ләбиб ЛЕРОН. Кыршау. *Бәян.* ....................74
Дамир ГАРИФУЛЛИН. Гомер фасылларын озатамын... *Шигырьләр.* ....................113
Илдус ДИНДАРОВ. Ак төннәрнең кара көннәре. *Повесть.* ....................117

ЯҢА ИСЕМНӘР

Эльвина МИҢНУЛЛИНА. Тормыш ул – аяусыз бомба... *Шигырьләр.* ....................151

«ОЯСЫНДА НИ КҮРСӘ...» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Рабит БАТУЛЛА. Миң. *Хикәя.* ....................154

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Илкар ТӨРКУГЛЫ. Олыс нигезендә, телендә яши... *(Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ тәрҗемәсе).* ....................159
Сироҗиддин РАУФ. Яшәү җыры. *(Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА тәрҗемәсе).* ....................161

ЮБИЛЕЙЛАР

*Фотоархив*: Татарстан Язучылар берлеге оешуга – 90 ел. ....................164
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Чор рухын, заман сулышын тоеп. *(Тел галиме Фәрит Юсуповка 85 яшь тулу уңаеннан).* ....................166
Марс ГАИТОВ. Казан энциклопедистика фәнни мәктәбе. *(Мансур Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтына – 30 ел).* ....................172

КИТАП КҮЗӘТҮ

Рәҗәп БӘДРЕТДИНОВ. Хатыйп Миңнегулов – инсаниятнең бөек үрнәге. ....................181
Ралина ХӘБИРОВА. Тәлгат Галиуллинның 10 томлык «Сайланма әсәрләр» басмасына күзәтү. ....................183

*Хатлар яздым утырып:* Әнгам АТНАБАЙның Рәдиф ГАТАШка язган хатлары. ....................186

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Шигырь ул – тере җан иясе. *(Энҗе МӨЭМИНЕВАның тууына – 100 ел).* ....................189
Иманым – халыкка хезмәт. *(Миркасыйм ГОСМАНОВның тууына – 90 ел). Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ....................190

Әдәби сканворд. *Рәис ГАБДУЛЛА төзеде.* ....................191

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 5 (1219) 2024*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 27.04.2024, график буенча 27.04.2024, басылып чыгу вакыты 03.05.2024
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-0931. Тираж 4566.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.
12+
© «Казан утлары», 2024 ел



Фирүзә
Җамалетдинова

# БҮРЕЛӘР УЛАВЫН ИШЕТӘМ ЯКЫННАН...

## Илкәем

Илкәем, безнеңчә яшәргә мәҗбүрсең,
Кыйммәтләр башкарак, асылың үзгәргән.
Сүзләрең телеңдә әлегә кипмәгән,
Сагышың агыла безнең дә күзләрдән.

Илкәем, кайчакта еларга мәҗбүрсең,
Бернишләр хәлең юк, без шулай уйлагач.
Син – кемдер су сибәр диепләр ышанып,
Чүлдә дә яшәргә тырышкан төз агач.

Ятларга – ятсыңдыр, читләргә – читсеңдер,
Алар һич яратып төбәлмәс күзеңә.
Ышанмас сүзеңә. Әмма без сайлаган
Дәһшәтле язмышың килешкән үзеңә...

Без ничек күтәрсәк – син шушы күкләрдә,
Һәм ничек төшерсәк – син шушы төпкелдә.
Күр, тарих эзлибез, кара җир актарып,
Казыну нигәдер ут-кузлы ул көлдә?!

Һаман ут салырга ашкына йөрәкләр.
Һаман да бар гөнаһ өчен дә түлисең.
Беркем дә бирмәгән соравым урынсыз:
«Илкәем, син ничек яшәргә телисең?..»

---

Фирүзә ЖАМАЛЕТДИНОВА (1960) – *шагыйрә, прозаик; ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Һ.Такташ, Ф.Хөсни исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Толымлы ай», «Җирбизәк», «Хикәяләр» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Халкымны яратып

Учаклар сүнмәгән заманда
Җил йөргән тирмәләр тирәли.
...Кемнәрдер күн читек кигәндә,
Кемнәрдер җиләнен төймәли.

Башымны югары күтәрәм! –
Халкымның дәүләтле чаклары!
Тарихы – тояклар тавышында, –
Яратам ничек бар, ни барын!

...Учаклар пыскыган чорларда
Давыллар күтәргән тирмәсен.
Әйткәндер шикелле дәвер дә:
«Бу халык, әйдә, бер чирләсен».

Башымны тотамын!.. – Тыңлаучы
Булганмы ул чакта моң-зарын?
Көчсезне тукмавы бик җиңел... –
Яратам ничек бар, ни барын!

Учагы сүнгәндер – ут күрше
Алгандыр һәр утлы күмерен.
Чор буйлап җылылык тараткан,
Уйламый ялкыны кимерен.

...Күралмыйм кайчакта халкымны,
Күзаллап җиңүсез язларын.
Тоям күк дәүләттән язгандай
Теленнән, диненнән язарын...

Учакның көлләре суынган,
Тирмәләр тузгандыр туфанда.
...Бер очкын кабынган шикелле
«Халкым!» дип дәшәр сүз туганда.

Сагынам үткәнен... Җуймыйм дип,
Чигүле читекләр киямен.
Меңьяшәр халкымны яратып
Башымны иямен! Иямен...

## Бабам тал утырткан

Бабам тал утырткан капкага читләтеп,
Теләгең туфракка аш итеп кушкандыр.
Хыялын өстәгән, өметен салгандыр,
Сары төс – көздәндер, аклыгы – кыштандыр.

Ул нәзек, бик юка бер чыбык булгандыр,
Теләкнең кодрәтен тойгандыр шулай да.
Һәм үсеп киткәндер, яшим дип әйткәндер,
Тамырын туган җир җылыткан бер айда.

...Әтине, әнине шушы тал ышыклап,
Серләрен яшергән яфрагы күзенә.
Көн үскән, ай үскән, куерган җәй саен,
Елдан-ел сокланып үткәннәр үзенә.

...Төптән нык иде ул. Кәүсәсе яшерде,
Без куыш уйнадык шушы тал тирәли.
Мәңгелек бу җирдә ул яшен оныткан,
Куерган яфраклар җилдә дә тибрәлми.

Кайрысы купкан, күр, эчтәнме черегән,
Мин беләм давылның җавапсыз калмасын.
Кисалмыйм тик аны, эндәшәм улыма:
«Ерак тор, бәбкәем, өстеңә аумасын!»

Улкаем, барыбер, сүземне тыңламый,
Якын ук килгән дә юл эзли серенә.
«Бу талны киссәләр кисәрләр, әнием,
Төбендә, әнә, яшь үсенте күренә...»

## Әни җөй җөйли

Келтер-келтер әни җөй җөйли,
Тегү машинасы ни көйли?

Келтер-келтер бер җөй заманга:
«Тишек-тошык арта һаман да...»

Әнкәемнең уе, һай, асыл:
«Бөтәйтәсе иде дөньясын!»

Язын җөйли, җөйли көзләрен,
Җепкә ялгый өмет сүзләрен:

«Ничек тегим чорның ярасын...»
Алмашка гел бирмәк яңасын.

Кышын кышлый шулай, җәй җәйли,
Келтер-келтер әни җөй җөйли.

## Хәтер башкаласы

Минем хәтер башкаласы – Яшьлек.
Шунда кайтып төпләнәм дә һаман,
Киталмыйча йөдәп бетәм тәмам.
Ә китәргә кирәк миңа аннан.
Үткән көннәремнең йөрәгенә
Ләйсән тамчылары булып тамам.

Бөтен юллар башкалага илтә.
Бәхет капкалары ачылып китә –
Гүя мине анда кемдер көтә.
Помпейларны уйлыйм... Болгарларны...
Минем хәтер башкаласы исән!
Аны яшәтүче тик мин икән...

## Якут илендә

Эссе соң җәйләре Мәңгелек туңлыкта,
Мин монда үткәннәр куймаган бер нокта.

Мин монда нур җыям кабынган ялкыннан,
Бүреләр улавын ишетәм якыннан.

Бу яклар әле дә боланлы, тирмәле.
...Утырган бабамнар бер учак тирәли.

Бик ишле гаилә яшәгән кайчандыр,
Кайсыдыр – баһадир, кайсыдыр – бик чандыр.

Куанган балыктан йә аудан кайтканда,
Ул якты эленеп калгандыр кай таңда?!

Шул якты төшә күк җаныма әле дә,
Тере дә түгел мин, түгелмен үле дә.

Мәңгелек туңлыкта туңмаслык кавемне,
Җиңәргә теләгән әйткәндер: «Кем кемне?!.»

Яуларда җиңүләр – зур тарих ул чактан...
Алар бит ялкынны алган шул учактан!

Зәмһәрир җилләргә һичничек күнмәгән
Бабамнар учагы! – Ул әле сүнмәгән...

## Сорау бирәм

Бил бирмәскә дибез, бирешәбез,
Иелмәскә дибез, иеләбез.
«Ирек» диеп әйткән чагында без
Төкереккә хәтта төеләбез.

Йөткерәбез аннан күкрәк тотып,
Шул чагында Тукай төшә искә.
Акланасы килә сәбәп барга,
Хәзер инде дөнья, диеп, үзгә.

«...сынды кылыч...» – сынасылар сынган,
Авасылар ауган бу заманда,
Без бит әле барбыз! Җан бит исән!
Аһ, юрыйсы килми һич яманга...

Сабан туе әле җуелмаган,
Биле ныкны көтеп тора мәйдан.
Бабайларның түре монда, диеп,
Тукай тавышы килә әллә кайдан.

Ә халыкны шушы мәйдан туплый,
Көрәшләре тота күк югары.
«Сабантуйга диеп кайткансыңдыр?..» –
Мин улыма сорау бирәм бары.

«Әйе, әни... Шуңа...» Ә соң миңа
Нәрсә кирәк тагын моннан ары?!.

## Яңгырлы бер көндә

Болытлы, яңгырлы бер көндә
Мин бәйле түгелмен беркемгә.
Чыгасым юк хәтта кибеткә,
Юл, димим, бетмәгән кибеп тә.

Яшенле яңгырлы бер көндә,
Мөгаен, бар да үз иркемдә.
Вакыт та ага үз көенә,
Өчпочмак исләре өемдә.

Күкрәүле, яңгырлы бер көндә
Йөземнән якты нур бөркелә.
Көндәлек күрсәтә улкаем,
«Бишле»ләр алган ул фән саен.

Бүгенге яңгырлы бер көндә
Тәрәзгә төбәлдем: күк – иңдә...
Гүяки бик авыр ул күкләр,
Офыкка текәлдем мин никләр?..

Ә анда, еракта, ядрәләр
Телгәли аналар йөрәген.
Аңламый җирдә ни кирәген,
Сындыра өметен, терәген...

Мин – Ана! Башкача булалмыйм,
Мин – Ана, ышанмыйм беркемгә!
Тәрәзгә төбәлдем... Ник елыйм
Яшенле яңгырлы бер көндә?..

## Казык

Халкым кая казык какса, шунда шәһәр үскән,
Мәчет салган, ай караган түбәсеннән, өстән.

Айны камап, җиһан ялмап яңгыраган азан,
Шул илаһи тавышына биек калу язган.

Халкым кайда ат тугарса, шунда гөрли базар,
Базар аша үтүләрен кем әйтмәскә базар?

Саткан-алган, шау-шуына булмагандыр тиңнәр,
Баш югары, гәүдәләр төз, һич төшмәгән иңнәр.

Халкым кайда – иман нуры шунда тапкан аны,
Иман белән яшәгәндә тыныч булган җаны.

Ни үзгәргән? Иртәләрне алыштырган киче,
Әллә бер дә калмаганмы казык кагар көче?

Казыкларның черегенме әзерләгән заман? –
Бүгенгемне уйлаганда никтер хәлем яман.

Тарихың да, газиз халкым, кем өчендер азык.
Сине генә көтә, ишет, син кагасы казык!

***

Кайгылар сындыралмады,
Эреталмады шатлык.
Җилләреннән сизелсә дә,
Бу дөньяларга ятлык.

Мин үз иттем бар җиһанны,
Яраттым һәрбер гөлен.
Гел мәхәббәт тараткянга
Йөрәкләр телем-телем.

Ары үттем... Давыл узды,
Юлларымны бүлмәде.
Кайгысы да, шатлыгы да
Мәңгелеккә килмәде.

Алда ни? Аллаһы белә,
Карыймын бары көлеп.
Бу дөньяның кадерлесе
Булып яшимдер кебек...

## Күкләрнең яшьтәше

Күзләрнең бәгыре өзелә,
Күк тулып түгелә күз яше.
Күзәтәм өзелә-түгелә,
Гүя мин күкләрнең яшьтәше.

Ә кичә кояшлы көн иде,
Ничекләр күрмәдем бар нурын?!
Иркәсе биштәрен тутыра:
«Исән кайт, үлмә син, матурым!»

...Сугышның җөйләре сүтелгән.
Күңелләр янәдән кителгән.
Кемнәрдер каядыр чакыра,
Ул юллар югыйсә үтелгән...

Гыйбрәтләр алмаган безме ул?! –
Мең сорау, җавабы – тирәндә.

Ә бүген күкләрнең күз яше
Чылаткан кешеләр тирәмдә.

Туңасыз, өшисез, кешеләр,
Бер очкын сүнмәгән йөрәктә.
Тик сезне җылыта алмам шул
Ил, Ватан учагы кирәктә.

Күр, охшар икән лә охшаса
Заманның заманга шәкеле.
Чорлардан чорларга йөгерәм,
Мин яшәп арыдым шикелле.

Ишетәм: «Исән кайт, кадерлем!..»
Күк тулып түгелә күз яше.
Таяныр терәгем табалмыйм –
Гүя мин күкләрнең яшьтәше...

Зөлфәт
Хәким

# СЕРЛЕ ТӘҢКӘ

РОМАН

**21**

Икенче көнне Равил театрга теләр-теләмәс кенә барды. Бүгенге тамашадагы ролен ул бик ярата, башка көннәрдә уйнарга атлыгып тора, бүген исә кәефсез, күңелдә шатлыкның әсәре дә юк иде.

Спектакль башланырга әле сәгать ярым вакыт бар иде. Администратор кыз эчке элемтә телефонынннан шалтыратып:

– Сине телефонга чакыралар, – дигәч, Равил әле кем икәнен белмәсә дә, гримёркадан атылып чыгып, баскычтан астагы администратор бүлмәсенә йөгерде.

Шалтыратучы Лаура булып чыкты:

– Синең спектакльме бүген? – диде ул.

– Әйе. Әллә киләсеңме? – диде Равил, канатланып.

– Тамашаны карарга килә алмыйм. Ничәдә тәмамлана?

– Унынчы яртыда.

– Хатының кайттымы?

– Юк әле.

– Мине сәгать унда Чуйков урамында көт.

– Юк, унга мин кайтып җитешә алмам. Әйдә, унберенче яртыга.

– Ярар. Тулай торак янында мине көтәрсең.

– Көтәм, көтәм, – диде Равил, чиксез куанып. – Көтәм, Лаура!

Күңел тагын җилкенә башлады, илһам уты кабынды – аһ, бүген шәп уйнаячак ул үзенең ролен!

Залны тутырып утырган халыкка спектакль бик ошады, актёрларны көчле алкышларга күмделәр. Равил бүген башка көннәргә караганда да яхшырак уйнады, роль хәтта аз гына да алҗытмады. Лаура белән булачак ул бүген!

Равил, ашыга-ашыга киемнәрен алыштырды, битеннән гримны сөртте. Хәтта бүген хатынының кайтып керү ихтималы да куркытмады аны, театрдан атылып чыгып китте.

Унберенче унбиш минутта ул инде тулай торак янында, юлдан узган һәрбер машинаны күзәтеп, монысы белән Лаура килгәндер дигән өмет белән әрле-бирле йөреп тора иде.

---

*Ахыры. Башы узган санда.*

Ниһаять, юл кырында тукталган караңгы төстәге җиңел машинадан Лаура чыкты – соңгы вакытта кия торган соры плащтан, шәлен бүген башкачарак бәйләгән, кулына җыйнак кына куе зәңгәр төстәге юл сумкасы тоткан. Равил аның каршысына ашыкты.

– Исәнме, Лаура!

– Исәнме.

– Бир сумкаңны.

– Юк, юк, үзем тотам, – дип, Лаура, никтер сумканы бирергә теләмәде.

Тулай торак ишегеннән кергәч, вахтёр апа зур кызыксыну белән боларны каршы алып, Лаураны җентекләп күзәтте.

Равил аның яныннан үтеп барышлый:

– Хәерле кич, апа, – дигәч, вахтёр:

– Хәерле, хәерле... – дип, серле итеп җавап бирде.

Вахтадагы хатын артык сораулар биреп тормады, алар дүртенче катка менеп киттеләр. Гөлнара кайтмаган булса ярар иде дип уйлады Равил баскычтан менгәндә, вахтёр ападан сорыйсы калган. Әллә Лаура монда Равил янына бөтенләйгә килгәнме?.. Әнә бит, сумка күтәргән... Бу турыда ул сорарга базмады. Әгәр Лаура аның янына бөтенләйгә килгән булса, Гөлнара кайтып кергәч, коточкыч низаг кубачак... Ни булса, шул... Иң мөһиме – Лаура аның белән янәшә.

Баскычтан каршыга төшеп килүче ике кыз, стенага елышып, исәнләштеләр, Лаурага дикъкать белән карап калдылар. Дүртенче катка менгәч тә, кулына таба тотып, уртак кухнядан чыгып килүче юан гәүдәле яшь кыз, исәнләшеп, бер мәлгә Лаурага текәлеп торды.

Гөлнара әле кайтмаган иде. Бүлмәдә тәртипсезлеккә читенсенеп, Равил теләсә ничек аунап яткан әйберләрне тиз-тиз җыештырган булды.

– Чишен, – диде Равил, курткасын салып.

– Чишенеп тормыйм, – диде Лаура.

Равил аптырап китте:

– Ничек инде?..

Лаура нәрсәдер әйтергә җыена, әмма кыенсына кебек тоелды.

– Син, Равил, ышанычлы кеше... – диде Лаура. – Менә бу сумканы яшерергә урын таба алмассыңмы икән? Кичектермичә яшерергә кирәк аны.

– Нәрсә соң анда?

– Монда нindидер запрещённый әйберләр. Мин сиңа аннары аңлатырмын. Бездә обыск булды. Мин бу сумканы алып качтым, юкса, абыйның гына түгел, бөтен нәселебезнең эшләре харап була иде. Абыйның сумканы мунча өйалдына яшергәнен күргән идем мин. Тентү вакытында, сумканы алып, бакча артына йөгердем, беркем сизми калды, аннары, качапоса барып, стройматериаллар склады сакчысының телефоныннан сиңа шалтыраттым.

Равил сумканың замогын ачып, эченә күз салды, анда төрле төстәге полиэтиленга чорналган төргәкләр иде.

– Актарма, яме, – диде Лаура.

– Ярар.

– Минем бу товарга катнашым юк. Абыем кереп батты бу матавыкка, хәзер үзе дә үкенә инде. Ул моның белән шөгыльләнергә мәҗбүр булды,

чөнки бурычлары күп. Зинһар, яшереп сакла моны. Бу – бик кыйммәтле товар, аның белән абыем барлык бурычларыннан котыла алыр иде.

– Кая яшерергә соң аны?.. – диде Равил, уйга калып. – Гөлнара менә-менә кайтырга тиеш.

– Уйла, Рауль, уйла. Яшер, зинһар! Берүк хатының күрмәсен, – диде Лаура, өзгәләнеп.

Әле кая яшерергә икәнне белмәгән килеш, Равил сумканы алып калырга ризалашты. Лаураның һәр үтенечен үтәргә әзер иде ул, тәрәзәдән сикер дисә дә, мөгаен, аны-моны уйламыйча сикерер иде.

Равил Лаураны кочагына алды.

– Равил, хәзер кирәкми, – диде Лаура, аның кочагыннан чыгып. – Йә хатының кайтып керер.

Равил түрдәге урындыкка барып утырды, Лаура ишек катында торып калды.

– Өйләнергә ашыкмаска иде миңа, – дип куйды Равил, никтер түшәмгә карап.

Лаура аның янына килде, якты елмаеп, Равилне битеннән үпте:

– «Өйләнсәң, бәхетсезлекнең ни икәнен белерсең, өйләнмәсәң, гомер буе бәхетсез булырсың» дигән әйтемне ишеткәнең бармы?

Равил җанланып китте.

– Минем затлы шәраб бар, – диде ул. – Махсус алдым, синең белән эчәргә.

– Мин спиртлы эчемлек эчмим, рәхмәт, – дип, кулын Равилнең иңенә куйды Лаура.

Равил аның кулын тотып, кат-кат үпте.

– Син миндә кунасыңдыр бит?

– Юк. Мин өйгә кайтырга тиеш. Озатып та торма. Безгә хәзер синең белән бергә күренергә ярамый. Харманның сеңлесе булгач, мине күзәтәләрдер, мөгаен.

– Лаура, туктале, ашыкма, бераз янымда бул инде, – дип, Равил урыныннан кузгалды.

– Бераз булам, – диде Лаура, икенче урындыкка утырып.

– Мин сине яратам, Лаура! – диде Равил, бүлмә буйлап әрле-бирле йөреп.

– Чын әйтәсеңме? – дип сагышлы елмайды Лаура.

Равил, килеп, аның каршында чүгәләде:

– Әйе, чын әйтәм. Һич уйларымнан чыкмыйсың. Син бит минем беренче мәхәббәтем.

– Миңа кадәр гашыйк булганың юк идемени? – диде Лаура, аның башыннан сыпырып.

– Гыйшык-мыйшыклар булгалады, әмма алары мәхәббәт түгел иде әле.

– Сәер, киләчәккә бикләп куелган чегән кызына ничек гашыйк булырга мөмкин иде? – дип көлемсерәде Лаура.

– Киләчәкнең, синең анда бикләп куелуның ни катнашы бар?! Мин сине күрдем... Әллә нишләп киттем мин сине күргәч... Ничек шундый гүзәлне салкын киләчәккә ябып куярга мөмкин иде, аңламыйм.

– Бер күрүдә туган мәхәббәтне дәвалавы бик авыр дигәннәрен ишеткәнем бар иде шул.

Равил Лаурадан җылы сүзләр көтте, аның да яратам дип әйтүен ишетәсе килде, әмма Лаура моңсу күзләре белән Равилгә карый да елмая гына.

Равил тезләнгән килеш башын Лаураның алдына салды:

– Минем сине югалтасым килми, Лаура. Нык ярату газап тудыра, мин моны беләм... Әмма миңа син бик кирәк, тагын юкка чыгарсың дип куркам.

Лаура бармаклары белән Равилнең колагын капшады.

– Теге вакытта коткармаска идең мине, – диде ул моңсу тавыш белән. – Без танышмаган булыр идек, арабызда берни булмас иде.

– Коткармасам, сине милициягә тапшырырлар иде.

– Тапшырсалар ни. Мине авылга килгән өчен гаепли алмыйлар иде бит алар. Авылга чегән кызының марля алырга килүе җинаятьмени?

– Нишләп син «коткармаска идең» дисең? Синең миңа карата тирән хисләрең юкмыни?

– Син бик әйбәт кеше, мондый егетне бүтән очратканым юк минем. Син артык ихлас, артык гадел, дөньяга сокланып карыйсың, ә дөнья төкерә ул синең якты елмаюыңа.

Равил торып басты, Лаураның сүзләре белән аның һич кенә дә килешәсе килмәде.

– Минем өчен син – илаһи зат. Шуңа күрә синнән мондый сүзләр ишетүе авыр миңа, – дип, Равил тагын бүлмә буйлап йөрергә тотынды.

– Сиңа алга таба яшәве җиңел булмаячак. Яшәеш кануннары отыры вәхшиләнәчәк, ә синең күңелең моны кабул итәргә теләмәячәк. Син чынбарлыктагы кануннарга протест белдерәчәксең, ә ул кануннардан тыш башкалары юк.

– Син минем киләчәгемне дә әйтеп бирә аласыңмы әллә?

– Бир әле кулыңны.

Равил Лаурага кулын сузды.

– Кулыңнан ук күренеп тора, олы җанлы икәнлегең, – диде Лаура, Равилнең уч төбендә нәфис имән бармагын йөртеп. Әмма монда синең юлың сикәлтәле, авыр булачагы язылган.

– Мин бәхетсез булачакмынмыни? Син бит тугыз ел элек миңа бәхет юраган идең бугай...

– Сабый бала кебек син... Мин бит хәзер сиңа бәхетсез булачаксың димәдем, тормышың авыр, сикәлтәле булачак дидем.

– Яшәве җиңел түгел инде ул. Кеше бит үзенә генә буйсынмый, аның эчке күңеле нинди генә булмасын, ул барыбер кемнәргәдер, нәрсәгәдер яраклашырга тиеш. Кызганыч, адәм актыклары белән дә гармониядә яшәргә туры килә. Белсәң иде театрдагы хәлләрне! Ярый әле, халык театрны сәхнәдән генә, тамаша формасында гына күрә, театрның үзендә, эчендә нинди кешеләр, нинди пычраклыклар булганны белсә, бәлки тамашачы театрга йөрмәс тә иде.

Равил урындык алып килеп, Лаура каршына утырды. Хисләрен, теләкләрен, ниятләрен җиткерергә сүзләр табалмады ул, ничек аңлатырга Лаурага эчендә ниләр кайнаганын?!

– Мин сине яратам, Лаура, – диде ул һәм моны шулкадәр күңел тирәнлегеннән әйтте ки, хәтта күзләре бераз дымланды.

– Мин дә сине яратам, – диде Лаура.

– Чын әйтәсеңме?

– Мондый кешене ничек яратмыйсың инде. Сине бик күпләр яратадыр...

– Минем яратуым башка төрле. Мин сине мәңге яратачакмын!

– Бу мөмкин түгел.

– Нишләп? Минем белән бергә булсаң, бергә яшәсәк, ямансу, читен булыр дип уйлыйсыңмы? Мин синең тормышыңны төксе итмәс идем, сиңа рәхәт, кызык булсын өчен бар көчемне куяр идем.

– Инде күпме әйтергә була: без бит синең белән төрле дөнья кешеләре, шуны аңла.

– Ни дигән сүз инде бу?!

– Бергә яшәвебезне ничек күз алдыңа китерәсең?

– Аңламадым?..

– Туганнарым миңа беркайчан гаджо белән яшәргә рөхсәт бирмәячәкләр, ә мин яши торган шартларда син бер генә көн дә тора алмаячаксың. Син безнең чегәннәр гаиләсендә яши алыр идеңме?

– Юктыр, мөгаен, – диде Равил.

– Менә шул шул.

– Син минем белән якты дөньяга чыга аласың дип уйлыйм...

Лаура көлеп җибәрде:

– Сезнең дөнья яктымыни ул?!

– Мин сине яратам, сине сагынып бимазаланам. Бу мине ирексез итә, әмма үземне бернишләтә алмыйм.

– Димәк, башка кайгың юк, – диде Лаура битараф тавыш белән.

Равилнең кинәт йөзе караңгыланды:

– Миңа карата мөнәсәбәтеңне беләсем килә, – диде ул, башын салындырып.

– Син миңа бик якын кеше, Рауль, мин сиңа ышанам, шуңа күрә дә инде, бу сумканы күтәреп, сиңа килдем. Син моны яшер, беркемгә дә әйтмә. Алга таба уйларбыз, синең белән очрашырга җай табармын, үземнең дә синең белән буласым килә. Бу арада көннәр тынгысыз, безне тентиләр, абыйга куркыныч яный... Гел болай булмас дип өметләнәм... – Лаура күз яшьләре аша елмайды: – Рауль, аңламыйм – нәрсә күрдең, нәрсә таптың син миндә?

– Лаура!

Равил аның плащын салдырмакчы булды, әмма Лаура, торып, Равилне этте:

– Миңа кайтырга кирәк.

– Кайчан тагын очрашабыз?

– Белмим. Мин сине үзем табармын. Зинһар, сумканы яшер, яме.

– Яшерәм, яшерәм, борчылма, – диде Равил.

Юл буенда озак тормадылар, аксыл төстәге Жигули машинасы болар янында туктады.

– Син минем белән барма, – диде Лаура, машина ишеген ачканчы. – Үзем генә кайтам. Сау бул!

Машина борылышта күздән югалгач та әле, Равил шактый вакыт юл читендә басып торды.

Равил сумкада нәрсә икәнен аңлады. Юк, миңа моны калдырма дип әйтә алмады ул, киресенчә, сумканың аңарда саклануы алга таба да Лаура белән очрашырга сәбәп булыр дигән өметле уй өстенлек алды. Кызганыч, Лаура ашыгып китеп барды, югыйсә иртәгә театрда ял көне, аның белән көн буе бергә булырга мөмкинлек бар иде.

Равилгә мондый кыска вакытлы очрашуларның ләззәте юк, киресенчә, бу аны киеренкелектә тота, авызга ризык керми, сәхнәдә уйнавы авыр, театрда исә нәрсә булды, нишләп болай кәефсез дип, бөтенесе төпченә башлады, инде хатыны белән аерылышалар бугай дигән имеш-мимешле гайбәтләр дә ишетелгәләде.

Тумбочканың астын бушатып, сумканы шунда урнаштырырга туры килде, чөнки бу кечкенә бүлмәдә аны башка яшерер урын юк иде. Гөлнара килгәч, күрәчәк, һичшиксез актарачак. Кая яшерергә? Әнәсләргә илтеп булмый бит инде – ул угрозыск кешесе. Бәлки берәр җирдә күмеп куяргадыр... Һич югы авылга алып кайтырга, өйдәгеләргә күрсәтмичә берәр җиргә яшерергә кирәктер...

Соңгы вакытта йокының рәте юк, куркыныч төшләр керә, бүген тагын йокы начар булыр инде. Равил кайчандыр Гөлнара алып кайткан йоклаткыч даруны эчеп ятарга булды. Даруның тәэсире көчле булып чыкты – шактый вакыт караңгы уйлар белән бимазаланып ятканнан соң, ул каты йокыга талды.

Соң гына уянып, сәгатькә караса – унберенче ярты иде инде. Иренеп кенә торды, юынды, чәй куйды һәм шул вакытта Гөлнара кайтып керде.

– Сәлам, – диде Гөлнара, бүлмә эченә күз йөгерткәннән соң, иренә текәлеп.

– Сәлам, – дип елмаерга тырышты Равил.

– Әллә яңа тордыңмы син? – диде Гөлнара, кулындагы сумка белән пакетны идәнгә куеп.

– Әйе. Йоклата торган дару эчеп яткан идем.

Гөлнара усал итеп елмайды:

– Ай-яй рәхәт артист тормышы, көн уртасына кадәр йокларга мөмкин, – диде ул, җиңел пәлтәсен салып.

Равил Лаура алып килгән сумканы хатыны күрер дип коелып иңде.

– Әти-әниең нихәлләрдә? – дигән булды ул.

– Бер көе. Сиңа сәлам әйттеләр. «Нишләп син бездә чакта бер тапкыр да килеп китмәде?» – дип аптырадылар.

– Театрда эшләре тыгыз диденме?

– Әйтмәдем. Миннән башка рәхәт булдымы соң?

– Көн-төн театрда, рәхәтме-юкмы аңларлык түгел, – диде Равил. – Бер тапкыр да шалтыратмадың – ни театрга, ни вахтага, югыйсә өегездә телефон да бар...

– Ә ник үзең шалтыратмадың? Сөйрәлчек хатыннар белән гулять иттеңме?

Равилнең кәефе тәмам кырылды.

– Беркем белән дә гулять итмәдем, – диде ул, авыр сулап.

Гөлнара Равилгә шактый вакыт текәлеп карап торды – ире сагындым дип кочаклый башлар дип көткән иде ул, әмма Равил коры гына:

– Мин күрәм, монда кайтырга теләгең булмаган, ахрысы, – дип әйтеп ташлады.

Бер-берсен һич кенә дә сагынмаганнар икәне инде тәгаен аңлашылды.

– Мин берничә көн Гөлияләрдә кунам, – диде Гөлнара кинәт катгый тавыш белән.

– Нинди Гөлия ул?..

– Училищеда бергән укыган кыз, хәтерләмисеңмени? Туебызда да булды ул.

– Теге, инде ике тапкыр кияүгә чыгып аерылышкан подружкаңмы? – диде Равил, мыскыллы елмаеп.

– Анда синең эшең булмасын! – дип кинәт җикерде Гөлнара. – Үз тормышыңны рәтлә! Артист, имеш.

Шушы сүзләр белән ул сумкасын иңенә асты да чыгып китте.

**22**

Бу арада Равил бөтенләй үзен кая куярга белмәде. Берничә көн рәттән эшкә йә хәмер эчеп, йә махмырдан килгәч, театрда турыдан-туры кызыксына башладылар:

– Нәрсә булды?

– Хатын белән ызгыштык, – дип кенә җавап бирде Равил.

Бу сәбәпкә үз мөнәсәбәтен төрле кеше төрлечә белдерде. Кемдер: «Татулашырсыз әле», – диде. Кемдер: «Гаилә булгач, әлләниләр була инде», – дип тынычландырырга маташты. Кайсылары: «Гаиләңне сакла инде», – дигән булды. «Хатын-кыз бетмәгән дөньяда», – диючеләр дә табылды.

Әйе, хатын-кыз бетмәгән дөньяда, әмма Лаура – берәү генә!

Беркөнне ул үзенә: «Болай булмый! – диде. – Менә хәзер бер стакан шәраб эчәм дә иртәгәдән бер грамм да капмыйм!»

Шул көнне ул кичкырын чегәннәр йортына китте. Таксины читтәрәк туктатып төште дә шактый вакыт уйланып торды. Лаура яши торган йорт капкасы янындагы эскәмиядә кемдер утыра иде, ул әкрен генә шунда атлады.

Эре сөякле, яше сиксән тирәсендәге чал чәчле, ак сакаллы карт, күпне күргән, күпне абайлый торган күзләрен бер ноктага төбәп, трубкасын тартып утыра, бармаклары, трубканы эләктереп тотыр өчен махсус кәкрәйгән шикелле иде. Аның иске телогрейкасыннан да тәмәке исе килә иде, ахрысы. Күп йөргән ботинкасы кайчандыр бик затлы булгандыр – безнең кибетләрдә мондый аяк киеменең булганы да юктыр.

– Исәнмесез, – дип сәламләде картны Равил. – Сез бу йортта яшисезме?

– Сиңа нигә минем кайда яшәвем? – диде карт тыныч кына, үзенең «нокта»сына текәлгән килеш.

– Миңа Лаура исемле кызны күрергә иде.

Карт дымлы күзләре белән Равилгә карады:

– Утыр, нишләп басып торасың, – диде ул тонык тавыш белән.

Равил, янәшә утырып, соравын кабатларга кыймый торды. Картның трубкасы инде сүнгән, әмма ул аны барыбер торымнан-торымга авызына кабып суыра иде.

– Погода әйбәт бүген, – дип куйды Равил.

– Җаның тыныч булса, погода һәр көнне әйбәт, – диде карт, корык-корык ютәлләп.

Равил игътибар итте – бүген йорттан тавышлар ишетелми, тирә-якта бала-чага авазы да юк иде.

– Сез Лаураны беләсезме? – дип сорады Равил.

– Беләм.

– Өйдәме ул?

– Өйдә беркем дә юк.

– Кайда соң алар? – дип сораганын Равил үзе дә сизми калды.

– Белмим.

– Сез монда хәзер берүзегез калдыгызмыни?

– Кемдер йортка күз-колак булырга тиеш бит инде. – Карт, башын борып, Равилгә карап торды. – Син кем?

– Минем исемем Равил.

– Милициядәнме?

– Юк. Нишләп алай сорадыгыз?

– Соңгы вакытта милиция теңкәгә тия.

– Минем Лаураны күрәсем килгән иде.

– Ни йомышың бар аңа?

– Без – күптәнге танышлар.

– Ябык ишекне күрсәң, эчтә нәрсә барлыгын белми торып, анда керергә ашыкма, белсәң дә, ул ишекне шундук ачарга омтылма. Бәлки, ачмавың яхшырактыр, чөнки, анда кергәч, нәрсәләр буласы билгесез бит. Син кем Лаурага, ул сиңа кем?

– Лаура белән без – дуслар...

– Дуслык нәрсә соң ул? Туганлык элемтәләре булмаса, кешеләр арасында чын дуслык була алмый.

– Ничек инде?! Дөньяда дуслык бар бит инде ул.

– Бу дөньяда бик күп юк нәрсәне бар дип саный кеше. Дуслык туганнар арасында гына булырга мөмкин, дошманлык та туганнар арасында көчлерәк була.

Равил, үзе дә сизмәстән, бу әңгәмә белән мавыгып китте:

– Ә мәхәббәт? – диде ул.

– Нәрсә мәхәббәт?

– Туганлык булмаса, мәхәббәт тә юкмы?

– Әгәр егет белән кыз, ир белән хатын арасында мәхәббәт бар икән, димәк, алар арасында дуслык та булырга мөмкин. Мәхәббәт җимеше – бала, ә бу инде – туганлашу дигән сүз. Ике кеше нәселне дәвам итә, мәхәббәт – мәхәббәт ул, нәселне дәвам итүгә хезмәт итә торган хис.

– Ике кешенең, бер үк кавемнән булмасалар да, җаннар якынлыгы булырга мөмкин бит.

– Җаннар тәгаен якыная алмыйлар, җаннан җанга юлның чиге юк, аны ахыргача үтү мөмкин түгел. Галәмгә барып җитеп буламы? Аның ахыргы стансысы кайда? Галәм буйлап сәяхәт кылучы метеоритлар да мәңге очып кына йөри ала, беркая барып җитә алмый. Кеше күңеле дә шундый аерым бер космос.

– Сез Лаураның кеме буласыз?

– Без – бер нәселдән.

– Аны кайда, ничек күреп була икән?

– Кем соң син?

– Без инде моннан тугыз ел элек танышкан идек. Монда, Казанда соңгы вакытта берничә тапкыр очраштык. Минем аны бик күрәсем килә, мин яратам аны, – дип өстәп куйды Равил, әйтерсең лә шушы ак чәчле чегән карты аның хәлен аңларга тиеш иде.

– Мин аның кайда икәнен белмим. Күрәм, син ачык кеше, кирәгеннән артык ихлас егет.

– Лаура да миңа шулай дигән иде, – дип елмайды Равил.

– Начар сыйфат.

– Нишләп?

– Ихлас кешеләр үзләренчә куркыныч – турысын әйтеп салып, якыннарына зыян китерә алалар.

– Якыннарың начар гамәлләр кыла торган кешеләр булмаса, синең ихласлыгыңнан нинди зыян булырга мөмкин?

– Нәрсә соң ул – начар гамәл? Бер кешегә яхшылык кылсаң, икенче берәү өчен зыян булырга мөмкин. Бездәге игелек сезнең өчен яманлык булып күренергә мөмкин. Кешеләр әллә нинди касталарда булырга мөмкин: уголовниклар, җитәкчеләр, иректә йөрүчеләр, милиционерлар, чиновниклар, партия членнары – боларның һәрберсе өчен игелек үзгә.

– Миңа сәер тоелды теге сүзегез... Мәхәббәттән башка дуслык була алмый дип саныйсызмыни?

– Дуслыкка, гомумән, ышанмыйм мин. Нәрсә соң ул дус? Кем ул – дус? Дуслык бармы соң ул? Дустың белән сине ерткыч җанвар куа башласа, һәркайсыгыз ныграк йөгерергә тырышачак. Якын дустың харап булмасын дип, син, артта калып, ерткыч авызына керергә тырышмаячаксың...

– Шәп мисал, – дип көлеп җибәрде Равил.

«Нива» машинасы үтеп китте дә, урам башында борылып кире килгәч, йорт каршында туктады. Машинада дүрт кеше утыралар иде. Берсе – шофер кырыенда утырганы – чыгып киерелеп куйды, икенчесе, арткы ян тәрәзә пыяласын төшереп, тәмәке кабызды.

– Тагын килделәр, – дип сыктанып куйды карт.

Күп тә үтмәде, киерелгәне болар янына килеп басты. Күренеп тора, махсус кием кигән тыгыз гәүдәле 25-30 яшьләрдәге бу егет спорт белән шөгыльләнә, аның хәрәкәтләре җиңел вә житез иде.

– Нихәл, Михэй дәдәй, – диде ул, кыска чәчен никтер ике куллап артка таба сыпырып.

– Сәлам, – диде чегән карты, теләр-теләмәс кенә.

– Мине хәтерлисеңме?

– Мин сине күреп беләм. Исемеңне генә хәтерләмим, – диде Михэй карт.

– Абрек минем исемем. Харман кайтмадымы?

– Юк.

– Ә бу кем? – дип ишарәләде Абрек Равилгә. – Минем сине инде кайдадыр күргәнем бар шикелле.

– Казан бик зур түгел бит ул, – дип җавап бирде Равил.

– Михэй дәдәй, кем бу?

– Ул әле яңа гына килде. Бу тирәдә йорт сатучы юк микән дип кызыксына, – диде Михэй.

Абрек мыскыллы елмаеп:

– Акчаң күпмени? – диде.

– Миңа белешергә куштылар, үземә түгел, – диде Равил.

Абрекның дөрес юлда йөрүче кеше түгел икәне әллә кайдан күренеп тора иде, ул, чак кына Михэйга таба иелеп, яман усал тавыш белән:

– Михэй дәдәй, Харманга әйт, бу – соңгы кисәтү! – диде. – Секач янына килсен, ул аны көтә.

– Сез Харманга үзегез әйтегез, – диде Михэй, читкә карап. – Мин олы яшьтә, бүген бар мин, иртәгә юк. Бер-берегездән хәбәр ташып йөрергә минем вакытым да, хәлем дә калмады инде.

– Кайда соң ул? – диде Абрек.

– Белмим.

– Беләсең син, алдыйсың, картлач. Нишләп шушы кадәр алдакчы соң сез барыгыз да?!

– Миңа ышанмаган кешене мин алдыйм, – диде Михэй тыныч кына. – Миңа ышанган кешегә актык ризыгымны бүлеп бирә алам.

Абрек читкә төкереп куйды, аннары ямьсез елмаеп:

– Беләбез инде синең философ икәнеңне, – диде. – Гомер буе кырын-мырын гамәлләр кылып, хәйләләп яшиләр дә, картайгач, дөрес, матур сүзләр сөйләргә тотыналар.

– Нишлисең бит, кеше Алла кушкан юлдан гына йөрми, шайтан коткысына да бирелеп яши. Алла кешегә акыл биргән, шайтан – хәйләкәрлек. Дөньяда исән калыр өчен кайвакыт башкалардан хәйләкәррәк булырга кирәк.

– Аны мин философ булмасам да беләм, – диде Абрек. – Харманны Секач көтә, зарыгып көтә.

Абрек бүтән бер сүз дә әйтмәде, машина янына китте һәм, ул кереп утыргач, «Нива» тузан куптарып китеп барды.

– Болар кемнәр? – дип сорады Равил.

– Бандитлар, – диде карт, машина киткән якка карап. Ул авыр сулап куйды. – Хәзер үк китәр идем моннан. Йортта булырга куштылар шул. Хәзер үк теләсә кайсы тарафка бу тирәдән ераккарак юл тотар идем, менә хәзер үк юлга чыгар идем. Нинди зур бәхет бит ул – үз иркеңдә юлдан бару!

– Төнлә дәмени?

– Юлда чакта күктәге Ай – чегән өчен Кояш.

Шактый вакыт дәшмичә тып-тын утырганнан соң, Равил кузгалды:

– Мин машина юлы белән түгел, турыга барсам, олы юлга чыга аламмы? – дип сорады ул үз уйларына чумып утырган карттан.

– Туры барып кына әле беркемнең дә олы юлны тапканы юк, – дип җавап бирде Михэй.

**23**

Ике бүлмәле фатир Лаура өчен төрмәгә тиң иде. Монда ниндидер карт әби яшәгәндер, ахрысы – гади шкаф, иске телевизор, ике тумбочка, төсе уңган җәймәле диван, чалшайган урындыклар – боларның барысыннан да «борынгылык» аңкый, ичмаса телевизор да күрсәтми иде.

Лаура үзен алгы бүлмәдәге көзгедән карап торды: халат килешми иде аңа, йокысыз төннәрдән күз тирәләре каралып тора, йөзе сулыгып калган. Нишләргә белмәгәч, ул инде әллә ничә тапкыр чәй кайнатып эчте. Кечкенә кухняның тар гына өстәлендә әллә кайчаннан бирле чистартылмаган чәйнек, китек-ярык савыт-саба тора, әлүмин кашыклар ята. Бу фатирда гына түгел, гомумән, Казанда тынчу инде Лаурага. Көньяк тарафларына китәргә тиеш иде бит ул, анда ачык кырларга чыгарга мөмкинлек бар,

шунда гына җаны ял итәчәк аның. Харман абыйсының проблемалары бетү белән моннан качарга кирәк.

Ишек йозагы кыштырдагач, Лаура куырылып китте. Тын да алырга куркып торганда, ул үзенең йөрәк тибешен ишетте. Ишектәге «глазок»тан карарга базмыйча, ул, аяк очларына гына басып, диванга барып утырды. Менә ишек әкрен генә ачылды, сак кына басып, кемдер керде.

Харман пәйда булгач, Лаура иркен сулап куйды. Абыйсы пакет белән ризык алып килгән иде.

– Суыткычка куй, – диде Харман, пакетны сеңлесенә биреп.

Харман – урта буйлы, төптән юан гәүдәле, кырыкка җитеп килүче ир-егет иде. Аның башы алдан пеләшләнә башлаган, калган өлешендә чәчен нәселдән килгән бөдрәлек бизәп тора, Лаура абыйсы белән аз гына да охшаш түгел, Харманның йөзе түгәрәк, күзләре куе чәй төсендә, җәенке борынлы, калын иренле, тыгыз гәүдәсе, юан муенлы киң җилкәсе бераз кәкрерәк аякларына урнаштырылган какшамас бер бронза монументны хәтерләтә иде.

Ризыкларны суыткычка урнаштырып, абыйсы янына чыккач, Лаура:

– Нишләп озак килми тордың? – диде.

Харман курткасын салмаган килеш тәрәзәдән тышка карап тора иде.

– Артымнан күзәтеп йөрүчеләрне шәйләдем, – диде ул. – Урап-урап килергә туры килде.

– Харман абый, китик тизрәк моннан! – диде Лаура, ачынып.

– Мондагы матавыкларны ерып бетермичә китәргә ярамый. Товарны аңа биреп, дөрес эшләдең микән?

– Кая яшерергә тиеш идем соң мин аны? Ул – ышанычлы егет. Әле ярый тентү вакытында алып качарга батырчылыгым җитте.

Харман сеңлесенә елмайды:

– Ничек белдең кая яшергәнемне?

– Керләр элгәндә, мунча өйалдына сумка белән кергәнеңне күреп алган идем. Синең тайник кайсы төштә икәнне беләм бит мин.

– Ярый күргәнсең әле, – дип куйды Харман. – Актёр подводить итмәс микән дип кенә борчылам.

– Ул сине милициядән чыгарырга ярдәм итте.

– Менә шул угрозыскттагы дустына товарны илтеп бирсә?

– Юк, алай эшләмәс, – диде Лаура. – Без монда озак булачакбызмы?

– Ростовтан безнең кешеләр килергә тиеш, алар килгәч чыгарбыз.

– Абый, тизрәк котыл бу товардан, котыл бу эштән, – диде Лаура, өзгәләнеп. – Инде Казаннан китәрмен дип хыялланган идем.

– Лаура, әлегә син монда булырга тиеш. Актёрдан товарны алгач китәрсең. Иң яраткан сеңлем бит син минем, – дип, Харман сеңлесен кочып, битеннән үпте.

– Син дә – минем иң яраткан абыем, – диде Лаура, яулык почмагы белән күз яшен сөртеп. – Нишләп син гел тирән матавыкларга килеп эләгәсең? Югыйсә Одессага китәргә мөмкинлегебез дә бар иде бит...

– Кая барсак та, шул ук дөнья, шул ук тормыш, – диде Харман, авыр сулап. – Анда да шул ук кояш нурын сибә. Кайда безне көтәләр? Без аннан бер киткән идек бит инде.

– Безнең кавем кайчандыр бер киткән җирләргә яңадан бара түгелме?

– Түз, күп калмады, тиздән китәбез моннан.

Кинәт ишекне шакыдылар. Лаура дерт итеп куйды, Харман әкрен генә ал бүлмәгә атлады. Ишекне ныграк кактылар. Инде катырак дөбердәтә башлагач, Лаура, ишек катына барып:

– Кем? – дип сорады.

– Электрик, – диделәр тыштан. – Счётчикны карарга кирәк.

– Әле күптән түгел тикшерделәр, – дигән булды Лаура.

Ишеккә тибә үк башладылар, ватулары ихтимал дип уйлап, Харман ачарга булды.

Фатирга бер-бер атлы дүрт егет килеп керде, барысы да күн курткадан, дүртесенә дә 25-30 яшьләр тирәсе иде. Алдан кергәне Абрек иде. Ул, олы авызын чалшайтып, ямьсез елмайды:

– Син, Харман, электр уты өчен дә түләмисең, бурчыларың да күп, өстәвенә кеше товарына кул сузасың. Ай-яй, начар кеше булып чыктың син.

– Син әйбәт кешеме? – дип мыгырдады Харман.

– Дусларым мине бик әйбәт кешегә саныйлар. Гиза, мин начар кешеме?

– Абрек, братан, во! Ха-ха-ха, – дип көлеп куйды Гиза.

Гиза – карап торуга кәмит кыяфәтле, бераз аксый торган бандит, такыр башлы, борынына кайчандыр каты сукканнар, ахрысы – чак кына кыеграк иде. Төссез мыегы үзенә һич кенә дә килешми, аны ул торымнан-торымга, гел бармаклары белән сыпырып куя иде.

Абрек, күзләрен Харманнан алмыйча, сакаллы, кызгылт көрән күзле, чәчен бокс итеп алдырган, сикертмәле борынлы иптәшенә эндәште:

– Басмач, син ничек уйлыйсың, мин әйбәтме?

– Базара нет, – дип баш какты Басмач, кулындагы эспандерын еш-еш кысып. – Абрек, әллә нинди пүчтәк сораулар бирмә инде.

– Долган, минем хакта ни уйлыйсың? – диде Абрек, Лауруны күз карашы белән капшап.

Арттарак басып торган озын буйлы, ябык, әмма эре сөякле, сары чәчле, зәңгәр күзле һәм кепкасын батырып кигән бандит алга атлады:

– Син – изумительный кеше, Абрек, – диде ул, авызын җәеп.

Абрек көлеп җибәрде:

– Менә күрдеңме, Харман, ишеттеңме? – диде ул, кинәт көлүдән туктап. – Мин әйбәт кеше, ә син адәм актыгы булып чыктың. Качарга уйлый күрмә, подъезд төбендә миннән дә куркынычрак кешеләребез сакта тора.

Гиза йокы бүлмәсен карап чыкты, туалетка күз салды, кухняны тикшерде.

– Яхшырак фатир таба алмадыгызмыни качып ятарга? – диде Гиза, фатирны айкап чыккач.

– Безгә комфортның кирәге юк, – диде Харман, түрдәге урындыкка утырып.

– Харман! – диде Басмач. – Җир шары зур түгел бит ул, качып котылырмын дип уйлыйсыңмыни?

– Качарга теләсәм, сез мине таба алмас идегез, – диде Харман, һич кенә дә исе китмичә.

– Секач нык рәнҗи сиңа, – диде Абрек, телевизор өстенә таянып. – Товар кайда?

– Миндә товар юк, – диде Харман. – Товар көньякта калды. Мин инде әйттем сезгә – үзем көчкә качып котылдым, товар дошманнарда калды.

– Бераз көтик, – диде Долган. – Хәзер Секач килә монда, үзе синең белән сөйләшер.

– Бу хатыныңмы? – диде Абрек, диванда бөрешеп утырган Лаура каршына килеп.

– Юк.

– Сөяркәң?..

– Сеңлем.

– Бик чибәр икән сеңлең, – диде Гиза, күзләрен майландырып.

– Исемең ничек? – диде Абрек.

Лаура дәшмәде.

– Телсезме әллә? – диде Басмач.

– Телсез түгел, – диде Харман. – Сөйләшәсе килми.

– Тиздән икегезнең дә сөйләшәсе килер, – дип ысылдады Долган.

Күп тә үтмәде, ишек ачылды, корык-корык йөткереп, күпне күргән кыяфәтле ир-егет керде. 40-45 яшьләр тирәсендәге, уртадан озынрак гәүдәле бу кешенең өстендә күн плащ, тигез үтүкләгән чалбар, башында эшләпә, аягында затлы ботинка иде. Ябык булса да, аның каты сөякле икәне күренә, физик көче һәр хәрәкәтеннән сизелеп тора иде. Кылыч борыны, юка иреннәре, сул як битендәге, каш өстендәге җөйләре курку белмәс кешеләргә хас ныклы ияге, соры күзләре, үткен карашы – кино өчен махсус ясалган образны хәтерләтә иде.

– Хуш килдегез, Секач әфәнде, – дип сәламләде аны Абрек.

Секач, плащ кесәсеннән ап-ак кулъяулык алып, эшләпәсен салды, башта маңгаендагы тирне сыпырды, аннары эшләпә эчен әйләнә-тирәли сөртеп алды. Эшләпәсен кигәч, ул салкын күзләре белән әле Харманга, әле Лаурага карап торды.

– Хәерле көн, Харман! – диде Секач, ниһаять, карлыккан тавыш белән. – Синең ничә хатының бар соң ул?

– Сеңлесе, – диде Абрек, Харман дәшми торгач.

Секач Лаурага текәлеп карады:

– Бик гүзәл икән. Мондый адәм актыгының шушы кадәр чибәр сеңлесе бар дип уйламассың да. – Аннары Харманга якын килеп: – Ничек хәлләрең? – диде.

Харман читкә карап:

– Нинди максат белән сорыйсың? – диде.

– Минем сезнекеләр белән мондый конфликтның беркайчан да булганы юк иде, – диде Секач. – Син бөтен нәселеңне куркыныч астына куясың, аңлыйсыңмы шуны?

– Син безгә каршы сугышып, үзеңә хилафлык китермәгәең, – диде Харман тыныч кына.

– Син әле миңа яныйсыңмы?! – дип, ямьсез итеп көлемсерәде Секач. – Безне җиңәргә уйлыйсыңмы әллә?

– Сиңа безнең белән сугышу файдага түгел дип әйтмәкче идем, – диде Харман.

Секач кыжрап куйды:

– Хам! Ростовтан сиңа ярдәмгә боевиклар чыккан дип ишеттем. Алар

Казанда нишләмәкче булалар? Казанда барыбер без җиңәбез. Казан – безнеке, шуны аңлыйсыңмы?

– Казан ул беркемнеке дә түгел, – диде Харман. – Казан ул – Казанныкы. Дөнья беркемнеке дә түгел. Дөнья – дөньяныкы.

– Философ... – дип көлемсерәде Абрек. – Михэй дәдәй школасы.

Секач, әрле-бирле йөреп, уйга калды, бу вакытта Абрек түрдә аның күрсәтмәләрен көтеп торды, Басмач белән Долган Харманның як-ягына бастылар, Гиза Лаура янына килеп басты.

– Чибәр кыз белән качып ятасың... – диде Секач, кашларын җыерып.

– Сеңлем ул минем, ишетмәдеңмени! – дип, тавышын күтәреп җавап бирде Харман.

Секач авызын җәеп елмайды:

– Исемең ничек, гүзәл?

Лаура дәшмәде, атаманның күз карашыннан качар өчен башын читкә борды.

– Исемен әйтми, прикинь, – диде Долган.

– Минем исемем Секач, мин – бик әйбәт кеше, – дип елмайды Секач. – Кияүгә чыгасыңмы миңа?

– Аның ире бар, – диде Харман.

– Ник, башка кешегә чыгу бар бит инде ул, – диде Басмач, кет-кет көлеп.

– Чегән хатыныннан да тугрырак хатын юк, – диде Харман.

– Хәтәр икән. Чынлап та сеңлеңә өйләнермен дип курыктыңмы әллә?

Бандитлар бер-берсенә карашып көлеп куйдылар.

– Мине ошатмасаң, менә минем дустыма чык. Карале, нинди егет! – диде Секач, Басмачка ымлап. – Сакалы гына ни тора. Басмач белән менә дигән пар булыр идегез.

– Кәҗәнең сакалы озын, әмма ул барыбер тәкә түгел, – дип аваз салды Лаура.

– Авызыңны чамалап ач, әй! – диде Басмач, ачусыз гына. – «Кәҗә» сүзе белән шаярма.

– Кызма, Басмач, хатын-кыз ни әйтмәс, – диде Секач, ямьсез елмаеп. – Бездә шундый әйтем бар: кешедә «козёл» күрсәң, димәк, син үзең «коза». Ха-ха-ха. – Кинәт ул үтә җитди кыяфәткә керде. – Мин аңламыйм, сез нишләп безнең белән болай дорфа сөйләшәсез? Сезнең хәлдә тыйнаграк булу мәслихәт түгелме? Сездә, чегәннәрдә, ялгышмасам, «Язмышыңны алдый алсаң, бәхетле булырсың» дигән әйтем бар...

– Әйе, бар, – диде Харман.

– Мине алдый алырмын дип уйлаган идеңме? Язмыш менә мине каршыңа китереп куйды.

– Язмыш Алла түгел, мин аңа буйсынмыйм, – диде Харман, Секачка туры карап.

– Син дә, гүзәлкәй, шулай саныйсыңмы? – дип, Лаурага борылды Секач.

Лаура җавап бирмәде.

– Абыең аркасында бөлгенлеккә төшәсез бит, берниегез калмаячак.

Лаура, Секачка усал караш ташлап:

– Колагың булса, алкалар табылыр, – диде.

– Без бит колакларыңны да кисә алабыз, – диде Секач яман усал тавыш белән. Аның күзләре бу мәлдә коточкыч, бу – әйткән сүзен һәрвакыт үти

торган кеше карашы иде. – Хәтта менә бу яшькелт-зәңгәр күзләреңне дә чокый алабыз. Абыеңа әйт, акылына килсең, минем таләпләремне үтәсен. – Ул шкафка аркасы белән терәлеп, уйга калды. – Абрек, нишләргә инде болар белән, ә?

Абрек ясалма кыланчык позага басты:

– Харман, син үзеңне нинди җәзага лаеклы дип саныйсың?

– Мин инде сезгә аңлаткан идем, тагын кабатлыйм: Сочида товарны алгач, без – ике кеше, «Дубовый» посёлогында кунып, иртән тимер юл станциясенә барырга, аннан поезд белән Казанга китәргә тиеш идек... Төнлә һөҗүм иттеләр...

– Кемнәр?

– Белмим. Краснодарлылар дигән шигем бар.

Чынында исә вакыйга башкачарак булган иде. Харман Сочи якларында криминал тарафларда шактый билгеле вә абруйлы кеше иде, әмма Ростовтагы Дава исемле криминал авторитетка бурычлы булуы соңгы вакытта аның һәр омтылышына хилафлык китереп торды. Ростовлылар белән бергәлектә майтарган эш уңышсыз тәмамлангач, Харман Давага зур акча түләргә тиеш булып калды.

Шул көннәрнең берсендә Сочидагы берәү Харманга үтенеч белән мөрәҗәгать итә – Казанга «тыелган товар» илтергә. Товарны Люберцы каласыннан Стас атлы кеше яки аның дуслары, килеп, Харманнан алып китәргә тиеш була. Харман бу эштә бернинди авырлык вә куркыныч күрми, шундук ризалык бирә.

Бу хакта Дава ишетеп ала да Харманга тәкъдим ясый – товарны Казанга алып бармаска, юлга ике кеше генә чыгарга һәм Дубовый посёлогында төн кунарга. Йортны Дава үзе әзерләп куя, ачкычны бирә, шуннан төнлә Даваның кешеләре, һөҗүм итеп, товарны алып качарга тиеш була. Харман таладылар дип акланачак, юлдашы да моны раслаячак. «Барып чыкса, миңа бурычыңны түләдең дип саныйм», – диде аңа Дава. Харман моңа сөенде, чөнки болай җайлы гына бурычтан котылу аңа бик тә кулай иде.

Дубовый посёлогында Дава әзерләгән йортта Харман төнлә йокламады. Юлдашы йоклый, ул әле эшнең кайсы якка борыласын белми. Әмма Харман җан тынычлыгын җуйды, чөнки бүген ул Сочидан чыгу белән үк артларыннан күзәтүчеләрне шәйләде. Дава кешеләре түгел иде алар.

Сөйләшенгәнчә, ростовлылар нәкъ төнге сәгать икенче яртыда бәреп керергә тиешләр иде. Йөрәк урынында түгел. Сәгать уникеләр тирәсендә Харман һава суларга чыкты, аның күңеле сизде – бу тирәдә кемдер йөри, әмма Дава кешеләренә иртәрәк иде әле. Харман, әкрен генә койма янына килеп, тыштагы авазларга колак салып торды. Кайбер сүзләре колакка чалынгач, Харманның йөрәге жу итте – юк, болар ростовлылар түгел! Хәзер йортка бәреп керүләре ихтимал... Нишләргә?.. Харман шыпырт кына өйгә кереп китте. Иптәше гырлап йоклый. Харман сумканы алды да, тәрәзәне ачып, бакча ягына сикерде.

Инде бакча артыннан йөгергәндә Харман йорт ягыннан пистолеттан аткан тавыш ишетте.

– Мин качып котыла алдым, – дип, инде әллә ничә тапкыр кабатлады Харман.

– Әйе, син качкансың. Син бит бик җитез кеше, – диде Басмач чәнчүле тавыш белән. – Товар беләнме?

– Юк, минем бернидә хәбәрем юк иде, – диде Харман. – Юкса мине үтерәләр иде.

– Товар кайда соң? Безгә синең исәнме-юкмы икәнең мөһим түгел, товар безнең кулда булырга тиеш.

– Миндә товар кайгысы юк иде. Сумка һөҗүм итүчеләрдә калды.

Секач Харманга ямьсез итеп елмайды:

– Юк, Харман, сумканы син үзең белән алып качтың. Һөҗүм итүчеләр минем Сочидагы дусларым иде. Напарнигың каршылык күрсәткән, аны атып үтергәннәр, урыны оҗмахта булсын. Анда бернинди сумка тапмаганнар, аны син алып качкансың.

– Ә син нишләп Стаска тапшырылырга тиеш товарны таларга булдың? – диде Харман.

– Чөнки Стас – минем дошманым. Мәскәүдән ул мине кысрыклап чыгарттырды, миңа бик нык комачаулады ул. Мин дә төшеп калганнардан түгел, аңа каршы сугыш игълан иттем. Ә нишләп син үзең һаман Стаска илтеп тапшырмыйсың товарны? Товарны аңа илтергә тиеш булгансың бит...

– Минем товар белән Казанга баруым турында ментларга хәбәр килгән.

– Бәлки син товарны инде ментларга тапшыргансыңдыр?

– Товар миндә түгел.

– Кемдә?

Харман Секачка текәлеп карады:

– Карале, Секач, Стас синнән үч алыр дип курыкмыйсыңмы?

– Юк, курыкмыйм. Аны эләктергәннәр, ул кайсыдыр СИЗОда инде хәзер. Кайсы зонада утырачагын белгәч, минем кешеләр шунда аның башына җитәчәкләр. Товарны бир, юкса ментларга эшләүче булып танылачаксың.

Харман көлеп куйды:

– Моңа беркем ышанмаячак. Үзең күреп торасың, мине ментовкадан чыгардылар.

– Әйе, чыгарганнар. Монда ике фараз бар: йә син товарны милициягә тапшыргансың, йә милиция хәзер синең арттан күзәтеп торачак. Казанда чакта мин сиңа, синең кешеләреңә беркайчан җил-яңгыр тигезмәдем. Бир товарны!

– Казанда мин сиңа гел яхшы түләдем, бушка син безнең өчен берни эшләмәдең. Секач, мин алдамыйм, чын әйтәм, товарсыз качтым.

– Җәзалый башласак, дөресен сөйләрсең, – диде Басмач. – Сеңлеңне алып китәбез, синең интекконеңне күрмәсен. Аның үзенә дә аулакта допрос ясарбыз, син дә аның җәфаланганын күрмәссең.

– Моның өчен, беләсезме, сезгә нәрсә була?! – диде Харман яман усал тавыш белән.

– Мин беркая да бармыйм сезнең белән! – диде Лаура, котсыз калып.

– Секач, шаярма! – диде Харман тыныч, әмма янаулы тавыш белән.

– Мин шаярмыйм, мин, гомумән, шаяра белмим. Егетләр, бу сылукайның кулларын бәйләгез, машинага алып чыгып утыртыгыз.

Гизаның якын килүе булды, Лаура ярсып кычкырды:

– Якын килмә!

Әмма Гиза инде Лаураның кулыннан эләктереп алган иде. Шул вакытны Харман, атылып килеп, Гизаны, курткасыннан йомарлап тотып, үзенә тартты, теге чак кына егылмый калды. Долган белән Басмач Харманга

берничә тапкыр каты гына ордылар, Харман егылды һәм, аны типкәләргә җыенганнарын күреп, Лаура:

– Туктагыз! – дип кычкырды. – Мин беләм товар кайда, кемдә икәнне.

Барысы да шып туктап, Лаурага текәлделәр, абыйсы, идәннән торып, кул арты белән борыныннан аккан канны сыпырды.

– Белми ул, – диде Харман. – Курыкканга күрә генә шулай ди.

– Дәшмә! – дип кычкырды Абрек. – Сеңлең сиңа караганда акыллырак булып чыкты. Ну, әйдә, чибәркәй, колись.

– Мине чыгарыгыз, – диде Лаура, калтыранып. – Мин товарны сезгә алып киләм.

– Юк, беркая чыкмыйсың! – дип кырт кисте Секач. – Син дә, Харман да шушында ятачаксыз, йортны минем кешеләр саклаячак. Кая яшергәнеңне әйт.

– Мин аны күптәнге бер танышыма тапшырдым... Татар егете ул... Мин аңа яшерергә куштым.

– Ул кешенең исемен, адресын әйт. Без үзебез товарны барып алырбыз.

– Аның исеме Равил Шәмсиев, ул театрда актёр булып эшли, товар аңарда.

– Адрес?

– Адресын төгәл белмим, – диде Лаура. – Чуйков урамы дип кенә истә калган. Медучилищеның тулай торагында яши, театрда эшли.

– Ничә яшь?

– Егерме алты.

– Кыяфәте нинди?

– Төз гәүдәле, чибәр егет... Төскә-биткә карарак, туры, озынча борынлы.

– Долган, Гиза, сез икегез хәзер үк ул чибәр егетне табыгыз! – дип боерды Секач. – Ә сез, абый белән сеңел, товар минем кулга төшкәнче, монда буласыз.

Секач кызу адымнар белән фатирны айкап чыкты:

– Суыткычта ашарга бар икән сезнең... Туалет төзек... Кранда су бар... – диде ул.

– Җибәрегез безне! – дип елап җибәрде Лаура.

– Җибәрер идек, абыең Харман бик начар кеше булып чыкты. Начар кешеләр миңа гел очрап тора, әмма Харман шикелле кабахәтне беренче тапкыр очраттым. Син, Харман, болай эшләргә тиеш түгел идең, минем кем икәнемне, Казанның нинди шәһәр икәнен яхшы беләсең бит. Казанны Мәскәү дә ала алмыйча җәфа чиккән – немец инженерлары ярдәм итмәгән булса, Иван Грозный да яулый алмаган булыр иде Казанны. Моны мәктәптә тарих укытучысыннан ишеткән идем. – Секач көлеп куйды. – Харман, алай-болай синең дусларың арасында нимес инженерлары юкмы? Син миңа алай ямьсез карама! Мин үземнекен алырга телим. Киресенчә, мин сиңа яман усал карарга тиеш.

## 24

Театрда репетиция вакыты иде. Сәхнәгә ут куючы егет тәнәфестә Равилне фойега чакырып чыгарды:

– Равил, анда сине ике егет көтеп тора, – диде ул. – Сине чакыралар, аларның кыяфәтләре яман. – Һәм, сәерсенеп, өстәп куйды. – Андый дусларың барлыгын белми идем.

Равил, икенче катка менеп, тәрәзәдән карады, чынлап та, ул анда шикле кыяфәтле ике егетне абайлады. Аның башында уйлар өере кайный башлады: Лаура биргән сумканы кичектермичә яшерергә кирәк, һаман тулай торак бүлмәсендә бит әле ул. Равил, аскы катка йөгереп төшеп, баш режиссёр бүлмәсенә керде.

– Авылга шалтырткан идем... Әти авырый, – дип алдады Равил. – Берике көнгә җибәрегез, зинһар, – дип үтенде ул.

Баш режиссёр, өлкән яшьтә булса да, яшьләрчә кыяфәтле агай стенада эленеп торган репертуар плакатына каерылып карады:

– Иртәгә нинди тамаша әле безнең? Берсекөнгә... Син уйнамыйсың бу спектакльләрдә. Ярар, ике көнең бар. Бик каты авырыймыни әтиең?

– Каты шул.

Равил, янә икенче катка менеп, тәрәзәдән карады, тегеләр һаман шунда торалар иде. Равилнең йөрәге жу итте, болар һичшиксез мине көтәләр дип уйлады ул. Равил тавыш операторының бүлмәсенә йөгерде, ишекне киереп ачып атылып керде.

– Вадим, чыгып тор әле!

Вадим, театрда күптән түгел эшли башлаган егет, режиссёр гына түгел, актёрлар кушканны да гел берсүзсез үтәргә атлыгып торучы иде, ул шундук үз бүлмәсеннән чыгып китте.

Равил N каласына, җизнәсенә шалтыратырга булды.

– Җизни, мин сиңа барысын да аннары аңлатырмын. Зинһар, килеп ал мине, бүген үк, хәзер үк. Мин, сезгә кайтып, бер-ике көн кунам.

– Нәрсә булды?

– Аннары сөйләрмен. Җизни, үтенеп сорыйм! Син отпускта бугай бит...

– Без иртәгә авылга кайтырга җыенган идек.

– Җизни, килеп алмасаң, эшләр харап булырга мөмкин. Апага бер сүз дә әйтми тор.

– Ярар. Театрга килимме?

– Юк, Чуйков урамына. Адресны хәтерлисеңдер бит?

– Хәтерлим. Ничәләрдә килим?

– Хәзер үк юлга чык.

– Ярар. Димәк, сәгать ярымнан килеп тә җитәрмен инде.

Җизнәсе Кәрим – Актаныш егете – Равилнең апасы белән N каласының поликлиникасында танышты. Донор буларак кан бирергә килгән егетнең күңеленә Илүсә исемле шәфкать туташы бик хуш килде. (Илүсәнең, авылда отработкасын үтеп, монда килеп урнашкан чагы гына иде әле.) Илүсә дә шәһәр электр челтәрендә электриклар мастеры булып эшләүче егеткә битараф калмады, бик акыллы, төпле, тормышка җитди карый торган егет булып чыкты Кәрим. Очраша башладылар, күп тә үтмәде, алар гомер юлыннан бергә атларга тиеш икәнне аңладылар.

Никахлашулары 1979 елда – Равил армиядә чакта булды, ул армиядән кайтканда, аларның дүрт айлык Алсу исемле матур кызлары бар иде, өч елдан малай туды, шул елны фатирлы да булдылар.

Җизни килә, сүзендә тора ул дип уйлады Равил.

Ул тагын тәрәзәдән тышка күз салды – тегеләр һаман китмәгәннәр, шунда торалар иде. Теге көнне Михэй карт янына килгән егетләр булса,

алар, әлбәттә, Равилне танып алачаклар. Шул вакытны театрның хуҗалык ишегалдында машина тавышы ишетелде һәм Равил, сәхнә артындагы баскычтан аска төшеп, театр ишегалдына чыкты да «КамАЗ» машинасы белән каядыр барырга җыенган шофёрга эндәште:

– Марат, мине утыртып алып чык әле, теләсә кайда төшеп калырмын. Урамда ике шикле кеше мине сагалап тора.

Марат бер сорау да бирмәде, Равилнең кыяфәтеннән эшнең җитдилеген аңлап:

– Утыр, – диде.

Равил кабинада башын аска иеп утырды, аны сагалаучылар машинага бернинди ригая бирмәделәр.

Театрдан шактый ара киткәч, Марат:

– Син кайсы якка барасың? – дип сорады.

– «Квартал»га.

– Мин ул якка бармыйм, сине светофордан соң төшереп калдырам, – диде шофёр.

– Рәхмәт, Марат.

– Кемнәр соң болар? – дип, ниһаять, кызыксынды Марат. – Ник куркасың алардан?

– Мин сиңа аннары сөйләрмен әле... бәлки.

Шәһәр үзәгенә җитәрәк машинадан төшкәч, Равил, такси тотып, тулай торакка элдерде.

Секач кешеләре – Гиза белән Долган – театр янында шактый озак йөрделәр, чыккан һәрбер кешедән Равилне сорап тордылар. Хезмәткәрләр ишегенең вахтасында утыручы хатын чыгып киткәннән файдаланып, Долган түзмәде, үзе театрга кереп китте.

Труппа мөдире – парик кигән юан хатын – куркыныч кыяфәтле егеткә шикләнеп карап торды:

– Сез кем? Нишләп йөрисез?

– Миңа актёр Равил кирәк иде.

– Кайсысы?

– Шәмсиев.

– Равил театрда түгелдер инде, ул бүген авылга кайтып китә, әтисе авырый.

Долган тыела алмады, яман итеп сүгенде дә чыгып йөгерде.

...Лаура, абыйсына карап, капма-каршылыклы уйлар кичерде. Батыр йөрәкле, ышанычлы кеше аның абыйсы. Әмма бу эшкә ник тыгылган ул?! Ахыры ничек булыр икән?.. Чыгып качарга маташудан мәгънә юк, хәзер инде җайлы гына котылу мөмкин түгел – моны Харман үзе дә яхшы аңлый.

– Сумканы уголовный розысктагы дустына илтеп тапшырмадымы икән? – дип, инде әллә ничәнче кат сорады Харман.

– Юктыр дип ышанам.

– Актёрга ышанасыңмы? – дип, чыраен сытты абыйсы.

– Ул – иң элек кеше, аннан соң гына актёр, – дип җавап бирде Лаура.

Күпмедер вакыт узгач, Долган белән Гиза килеп керделәр.

– Тумышы белән кайдан ул? – дип сорады Долган, еш-еш сулап.

– Кайсы районнан, кайсы авылдан? – дип төпченә башлады Гиза.

Лаураның инде башка чарасы юк иде – Равилнең кайсы районнан икәнен дә әйтте, туган авылының исемен дә атады.

Долган белән Гиза озак уйлап тормадылар, Аулаш авылына юл тоттылар.

**25**

Җизнәсенә Равил юлда барысын да сөйләде. Кәрим пошаманга калды, кайнешенең мондый матавыкка эләгүен күз алдына китерүе кыен иде аңа.

– Милициягә илтеп биреп, барысын да ничек бар шулай сөйләсәң, яхшырак булмас идеме? – диде ул.

– Юк, мин Лаурага сүз бирдем.

Илүсәнең Кәримгә чегән кызы турында, энесенең аңа гашыйк булганын көлә-көлә, кызык итеп сөйләгәне бар иде, ә менә хәзер исә бер дә көләрлек түгел, эшләр хөрти инде.

– Алар күптән түгел генә яңа машина алганнар – «Жигули»-«пятёрка», салонда әле һаман завод исе бар иде. Равил, караңгы уйлардан арынырга теләп, алгы панельне кулы белән сыпырды:

– Әйбәт машинамы? – диде ул.

– Әйбәт, – диде Кәрим. – «Шестёрка» булмады инде, ярар, булганына шөкер, моны да комсомол горкомы аша гына эләктерә алдым. Машина ул яңа чакта нинди дә шәп инде. Фордтан: «Нинди машина иң яхшысы?» – дип сорагач, «Яңасы!» – дип җавап биргән.

Трассадан чабып барганда, аларны Равилне эзәрлекләүче Долган белән Гиза машинасы узып китте – нәкъ юл икегә аерылып, берсе калага алып керә, икенчесе Аулаш авылына илтә торган урында.

Шәһәр алдындагы ГАИ постына җитәрәк, Кәрим шомлы тавыш белән:

– Туктатып, тентесәләр... – дип куйды.

Равил котсыз калды, бу турыда бөтенләй уйламаган иде ул.

Постны әкрен генә узып барганда, гөнаһ шомлыгына каршы, инспектор, таяклы кулын алга сузып туктарга кушты. Йөрәкләр жу итте. Инспектор – какча гәүдәле, озынча битле, кысык күзле сержант – башта машина тирәли әйләнеп чыкты, шуннан соң гына машинадан чыгып баскан Кәрим янына килеп документларны тикшерде.

– Багажнигыңны ач, – диде инспектор.

Равилнең үзәге куырылды. Ничек тә булса, сержантның игътибарын башка нәрсә белән җәлеп итеп, багажникны ачтырмаска кирәк, чөнки, сумканы күреп, аны да ачарга кушуы ихтимал иде. Инспектор белән Кәрим машина артына юнәлгәч, ниндидер көч Равилне машинадан этеп чыгарды:

– Хәерле көн, иптәш инспектор! – дип, машина артына атлады ул. – Без бик ашыгабыз.

Равилне күреп, инспекторның йөзе кинәт яктырып китте:

– Актёр Равил Шәмсиев әфәнде түгелме соң? – диде ул, кулларын як-якка җәеп.

– Әйе, мин, – диде Равил, җиңеллек тоеп.

Инспектор, документларны кире Кәримгә биреп, Равил белән ике куллап күреште, ул инде машинаны тикшерү турында шундук онытты.

– Якташыбыз танылган актёр булуы белән гел горурланабыз, – диде

ул, Равил Шәмсиевне очратуына ихластан куанып. – Без бит синең белән якташлар да әле. Ялгышмасам, син бит Аулаш егете?

– Әйе, Аулаштан мин.

– Ә мин Каргалыдан. Ничек анда Казан? Гөрлиме?

– Казан кайнап тора инде ул. Казанда булсаң, театрга кил.

– Ярар, Алла боерса, җай чыкса, – диде инспектор.

– Без ашыга идек, – диде Равил. – Апа авырып тора. Менә җизни килеп алды, хәлен белергә барам.

– Ярый, хәерле юл! – диде сержант, һаман елмаеп.

ГАИ постыннан ерагайгач та әле, алар шактый вакыт сөйләшмәделәр – киеренкелек шулхәтле көчле иде.

– Җизни, чак калдык бит, – диде Равил, тирән сулыш алып.

– Ярый әле, инспектор татар кешесе булды, рус кешесе сине танымас иде, – диде Кәрим, газга ныграк басып. – Кайткач, синең белән бер ярты аракыны эчәргә тиеш без.

Кәрим белән Илүсәнең фатирлары җыйнак кына, әмма ямьле итеп җиһазланган иде. Аларда һәрвакыт тыныч, рәхәт була, әмма бу юлы Равилнең үзендә җан тынычлыгы юк иде.

Бу вакытта бандитларның «Нива» машинасы Аулаш авылына килеп керде. Үзәк урамда урнашкан кибеттән чыгып килүче хатыннан актёр Равил Шәмсиевнең әти-әниләре кайда яши дип сорагач, хатын шундук аңлатып бирде, һәм «Нива» машинасы Шәмсиевләр йорты каршына килеп туктады.

Бу вакытта Закир сыер астын чистартып чыккан иде, ишегалдына сәер кыяфәтле егет кергәч, ул аптырап китте.

– Сәлам, абзый, – диде Гиза.

– Сәлам.

– Син Равилнең этисеме?

– Әйе.

– Ул авылга кайтырга тиеш иде, өйдәме ул? – дип сорады Гиза.

Закир аптырап китте:

– Өйдә түгел ул, аның бу арада кайтырга исәбе юк иде бугай.

– Безне Лаура исемле кыз монда җибәрде.

– Нинди Лаура?

– Чегән кызы. Лаураның әйтер сүзләре бар, ул бәлагә тарыган, Равилне табарга кушты.

– Равил Казанда, – диде Закир. – Әле кичә генә телефоннан сөйләштек.

– Сәер... Ул бит бүген монда кайтырга тиеш иде...

– Син Равилне каян беләсең? – диде Закир, улының мондый дуслары булмаганны белгәнгә күрә.

– Һи, Равил Шәмсиевне белмәгән кеше юк, – дип көлемсерәде Гиза, капкадан чыгып киткәндә.

Закир койма ярыгыннан карады: Гиза машинага кереп утырды, рульдә икенчесе иде. Ят машина читкәрәк барып туктагач, Закир, тиз генә өйгә кереп, хатынына Равилне эзләп килүчеләр турында әйтте. Алар икәүләшеп бер урында тик торган машинаны тәрәзәдән күзәттеләр.

– И Ходаем, кемнәр икән болар? – диде Нурия, хафаланып.

– Белмим. Хәтерлисеңме, чегән кызын?

– Чегән кызын?.. – дип уйга калды Нурия.

– Теге, Равил келәтне ачып качырган иде...

– Әйе, әйе, – дип, исенә төшерде Нурия.

– Шул чегән кызы, имеш, ниндидер бәлагә тарыган, Равилдән ярдәм көтә, имеш. Теге вакытта ук әйткән идек аңа – ул чегән кызы белән бер-бер начар хәл килеп чыкмагае дип. Менә, ничә ел үткәч, Равилне эзләтә...

– И Ходаем, кемнәр икән соң болар? Чегәннәр микән?

– Минем белән сөйләшкәне чегән түгел бугай. Ләкин кыяфәте җанбиздергеч, шпанага охшаган.

– И Ходаем...

– Мин, почтага барып, театрга шалтыратыйм әле, Равил хәзер театрдадыр.

Закирның капкадан чыкканын күргәч, Гиза машина ишеген ачып кычкырды:

– Абзый, кая барасың?

– Кибеткә, – дип җавап бирде Закир. – Шикәр беткән.

– Әйдә, машина белән алып барабыз.

– Юк, рәхмәт, якын бит.

Закир, кызу-кызу атлап, үзәк урамга китте. Ул җан тынычлыгын җуйды – бер-бер бәла булмагае, болар бер дә юньле кешеләргә охшамаган. Почтада Миләүшә исемле кыз эшли иде, аның кашларын җыерып, авылдашларга өләшәсе гәҗит-журналларны аралап утырган чагы иде.

– Миләүшә, сеңлем, шәһәргә шалтыратып алыйм әле, – диде Закир, еш-еш сулап.

– Шалтырат, шалтырат, Закир абый, – диде Миләүшә, Закирның хафалы кыяфәтенә гаҗәпләнеп.

Закир Илүсәләрнең телефон номерын җыйды, элемтәнең теге очында Кәримнең тавышы ишетелде:

– Әйе, бабай, тыңлыйм.

– Алло, Кәрим! Ничек хәлләр?

– Бер көе.

– Сез иртәгә ничәләрдә кайтасыз?

– Белмим әле, бабай.

– Илүсә өйдәме?

– Өйдә.

– Чакыр әле.

Илүсә, нык дулкынланып, телефон трубкасын алды:

– Әйе, әти, тыңлыйм.

– Илүсә, без монда әниең белән ут йотып утырабыз... Таныш түгел кешеләр Равил белән кызыксындылар, төпченделәр. Кайтырга тиеш иде, кайттымы, диделәр. Кайтырга тиеш түгел иде бит ул...

Илүсә бер сүз дә әйтергә өлгермәде, Равил, трубканы апасыннан тартып алып, әтисен сәламләде.

– Әти, исәнме! Мин апаларда, борчылмагыз.

– Ничек инде борчылма?! Монда безгә ниндидер сәер кешеләр килде, сине сорыйлар. Нәрсә булды, кемнәр килде монда сине эзләп?

– Курыкмагыз, ачыкларбыз.

– Син нишләп Казанда түгел? Нишләп Илүсәләрдә син? Аңлат әле.

– Әти, мин исән-сау бит, ник кайгырасың. Ачыклармын кемнәр икәнен.

– Алар: безне Лаура җибәрде, без Лаура кешеләре, диделәр. Теге чегән кызы түгел микән ул, хәтерлисеңме, авылда тотып келәткә япканнар иде. Син, ташбаш, аны коткарып йөрдең әле... Шул микән әллә?..

– Әти, шул Лаура инде ул, аларны Лаура җибәргәндер инде, алайса.

– Ник сине эзләтә соң ул?

– Ул эзләтми. Әти, кайткач барысын да сөйләрмен, хафаланма инде.

Телефон трубкасын куйгач, Закир Миләүшәнең барысын да ишеткәнен аңлап, аңа карап торды.

– Закир абый, бер-бер хәл булдымы әллә? – диде Миләүшә, куркуга калып.

– Юк, юк, куркырлык бернәрсә дә юк. Син, сеңлем, ишеткәнеңне беркемгә дә әйтмә инде, яме.

– Ярар.

Тегеләрнең машинасы һаман шул урында тора иде. Закир, тагын эндәшмәсәләр ярар иде дип, ул якка карамыйча, тиз генә капкадан кереп китте.

Ниһаять, көтүләр кайтып, караңгы төшә башлагач, берничә сәгать буе Закир белән Нуриянең котларын алып торган машина китеп барды.

Аларның китүе Закир белән Нурияне тынычландырмады, нәрсә булды икән, ахыры ничек булыр икән дип хафаланып, икесе дә төнлә йоклый алмадылар.

**26**

Равил апасына барысын да, ничек бар шулай, бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Илүсә апаларча озын-озак итеп нотык укыды, теге вакытта чегән кызы белән бәйләнгәне өчен ачуланганын да искә төшерде. Алты яшьлек Алсу белән өч яшьлек Айдар Равилне бик яраталар иде. Аларның сөйләшәселәре, Равил абыйсы белән шаярып, төрттереп уйныйсылары килә, әмма Равилнең кәефе начар иде, моны күреп, Алсу балакай да пошаманга калды. Хәтта бу юлы гадәттәгечә мин дә артистка булам, синең белән театрда бергә уйнарбыз дип әйтмәде. Айдар әллә ничә тапкыр: «Лавил абый, мин сине телевизолдан күлдем», – дигәч тә, Равил бары тик моңсу итеп елмаеп кына куйды.

Равил сумканы аларда калдырырга булды. Әлбәттә, Кәримгә дә, Илүсәгә дә бу ошамады, әмма алар Равилне бик яраталар, хөрмәт итәләр, аның өчен борчылалар, шуңа күрә каршы килмәделәр.

Икенче көнне Кәрим Равилне Казанга ук илтеп куя алмады, эштә бик мөһим киңәшмә буласы иде, трассага кадәр генә алып барды.

Трасса буенда егерме минут чамасы торгач, Мамадыштан Казанга баручы «УАЗ» машинасы юл уңаеннан аны утыртып алып китте.

...Казан аңа бүген шомлы булып күренде, монда ниндидер куркыныч яныйдыр кебек тоелды. Чуйков урамының да шыксыз, пычрак икәненә игътибар итте.

Тулай торакка җитәрәк арттан кемдер:

– Син алай-болай актёр түгелме? – дип эндәшкәч, Равил сискәнеп куйды.

Ул туктады, беравык баскан урыныннан кымшанмыйча торганнан соң, борылып:

– Әйе, актёр, – диде.

Ике шәүлә ун-унбиш адым читтәрәк басып торалар иде.

– Исемең Равилме әллә?

– Әйе.

– Хәерле кич, – диде берсе, һәм алар Равилгә таба атладылар.

– Исәнмесез.

Долган, аның каршысына килеп, туп-туры сорау бирде:

– Сиңа товар тапшырганнар, кайда ул?

– Нинди товар? – дип белмәмешкә сабышты Равил. – Сез кем?

– Актёр булсаң да, хәзер син ышандырырлык итеп уйнамыйсың, – диде Гиза. – Лобачевский әйткәнме әле: «не верю» дип?

Равил боларның кемнәр икәнен аңлады.

– «Не верю» дип Станиславский әйткән, – диде ул.

– Кем әйтсә дә, барыбер түгелмени! – дип тавышын күтәрде Гиза. – Товар кайда?

– Мин аңламыйм, сезгә ни кирәк? – диде Равил.

– Безгә товар кирәк, – диде Долган. – Һәм татар халкы өчен синең исән булуың да кирәк. Чөнки син яшәргә тиеш, алайса, театрыгыз ятим кала бит. Ә инде товарны бирмәсәң, халык талантлы кешесеннән мәхрүм калачак.

Равил, Лауранын кисәткәнен истә тотып, ахыргача белмәмешкә сабышырга булды.

– Миндә бернинди товар юк, – диде ул, катгый итеп.

– Лаура сиңа биргән бит, – дип күзләрен челәйтте Долган.

– Лаура?..

– Лаура! Син беләсеңдер бит аны?

Белмим дип әйтергә никтер Равилнең теле әйләнмәде.

– Беләм, – диде ул.

– Ул сиңа сәлам әйтте, – диде Долган, елмаеп.

– Кайда ул? – диде Равил.

– Ышанычлы җирдә, – диде Гиза һәм лачт итеп җиргә төкерде. – Ни йөгереп кача алмый, ни очып китә алмый торган урында.

– Миңа Лауараны күрергә кирәк, – диде Равил.

– Товарны бир башта, аннары күрерсең, – диде Долган.

Равил, Лаураны күрми торып, товар барлыгын әйтмәскә булды.

– Миндә бернинди товар юк, – дип кабатлады ул.

Гиза иптәшенә карады:

– Нишләтәбез моны?

– Секач нәрсә әйтер. Аның белән киңәшләшергә кирәк, – диде Долган.

– Ну, артист, бүген яшә әле, – диде Гиза, тагын төкереп. – Товарны хәзер үк бирмәгәнеңә үкенергә туры килмәгәе.

**27**

Бандитлар киткәч, Равил уйга батты. Нишләргә? Әнәскә шалтыратырга инде, башкача булмый. Ул үз бүлмәсенә менеп тә тормады, вахтадагы телефоннан Әнәскә шалтыратты.

– Әнәс, сәлам. Йокыңнан уяттыммы әллә?

– Уятмадың. Ятарга җыена идем.

– Әнәс, туган, очрашырга кирәк.

– Иртәгә.

– Юк, бүген кирәк.

– Нәрсә инде тагын?

– Телефоннан әйтә алмыйм.

– Ярар, көтәм, – диде Әнәс сүренке тавыш белән.

Бу юлысы Әнәс аны караңгы чырай белән каршы алды. Равил аңа яман товар турында әйтмәскә булды.

– Әнәс, мине нииндидер бандитлар эзәрлеклиләр, – диде ул, ишектән керүгә үк. Алар Лаура белән абыйсы турында кызыксыналар, минем Харманга ярдәм иткәнне белгәннәр, ахрысы. Алар нииндидер товар белән кызыксыналар. Мин каян белим инде аларның товарларын...

– Оныт ул чегән кызын дип әйттем мин сиңа! Кая тыгыласың син?! Куркыныч хәзер. Перестройка башланганга ел ярым вакыт узды, инде кешеләр бер-берсен үтерә башладылар.

– Миңа нишләргә соң?

– Товар синдә булмагач, ник куркасың?

– Алар нииндидер Секачны телгә алдылар, синең андый кеше турында ишеткәнең бармы? – дип сорады Равил.

Әнәснең хәтта чырае бераз тартылыбрак китте:

– О, ишетү түгел, күргәнем дә бар, – диде ул. – Криминал дөньяда абруйлы кеше. Алайса, шул Секач кешеләре килгәндер дә инде синең яныңа.

– Милиция беләмени ул банданы?

– Милиция әллә кемнәрне, әллә нәрсәләрне белә. Милиция кайвакыт булмаган нәрсәләрне дә белә ул. Харман белән Секачның конфликты турында да беләбез, Харманны якларга Ростовтан банда килә дигән хәбәр дә бар...

– Чегәннәрме?

– Юктыр. Харман – көньякта авторитет тоткан кеше. Аның боевиклары чегәннәр түгел, интернационал, җинаятьчеләрнең милләте юк.

– Аларны куркытып, конфликтларын туктатып булмыймы соң?

– Ә нигә аларның конфликтына тыгылырга? Үзара сугышсыннар.

– Димәк, милиция бөтенесен дә белеп тора?

– Алар турында белеп тору, хәбәрдар булу – безнең эшебез бит ул. Син курыкма, Лаура белән безнең арада берни дә юк диген, Харманга ярдәм итүдә катнашмадым диген. Алай-болай бик нык яный башласалар, миңа хәбәр итәрсең.

– Алар инде янадылар.

– Янадылар дип кенә, әле аларны хөкемгә тартып булмый. Син – үзеңә үзең геморрой ясаган кеше. – Әнәснең сүзне тизрәк башка нәрсәгә юнәлтәсе килде. – Гөлнара отпускадан кайттымы?

– Кайтты, – диде Равил, чыраен сытып.

– Сәлам әйт аңа.

– Ул кайту белән дус кызы янына китте, шуннан соң күргәнем юк әле.

– Чегән кызлары артыннан йөргән кеше белән нинди хатын торсын, – диде Әнәс, көлеп.

– Аерылырбыз, ахрысы, – дип куйды Равил, авыр сулап.

– Ихтыярың. Әмма чегән кызына өйләнә күрмә, – дип көлемсерәде Әнәс.

Равил тулай торак янында шактый вакыт уйга батып торды – бүлмәгә керәсе килмәде, күңел тартмады. Тулай торакның ишеген ачу белән үк, иңенә җылы яулык салган вахтёр хатын аңа нидер әйтергә телидер шикелле тоелды. Дөрес сиземләгән Равил – вахтёр хатын шомлы тавыш белән пышылдап диярлек:

– Уголовный розысктан килделәр, сине сорадылар, – диде.

Равил эчке сискәнү тоеп:

– Нәрсә дип сорадылар? – дип пышылдады.

– Өйдәме? – диделәр. Юк, дидем... Бәлки хатыны өйдәдер, дидем. Алар бүтән сүз әйтмәделәр, өскә менеп киттеләр.

– Кайчан?

– Бер сәгать элек?

– Алар шундамыни хәзер?

– Юк, чыгып киттеләр инде. – Вахтёр хатын як-ягына карап куйды. – Равил, нәрсә булды? – дип пышылдады ул.

– Бернәрсә дә булмады.

– Гөлнараны бу арада күргәнем юк, аның белән бер-бер хәл булмагандыр бит?

– Юк, исән-сау.

Вахтёрның сораулары күп иде, әмма Равил аны тыңлап тормады, дүртенче катка йөгереп менеп китте.

Бүлмәнең асты өскә килгән иде. Димәк, Әнәсләргә барып кайткан арада кереп тентегәннәр. Бандитлар эше, угрозыскта дип, вахтёрга юри әйткәннәр, ялган удостоверение күрсәткәннәрдер.

Әллә сумка турында әйтергә идеме Әнәскә?.. Юк, ярамый! Беренчедән, Лаурага сүз бирде, икенчедән, Әнәс, ни дисәң дә, барыбер угрозыск кешесе.

... Шул ук төнне Долган белән Гиза Абрек янына барып киңәшләштеләр дә, юл уңаеннан Басмачны өеннән кереп алып, Лаура белән Харман тоткынлыкта яткан фатирга бардылар.

– Товар кайда? – диде Басмач.

– Мин әйттем инде, – диде Лаура.

Гиза, кыҗрап, алга чыкты:

– Ул бит миңа: «Лаура бернәрсә бирмәде», – диде.

– Алдый, – диде Лаура, читкә карап.

– Мине чыгарыгыз, мин үзем ул актёрдан товарны алам, – диде Харман.

– Юк, Харман, син монда гына ятачаксың, – диде Басмач. – Товар белән качуың ихтимал. Син болай да алдап йөрдең инде безне.

– Мине чыгарыгыз, – диде Лаура. – Ул минем белән гел очрашырга атлыгып тора. Мин аңа шалтыратам – театрга яки тулай торакка. Алып кил дисәм, алып киләчәк, кая кушам – шунда алып киләчәк.

– Юк, сине дә чыгармыйбыз, – диде Долган.

– Әллә Лаура шалтыратсынмы? Без янында торырбыз, – дигән тәкъдим ясады Гиза.

– Телефоннан берәр сигнал биреп, теге качса? – дигән шиген белдерде Долган.

Басмач беравык уйланып торганнан соң:

– Юк, юк, болар монда булырга тиеш, – дигән катгый карарга килде. –

Ул шамакайны хәзер катырак куркытырга кирәк. Секач тагын бер тапкыр әйбәтләп сөйләшеп карарга кушты. Аннары инде, үзегез беләсез – башта аны монда алып киләбез... Кем әйтмешли, очная ставка... Аннары күз күрер.

**28**

Равил бүлмә уртасында тораташ булып катып торды. Шкафны, шифоньерны актарганнар, караватастында иске чемодан бар иде, аның эчендәге әйберләрне идәнгә койганнар, матрасны ертканнар. Почмактагы бәләкәй өстәл астында кәчтрүлләр, савыт-саба иде – алар да идәндә аунап ята, кайберләре ватылган.

Равил, чишенеп тә тормыйча, идәндә аунап яткан мендәрне баш астына салып, ертык матраска чалкан ятты. Түшәмгә карап яткан килеш кенә шушы пыран-зыран килгән бүлмә белән бергә җир астына убылып төшәргә иде. Утны да сүндермәде, уйга батып ятканнан соң, таң беленгәндә генә бераз йокымсырап алды ул.

Театрга барырга кирәк. Барасы килми. Әти белән әни кайгыга батканнардыр инде. Чәй кайнатып, теләр-теләмәс кенә чәй эчеп утырганда, вахтадагы апа менеп, аны аска төшәргә чакырды. Вахтёрларның бүгенгесе – олы яшьтәге апа – Равилгә бик шикләнеп карый, тегесе сөйләгәндер, күрәсең.

– Сине дусларың чакыра, – диде вахтёр апа, Равилнең аксыл чыраеннан сәерсенеп.

– Нинди дуслар?

– Каян белим мин синең дусларыңны? Сәгать дүртләрдә авылдан әтиең дә шалтыратты. Уятмыйм, йоклый ул, дидем. Өйдәме, чирләмиме дип, кат-кат сорады. Йокласын инде, уятмыйм, торгач, үзе сезгә шалтыратыр дидем, бер көе, сау-сәламәт, бүлмәсендә, йоклый дидем. Гөлнара кайттымы, дип тә сорадылар. Кайткан бугай дидем... – Вахтёр апа Равилне иңеннән сыпырып куйды. – Равил, балакаем, хатын белән ызгыштым дип, болай ук бетерешмиләр инде. Татулашырсыз әле, гаилә булгач, арада әлләниләр була инде ул.

Шушы сүзләр белән вахтёр апа беренче катка төшеп китте. Әйе шул, танылган актёр булгач, синең турында бөтен нәрсәне белеп торалар – өйдәме икәнеңне дә, хатының белән ызгышканны да.

Тышта аны Секач кешеләре – Басмач, Долган, Гиза көтәләр иде. Гиза машина рулендә, Басмач белән Долган тулай торак баскычы янында тәмәке тартып сөйләшеп торалар иде.

– Лаураның сине күрәсе килә, – диде Басмач.

– Кайда соң ул? – диде Равил.

– Әйдә, күрерсең, сине хәзер шунда алып барабыз, – дип, Басмач тәмәкесен читкә томырды да машинага таба китте.

Долган тәмәке төпчеген ботинкасы белән сытып, Равилгә елмайды:

– Карета подана, сударь. Әйдә, читенсенмә. Күрәсеңме, хәзер машинада гына йөртәбез үзеңне.

Долган арткы утыргычка утырды, Равилнең башка чарасы юк иде, ул машинаның икенче ягыннан аның белән янәшә урнашты.

Гиза машинаны кабызды, аның белән янәшә утырган Басмач, борылып, Равилгә текәлде:

– Ничек хәлләр?

– Ярыйсы, – диде Равил, башын читкә борып.

– Ник бездән качып йөрисең?

– Мин беркемнән дә качып йөрмим.

«Жигули» зур тизлек белән Казан буйлап чапты. Лаура янына барабыз дигәч, Равил хәтта сөенгән кебек иде, әмма машинага кереп утыргач, шикләнә башлады, бераздан инде курку биләп алды – Лаура янына алып баралар микән соң аны?

Машина әле шәһәр эченнән бара... Нинди уй икән боларның башларында... Үзара сөйләшмиләр, Равилгә дә бер сүз дәшмиләр... Менә машина иске хрущёвкалар тезелеп киткән микрорайондагы йортның ишегалдына кереп туктады, нинди район, нинди урам икәнне Равил аңламый да калды.

Аны биш катлы йортның урта подъездына алып кереп киттеләр, өченче катка менгәч, фатир ишеген үз ачкычлары белән ачып керделәр.

Равил, Лаураны күреп, беравык өнсез калып торды. Лаура ябыгып, сулыгып калган, күзен оча алмый калган кошны хәтерләтә иде ул. Абыйсының янәшә булуы гына Равилне бераз тынычландырды.

– Ну, кайсыгыз алдый? – дип, озакка сузмыйча сүз башлады Басмач.

Лаура төссезләнгән күзләре белән Равилгә карап:

– Бир боларга сумканы, – диде.

– Ярар, – диде Равил, Лаурадан күзләрен алмыйча. – Сине җәберләмәделәрме?

Басмач көлеп җибәрде, аңа кушылып, Долган белән Гиза да көләргә тотындылар.

– Ха-ха, ә җәберләсәләр, нишләрсең? – диде Долган, ыржаеп. – Син хәзер инде үзең турында кайгыр. Әле без уйлашырбыз – синең үзеңне җәберләргәме, юкмы...

– Лаура! Харман! Сез тоткынлыктамы? – диде Равил, әле Лаурага, әле аның абыйсына карап.

Басмач яман кыяфәт белән Равилнең каршына басты:

– Булды. Свидание окончено.

– Җибәрегез Лаураны! – дип, кинәт җикерде Равил.

– Кычкырма, күршеләрдән ару түгел, – диде Гиза, авызын чалшайтып.

– Рауль, алып кил сумканы, – диде Лаура тыныч кына.

– Сине җибәрерләрме соң? – диде Равил, Лаурага таба атларга тырышып.

Басмач аны ике куллап этеп җибәрде:

– Анда синең ни эшең бар?! Ишетмисеңмени?!

Лаура, көтмәгәндә, җан өзгеч тавыш белән кычкырып җибәрде:

– Алып кил сумканы, идиот!

Әйтерсең лә өстенә кайнап торган су сиптеләр – Равил бер мәлгә өнсез калды. Ялгыш ишетмәдеме ул – Лаура аңа «идиот» диде түгелме?! Аның бит мондый Лаураны күргәне юк иде. Ул инде Лаурага охшамаган да, аның каршысында нәфрәт чәчрәтүче усал хатын утыра иде. Равилнең үзәге куырылды, нишләргә, ни әйтергә белмәде, чарасызлыктан тораташ булып катып калды.

– Без аның белән барабыз, бергә алып киләбез, – диде Долган.

Равил, беркавым урыныннан кымшанмыйча торгач, ниһаять, үзен кулга алып:

– Миңа Секачны күрергә кирәк, – диде.

– Секачны? – дип гаҗәпләнде Басмач.

Долган, якынрак килеп:

– Син аны беләсеңме соң? – диде.

– Беләм, – дип алдады Равил. – Сумка ышанычлы урында саклана. Аның миңа кирәге юк, киресенчә, аннан миңа тизрәк котылырга кирәк. Башта Секач белән очрашырга телим.

– Товар кайда? – диде Басмач, тешләрен шыгырдатып.

– Казанда түгел. Миңа башта Секачны күрергә кирәк.

Басмач башын аска иеп уйланып торды да Долганга карады:

– Секач кайда икән хәзер?

Долган, сәгатенә карап:

– «Алтынай»да булырга тиеш, төшке ашта, – диде.

– Ярый, Гиза, запрягай лошадей, киттек, – диде Басмач.

Машина «Алтынай» ресторана янында туктагач, Долган ресторанга йөгереп кереп китте һәм, күп тә үтмәде, ул кире чыкты.

– Ресторанда, – диде Долган, машина ишеген ачып. – Керергә кушты.

Гардеробта чишенгәннән соң, Равилне ресторанның банкетлар залына алып керделәр. Купшы җиһазлы залның зур өстәле башында Секач белән бер яшь, чибәр, әмма инде шактый таушалган 25-30 яшьләрдәге кыз ашап утыралар иде.

Секач Равилгә усал итеп карап торды, ә кыз исә зур кызыксыну белән актёр егетне күзәтеп утырды. Секач, авыз кырыен салфетка белән сөртеп, тонык тавыш белән:

– Син кем? – диде.

– Равил. Актёр. Театрдан.

– Синмени инде ул? Әйе, әйткәннәр иде. Актёр буларак, коточкыч трагедиядә катнашырга теләдеңмени? Бездә бит тамашалар театрдагы кебек матур тәмамланмый.

– Миңа сезнең белән күзгә-күз карап сөйләшергә кирәк, – диде Равил.

Секач янәшәсендәге чибәркәйгә борылды:

– Җаным, бар, һава сулап кер.

Кыз, бернинди үпкәсез, джинсы курткасының түш кесәсеннән «Мальборо» сигареты чыгарып, икенчесеннән зажигалка алып, матур адымнар белән әкрен генә чыгып китте.

Секач утыргычында киерелеп утырды:

– Нәрсә әйтмәкче буласың, карачкы? – диде ул ыңгырашкан сыман тавыш белән. – Тыңлыйм.

Ни гаҗәп, бу бандитка, төс-бите, кыяфәте куркыныч булуга карамастан, затлы кәчтүм, ак күлмәк шундый килешеп тора иде.

– Милиция тентергә килгәч, Харманның сеңлесе Лаура бер сумканы алып качкан, – дип башлады сүзен Равил. – Аны ул миңа алып килеп бирде, яшерергә кушты.

– Син дә алар беләнмени?

– Кемнәр белән?

– Син Харман кешесеме?

– Юк, мин беркемнеке дә түгел.

Секач бер сүз дәшми Равилгә текәлеп, тик карап утырды. Равил аның

күз карашыннан нык каушады, хәтта ни әйтергә белми торды, ә Секач аңардан аңлату көтте.

Равил кабаланып, ничек булган шулай барысын да тәфсилләп, бернинди уйдырмасыз, ялгансыз сөйләде. Секач, аны бер тапкыр да бүлдермичә, игътибар белән тыңлап утырды.

Секачның чыраеннан усаллык каядыр юкка чыкты кебек.

– Аракы эчәсеңме, коньякмы? – диде ул.

– Аракы, – диде Равил шундук, һаман да әле каушаудан арына алмыйча.

Секач рюмкага түгел, фужерга мул итеп аракы салды. Равил аракыны эчеп куйды.

– Мин шәхсән үзегезгә алып килеп бирәм сумканы, – диде.

Равил, аракы эчкәч, хәтта чыраен да сытмыйча:

– Зинһар, шуннан соң Лаураны да, Харманны да азат итегез. Монда Лауралның бөтенләй гаебе юк, абыйсы өчен борчылу гына бар аңарда. Мине дә гаепләмәгез. Лаура беркемгә күрсәтмәскә, беркемгә бирмәскә кушкач, мин сезнең егетләргә товар юк миндә дип ялганладым. Мине аңлыйсыздыр...

– Син шул чегән кызы хакына башыңны утка салуга да бара аласыңмыни? – дип, чак кына елмайды Секач.

– Мин аның белән очрашуны тугыз ел көттем.

– Син җүләрдер, мөгаен. Тугыз ел хатын-кыз да ир кешене көтми. Угрозыскта эшләүче Әнәс сиңа кем?

– Без армиядә бергә хезмәт иттек.

– Товарны аңа илтеп бирә күрмә.

– Юк, мин аны сезгә китереп бирәм.

– Нишләп син минем белән «сез» дип сөйләшәсең? Мин бит партком секретаре да, яшелчә базасының директоры да түгел. Товарны бүген үк алып кил.

Равил сәгатенә карап алды:

– Соңгы рейска соңга калдым инде мин. Соңгы автобус китте инде. Иртәгә...

Секач кырт кисте:

– Бүген! Төн урталарына алып килерсең.

– Попутка белән андый товар күтәреп йөрү...

Секач аңа әйтеп бетерергә ирек бирмәде, сүзен бүлеп:

– Сине машина алып барачак, машина алып киләчәк, – диде.

– Сезне... Сине кайда табармын, кая алып килергә?

– Машина йөртүче белә, анысы өчен борчылма.

– Теге көнне... N га кайтканда ГАИ туктаткан иде... – дип, шөбһәсен белдерде Равил.

– Бу машинаны туктатмыйлар, – дип кул селтәде Секач. – Иске «Москвич», шофёрның кыяфәте гади. Машинасы өстендәге багажникка бер-ике капчык бәрәңге куярсыз. Шулай да ГАИ постын яктыдарак узарга тырышыгыз.

**29**

Өстенә ике капчык бәрәңге салган «Москвич-412» машинасы шофёры – 40-45 яшьләрдәге Әхәт исемле кешенең өстендә иске куртка, тезләре чыккан чалбар, аягында үкчәләре ашалган ботинка иде. Тыгыз гәүдәле бу агайның

бер эштән дә курыкмый торган гади кеше икәне күренеп тора иде. Бер сүз дәшми барган шофёр янында Равил үзен ничектер уңайсыз хис итте. Әхәт белмидер сумка турында дип уйлады Равил. Әллә белә микән?.. Бу кеше дә Секач төркеменнән түгел микән?.. Охшамаган...

Равилнең киеренкелеге хәттин ашты – тизрәк сумканы Секачка илтеп бирергә кирәк, киртәләр генә очрый күрмәсен инде берүк. Хәтта Әхәттән бернәрсә турында сорарга базмады, шүрләде, теге үзе дә сумка хакында бер сүз катмыйча, руленә ябышып утырды.

Ярты юлга җиткәч кенә, Әхәт:

– Пес итәсең килмиме? – дип сорады, һәм алар бер-ике минутлык тукталыш ясап алдылар.

Равил N каласына болай тиз барып җитәрләр дип уйламаган иде. Әхәт машинаны бик оста йөртә булып чыкты. Җизнәсе Кәрим өйдә булырга тиеш, Равил аңа телефоннан шалтыраткан иде.

Барып җиткәч, Равил Әхәткә:

– Әйдә, чәй эчеп, капкалап чыгарсың, – диде.

– Юк, рәхмәт, тизрәк Казанга кайтырга кирәк, – диде Әхәт.

Сумканы алып, кире Казанга юл тоттылар. Равил ГАИ посты яныннан үтәсе бар дип куркып барган иде, куанычына күрә, туктатучы булмады, хәвеф-хәтәрсез Казанга кайтып җиттеләр.

Инде караңгы төшеп килә иде, Равил үз уйларына чумган, шуңа күрә кай тарафка барганнарына игътибар бирмәде. Казан аша үтеп, башкаланың икенче ягындагы «сад-огород»лар бистәсенә килеп җиткәннәрен сизми дә калды ул.

Күз кочагында калтыранып, кышны көткән бакчалар арасындагы тар гына урамнан «Москвич» шактый вакыт әкрен генә барды. Ниһаять, яңа төзелгән җыйнак кына йорт янына килеп туктадылар. Җил-капка янында бер шәүлә күренде – мөгаен, сакчыдыр, ул Әхәтне таныды, кул болгап сәламләде дә тиз генә йортка кереп чыкты. Йорттан изүләре ачык халат кигән Секач чыкты, алар, Әхәт белән читкә китеп, беркавым сөйләшеп тордылар.

Әхәт белән хушлашкач, Секач кул ишарәсе белән Равилне чакырды. Равил машинадан чыкты, Әхәт багажникны ачып, сумканы алып бирде.

Секач Равилне коймага таянып каршы алды:

– Исән-сау килеп җиттеңме?

Йортка кергәч, Равил шаккатты – тыштан гади генә йортның эче болай ук купшы вә пөхтә булыр дип уйламаган иде ул. Керү белән, кухня сыман албүлмә – монда плитә, савыт-саба, суыткыч күзгә чалынды, тәрәзәгә матур кашагалар эленгән иде. Эчке бүлмәдән икенче катка менә торган баскыч күренде. Равилне албүлмәдән ары уздырмадылар. Өстәлдә төрле ризык урын алган, башланган коньяк, сыра, минераль су шешәләре тора, сыр, тавык ите, яшелчә – барысы да зәвыклы итеп туралган иде.

– Менә, Лаура ничек бирде, шулай тапшырам сумканы, – диде Равил һәм җиңел сулап куйды.

Секач затлы халатының путасын бәйли-бәйли текәлеп карап торганнан соң:

– Аның эчендәге әйберләр барысы да урынындамы? – диде.

– Бернәрсәгә дә кагылмадым, – диде Равил. – Анда нәрсә икәнен мин аңламыйм да әле.

– Башыңны җүләргә салма инде, – дип елмайды Секач. Аннары өске катта ишетелерлек итеп кычкырды: – Абрек!

Икенче каттан төшеп, эчке бүлмә аша Абрек пәйда булды.

– Клиент прибыл, – диде Секач. – Тикшер товарны.

Абрек сумканы эчке бүлмәгә алып кереп киткәч, Равил стенадагы затлы сәгатькә күз салды:

– Мин шәһәргә ничек кайтам хәзер? – диде ул.

– Ашыгасыңмыни? – диде Секач, өстәл янына урнашып. – Утыр. Эч, капкалап ал.

– Ашыгам дип... Барыбер кайтырга кирәк бит, – диде Равил, мул ризыклы өстәл янына утырып.

– Җитешерсең. Абрек товарны карасын әле башта.

Равил шүрли башлады – товар болар көткәнчә булмаса?.. Ул кагылмаганны исбатлый алмаячак бит.

Ниһаять, ишек авызында Абрек күренде:

– Тәртип, – диде ул канәгать тавыш белән.

Секач салкын елмайды:

– Маладис. Миндә түгел дип, безне алдап йөрүең генә ачуны китергән иде. Мин аңлыйм сине... Гафу итәм. – Беравык пауза тотканнан соң ул сорап куйды: – Лаура белән сезнең арада бик тирән мәхәббәт булдымыни соң?

– Мин яратам аны, – диде Равил.

Хәзер инде Равилнең күңеле бераз тынычланды, әмма Лаураны җибәрерләрме-юкмы – шул җанны тырнап тора иде. Абрек товарны тикшерде, боларның аңа бернинди дәгъвалары юк, Равил Лаура хакында тагын сүз катарга җай эзләп утырды.

Секач рюмкаларга коньяк салды.

– Ашыкмыйсыңдыр бит?

– Алай бик ашыгыр җирем юк инде хәзер, – диде Равил.

– Эч. – Секач артка каерылып кычкырды: – Рита!

Икенче каттан кемнеңдер төшкәне ишетелде һәм кухняда мөлаем йөзле 30-35 ләрдәге яшь хатын пәйда булды. Өстенә затлы халат кигән, яланаяк, чәчен артка койрык итеп җыйнап куйган. Рита Равилгә ямьле итеп карап куйды.

Секач ягымлы тавыш белән:

– Рита, итне җылытып, кыздырып бир әле, – диде.

Бер рюмка коньяк эчкәч, Равилнең эченә җылы йөгерде. Сүз иярә сүз чыгып, Равил үзе турында ресторанда сөйләп бетермәгән нәрсәләрне сөйләде, тагын берничә рюмка коньяктан соң Лаурага мәхәббәте хакында, серле тәңкә турында да бәян итте. Актёр буларак, Равил матур, тәмле итеп сөйли белә иде.

Секач, ни гаҗәп, аны зур кызыксыну белән тыңлап утырды.

– Син сөйләгән вакыйгаларның романтикасы көчле, әлбәттә, – диде ул, тирән сулыш алып. – Ул бүләк иткән тәңкә үзең беләнме?

– Әйе.

– Кая, күрсәт әле.

Равил, муеныннан салып, тәңкәне Секачка бирде.

– Бу сиңа бик кадерле әйбер инде... – диде Секач, тәңкәне кулында әйләндергәләп, җентекләп караганнан соң.

– Лаураларның нәселен элек-электән михнәтләрдән саклап килгән ул. Тылсымлы, бик борынгы әйбергә охшаган бит.

Секач, көлеп, тәңкәне Равилгә бирде дә рюмкаларга тагын коньяк салды.

– Син үзең акыллы күренәсең, – диде ул. – Шул нәрсәләргә ышанасыңмы?

– Ул бит Лаураның бүләге, кадерле бүләк.

– Шулай бик яратасыңмыни аны? Син бернәрсәгә, беркемгә ышанма. Нәселләрен саклап килгән, имеш. Беләсеңме, ничек яшиләр алар?.. Алар кайгы-хәсрәт күрмәгәнме?

– Күргәннәр, әлбәттә. Лаураның үзенең генә дә ире суда батып үлгән, кызын машина таптаган.

– Алар һәлак булганда тәңкә Лаурада идеме? – диде Секач, рюмканы кулына алып.

– Әйе.

– Нишләп сакламаган соң бу төймә аларны? Әйдә, тотып куйыйк.

Алар чәкештереп эчеп куйдылар, шуннан соң Секач дәвам итте:

– Менә хәзер ул тылсымлы әйбер синдә... Ә минем егетләрем чак кына синең башыңны сугып ярмадылар. Ярый, сумканы китереп өлгердең. Әле хәзер дә син минем каршымда утырасың, берничә минуттан язмышың кай тарафка борылыр, белмисең. Бернәрсәнең тылсымы юк, бернәрсәнең бәясе, кыйммәте юк.

Равил тәңкәне муенына тагып куйды да:

– Ә кешеләрнең кыйммәте бармы? – диде.

– Һәрбер кеше үзе куя үзенә бәяне.

Кухняга кызган иттән хуш ис таралды.

– Рита, көйдермә, – диде Секач, түрдәге плитә янында мәш килгән хатынга борылып.

– Булды, әзер инде, – дип, Рита табаны өстәлгә куйды. – Тагын берәр нәрсә кирәкме?

– Юк, кояшым, бар, ял ит, – диде Секач хатынга, ягымлы итеп. Бу минутларда Секач бөтенләй бандитка охшамаган иде. Рестораннагы кызга, мондагы Ритага мөгамәләсеннән күренә – хатын-кызны ярата ул. Равил дә тәмам тынычланды, коньяк белән затлы ризык үзенекен итте. Аның үзенең дә Секач белән күбрәк сөйләшәсе килә башлады.

– Хатыныңмы әллә? – диде ул, Рита киткән якка ымлап.

– Хатыннарым күп минем, – диде Секач. – Мондый байлык дөнья тутырук. Алар белән рәхәт бит, тормышымнан аларны алып атсам, минем нинди юанычым кала? Әмма артык якын итәргә, артык тирәннән яратырга шулай ук ярамый. Син аша, аша.

Равил Секач салган тагын бер рюмка коньякны эчте дә тәмләп ит ашарга тотынды.

– Күренеп тора, син ачык, дөрес кеше, – диде Секач. – Ихлас кешенең бер бәласе бар – ул башкалар да ихластыр дип ышана. Андый кеше гадел була, ул башкалар да гаделлдер дип ялгыша. Синең кебек кеше ул ярата да белә, чын-чынлап гашыйк була ала һәм хатын-кыз да аны шулай яратырга тиештер дип уйлый башлый. Беркемгә дә ышанма, яраткан кешеңә дә, туганыңа да, үзеңә генә ышан. Аннары... әйберләргә килгәндә... Әйбер сиңа кадерле икән, үзеңнән дә кадерлерәк булмасын. Син, вакыты җиткәч,

үләсең, черисең, ә бу мидәлең әллә ничә мең ел сакланачак әле. Озак еллар буе кулдан-кулга күчеп, сакланып килгәне өчен кадерлеме ул?

– Кеше үлә, чери дисең... Кешенең җаны үлемсез, – ди торган иде минем әбием.

– Ну, әбиең әйткәч, шулайдыр инде, – дип көлемсерәп куйды Секач. – Әгәр җан үлемсез икән, бигрәк тә син бу борынгы калай кисәгенә табынырга тиеш түгелсең.

– Истәлек бит ул.

– Ярар, шул истәлекне муеныңа асып, һаман чегән кызы аркасында, буталып, абынып йөр инде алайса.

Равилгә әңгәмә ошый башлады, Секачка зур кызыксыну белән шактый вакыт карап торганнан соң, ул:

– Бик кадерле булган әйберләрең синең дә бардыр? – диде.

– Бар, әмма мин ул әйберләрдән тылсым да, ярдәм дә өмет иткәнем юк, хорафатчан булу яшәргә комачаулый. Сине N га алып барып кайткан «Москвич» водителе Әхәтнең әнисе рак белән чирләп үлде, бик нык интекте бичара. Югыйсә әбисенең әбисеннән калып, бәла-казалардан саклый торган чулпысы бар иде. Мин аны Мәскәүдәге зур врачларга алып барып дәвалаттым, монда аңа тагын бер ел гына яшәргә калды дигәннәр иде. Акчаны кызганмадым, Мәскәү врачларына күп итеп түләдем, шулай итеп аннары әле тагын алты ел яшәде. Врачларны да әйтерием... Бер нәрсәгә, бер кешегә ышанырлык түгел.

– Син шундый абруйлы кеше... Ышанычлы кешеләрең бер дә юкмыни?

– Юк! Дөньяда һәрбер кеше актёр. Син генә актёр дип уйлаган идеңме әллә?

– Бөтен дөнья – театр, әйе. Моны инде күптән әйткәннәр.

– Әмма, сезнең театрдан аермалы буларак, тормыш театры – коточкыч тамаша, чөнки театрдагы спектакльнең башы һәм азагы бар, аны карарга мөмкин, карамаска мөмкин, ә тормыш театрының ни башы, ни азагы юк, режиссёры да күренми, рольдән дә баш тарта алмыйсың.

– Син бик акыллы кеше, дөньяны күргәнсең, кешеләрне аңлыйсың, – дип, соклануын яшермәде Равил. – Син теләсә кайда зур җитәкче булып эшли алыр идең.

Секач көлеп җибәрде:

– Ник, ә мин хәзерге вакытта зур җитәкче түгелмени? – диде ул. – Дөресен әйткәндә, арыдым мин. Минем беркайчан беркем белән болай ачыктан-ачык сөйләшеп утырганым юк иде. Тикмәгә түгелдер бу, күңелем сизә – нәрсәдер якыная.

– Әхәт синең берәр туганыңмы әллә?

Секачның кургаштай кырыс чырае кинәт бераз яктырып китте:

– И-и-и, Әхәт... Ул миңа туганым кебек. Үземнең туганнарым миңа якын түгел, Әхәт, мөгаен, бүгенге көндә минем иң якын кешемдер. Без бала чактан ук дуслар, әмма Әхәт минем дөнья кешесе түгел. Криминалга аның бер катнашы юк, мин аны төрле йомышларга чакырам, кемне кая алып барганын ул үзе белми, кызыксынмый да – мин сорыйм, ул үти. – Секачның йөзендә елмаю сыман якты чалым беленде. – Миңа алты яшь иде. Җәй көне күрше подъездга Казан янындагы авылдан бер гаилә күченеп килде. Йөк машинасы җиһазларын йорт каршына бушаткан, болар мәш

килеп, фатирга әйбер ташыйлар. Минем яшьтәге бер малайны күреп, мин алар янына килдем. Берәр нәрсә чәлдерергә өметләндем бугай мин – өйдә ашарга берни юк, әти гел исерек, ул вакытта әни, авырып, бүлнистә ята иде. Әйбер ташыганнарын күзәтеп, шул тирәдә йөрим. Малайның әтисе улына каяндыр шундый күп итеп итле пәрәмәчләр сатып алып килде, теге малай тумбочка өстенә утырып, пәрәмәч ашый. Минем карап торганымны күреп, малай мине үзе янына чакырып, пәрәмәч бирде. Ул – авылда үскән Әхәт исемле татар малае, русча начар сөйләшә иде, ә мин ишегалдында беркемгә сер бирми торган, курку белмәс булып үстем, әти уголовник та булгач, миннән куркалар иде. Әхәтнең әти-әнисе, олы җанлы кешеләр, мине бик якын иттеләр, безнең гаилә хәлләрен белгәч, кызганып, үзләренә чакыралар, ашаталар, акча бирәләр иде. Без дуслашып киттек, ишегалдында Әхәтне кыерсытырга маташып карадылар, әмма мин аны җәберләтмәдем, минем дустым икәнне белгәч, аңа беркем дә тимәде. Мәктәптә без Әхәт белән бер класста укыдык, мин аңа терәк булдым, миннән – Секачов Сергейдан бөтен класс куркып тора иде. Мин үзем 1945 елны тудым. Сугыш башланганда, әтине төрмәгә утырткан булганнар – караклык өчен, нәрсә урлагандыр, белмим. Төрмәдән сугышка алганнар. Сугышка кадәр апам туган булган, ул үпкәсенә салкын тиеп үлгән. Әти яраланып кайткан... Ул аксап йөри иде. Ун айлык чагымда әтине тагын төрмәгә утырталар, йорт каршында исерек баштан берәүне пычак белән чәнчегән, ә тегенең абыйсы кайдадыр зур җитәкче булган. Әти 1950 елны кайтты, миңа биш яшь иде, миңа бөтенләй чит-ят кеше иде ул. Истәлекле, тарихлы әйбер дигәннән... Кеше чәнчегән пычак белән без күп еллар буе өйдә ипи кискәнбез икән – менә шундый мисалларны искә алгач, үзем дә кайвакыт хорафатчан булып куям. Әти бик каты, вәхши кеше иде. Өстәлдәге итне ашаганы өчен песине ишегалдында кыйнап үтерде. Бик ярата идем песиебезне. Әти аны бетон тротуарга ала да ора, ала да ора, мин песине кызганып бии-бии еладым, астыма сидем. Әнине бик каты кыйный иде, ул исерек чакта өйдә чыдарлык түгел иде инде. Ярлы яшәдек, мин гел ач булдым. Үсә төшкәч, мин икесен дә күралмый башладым – әтине вәхши булганы өчен, әнине, түзеп, аның белән яшәгәне өчен. Авыр чакларда мин гел Әхәтләргә керә идем, әти-әнисе мине кызганалар, кайвакыт үзләрендә кунарга калдыралар иде. Аларның өендәге җылылыкны минем бүтән беркайда татыганым юк. Әхәтнең әбисе бар иде – Галимә әби – ап-ак яулыклы, аның кулында гел дисбе иде. Ул мине шулкадәр ярата иде, гаиләбезнең хәлен белгәнгә кызганып кына түгел, нык ярата иде ул мине. Иң якты хатирәләрем аларның гаиләсе белән бәйле. Мин, рус малае, тиз арада татарча сөйләшергә өйрәндем – шул игелекле кешеләр белән алар телендә сөйләшәсем килде. Алар минем иң якын кешеләремә әйләнделәр, әтисе – мировой кеше, ул әле исән. Әнисе тәмле әйберләр пешереп ашата иде, урамдагы шуклыкларымны, тәртип бозуымны ишетеп, миңа бераз нотык та укыйлар иде. Әмма минем күңелем һәрвакыт кискен вакыйгалар таләп итте. Минем бандитларча кылануымны Әхәт беркайчан кабул итә алмады, әмма барыбер дус булдык. Аңлата алмыйм... Җаным тыныч вакытта бу рәхәтлеккә нәрсәдер яный кебек тоела иде, рәхәт халәтемә зыян килмәсен өчен минниндидер яман эш кылырга, көчемне, әшәкелегемне күрсәтергә тиеш дип уйлый идем. Үскәч, без төрле

тарафларга киттек, Әхәт үз юлыннан атлады, мин үз юнәлешемне сайладым, әмма төрле юллардан йөрсәк тә, без барыбер дуслар булып калдык. Беренче тапкыр мине төрмәгә «по малолетке», өлкәннәргә ияреп, кибет баскан өчен утырттылар, аннары, сугышып, дүрт елга эләктем, шуннан соң – урлау, урлау, урлау... Биш ел утырдым... Аннары тагын җиде ел... – Секач беравык тынып торды, аннары: – Ник сөйлим мин сиңа боларны?.. – дип куйды.

– Бәлки, гомерең шулай узганга уфтанасыңдыр...

– Белмим, белмим. Кеше бит ул үзен һич аңлый алмый, яман эш кылганын белми ул, аннары үкенәме-юкмы – анысына да төшенә алмыйдыр. Бер тапкыр, суд алдыннан КПЗда ятканда, минем белән бер камерада баҗасын кыйнап үтергән кеше утырды. Ул миңа баҗасы белән ничек сугышканнарын, ничек үтергәнен кат-кат тәфсилләп сөйләде, туйдырып бетерде. Мин еллар узгач аңладым: бу, күрәсең, аның җан газабы, үкенүе, тәүбә итәргә теләве иде, әмма көчсез, слабак булудан курку сер бирмәскә өнди иде аны. Шуңа күрә, эчтән янса да, тыштан бравада белән сөйләде баҗасын үтергәнне. Бу дөньяда ниндидер рольгә алынгансың икән, син аны гел уйнарга омтыласың, криминал мохиттә яман эш, гөнаһ дип тормыйсың, иң каты сыйфатларыңны кулланасың, башкача булмый, юкса сине таптыйлар, бетерәләр.

– Әхәтләр гаиләсеннән башка тагын нинди дә булса якты хатирәләрең бардыр?

– Бардыр, бәлки...

– Мәсәлән, беренче мәхәббәт...

– Мәхәббәткә ышанмыйм мин. Беренче тапкыр гашыйк булганымны хәтерлим. Ул кызны минем белән әти-әнисе йөртмәде – бандит ул, аның башы төрмәдән чыкмаячак диделәр.

– Лаура белән Харманны җибәрәсеңме?

– Әлбәттә. Аларның миңа кирәкләре юк, әмма Харманны болай гына калдырмыйм. Мине алдамакчы булды... – дип, Секач каты итеп сүгенеп куйды.

– Бәлки гафу итәргә кирәктер...

– Андый кешеләрне гафу итәргә ярамый. Бер уйлаганда, Харманны гаепләү дә дөрес түгел, әмма мине алдарга маташуын кичерә алмыйм.

– Гафу итә белсәң, дошманнар азая түгелме?

– Дошман итәсе кеше сине, яхшылык кылсаң да, дошман итәчәк. Гафу ителмәслек нәрсәләр күп, хыянәтчене, сатлыкҗанны, кеше үтерүчене гафу итеп булмый. Үземнең дә үтерүчеләрдән яхшырак җирем юк, минем кушуым буенча күп кешенең башына җиттеләр, минем үземне дә гафу итмәүчеләр – муеннан. Бер попның сөйләгәне бар: берәү төнгә таба чиркәүгә килеп, аңа мин кеше үтердем, ярлыка мине, дигән. Батюшка баш тарткан, тәүбәсен кабул итмәгән, бар, кит моннан, дигән. Теге чиркәү янындагы агач ботагына асылынып үлгән.

– Төрмәдә, зонада асылынучылар бармы?

– Булгалый. Бер тапкыр зонада яныма разбой өчен эләккән бер яшь егет, килеп яшисем килми, тагын алты ел түзә алмыйм, асылынам, диде. Мин аңа әгәр сине бу дөньяда беркем, бернәрсә тотып тормый икән, асылын, дидем. Әниемне кызганам, ди. Алайса, асылынма, дидем.

– Асылындымы?

– Юк, асылынмады. Асылынырга җыенучы әйтеп тормый ул, тота да асылына.

– Үзеңә андый уйлар килгәне булдымы?

– Дөньядан туйган чаклар күп була, минем үземне дә бернәрсә, беркем тотып тормый бу дөньяда, үлемнән дә курыкмыйм, әмма мин беркайчан үземә кул салмаячакмын – дошманнардан оят.

– Үзең үткән юлны берәр кешегә теләр идеңме?

– Кешесенә карап, аңа нинди генетика салынганына карап. Миңа шунысы көлке тоела – бик күп үсмерләр, яшьләр хәзер дә уголовниклар мохитенә романтик күзлектән карый. Анда бернинди романтика юк, ул кануннар буенча һәркем яши алмый. Хәзерге заманда бигрәк тә – тәртипләр үзгәрә бара, иң абруйлы карак та хәзер элекке кануннар буенча яшәми. Син хәзер ниндидер кануннар буенча гына, кагыйдәләр бозмыйча яшәсәң, сине таптап китүләре ихтимал. Тагын шунысы бар: бер авторитет та криминал дөньяда яшәвен каты кануннар буенча башламый. Мин башта әниемнең әйберсен урлап саттым, аннары күрше карчыкның пенсиясен урладым, ун яшемдә классташымның сәпитен чәлдердем. Иң зур авторитет та үзенең криминал юлын дәүләткә каршы көрәшүдән башламый, кешеләрне рәнҗетеп, гади кешеләрнең акчасын урлап башлый. Менә шулай, Равил... Синдә мин чын кеше күзләрен күрәм. Йодрык төйнәп сугарга ашыкма, куркак булып калсаң кал, әмма мөмкин булса, сукма, үзеңне тый. Төрмә – синең урын түгел, анда эләгүе бик җиңел, әмма анда кеше булып калу авыр. Ә мин һәрвакыт сугарга тиеш, миңа башкача ярамый, гел сугыш халәтендә тормасам, мине бетерәләр. Миңа хәзер 41 яшь, мин башкача яши белмим. Бәлки яши дә алыр идем, әмма бу криминал дөньядан ычкыну мөмкин түгел, мин инде тамыр җәйгәнмен бу дөньяга.

– Син бернәрсәдән дә, беркемнән дә курыкмыйсыңмы?

– Мин бер нәрсәдән генә куркам – куркак булудан.

– Алладан курыкмыйсыңмы?

– Юк. Алладан куркудан хәзер инде мәгънә юк, ул миңа инде күптән кул селтәде. Бәләкәй чакта Әхәтнең әбисе Галимә әбинең намаз укыганын күреп, аның дисбесенә кызыгып торганымны хәтерлим. Намазын тәмамлагач, ул миңа: «Аллаһ барыбызны да ярата, сине дә рәхмәтеннән ташламас, балакаем», – дигән иде. Ул көнне Галимә әби миңа хөрмә төшләреннән үзе җыйган дисбесен бүләк итте, андыйлар аның берничә иде.

Секач түрдәге утыргычта яткан барсеткасыннан дисбе алып килде.

– Менә ул. Мин аны гел үзем белән йөрттем.

– Бәлки бу дисбе сине саклап килгәндер? – диде Равил.

– Нәрсәдән, кемнән? Мин бит күрәсемне барыбер күрдем. Әйбергә ышанмыйм мин. Колымада утырганда, китапханәче бар иде, ул инфаркт белән кинәт үлеп китте. Ниндидер фабриканың партком секретаре вазифасында эшләгән, иң кадерле әйберсе – күкрәк турында йөрткән партбилеты булган. Хатынын сөяркәсе белән тоткан, икесен дә кыйнап ташлаган, хатыны исән калган, сөяркә бүлнистә үлгән. Сигез ел биргән булганнар. Ул хәтта зонада, үзен партиядән чыгарсалар да, коммунистлар партиясенә табына иде. Партбилетыннан мәхрүм калу – аның өчен иң зур фаҗига иде... Партбилеты сакламады ул кешене.

– Син берәр тапкыр өйләндеңме соң?

– Әйе. Әмма аеры-чөйре яшәдек. Соңгы тапкыр утырганда, хатын үзе развод ясады.

– Балаларың да бармы әллә?

– Ике кызым бар, үсеп җиткәннәрдер инде. Хатын күптән инде башка кешегә чыкты, барысы да миннән баш тарттылар. Ярый әле, хатын малай тапмады, минем юлдан киткән булыр иде.

– Димәк, улың булса, аның син узган юлдан баруын теләмәс идең?..

– Мондый юлны сынмыйча, бөгелмичә узу һәркемнең дә хәленнән килми.

– Дөньядан ямь табарга беркайчан да соң түгелдер, минемчә. Криминал мохиттән башка да әллә нинди киңлекләр бар лабаса – төрле илләр, төрле халыклар, табигать...

Равилнең бу сүзләреннән Секач көләргә тотынды, аның көлүе истерика дәрәҗәсендә иде.

– Бала чакта яз көне суга батып кайтканым өчен әти мине элгечкә аягымнан баштүбән асып куйган иде – язгы гөрләвекләрне күргәч, шул искә төшә, – диде Секач, көлүдән туктап. – Бер тапкыр җәй көне, рөхсәт сорамыйча, Иделгә кармак белән балык тотарга бардым, шуның өчен әти мине кыйнап, авызыма чи балык тыккан иде – җәй көне шундый хатирәләр калка. Бер тапкыр, көз көне дуслар белән Казансу буенда учак ягып, курткамны көйдердем, шуның өчен исерек әтием янып торган папиросын беләгемә сытып сүндерде. Кыш көне урамга сорамыйча чыгып киткәнем өчен балконда мине шәрәтән тотканын хәтерлим. Һәр ел фасылы белән бәйле тетрәндергеч вакыйгаларым күп минем. Ә син табигать дисең... Ха-ха-ха...

Секачның болай да төссез чырае кинәт ап-ак булды, эчке нәфрәте бөтен кыяфәтеннән аңкыды.

– Сине Галимә әбинең дисбесе ташламас, – диде Равил тынычландырырга теләгән сыман.

– Кызык кеше син. Ниндидер төймәләрнең тылсымына ышанасың... Генетика дигән нәрсә бар, буыннан-буынга кан белән күчә торган сыйфатлар бар... Әллә нинди борынгы обереглары булырга мөмкин... Әмма кешедән-кешегә яхшысы да, начары да кан белән күчә, язмыш дигән нәрсә бар, күрәчәк дигән нәрсә бар. – Секач елмаерга тырышты, ләкин күзләре нәфрәтле килеш калды. – Мирела тәңкәсе... Дракула акчасы... Галимә әби дисбесе... Ха-ха-ха...

Инде таң ата башлады. Сәгать дүртләр тирәсендә Секач янына машина белән берәү килде, алар ярты сәгать чамасы аулакта сөйләштеләр. Равил шул машина белән Казанга кайтып китте.

Равил берничә көн рәттән Секач белән булган әңгәмә тәэсирендә йөрде.

## 30

Каһәр суккан сумкадан котылганнан соң өч көн узгач, бөтенләй көтмәгәндә, театрга Харман шалтыратты. Лаураның абыйсы очрашырга кирәк дигәч, Равил каушады, әмма шундук тынычланды, хәтта сөенде – димәк, алар инде хәзер тоткынлыкта түгел. Харман «Совет» кунакханәсе янына килергә кушты. Равил, театрда беркемгә әйтеп тормыйча, шунда йөгерде.

Харман Равилнең исәнләшүен җавапсыз калдырды һәм беренче сүз итеп:

– Секач миннән товар таләп итә, – диде.

– Тагынмы? – дип аңышмый торды Равил.

Харман яман усал тавыш белән:

– Тагынмы түгел, шуны ук! – диде. – Товар кайда?

– Мин аны Секачка илтеп бирдем, – диде Равил, аптыраушта калып.

– Алар миңа син сумканы алып килмәдең диделәр.

– Илтеп тапшырдым. Ышанмасаң, әйдә, Секач янына барабыз, күзгә-күз сөйләшәбез.

– Товар кайда? – дип тешләре арасыннан сытып чыгарды Харман.

– Син миңа ышанмыйсыңмыни, мин бит КПЗдан котылырга сиңа ярдәм иткән кеше... – диде Равил, аптырагач.

– Ярдәм ит дип мин синнән сорамадым бит. Ярдәмче! Лицедей, клоун! – дип, аты-юлы белән сүгенеп куйды Харман.

– Хәзер Секач кайда икән, белмисеңме?

– «Татарстан» кунакханәсенең ресторанында утыра, – диде Харман, юлның теге ягындагы бинага ишарәләп.

– Әйдә, аның янына кереп, күзгә-күз сөйләшик, – диде Равил.

Төшке аш вакыты булганга, «Татарстан» ресторанының залында кеше шактый күп иде. Түрдәге өстәлләрнең берсен Секач белән Абрек алганнар, алар инде ашаганнар, китәргә җыеналар иде, ахрысы.

Харман белән Равил килгәнгә Секач һич кенә дә гаҗәпләнмәде, утыргычында арткарак каерылып, салкын гына:

– Ни йомыш? Тыңлыйм, – диде.

Бүген ул инде теге көнне Равил белән сөйләшеп утырган Секач түгел, ихлас әңгәмә корып булмаячагы күренеп тора иде.

– Секач, мин бит сиңа сумканы китереп бирдем, – диде Равил.

– Әйе, алып килдең, – диде Секач, теш арасын шырпы белән каезлап. – Без аны карадык, тикшердек. Ә ул чын товар түгел, туфта булып чыкты.

Харман, ачудан бер урында таптанып:

– Миндә чын товар иде, – дип җикерде. – Димәк, бу фраер алмаштырган, – диде ул, Равилгә ымлап.

Абрек, сагаеп, як-ягына карап куйды:

– Кычкырып сөйләшмә. Юри кычкырасыңмы әллә?! – дип пышылдады ул.

– Мин сумкадагы әйбергә бөтенләй кагылмадым, – диде Равил. – Мин бу эшләрдән ерак кеше. Минем андый әйберне алыштырып, бутап, яшереп йөрергә теләгем дә, мөмкинлегем дә юк.

Секач әле Равилгә, әле Харманга карап торды:

– Мин бу артистка ышанам, – диде ул. – Ә сиңа, Харман, ышанмыйм.

– Анда туфта булса, мин синнән качып йөрер идемме? – диде Харман, үзен кая куярга белмичә.

Секач теш каезлаган шырпысын өстәлгә ташлады.

– Син миңа тагын шуның кадәр товар алып килергә тиеш, – диде ул тыныч тавыш белән. – Әмма бу юлысы чынны.

– Секач! Мин җүләр түгел, – дип кыза башлады Харман. – Комсызлыкның да чиге булырга тиеш. Ни өчен тагын шуның кадәр тиеш мин сиңа?

– Алдап йөргәнең өчен.

– Артыгын кыланасың, Секач, – диде Харман, башын чайкап.

– Юк, мин артыгын кыланмыйм. Артыгын менә бу актёрлар, тамашачыга ярыйм дип, сәхнәдә тырыша-тырыша кылананалар.

Равил бу кешеләрдән җаны бизгәнне тойды, аның тизрәк чыгып йөгерәсе килде, моннан ераккарак, боларны бүтән күрмәслек тарафларга олагырга теләде.

– Мине тынычлыкта калдырыгыз! – диде ул, ялгыш сүз ычкындырудан үзен көчкә тыеп. – Мин бу эшләрдә катнаша алмыйм. Мин мәҗбүр булдым... Лаура хакына. Мин аңа ярдәм итәм дип уйладым...

– Нинди әкият сөйлисең син?! – диде аңа Харман, авызын кыйшайтып.

– Без аның белән 1977 елда ук очрашкан идек. Менә ул бүләк иткән тәңкә... Без...

Равил калтыранган куллары белән куртка астындагы күлмәгенең өске төймәләрен чишеп, муеныннан Лаура бүләк иткән тәңкәне салып күрсәтте.

Харман, көтмәгәндә, аның кулыннан тәңкәне йолкып алды да:

– Синдә булырга тиеш түгел ул. Бу – Мирела тәңкәсе! – дип, аны үзенең кесәсенә тыгып куйды.

Секач белән Абрек, боларны күзәтеп, кинәт көлеп җибәрделәр.

Равил:

– Мин берегез алдында да гаепле түгел, мин Лаурага ярдәм итәргә теләдем, – диде дә рестораннан чыгып китте.

Равилнең башында уйлар өере бөтерелде, Пушкин урамы буйлап, кая барганын да аңламыйча атлады.

Ирек мәйданына җитәрәк аны Харман куып җитте.

– Син болай гына котыла алмассың! – диде Харман, аны туктатып. – Секач барыбер миннән чын товар таптыра.

– Чын товар аңарда бит инде, – диде Равил битараф тавыш белән. – Туфта дип, юри әйтә ул, моңарчы качып йөргәнеңне гафу итә алмый.

Харман, ачудан калтыранып, Равилне түшеннән йомарлап тотты:

– Син миңа шул товар бәясен бирергә тиеш!

– Миңа башта Лаура белән сөйләшергә кирәк, – диде Равил.

Харман як-ягына каранып алды да кесәсеннән төймәле пычак чыгарды.

– Тагын бер тапкыр Лаура белән күрешсәң, мин сине үтерәм! – диде ул ярсып һәм җил-җил атлап китеп барды.

Равил алга таба нәрсә булыр дип хафаланды, уйларның рәте-чираты калмады. Лаураны күреп сөйләшергә мөмкин булыр микән? Нишләп болай килеп чыкты соң? Хәзер инде серле тәңкәдән дә колак какты... Серле...

Әйе, кеше борынгы әйберләргә, гомумән, тарихка үткәннәрне матур күрсәтә торган күзлектән карарга ярата. Ул тәңкә Дракула чорындагы вакыйгаларга, бөек вә фаҗигале үзгәрешләргә, Казандагы кискен борылышларга шаһит булгандыр. Ә бүгенге көн, хәзерге чынбарлык, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре, бәйләнешләре – һич кенә дә сокланырлык түгел, киресенчә, гади, примитив булып күренә. Үзенә хыянәт итмәгән, дөрес яшәгән кешегә нәрсәгәдер, кемгәдер табыну кирәк микән?.. Мәхәббәткә кеше табынмый кала алмыйдыр шул. «Коткарасың калмаган иде мине», – диде аңа Лаура күптән түгел. Чыннан да, әллә коткарасы калмаганмы? Күреп кенә калган булсам, болай яратмас идем бәлки, Лаура аңа серле тәңкә бүләк итмәгән булыр иде. Тәңкә Равилгә уңыш китердеме

әллә? Киресенчә, хәзер аның хәле мөшкел. Борынгы әйбер, тылсымлы, истәлек, имеш, данлы вакыйгаларга шаһит тәңкә, тарихи шәхесләр күргән, аларның кулларында булган, имеш... Әгәр гасырлар узганнан соң пычракта казынып яшәргә, караклар белән сөйләшеп утырырга, түбәнсенергә туры килә икән, тарихи әйберләргә сокланып караудан ни мәгънә?!

Ул тәңкә кемгә ярдәм иткән? Аның кыйммәте нәрсәдә? Борынгы булуындамы? Ул заман инде безнеке түгел, без инде аны югалттык. Ул заманнан килгән ташлар, тәңкәләр безгә ни бирә? Алар безгә дөресен җиткермиләр. Без ышанырга телибез, ышанасыбыз килә, без алданырга телибез, алданасы килә.

Алданырга омтылып, нәрсә өмет итә кеше, нәрсә эсти? Чынбарлыктан канәгать түгелме? Бүгенге көн элеккеләренә караганда начаррак, киләчәк көннәр бүгенгедән яктырак булырга тиеш дип саныймы? Син хәзер менә монда, бүген яшисең, менә син! Үткән заманнар синнән башка булган, ә киләчәк нәрсә алып килер – белмисең. Яшә бүген, яшә хәзер! Бүгенге әйбернең кадерен бел!

Бүгенге көннең нәрсәсе кадерле? Илдә кан коеп, җитмеш елдан соң дөрес юлдан бармаганбыз дип, мәчетләрне, чиркәүләрне җимергәннән соң, аларны яңадан төзеп, тарихны ничек телисең, шулай язып, тираннарга һәйкәл куеп, аннары аларны аударып... Кемнең, нәрсәнең кадерен белергә тиеш мин?

...Ике ел элек Мәскәүдә узган Татарстан мәдәнияте көннәрендә катнашкан иде ул – зур сәхнәдән татар шагыйрьләренең шигырьләрен укыды. Икенче көнне театрда уйнарга тиеш булганга, Равил Казанга алданрак кайтып китте. Мәскәү белән Казан арасында йөри торган «Татарстан» поездында ул өлкән яштәге бер абзый белән бер купеда кайтты. Владимир Алексеевич исемле бу кеше гомерен медицинага багышлаган, сугышта да госпитальләрдә хирург булып хезмәт иткән, акыллы, күпне күргән зат иде.

Аның белән булган әңгәмәне Равил бүгенгедәй төгәл хәтерли.

Үзенең иртәгә уйнаячак роле турында әйткәч, Владимир Алексеевич кызыксынып сорады. Равил үзенең персонажы хакында кыскача сөйләп бирде. Равил акылдан язарга җитәр дәрәҗәдә гашыйк булып, мәхәббәтен гомер буе саклаган, яраткан кешесе хакына авыр сынаулар үткән, хәтта үлем белән очрашкан бер сәер кешене уйный иде.

– Спектакльдәге вакыйгаларга чын күңелдән ышанып утыручы тамашачыга гаҗәпләнәм мин, – диде пенсиядәге хирург, елмаеп.

– Сез мин уйнаган персонаж тормышта булмый дип уйлыйсызмыни?

– Кемдер әйткән: «Мәхәббәт – ике кешенең бергә кушылган эгоизмнары». Мин бу фикер белән килешәм. Беркемне дә үзеңнән ныграк ярату мөмкин түгел. Акылга зәгыйфь булсаң гына, мәхәббәт хакына, яраткан кешең хакына үзеңне корбан итәргә мөмкиндер.

– Гомумән, мәхәббәт юк дип саныйсызмы әллә?

– Мәхәббәт бардыр, әмма ул халәтнең үзенең билгеле бер мөмкинлекләре бар, мәхәббәтнең чыдамлык чиге бар.

– Мәхәббәт хакына җанын фида кылучылар бар бит...

– Кайда? Кинодамы? Сәхнәдәме? Китаплардамы? Легендалардамы? Бәлки. Ә чын тормыштан андый мисал китерә аласыңмы?

– Сезнең беренче мәхәббәт кайчан, ничек булды?

– Студент чагымда, сугышка кадәр.

– Иң яктысы – беренче мәхәббәт, килешәсезме?

– Әйе. Иң матуры – беренче мәхәббәт, аның үзбәясе югары, эчке тәэссораты озак саклана. Әмма син аны аерылганнан соң тормыш юлында бүтән беркайчан очратмаган сурәттә генә. Беренче мәхәббәт өчен хистән, дәрттән тыш, вакыт белән пространство зур роль уйный. Ерак ара, очраша алмау – болар беренче мәхәббәтнең яктылыгын, аны сагынуны көчәйтә. Еллар узганнан соң очрашкач, аның үзгәргәнен күрәсең, җаның бизмәсә дә, аңлатып булмаслык үкенеч туа, бергә булган якты көннәрнең еракта калганын анык аңлыйсың, татлы мизгелләрне кабатлый алмаганыңнан һәм үткәннәргә кире кайта алмавыңнан тын гына сулкылдаган газап тоясың.

– Шулай да, мин килешмим, – диде Равил. – Беренче мәхәббәттән соң да гашыйк булгансыздыр, башкаларны яраткансыздыр? – дип кызыксынды ул.

– Бик нык гашыйк булып, бик каты ятратканым булды.

– Гомер юлыннан бергә атладыгызмы аның белән?

– 1947 елда дус-ишләрем, коллегаларым белән минем туган көнемне бәйрәм иттек. Кунаклар таралышкач, без өчебез – мин, минем сөйгән кызым Валя һәм бер коллегам – калып, таң атканчы бергә утырдык. Мин исерек баштан артык күп сөйләп ташладым: немецлар безгә караганда яхшырак сугыштылар дип, үз-үзенә атып, минем аша үткән «самострел»лар турында, безнең солдатларны хайван урынында күрделәр дип... Кыскасы, ярамаган сүзләрне күп сөйләп ташлаганмын. Коллегам минем өстән шикаять язган. Тикшерү барганда Валяны да чакырып сорау алдылар. Без аның белән тиздән өйләнешергә тиеш идек, бик ярата идек бер-беребезне. Аңардан сораганнар: «Владимир шундый-шундый сүзләр, шундый-шундый фикерләр әйттеме?» «Әйе, әйтте», – дигән Валя һәм шундук кул куйган. Миңа 10 ел бирделәр. Мин 1953 елны, 6 ел утырып, азат ителдем.

Владимир Алексеевич тынып калды, бүтән бер сүз дәшмәде. Поезд Казанга килеп җиткәндә Равил йокыдан уянды, Владимир Алексеевич купеда инде юк иде.

**31**

Бу матавыкның азагы кайчан булыр икән дип, Равил җан тынычлыгын җуйды. Әмма көтмәгәндә килеп чыккан вакыйга чынбарлыкка үзенең төзәтмәләрен кертте. Беркөнне Казан читендә ике криминал төркемнең бәрелеше турында радиодан сөйләделәр, телевизордан күрсәттеләр, гәҗитләрдә яздылар. Ростовлылар белән Казанныкылар сугышында, Секач кушаматлы лидерның һәм тагын берничә кешенең үтерелүе хакында да әйтелгән иде.

Аны Лаура язмышы гына борчыды – кайда икән ул?

Равил Әнәс янына барырга булды, мөгаен, ул барысын да беләдер. Милиция бүлегенә җитәрәк Әнәс аңа үзе очрады, ул каядыр бик ашыга иде.

– Равил, минем срочно барып кайтасы җирем бар. Башка вакытта килерсең, яме, – диде ул, көтеп торган машина янына тиз-тиз атлап.

Равил машинага кадәр аңа ияреп барды.

– Секачны үтергәннәр икән... – диде Равил.

– Аны кайчан да булса бер үтерергә тиешләр иде, – диде Әнәс. – Синең дустың Харманны да үтергәннәр. Ростовлылардан өч кешене, Казаннан

икене наповал бәргәннәр, яралылар күп. Вупшем, от души атышканнар. Исән калганнарын тоткарладылар инде. Казан бандасындагыларның дүртесе әле качып йөри, но аларны да тиздән тотарлар инде.

– Лаура турында берни дә белмисеңме?

– Каян белим мин аны?! – дип җикерде Әнәс. – Башны катырма! Белмим. Каян белим мин! Секач-Харман эшләренә минем бөтенләй катнашым юк. Башка группа алып бара ул эшне. Син үзеңә үзең маҗаралар эзләүдән тукта.

Әнәс, «УАЗ» машинасына утырып, саубуллашмыйча да китеп барды.

Әйе, кеше үзгәрә инде ул. Әнәс тә армиядәге кебек дусты түгел инде. Дөньяда беркем дә кичәге булып кала алмый. Хәтер генә элек нинди булганыңны саклый, оныттырмый. Хәтер генә кайчандыр кичергән хисләрне, тойгыларны сакларга мөмкин, әмма син инде аларны яңадан татый алмыйсың, кабатлап яши алмыйсың. Хәтер күбрәк якты вакыйгаларны саклый бугай – авыр чакларда сине тынычландырыр, гомер гел авырлыклардан тормады дип ассызыклар өчендер.

Бүген яшәргә комачаулый торган хатирәләрдән арынырга иде, соңгы вакытта булган күңелсез вакыйгалар онытылсын иде. Бандитлардан, Харманнардан, милициядән читтәрәк булырга иде, алар белән ара өзелсен иде, Лаура белән очрашуларның да якты мизгелләре генә калсын иде хәтердә.

Декабрь башы... Казан каласы кышка кереп бара.

Беркөнне тулай торак вахтасында аңа повестка бирделәр. Милиция бүлегенә чакыру алгач, Равил ни уйларга да белмәде. Харманны коткару өчен мең сум акчаны илтеп биргәнем өчендер дип, пошаманга калды. Әнәскә шалтыратырга микән? Әмма соңгы очрашуны истә тотып, аңа әйтми торырга булды.

Следователь Кирсанов – киң җилкәле, кырыс йөзле, сары чәчле, сары каш-керфекле капитан – үтә җитди кыяфәттә бер бармагы белән генә иске машинкада нәрсәдер басып утыра иде.

Равилнең «Исәнмесез» диюенә, капитан, каршысындагы урындыкка ымлап:

– Утырыгыз, – диде һәм машинка төймәләренә шык-шык басуын дәвам итте.

Кәгазьне машинкадан алгач кына, Кирсанов үткен зәңгәр күзләрен Равилгә төбәде. Ул Равилнең паспортын карады, аннары исеме-фамилиясен, кайда яшәвен, эш урынын үзеннән әйттерде. Капитан башта кулдан кәгазьгә язды, аннары машинкада шуны бастырды. Равил шул арада инде әлләниләр уйлап бетерде, чөнки ник чакырганнарын чамаласа да, әле төгәл белми иде.

– Сез Секачов Сергейны беләсезме? – дип сорады тикшерүче.

– Юк, – дип әйтеп ташлады Равил.

– Аның дачасына ник барган идегез соң?

– Минем бернинди дачада булганым юк.

– Гражданин Шәмсиев, дөресен сөйләсәгез, үзегез өчен яхшырак булыр, – диде капитан. – Нинди йомыш буенча «Секач» кушаматлы кеше белән очраштыгыз?

Әйтерсең лә көчле куллар түштән йомарлап тотты, Равил өзек-өзек аңлатырга тотынды:

– Мин... Лаура исемле чегән кызы белән... Без тугыз ел элек инде танышкан идек... Секач аның абыйсы белән конфликтта... Мин Лаурага тимәгез дигән үтенеч белән Секачка мөрәҗәгать иттем...

– Секачка бирәр нәрсә алып килдегезме?

– Юк.

– Дачада тагын кемнәр бар иде? – диде Кирсанов, Равилнең үзен тотышын җентекләп күзәтеп.

Равил үзен чолганышта калып баргандай хис итте, сорау артыннан сорау яңгырый, ә бит аларның барысына да җавап бирергә кирәк, буталып бетүең ихтимал.

– Кемдер бар иде бугай... Мин аларны белмим, – диде Равил.

– Секач белән кайда, ничек таныштыгыз?

Равил нык каушады. Капитанның сораулары чиксез булачак, барысына да ничек җавап табып бетермәк кирәк. Ул, башын салындырып, капитанның бу соравын җавапсыз калдырды.

– Абрек кушаматлы кеше бар идеме анда? – диде Кирсанов.

– Бәлки булгандыр, мин аларның барысының да исемнәрен белмим.

– Рита бар идеме?

– Нинди Рита? – диде Равил, андый исемне хәтерендә эзләп.

– Сезгә ит кыздырып биргән Рита. Ул әйтте: сез Секачка ниндидер сумка алып килгәнсез, төн буе сөйләшеп утыргансыз. Абрек та шулай диде. Секачка нинди сумка алып килдегез?

– Мин сумкада нәрсә икәнне белмәдем. Секачка илтеп тапшырдым гына.

– Аны кем тапшырырга кушты?

Нәрсә дип җавап бирергә? Равил үзен ярдәмсез хис итсә дә, үзе өчен карар кылды инде – сумканы Лаура китергәнне әйтмәячәк, Лаура турында әйтергә ярамый, Равил аны катнаштырмаячак.

– Лаураның абыйсы, – дип ялганлады ул.

– Харманмы?

– Әйе.

– Сумканы кем бирде сезгә?

– Харман.

– Харман бит шул товар белән Секачтан качып йөргән, нишләп сезгә, сумканы биреп, бар, Секачка илт дияр икән ул? – Кирсанов «син»гә күчте. – Равил, син татар халкы өчен зур актёр, әмма минем өчен – подозреваемый. Харман белән кайчан таныштыгыз?

Равил башын аска иеп, уйга калды, Кирсанов, соравын кабатлады:

– Син Харман белән күптән танышмы?

– Күптән түгел, – диде Равил, башын калкытып. – Лаура белән Казанда шушы көздә очраштык та абыйсы белән дә танышырга туры килде.

– Шул арада Харманның ышанычлы кешесенә әйләндеңме? Товарны ул бирде дип алдыйсың син.

– Сумканы миңа Харман бирде, – диде Равил, капитанның йөзенә туры карарга куркып.

– Димәк, син дә бу җинаять чылбырының бер буыны, бер боҗрасы, – диде Кирсанов. – Сочидан товарны җибәргәннәр... Харман аны Казанга алып килгән... Аны сиңа биргән... Ник син аны Люберцы кешеләренә тапшырмадың икән? Нишләп Секачка илтеп бирдең?

– Минем ул җинаятьчеләр төркеменә бер катнашым да юк, – диде Равил. – Харман, шалтыратып, очрашыйк, диде. Ул Лаура белән аралашуыма каршы,

башта мин шул хакта сөйләшергә телидер дип уйладым. Ә ул сумка алып килде, яшереп куярга кушты.

– Син, Харманга ачу итеп, товарны Секачка илтеп бирдеңме? – дип, шундук сорады капитан.

– Ачу итеп түгел. Секач кешеләре килеп, миннән товарны даулый башладылар, мин илтеп бирдем.

– Син миңа дөресен сөйләмисең, – диде Кирсанов тыныч тавыш белән һәм озак итеп Равилнең җавапларын машинкада басты. – Укы да имзаңны куй, – диде ул, берничә бит кәгазьне Равил алдына салып. – Шушы көннәрдә повестка килер... Бар, повестка алу белән монда килерсең.

Равил Кирсанов кабинеты урнашкан дүртенче каттан әкрен генә баскычтан төшкәндә, аның каршысына папка тотып менеп килүче лейтенант кыз матур итеп елмайды:

– Исәнмесез! Сез Равил Шәмсиев түгелме?

– Юк, – диде Равил, бу минутларда үзен күрәлмыйча.

Әнәснең бүлмәсе икенче катта иде, Равил шунда юнәлде.

Әнәс үзе генә түгел, каршысында олы яшьтәге бер апа утыра иде, коридорда шактый вакыт көтәргә туры килде.

Килүенә Әнәснең шат түгел икәнен Равил керү белән үк сизде. Нинди бәлагә юлыкканын әйтә алмый утырды, чөнки Әнәс эшнең күплеге, кешеләрнең бозылуы турында үзенең аһ-зарларын озын-озак итеп сөйләргә тотынды. Соңыннан, башын чайкап:

– Ай-яй, нәрсә булды кешеләргә! – дип куйды ул. – Әле генә монда булган апаның малае йөргән кызына, көнләшеп, алты тапкыр пычак кадаган. Апа үзе гомер буе укытучы булып эшләгән, улымны төрмәгә утыртмагыз дип елый... – Әнәс Равилгә кашларын җыерып карап торды. – Нишләп чыраең ак? Чегән кызы хыянәт иттеме әллә? Берүк аңа алты тапкыр пычак белән кадый күрмә.

Әнәс үзенең тупас шаяруыннан үзе көлеп куйды, Равил аның сөйләгәнен дә, көлүен дә ишетмәгәндәй, дөньядан ваз кичеп утырды.

– Нәрсә булды тагын? – диде Әнәс, ниһаять.

Равил үзенең нинди яңа бәлагә тарыганын ничек бар, шулай сөйләп бирде, сумка турында да, Кирсановка ялган мәгълүматлар бирүен дә бернинди ялгансыз әйтте.

Әнәс шаккатып тыңлап утырды.

– Ну, син дурак, Равил! – диде ул. – Сәер кеше икәнеңне армиядә үк чамалаган идем, әмма бу кадәр үк тиледер дип уйламаган идем. Сиңа төрмә яный, шуны аңлыйсыңмы?! Ичмаса, башта минем белән киңәшләшергә идең.

– Мин синең белән гел киңәшләшеп тордым түгелме...

– Син миңа сумка турында әйтмәдең. Бу – җинаять! Сиңа уголовный эш ачачаклар.

Равилнең кинәт бөтен нәрсәдән, бөтен кешедән җаны бизде, дөньядан ваз кичүе бу мәлдә аның хәтта кыяфәтенә чыкты. Ул усал итеп, Әнәскә туп-туры карады:

– Син мең сум акча алдың... Харманны болай да чыгарасы булганнар...

Әнәс беравык ни әйтергә белми утырды.

– Мең сумнан миңа бер тиен дә эләкмәде, – диде ул, башка сүз тапмагач.

Равил, акча турында сүз катканына үкенеп, авыр сулап куйды.

– Син миңа ярдәм итә аласыңмы? – диде ул басынкы тавыш белән.

– Нинди ярдәм?

– Уголовный эштә мине катнаштырмаска.

– Ул бит бик зур эш, – диде Әнәс чыраен сытып. – Мин тыгыла алмыйм. Анда ике группировканың сугышы хакында сүз бара, аларның конфликтында күп кеше катнашты, анда утлы корал, наркотиклар, үтереш, суеш... Анда күп нәрсә... Хәзер менә син дә шулар белән бер бәйдә йөриячәксең инде.

– Кирсанов белән сөйләш. Бәлки мине бөтенләй катнаштырмаска мөмкинлек бардыр.

– Катнашкансың бит инде – тыелган товарны бер бандиттан икенчесенә ташучы курьер буларак. Кирсанов мине якын да китермәячәк, минем аның белән мөнәсәбәтләр начар, ул мине күрәлмый, мин анда тыгыла алмыйм.

Равил «служак»ка текәлеп карады:

– Үзгәрдең син, Әнәс...

– Сиңа да үзгәрергә вакыт, – диде Әнәс, авыз чите белән усал елмаеп. – Шушы гәүдәң белән маңкаңны агызып йөрисең. Чегән кызы сиңа ни алып килгәнне аңларлык та башың юкмыни?! Бу кадәр үк тинтәк булырга ярамый бит инде. Кирсановка дөресен сөйләргә кирәк иде. Белүемчә, Секач кешеләрен инде барысын да тоттылар, алардан энәсеннән җебенә кадәр сөйләтәчәкләр – кем кемгә нәрсә биргән, кем нинди роль уйнаган...

Шул вакытны ишек шакыдылар. Ишек кысып кына ачылды, бер үсмер егет башын тыгып:

– Мөмкинме? – диде.

– Повестка буенчамы?

– Әйе.

– Бер минут көтеп тор, – диде аңа Әнәс. – Менә, тагын бер тиле... Ну, моңа унсигез яшь кенә әле, баш мие кенәри кошыныкы шикелле генә. Син бит акыллы кеше, Равил! – Әнәс өстәлендәге папканы ачты. – Равил, гафу ит, мин эшемне дәвам итәргә тиеш.

Равил кая барганын да белмәгән халәттә Казан үзәге буйлап атлады. Нишләп Лаура үзенә шулкадәр тарта? Шулай еллар да баса алмаслык итеп нык гашыйк булдымыни соң ул чегән кызына? Кешене аңлар өчен аны яратырга кирәк диләр. Ни дигән сүз инде бу? Лаураны аңлый алдымы соң ул? Нинди җепләр һаман өзелмичә тотып тора аны? Нигә кирәк бу? Әгәр бу халәтем мәхәббәт икән, нигә ул миңа, аның мәгънәсе бармы соң? Газаплы мәхәббәт чын мәхәббәт буламыни? Әгәр яшәргә комачаулый икән, мәхәббәт түгелдер лә ул. Нишләп мин, үз эшемдә шактый зур уңышка ирешкән, хатын-кыз игътибарына беркайчан кытлык кичермәгән ир-егет, болай тиз төшенкелеккә бирелләм? Секачлар, Абреклар шундый ук кешеләр ләбаса, нишләп алар чыдам, курку белмәс затлар? Хәер, алар кебек булыр өчен каты бәгырьле, кансыз булу зарур. Әнә, Секач инде теге дөньяда. Абсолют чыдам кеше юктыр инде ул. Лаура – миңа бөек сергә кагылырга, ике җанның, ике тәннең сихри кушылуын татырга мөмкинлек биргән беренче кыз, аңа гашыйк булмаслык түгел иде, хәзер дә яратып туймаслык ул. Равил үзенең юк кына нәрсәгә дә мөкиббән китүчән икәнен аңлый башлады. Соклану

иллюзиясез булмыйдыр инде, күрәсең. Вәләкин Лаура белән якынайгач та, аңа таң калу, аны ярату юкка чыкмады бит. Димәк, чын мәхәббәттер инде ул. Әнәс мине тиле диде. Шулайдыр. Нык ярата торган кеше зирәк акыллы була микән? Әйе, мин – дурак, мин – шыр тиле. Чөнки минә-менә үземә уголовный эш ачулары ихтимал, ә мин Лаураны яратуым турында уйланып барам. Әйе, сумканы алудан баш тартырга кирәк иде, гафу ит, Лаура, мин бу үтенечеңне үти алмыйм дип әйтергә тиеш идем... Нишләп кайвакыт ихтыяр көчемне җуям соң мин?.. Нишләп Лаура алдында бөтенләй бер мәҗнүн булып калдым? Равилнең кайдадыр, кайсыдыр китапта укыганы бар иде: «Бигүк хискә бирелмичә, аз яратучы кеше үзен аямыйча яратучыга караганда һәрвакыт көчлерәк була. Үзен яратырга ирек биреп, үзе бөтенләй яратмаучы тагын да көчлерәк. Дәртле мәхәббәт иясе беркайчан хаким була алмый, расчётлы кеше генә хакимлек итә ала...»

Лаурага сумканы милициягә илтеп бирергә тәкъдим иткән булсам?.. Һич югы: берничә көннән соң сумкаңны алып кит дияргә тиеш идем мин.

Ә шулай да следовательгә сумканы Харман бирде диюем яхшы булды, Лаураның катнашы барлыгын беркем белми – Харман инде исән түгел, Секач кешеләре Лаура алып килгәнне күрмәделәр. Алга таба да сумканы Харманнан алдым дип тукырга тиешмен. Лаураны җавапка тартмаячаклар. Ә үземне?.. Повестка көтәргә куштылар түгелме?..

Күңелне курку биләп алды – нәрсә булып бетәр? Төрле кеше төрлечә курка... Тагын Секач күз алдына килеп басты. Ул да курыккандыр, куркуын күрсәтмәгән генәдер, яшергәндер, юкса муенына тәре тагып, кулына Әхәтнең әбисе Галимә бүләк иткән дисбе тотып йөрмәс иде. Әмма тәре дә, дисбе дә сакламады үзен, башына җиттеләр. Харманны да үтерделәр. Тәңкәне йолкып алганда, Харманның күзләре ерткычныкы шикелле иде. Хәзер серле тәңкә кайда икән? Серле... Аның сере нәрсәдә?.. Мин аның тылсымына ышанган идем. Ул тәңкә Лауралар нәселенә бәхет китердеме соң? Равил үзе соңгы вакытта рәхәт яшәдеме? Бердәнбер юанычы – театр, әмма андагы ләззәтне татыр өчен тормыш-көнкүрешнең тыныч булуы зарур.

1499 елда Гәүһәршад Казанга Миреланы алып килеп уңышка ирешкәнме? Символлар, обереглар, табынган, могҗизалы дип саналган әйберләр Казанга ярдәм иттеме?

Кешеләр үзгәрмәде, кеше ышана ул. Начар кеше дә, яхшы кеше дә ышана, әмма үзенә генә аз ышана кеше.

Лаура да хәзер күз алдына илаһи зат булып килеп басмый инде. Әмма җәйге төнне, аның белән булган кыска гына вакытны беркая куеп булмый, онытырга мөмкин түгел.

Әллә чынлап сихерле тәңкә бүләк иткән идеме ул?

Лаура минем яныма абыйсын коткарырга ярдәм сорап кына килде түгелме?.. Равилне бит ул абыйсын коткарырга ярдәм итәр дип өметләнеп кенә тапты. Һаман сабыйлыктан арына алмыйм, нишләп болай тиз ышанам соң мин? Элекке хисләремне, тойгыларымны кат-кат яңартырга маташам, ә Лаура...

Бу халәттә Равил шактый вакыт йөрде. Әмма тормыш үз агымы белән бара, кеше игътибарын үзе теләгән тарафларга юнәлтә. Гөлнара белән аерылышырга гаризаны бернинди үкенү-уфтанусыз яздылар, гомер

юлыннан киләчәккә бергә атларга икесе дә теләмәде, дөньяга туа алмаган бала гына күңелдә тирән яра калдырды.

Ярар, яшәү дәвам итә. Аның театры, яраткан профессиясе, җан атып торган тамашачысы бар. Аның әти-әнисе исән, һәм алда әле яшәешнең иркен болыны җәйрәп ята.

**32**

Ишекне шакымыйча гына килеп кергән зифа буйлы яшь хатынга капитан Кирсанов беравык аптырап карап торды. Бер сүз дәшмичә, хәтта исәнләшмичә дә, пәлтәсенең сәдәпләрен чишеп, каршысындагы урындыкка аякны аякка атландырып утырган бу чибәр затка Кирсанов үзе:

– Исәнмесез, – диде. – Сез кем буласыз?

– Лаура.

– Ә-ә-ә, әйе, әйе. Мин бик шат, – диде капитан, Лаураның кышкы аяк киеме затлы икәненә игътибар итеп.

– Шат? – дип көлемсерәде Лаура, башындагы мамык яулыгын маңгай турында ике куллап калкытып. – Мине күрүегез шулай бик куандырамыни?

– Казаннан китәрсез дә, сезне эзләп аһ итәрбез дип борчылган идем.

– Кирәк кешене сез әллә кайлардан табасыз. Мине уголовный розыск кешесе тиз тапты, следователь Кирсановка барырга кушты. Менә, килдем, ник кирәк булдым мин сезгә?

– Лаура, берничә сорауга җавап бирегезче.

– Тыңлыйм.

– Абыегыз Харманның соңгы вакытта нинди эшләр белән шөгыльләнгәнен беләсездер инде?

– Белмим. Абыем Харман бу дөньядан инде китте, борчымагыз аның рухын.

– Гафу итегез, Лаура, аңлыйм... Ләкин сез дә мине аңлагыз, коточкыч конфликтта кешеләр һәлак булды, уголовный эш башланды, мин шул вакыйгага кагылышлы сораулар бирергә мәҗбүр. Ике төркем арасындагы конфликтның сәбәпләре байтак, ул сугыш инде күптәннән бара, әмма шушы арада килеп чыккан бәрелешкә абыегыз Харман Казанга алып килгән товар этәргеч ясады. Безгә мәгълүм: Харман товарны алып килгән, Секач моны белеп эзәрлекли башлаган. Әйтегез әле, ахыр чиктә Харман Секачка үзе теләп биргәнме товарны?

Лаура иңнәрен сикертеп:

– Мин хәбәрдар түгел, – диде. – Нинди товар? Миңа абыемның беркайчан андый серләрен ачканы булмады.

– Сез актёр Равил Шәмсиевне беләсезме?

– Беләм, – диде Лаура, сагаеп.

– Күптәннәнме?

– Моннан тугыз-ун ел чамасы элек танышкан идек.

– Сез шул вакыттан бирле элемтәдә булдыгызмы аның белән?

– Юк.

– Соңгы тапкыр кайчан очраштыгыз?

– Шушы көзне, монда, Казанда.

– Харман белән алар бер-берсен күптән беләләрме?

– Алар бер-берсен белмиләр, алар бөтенләй таныш түгел иде. Дөрес, абый күптән түгел аның турында белде һәм миңа аның белән аралашмаска кушкан иде.

– Ник?

– Ник икәне аңлашыла бит инде, сез безнең яшәү рәвешен, законнарыбызны яхшы беләсез.

– Димәк, Харман белән Равил Шәмсиевнең мөнәсәбәтләре яхшы түгел иде?

– Әйтеп торам бит: аларның беркайчан аралашканнары булмады.

– Лаура, әйдәгез, ихластан сөйләшик әле. Абыегыз инде исән түгел, аңа берни янамый... Бөтен илне тетрәндергән атыш-үтереш эше Мәскәү контролендә тора. Бу эштә бер сумка тыелган товар «эленеп» тора. Ул товар, әлбәттә, бу кадәр кеше үтерерлек үк кыйммәт түгел, әмма, күрәсең, каһәр суккан сумка ике группировканың низагына соңгы тамчы булып тамгандыр. Бу эшкә катнашы булган һәрбер кешене ачыклау безгә бурыч итеп куелган. Харман товарны Равил Шәмсиевкә ник бирде икән? Алар бит аралашмаганнар...

– Белмим, – диде Лаура, уйга калып. – Раульгә бирде микәнни?

– Равил аны Секачка илтеп тапшырган, Равил моны үзе әйтте.

– Рауль үзе әйтте?! – дип гаҗәпләнде Лаура.

– Ник гаҗәпләнәсез? Харман кушты микән аңа илтеп бирергә, әллә башка кешеме?..

– Белмим.

– Бу җинаятьтә мине Шәмсиевнең роле кызыксындыра. Ростовлылар кешесеме ул, әллә Харманның ярдәмчесе булды микән?..

– Су бирегез, зинһар, – диде Лаура, яулыгын салып.

Кирсанов тәрәзә төбендәге графинны алып килеп, стаканга су салды.

– Товар Равилдә икәнне сиңа кем әйтте соң? – диде капитан,«син»гә күчеп.

Лаура йотлыгып су эчте, йөткереп алды.

– Мин белмәдем, – диде ул, стаканны өстәлгә куеп.

– Секач кешеләреннән инде сорау алдык. Аларга син сумка Равилдә дип әйткәнсең. Димәк, син белгәнсең. Сиңа Харман куштымы Равилгә сумканы илтеп бирергә?

– Юк.

– Үзең?..

Лаура капитанның йөзенә туры карап:

– Үзем, – диде.

– Абыең куштымы?

– Юк. Өйне тенти башладылар... Мин абыйның сумканы яшергәнен күргән идем. Мин бит белмәдем – тентүчеләр милициядәнме, әллә бандитлармы, шуңа күрә сумканы алып качтым.

– Сумкада тыелган әйберләр икәнне белдеңме?

– Юк, белмәдем. Полиэтилен төргәкләр икәнне күрдем, ни икәнен аңламадым.

– Равилгә нәрсә дип бирдең соң син аны?

– Абыйның әйберсе, яшереп тор дидем. Дөресе шул.

Лаура кинәт хәлсезләнде, әмма Кирсанов сорау алуны дәвам итте.

– Равил Шәмсиев белән сезнең мөнәсәбәтләр тирәнме?

– Ул ышанычлы кеше, – диде Лаура. – Ул чын кеше.

Кирсанов, паузадан соң, сорап куйды:

– Син аны яратасыңмы?

– Ничек инде рома кызы «гаджо»ны яратсын! Бу сорауны ник бирәсез?

– Сумканы тапшырганнан соң Равил белән ничә тапкыр очраштыгыз?

– Шуннан соң аны күргәнем юк.

Лаураның йөзеннән газап саркыды, ул алдына салынган яулыгын ике куллап бөгәрләде һәм елап җибәрде:

– Арыдым мин, туйдым... – диде ул, сулкылдап. – Миңа Казаннан китәргә кирәк.

Аның елавы Кирсановның күңелен аз гына да җебетмәде, ул коры гына:

– Сез әлегә Казанда булырга тиеш, – диде.

**33**

Равил икенче тапкыр килгәч, Кирсанов калын папкасын актара-актара, хәл-әхвәлләрне сораштырган булды. Равил аның сорауларына, пауза тотып, уйланып, саклык белән җавап бирергә тырышты. Капитан папканы тумбочкасының тартмасына тыгып куйгач, шактый вакыт текәлеп карап торды.

– Димәк, сез сумканы Харманнан алдыгыз? – дип чак кына елмайды ул.

– Әйе, – диде Равил.

– Тыелган әйбер икәнне белдегезме?

– Юк.

– Ничек инде, ни икәнен белми торып, сумканы алырга, аннары аны яшерергә батырчылык иттегез?

– Мин Харманның үтенечен кире кага алмадым, чөнки ул – Лаураның абыйсы. Миңа Харман белән мөнәсәбәтләрне җайга салу мөһим, юкса ул миңа Лаура белән очрашырга рөхсәт бирмәс иде.

– Ә Лаура сезнең белән очрашырга атлыгып торамы? – диде Кирсанов.

– Ни дигән сүз инде бу?

– Сез аны нык яратасыз, ахрысы?

– Яратам.

– Сезнең типтагы кешеләрне очратканым бар минем. Хатын-кызга каты гашыйк булып, аны пьедесталга менгереп куялар да аннан да гүзәлрәк кеше юктыр дип саный башлыйлар. Сез аңа кирәк микән соң?

– Мин яратам аны. Сезнең ни эшегез бар безнең мөнәсәбәтләрдә?

Кирсанов шактый вакыт Равилнең күзләренә карап торды.

– Син миңа дөресен әйтмәдең, – диде ул ачулы тавыш белән. – Сумканы сиңа Лаура китереп биргән.

Равил эчке сискәнү тойды, әмма үзенекен сукалады:

– Юк, сумканы миңа Харман китереп бирде.

Капитан, торып, тәрәзә янына барды, шактый вакыт уйланып торгач, тышка караган килеш:

– Син Лаураның бу эштә гаепле булуын теләмисең, аңлыйм, – дип куйды.

– Ул чынлап та гаепле түгел, – диде Равил, торып.

Кирсанов, кабинет буйлап берничә тапкыр әрле-бирле йөреп алгач:

– Утыр, утыр, – диде. Аннары, Равил янына килеп, чак кына иелде дә:

– Сумканы сиңа Лаура биргән, – диде. – Лаура миңа үзе әйтте. Закон буенча сез икегез дә бу җинаятьтә катнашкансыз булып чыга.

– Лаура берни белми! – диде Равил, борсаланып. – Миңа сумканы Харман китерде.

Кирсанов урынына барып утырды, телефон номерын җыеп, трубкага өч кенә сүз әйтте:

– Егор, алып кер!

Күп тә үтмәде, кабинетка Лаура белән озын буйлы лейтенант керделәр. Лаураның йөзе сулыгып калган, күзләре төссезләнгән, ул зәңгәрсу свитер кигән, пәлтәсе белән яулыгын беләгенә аскан иде.

Равил торып басты, Лаура стена буенда янәшә торган өч урындыкның берсенә әкрен генә барып утырды. Лейтенант, Кирсановка карап, күрсәтмә көтте. Кирсанов:

– Бар, мин сине чакырырмын, – дигәч, ул чыгып китте.

Равил, Лаурадан күзләрен алмыйча, бер урында тик басып торды.

– Утыр, утыр, – диде аңа капитан.

Равил өстәл каршындагы урындыкны Лаурага якынрак күчереп утырды.

– Лаура, хәлләрең ничек? – диде ул.

Лаура дәшмәде, ул, башын аска иеп, уйга чумды. Тикшерүче, утыргычында чак кына артка каерылып, башта Равилгә карап торды, аннары Лаурага эндәште:

– Лаура, сумканы сез Равилгә илтеп бирдегезме?

– Әйе.

Равил сикереп торды:

– Юк! Лаура! Алдыйсың! Абыең Харман алып килде миңа сумканы.

Лаура, башын калкытып, Равилгә карады, елмаерга тырышты, әмма елмая алмады, йөзеннән сагыш саркыды:

– Рауль, мин алып килдем сиңа сумканы, – диде ул сыктанулы тавыш белән. – Яшереп куй дип үтендем, син ризалык бирдең. Мин аңлыйм, син мине акламакчы буласың, мине катнаштырырга теләмисең. Рәхмәт, кирәкми. Ничек бар, шулай әйт.

– Лаура... – дип нидер әйтмәкче булды Равил, әмма сүзләр тапмады.

– Рауль, гафу ит мине, – диде Лаура, чак кына ишетелерлек итеп. – Минем аркада син дә пычракка кереп баттың.

Кирсанов уйга чумды, шуннан файдаланып, Равил Лаура янына барып утырды.

Кирсанов телефон номерын җыйды:

– Егор, кер!

Әлеге дә баягы лейтенант кергәч, Кирсанов аңа:

– Протоколларны мин кушканча тутыр, – диде. – Кул куйдырганчы миңа күрсәтеп алырсың.

– Есть! – дип җавап бирде лейтенант һәм Лаурага: – Гражданка, әйдәгез, минем белән, – диде.

Равилнең дә аларга ияреп барасы килде, ул кинәт сикереп торды, Лаура әкрен генә ишеккә таба юнәлгәч, ул да кузгалды.

Кирсанов коры гына:

– Шәмсиев, сезнең белән әңгәмәне мин дәвам итәм әле, – диде.

– Аны кая алып киттеләр? – дип сорады Равил, капитан каршысына килеп утыргач.

– Әлегә беркая да түгел. Аның белән башка кеше сөйләшә. Эшнең ничек җитди икәнен чамалыйсыңдыр инде?

– Әйе, чамалыйм.

– Синең бу матавыкка ничек килеп эләккәнеңне мин бик яхшы аңлыйм. Син – башка дөнья кешесе. Биографияңне һич кенә дә бозасым килми, әмма сумкада нинди товар икәнне белмәвең җаваплылыктан сине коткара алмый, чөнки, ничек карасаң да, синең аша үткән ул.

– Тыелган товар очраклы рәвештә генә минем кулга эләкте. Иптәш капитан, Лаурага берни дә булмыйдыр бит?

Кирсанов көлемсерәп куйды:

– Иң элек үзең өчен кайгырасы урынга син һаман Лаура дип утырасың. Үзе әйтеп тора бит: сумканы мин Равилгә бирдем, ди. Бәлки хәзер инде баш тартыр, абыем биргән, дияр. Карарбыз.

Равилгә һава җитми башлады, өстендә җиңел куртка булса да, эссе иде аңа. Капитан шактый вакыт дәшми утыргач, Равил, куркып:

– Миңа нәрсә була? – диде.

– Суд хәл итәчәк, – диде Кирсанов.

Кабинетта авыр тынлык урнашты. Равилнең күз алдына бер-бер артлы әти-әнисе, апасы, театрдагы иптәшләре килеп басты. Мин аларга ни әйтермен? Харап булдым микәнни? Профессиямнән дә колак кагачакмын бит. Гомер буена үзем белән йөри торган оят, хурлык булачак...

Кирсанов, аны уйларыннан арындырып:

– Мин сиңа ярдәм итәргә телим, – диде. – Синең бу матавыкка ялгыш килеп эләгүең инде ачыкланды. Сумканы Секачка Харман илткән дип язачакмын.

– Абрек белән Рита мин алып килгәнне күрделәр бит, – диде Равил, ә үзенең эченә барыбер бераз җылы йөгерде.

– Секачка товарны кем тапшырганы Абрекка да, Ритага да – барыбер. Мин аларны тиешле күрсәтмәләр бирергә күндерермен. Алар да: сумканы Харман алып килде дисәләр, сине бу эштән бөтенләй читләштереп булачак. Лаурага да аңлатырга кирәк булыр – сумканы Секачка Харман илткән дип күрсәтмә бирсен.

Равил әле ышанмыйча утырды, ул бары тик:

– Рәхмәт сезгә, – дип берничә тапкыр кабатлады. – Сез чын әйтәсезме?

Кирсановның йөзе яктырып китте, кырыслыгы да каядыр югалды:

– Милициядә аяусызлар, канечкечләр генә эшли дип уйлаган идеңме әллә? – дип елмайды ул.

**34**

Тагын повестка килер микән дип көтә-көтә, Яңа ел җитте. Соңгы вакытта Равил театрда автомат рәвештә генә уйнады, коллегаларына игътибары кимеде, алар белән аралашмый башлады. Аның болай сәерләнүенең сәбәбен хатыны белән аерылышуында күрделәр.

Февраль башында беркөнне Равил түзмәде, Кирсанов янына үзе барырга булды – теге эшнең ничек барганын яисә ахыры нинди булганын белергә теләде. Һәм, әлбәттә, Лаураның язмышы аңа тынгылык бирми иде.

Кирсанов, папка ачып, бу юлысы күзлектән, нидер укып утыра иде. Аның погоннарында инде дүртәр йолдызчык урынына берәр зур йолдыз беркетелгән – аңа майор исеме биргәннәр иде.

Кирсановның кәефе яхшы иде, ахрысы, бүген ул еш елмая һәм күп сүзле иде.

Равил:

– Миңа бүтән повестка килмәде... – дигәч, майор, шаярып: – Монда бик килергә атлыккан идегезмени? – диде.

– Юк, минем теге эшнең ничек тәмамланганын беләсем килә, йөрәгем барыбер урынында түгел, моңарчы гел повестка килерме-юкмы дип шөбһәләнеп йөрдем.

– Хәзер тәмам тынычлансаң да була инде. Гыйнвар азагында суд булды, ростовлыларга да, Секач кешеләренә дә төрле сроклар бирделәр, Абрекка дүрт ел чәпәделәр, күбрәк бирерләр иде, атыш вакытында ул атмаган, аның коралы булмаган, Рита шаһит буларак барды. Абрек та, Рита да минем үтенечем буенча судта сумканы Секачка Харман алып килде дип әйттеләр.

– Ә Лаура?..

– Аны бер делога да кертмәдем, хәтта шаһит буларак та үтмәде. Сез монда очрашканнан соң бүтән күрешмәдегезмени?

– Юк шул.

– Шалтыратканы да булмадымы?

– Юк. Кайда икән ул, белмисезме?

– Казанда түгелдер. Китәм дигән иде бит ул. – Майор җитди кыяфәткә керде. – Бәлки аның бүтән күренмәве сезнең өчен яхшырактыр?.. Сез упкын кырыеннан үттегез, чак кына харап булмый калдыгыз. Сөенергә кирәк!

Равилгә бу сүзләр җылы тәэсир итте, следователь Кирсанов аңа шундый зур яхшылык эшләде бит.

Равилнең дә бу кешегә ниндидер яхшылык эшлисе килде.

– Мин сезгә...– Аның бераз акча тәкъдим итәргә уе бар иде, әмма шундук кире уйлады. – Сез нинди эчемлек яратасыз: коньякмы, аракымы, виномы?

Кирсанов көлеп җибәрде:

– Мин бөтенләй эчмим. Сез миңа театрга чакыру билеты бирерсез, шәп тамашага, берәр премьерагамы анда...

– Ярар, килештек, – диде Равил, Кирсановның кулын кысып.

Лаураның хушлашмыйча каядыр юкка чыгуы эчне пошырса да, бандитлар белән чуалыштан исән-имин чыга алуы, хөкемнән котылуы, Гөлнара белән араларның өзелүе – барысы бергә өстән ниндидер авыр йөкне алып ташлаган кебек тәэсир итте.

Тормыш яңа сукмактан киткәндәй булды, тора-бара Равил бөтенләй тынычланды, яраткан эшенә җаны-тәне белән кереп китте. Театрда аның яхшы якка үзгәрүен күреп, дуслары сөенде, аны өнәмәүче хөсетләр, әлбәттә, көенде, ә Равил, рольләргә кытлык кичермичә, популяр артист булуы белән куанып, горурланып, үз эшеннән тәм-ямь табып яши башлады.

## 35

Көннәр, айлар, еллар үтә торды. Утыз яше тулуны Равил тагын яңа роле белән каршы алды. Соңгы вакытта аны бер генә нәрсә борчыды – кыйммәтләр үзгәргән, кешеләрнең хезмәт хакы азайган, әхлаклы кеше булдыксыз дип санала башлаган бу заманда театрның да яшәештә урыны, тоткан роле кимегән вә кечерәйгән кебек тоелды. Үз урының, үз фикерең өчен тормышның һәр тарафында, һәр өлкәсендә, шулай ук сәнгатьтә дә, көрәшергә генә түгел, хәтта кайбер әхлакый кануннарны да инкарь итәргә туры килә иде. Кайчандыр җимерелгән мәчетләрне кабат торгыза башладылар, яңаларын төзергә тотындылар, ә кешеләрнең яхшы якка үзгәргәне сизелмәде.

Әмма заман нинди генә булмасын, тормышта шатлык-бәхеткә һәрвакыт урын табыла. Утыз яшендә Равил, кем әйтмешли, үз кешесен, үзенең «икенче яртысын» тапты.

Аны Милли китапханәгә очрашуга чакырдылар. Равил ярты сәгатькә иртәрәк килде, аны каршы алган Галия исемле китапханәче кыз аерым бүлмәдә чәй әзерләде. Шәһәрдә туып-үсүенә карамастан, татарча дөрес вә матур сөйләшүче, инсафлы бу кызның табигый гүзәллеге генә түгел, нәзакәтле хәрәкәтләре, үзен тотышы Равилне таң калдырды. Егерме өч яшьлек Галия дә танылган актёрдан мөкиббән китүен яшермәде, сүз белән әйтмәсә дә, күз карашыннан бу очрашу аның өчен бик кадерле, бик кыйммәт һәм бик кирәк икәнне күрергә мөмкин иде. «Бүгенге көндә бу гүзәл кыз тормышыма ямь иңдерә алыр иде» дип уйлап куйды Равил.

Иҗади очрашудан соң, алар якыннанрак таныштылар. Укытучылар гаиләсендә туып үскән кызның актёр профессиясенә «дөрес» карап, аны югары сәнгать эшенә санавы да Равилнең күңеленә хуш килде. Алар еш очраша башладылар, тора-бара ял көннәрендә, буш вакытларында гел бергә булдылар.

Инде эшләр никахлашуга таба барганда, Равил сөйгәненә: «Минем бит әле болай нык яратканым юк иде!» – дип кабатлап туймады.

Аларның гаилә корып яши башлаулары илнең көтелмәгән юнәлештән киткән чорына туры килде. Ярый әле, торак мәсьәләсе тиз хәл ителде – театр җитәкчелеге тарафыннан «өскә» язылган хат ярдәмендә, никахтан соң бер ай үтүгә, яшь гаиләгә бер бүлмәле аерым фатир бирделәр. Гаилә корып, яңа тормышка аяк басу дәрте заман болгавырлыгын җиңде, гаилә учагын кабызган мәхәббәтнең җылысы чынбарлык салкыныннан саклап калды. Еллар узгач, перестройка вакытын, туксанынчы елларны тәнкыйтьләп сүгүчеләр белән Равил һич кенә дә килешмәде, аларга хәтта көлеп карады. Туксанынчы еллар башы аның өчен бәхетле еллар иде – ул Галияне очратты, аңа өйләнде, балалары туды.

Равил бу вакытта, яшьлеге белән хушлашып, хисләр колы гына булып түгел, җитди караш, «аек» акыл белән, гаиләсе өчен җаваплылык тоеп яши башлады. Төп эштән тыш төрле шабашкаларга йөрде, концерт бригадалары белән чыгып, акча эшләде, күп тә үтмәде, машина сатып алды. Гомер юлыннан бергә атлаучы кеше булуының ни дәрәҗәдә мөһим икәнен тәгаен аңлады ул. Гаилә җылысы, яраткан кешесенең янәшә булуы, балалары – шулар аны илһамландырды, яшәргә, эшләргә дәрт һәм дәрман биреп торды.

Иң кадерле, бәһасез байлыгың – балаларың икән ул. Балаларыңны үзеңнән

дә ныграк яратасың икән. Булсын, балаларыңны нык ярату бәлки шулай ук синең эгоизмыңның чагылышыдыр. Кеше яратырга тиеш! Кеше нәрсәне дә булса, кемне дә булса нык ярата икән – бу үзеңне яратудыр инде ул. Булсын! Иң мөһиме – син яратасың, син яратырга сәләтле, димәк, син мәхәббәткә ия.

Элегрәк театрдан башка яши алмам дип уйлый иде ул. Хәзер гаиләсе хакына, балалары хакына ул дөньяда югалмаячак, теләсә нинди эшкә әзер, теләсә нинди сынауларга чыдаячак. Йә гаиләң, йә театр дип сайларга туры килсә, Равил, һичшиксез гаилә дияр!

35 яшендә аңа Татарстанның атказанган артисты исемен бирделәр. Олыгая барган саен аның театрга мөнәсәбәте үзгәрә барды. Сәнгать әһелләре күзлегеннән караганда, театрның миссиясе шул ук, моның белән килешми мөмкин түгел, әмма аның халыкка тәэсире кимегәнне, театрның кешелек дөньясында тоткан урыны кечерәйгәнне алар да аңлый иде. Ике сәгатьлек тамаша ярдәмендә начар кешене барыбер яхшы якка үзгәртә алмыйсың – моны Равил хәзер инде яхшы белә. Кешене театр тәрбияли дигән сүзгә дә Равил хәзер ышанмый – гомер буе төрле тарафларда тәрбияләнгән, формалашкан кешене сәхнәдәге чыгышың белән генә ничек үзгәртмәк кирәк?!

Әйе, яшь чакта, эшли башлаганда, театрдан башка яши алмас кебек тоелган иде. Соңгы вакытта гел алышынып торган театр җитәкчеләре дә элеккеләреннән нык аерыла, болары күбрәк коммерция ягын карыйлар, күбрәк үз кесәләрен кайгырталар. Элек артист театрда төп кеше саналса, хәзер исә администрация хезмәткәрләре иң мөһим кешеләргә әйләнде – статус буенча да, хезмәт хакы буенча да.

Вакыт уза торды.

Кырык яшь тулды.

Кырык бишкә җитте.

Озакламый илле яшьлек юбилеен уздырыр...

Хәзер инде бөтен нәрсә бар кебек – гаилә, хатын, балалар, дан, акча, машина... Әмма җанда ниндидер аңлатып булмаслык сагыш, җирсү ята. Бөтен нәрсә җитеш, бөтен нәрсә бар кебек, әмма нәрсәдер җитенкерәми, нәрсәдер юк, Җиһанда үзеңнең барлыгыңны тирәнтен тою өчен тагын нәрсәдер җитми шикелле. Алай гына да түгел, нәрсәдер җуелган, ниндидер бик кирәкле нәрсә инде бүтән мәңге табылмас булып югалган шикелле.

Мөгаен, узган гасырның җитмешенче еллардагы һавасы җитмидер. Шул еллардагы яшьлек дәрте, шул чордагы таныш-белешләреңнең чисталыгы, ихласлыгы юкка чыккандыр, шул заманның җәй урталарындагы айлы төннәрен сагыну күңел сусавын елдан-ел арттырадыр, мөгаен. Чигәләр агара башлады, маңгайда җыерчыклар инде беленә, киләчәк якты күренә, ә күңел айлы сукмактан балачакка кайтып китүне тели. Минем газиз «М-107» матаем, син инде таралып, күгәреп, металлолом арасында юкка чыккансыңдыр. Чегән кызы Лаура, аның белән хуш исле печән чүмәләсендә кочаклашып йоклау – шушы дөньяда булды микән? Шушы дөньядадыр, әмма башка яссылыктадыр!

Бер илдә туып-үсеп, бөтенләй икенче илдә яшәргә туры килде. Аның иң рәхәт чагы «теге» илдә калды. Яши-яши ирешкән дан вә дәрәҗә, акча һәм мал – бала чактагы, үсмер вакыттагы бәхеттән барыбер өстен була алмас, күрәсең.

**36**

2005 елның җәе Равилгә көтелмәгән вакыйга әзерләгән икән.

Күп еллар узганнан соң, кайчандыр Лаура бүләк иткән тәңкәнең тагын кулына килеп керүе аның күңелен җилкендерде.

Шул тәңкә бу, шул!

Равил ипи комбинаты директорының кабул итү бүлмәсенә шалтыраткач, аны шундук директорның үзе белән тоташтырдылар. Куе тембрлы хатын-кыз тавышы Равилнең күңеленә хуш килде.

– Хәерле көн, Равил әфәнде! Гафу итегез, сезнең отчествогызны белмим.

– Нинди отчество инде ул татарда! – диде Равил. – Фәйрүзә ханым (директорның исеме шулай иде), сезнең белән очрашып сөйләшәсем килгән иде.

– Мин бик дулкынланам... Сезнең кебек кешеләр белән еш очрашырга туры килми... Бик шат булырмын очрашуыбызга, мин сезгә үземнең машинамны җибәрә алам.

– Рәхмәт, кирәкми, мин үземнең машина белән киләм. Кайчан кабул итә алырсыз икән?

– Сезне елның теләсә кайсы фасылында, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында кабул итәргә әзермен, – дип җавап бирде директор.

Затлы причёскалы, тулы гәүдәле, 45-50 яшьләрдәге директор ак халаттан иде. Яшьлеге белән хушлашырга ашыкмаучы сөйкемле хатын танылган актёрны проходнойда үзе каршы алды. Шул арада комбинат буенча танылган актёр килде дигән хәбәр таралды.

Хатын-кыз директорларның кабинетына хас җыйнаклык вә ямьлелек монда да бүлмәнең һәр тарафында саклана иде. Равил әдәп йөзеннән башта ипи комбинатындагы хәлләр, проблемалар, уңышлар турында сораштырды, аннары театр турында бераз сөйләде. Директор исә аның ни йомыш белән килгәнен әйтүен түземсезлек белән көтте.

Равил кыскача унҗиде яшендә чегән кызына гашыйк булуын бәян итте, Лauраның бүләге хакында да, бандитлар белән булган матавыкларны да төшереп калдырып сөйләде. Директор затлы кыяфәтле актерның сөйләгәнен йотлыгып тыңлап утырды.

– Равил әфәнде, бу вакыйга китап язарлык булган бит, – дип, ихластан соклануын белдерде Фәйрүзә.

– Хәзер мин сезгә ни йомыш белән килүемне әйтәм, – диде Равил, пинжәгенең түш кесәсеннән тәңкәне алып. – Сезнең комбинат тәэмин итә торган кибетләрнең берсендә ипи алган кеше кайчандыр миңа чегән кызы бүләк иткән тәңкәгә тап булган – ипи эченнән чыккан ул. Сезгә бернинди дәгъва юк... Киресенчә, мин шат... Чөнки тәңкә тагын миндә. Моның чегән кызы миңа бүләк иткән тәңкә икәненә иманым камил. Мине шул кызның язмышы борчый, инде 20 елга якын аны күргәнем юк, язмышын да белмим. Ничек тагын монда килеп чыккан икән бу әйбер?

Фәйрүзә уйга калды.

– Эшчеләремнән турыдан-туры сорасам, дөресен әйтмәсләр инде, куркырлар. Кайсы цехта булды икән ул, онга төшкәнме, су белән кергәнме, камырга эләккәнме... Ничек белергә?.. Равил әфәнде, бераз вакыт бирегез әле миңа, аны минем эшчеләремнең берәрсе төшергән булса, моны берәр ничек шыпырт кына ачыкларга кирәк.

Кабинетка директорның ярдәмчеләре чәй китерделәр, өстәлдә комбинат җитештерә торган тәм-том урын алды. Равил театрга чакыру билетлары китерергә вәгъдә биргәч, хуҗабикәнең йөзе кояш кебек яктырды. Сөйләшә торгач, август азагында Татарстан Республикасы көнен бәйрәм итү булачагы турында сүз чыкты. Ул көннәрдә актёрларның эше тыгыз булачагын ишеткәч, Фәйрүзә дә горур тавыш белән:

– Без дә бик каты әзерләнәбез, – диде. – Иң тәмле чәкчәкне без пешерәбез бит. Санаулы көннәр генә калып бара инде.

Равилне проходнойга озатырга директор тагын үзе чыкты һәм, саубуллашканда ипи эченә кергән тәңкә хезмәткәрләрнең кайсысында булганны ачыкларга вәгъдә бирде.

Шул тәңкә микән соң ул? Бәлки Дракула монеталары күп булгандыр. Шул тәңкә дип ышанасы килде Равилнең, гәрчә хәзер инде аны муенына тагып куярга теләге булмаса да.

**37**

30 август көнне Казан-калага табигать чалт аяз көннәр бүләк итте. Бу көнне шәһәрнең төрле тарафларында көйле-җырлы, шат авазлы чаралар гөрләп-кайнап торды. Мәдәни чараларның күбесе, әлбәттә, Казанның үзәгендә узды. Көндезге сәгать икедә, Тукай һәйкәленә чәчәкләр куйганнан соң, Камал театры каршында танылган шагыйрьләр үзләренең иҗат җимешләреннән тамашачыларны авыз иттерделәр, җырчылар җырлады, биючеләр биеде.

Татарстанның атказанган артисты Равил Шәмсиев тә Тукайның берничә шигыре белән чыгыш ясады. Затлы кыяфәтле, көчле вә матур тавышлы бу актёрны халык аеруча яратып кабул итте. Вакытлыча сәхнәгә әйләнгән баскыч мәйданчыгыннан төшкәч, аны чолгап алдылар, кемдер автограф алды, кемдер үзенең соклануын белдерде, кемдер рәхмәт әйтте, һәммәсенең атаклы кеше белән аз гына булса да аралашасы килде. Равил, кемнедер абайлап, кире баскычтан менеп китмәкче иде, аның үзе генә булуыннан файдаланып, кечкенә буйлы, джинсы костюм кигән мөлаем йөзле бер кыз куып җитте:

– Равил абый! Зинһар, туктагыз, тыңлагыз мине. – Кыз калтыранган куллары белән кыска причёскасын төзәткәләп куйды.

– Ник бу кадәр каушыйсың, сеңлем? – дип елмайды Равил.

– Равил абый... Минем исемем Сәрия... Мин... Ипи комбинатында эшлим... Мин... тестовод... Камыр цехында... Мин телефонымны кесәмнән алгач... белмим ничек килеп чыкты... Телефон чехолы минем бәрхет материалдан... Телефонымны кесәдән алганда эләккәндер инде... Сезгә бирәсе әйбер эләгеп чыккан да камыр изелә торган чанга төшеп китте...

Равил кызны, беләгеннән тотып, читкә алып китте.

– Сеңлем, тынычлан, ашыкмыйча сөйлә, – диде Равил, сүзнең нинди тәңкә турында barганын аңлап.

Сәрия чынлап та бик хафалы кыяфәттә иде.

– Миңа Венера апа... Әниемнең сеңлесе... Сезгә бер әйберне бирергә кушкан иде... Үзе ул гел командировкаларда...

– Мин түземсезлек белән бер сорауга гына җавап көтәм – тәңкә кемнән, ничек тагын монда килеп чыккан, Венера апаң каян алган аны?

– Белмим. Ул аны Сочидан алып кайткан.

– Апаң һаман командировкадамы?

– Киләсе атна башында кайта. Венера апа – йорт җиһазлары кибетенең директоры, ул гел командировкаларга йөри.

Венера Салмачы бистәсендә үзенең затлы коттеджында яши иде. Командировкадан кайтып, берничә көн узгач, аңа Равил шалтыратты, Венера аны шундук үзенә кунакка чакырды.

Матур капкалы көяз йорттагы муллык Равилне таң калдырды. Венера – илле яшьләр тирәсендәге купшы кыяфәтле хатын – Равилне «деловой кәчтүм» киеп, шәп причёска ясатып каршы алды. Чандыр гәүдәле яшь хезмәтче кыз зиннәтле җиһазлар белән бизәлгән иркен зал уртасындагы өстәлгә чәй әзерләгән арада Венера үзенең бизнесы турында сөйләргә өлгерде, сүзләрендә тормаучы партнёрлардан зарланды, моннан ике ел элек йөрәк өянәгеннән иренең вафат булуын әйтте.

– Сәрия сезгә тапшырдымы тәңкәне? – дип сорады ул, ниһаять.

Тәңкәнең нинди юл белән Сәриядән Равилгә килеп җиткәнен Венера белми – моны Равил аңлады һәм бу хакта сөйләп тә тормаска булды.

– Тапшырды, рәхмәт, – диде Равил.

– Соңгы көннәрдә, нишләптер телефонын алмый, җавап бирми. Соңгы вакытта театрда сирәк булам, элек еш йөри идем, хәзер вакыт та җитенкерәми. Мин үзем комедияләр яратам. Бик шат сезнең белән танышуыма.

Ниһаять, Равил үзенең төп соравын бирергә җай табып:

– Бу тәңкәне сезгә кем бирде? – диде.

– Мин ел саен Сочига барып ял итәм, анда дусларым күп. Туксанынчы елларда ук бергә эшли башлаган дус хатын шунда күчте, ялга баргач, гел шуларда яшим. Ул мине шул тарафларда дан казанган бер күрәзәче белән таныштырды. Хәзер, барган саен, шул күрәзәчегә кереп чыгам. Күрәзәче – чегән хатыны...

– Лаура исемлеме әллә? – дип сорады Равил, җилкенеп.

– Әйе, Лаура. Сез аның белән күптән таныш дип беләм.

– 1977 елда танышкан идек.

– Ул искиткеч кеше, беренче очрашуда ук ул минем узган гомеремне сөйләде, тормышымда ниләр күргәнемне әйтеп бирде, хәтта 38 яшемдә аягымны сындырганымны да әйтте, киләчәгемнең нинди буласын фаразлады. Искитмәле күрәзәче! Китәр алдыннан: «Казанда театрга йөрисеңме?» – дип кызыксынды. «Актер Равил Шәмсиевне беләсеңме?» – дип тә сорады. «Ничек инде белмәскә, ул бит танылган актёр, халык артисты, соңгы вакытта театрга сирәк барсам да, мин Равил Шәмсиевне беләм», – дидем. «Казанга кайткач, зинһар, менә бу тәңкәне аңа тапшыр», – дип үтенде. Аны сезгә бирергә сеңлем алынды, үземнең командировкага китәсем бар иде.

– Рәхмәт! Минем өчен бик истәлекле әйбер ул, – диде Равил.

Акыллы хатын буларак, Венера, актёрның кыяфәте кинәт үзгәргәнне күреп, артык сораулар бирмәде, Равилнең сөйләгәнен тыңлыйсы килде аның. Ә Равил Лаура турында гына сораштыра башлады:

– Лаура ничек анда? Тормышы, хәлләре әйбәтме?

– Болай ярыйсы шикелле. Сочи янында затлы йортта яши.

– Ире, балалары?..

– Күп тапкыр очрашырга туры килсә дә, аның гаилә хәлләре белән кызыксынганым булмады. Һәрхәлдә үзе генә түгел ул, анда шактый кеше яши, балалар да, олылар да бар.

– Миңа сезнең аша берәр сүз әйтмәдеме?

– Юк, сезгә атап сүзләр әйтмәде.

– Кыяфәте... Болай төскә-биткә нинди икән ул хәзер?

Венера авыр сулап куйды.

– Хәлләре әйбәт түгел бугай аның, Равил әфәнде, авырый, ахрысы, – диде Венера, сыктанып. – Нәрсә булды, нинди чир дип төпченеп тормадым инде. Шуны гына әйтә алам: киштәсендә йөрәк авыруыннан төрле дарулар күрдем. Соңгы тапкыр күрешүебездә ул бик нык ябыккан, йөзеннән төс качкан иде.

**38**

Кабан күле Казан шау-шуына илтифатсыз, ул үзенең эчке тынлыгын саклый белә. Сентябрь сагышы су өстендә тавыш-тынсыз җәйрәп ята. Әллә ничә мең, миллион тапкыр шулай ел фасыллары алмашыныр, башка кешеләр өчен, инде безнең өчен түгел. Киләчәктә дә монда уйга калып күпләр утырыр, әмма беркем Кабан күле серен ача алмаячак. Сере бар микән соң аның? Бар, нишләп булмасын, кеше аны үзе серле итә, серле дип саный икән, димәк, аның сере бар.

Равил күл ярының калкурак урынына барып утырды.

Ник җибәрде икән Лаура тәңкәне? Нәрсәне аңлата икән бу?

Абыйсының дорфалыгы өчен гаеп тоеп, бүләкне кире алырга ярамый дип, кире биргәнме?.. Әллә Лаура олыгайган көнендә печән чүмәләсендә кунган төнне сагынамы? Равилне дә сагынадыр бәлки...

Туктале, ахмак мин, Венерада Лаураның телефон номеры бардыр бит, нишләп сорамадым, нишләп Венера үзе дә тәкъдим итмәде? Әллә телефон номерын сорамавым да ниндидер билгеме?.. Тагын хорафатка ышана башладым бугай...

Хорафатчанлык кешене беркайчан ташламый, беркая китми ул. Барыр юлын табалмаган кеше генә хорафатчан була, дигән сүз белән Равил килешми. Кешегә курку хас, һәркем нәрсәдәндер, кемнәрдәндер курка, курыкканга күрә хорафатчан буладыр кеше. Равил тәңкәне бер учыннан икенчесенә салып уйлап куйды: «Әллә тагын берәр куркыныч вакыйга булырга торамы?» Серле, тылсымлы тәңкәдер бу, чынлап та. Юкса, кеше ышанмаслык юл белән тагын минем уч төбемә килеп кермәс иде ул».

Тән буйлап шом дулкыны йөгереп үтте. Нишләп күңел болай җилкенә?..

Бу әйбер бәлки кешесенә карап кына бәхет китерәдер. Равил үзенең унҗиде яшьлек чагын исенә төшерде, күз алдына Лаура килеп басты. Хәтер үсмер чакка алып китте: караңгы көннәре дә, якты мизгелләре дә булды тормышның, әмма унҗидедә чегән кызы белән печән чүмәләсендә кунган төнне берсе дә алыштырмас. Үз гомерендә Равилнең берсеннән-берсе тәмлерәк ризыклар ашаганы бар, әмма моннан егерме сигез ел элек чүмәлә төбендә утырып ашаган ипи белән сөттән дә тәмлерәк ризыкның булганы юк.

Мин кайчандыр бу тәңкәнең тылсымына, гайре табигый көченә ышандым,

ул миңа уңыш китерер, бәхетле итәр дип сабыйларча өметләндем. Әкияти могҗизалы төннән соң булган вакыйгалар аның сихрилегенә инандырды.

Серле төн... Серле чегән кызы... Серле тәңкә... Тиз арада Чистайдагы серле очрашу... Театр училищесына керү дә серле бер вакыйга сыман тоелган иде. Армиядә җиңел хезмәткә эләгү дә тикмәгә түгел, моның нindидер сере бардыр дип уйлаган иде ул. Армиядән кайткач, укуны дәвам итү, театрга эшкә керү – монысы да аның тәңкә серенә бәйле дип ышанды бит ул, киләчәкнең сере дә шушы тәңкәгә бәйле булачак дип уйлаган иде. Сабый акылы кешедән тиз генә китәргә ашыкмый шул. 1986 елда бер-бер артлы күңелсез вакыйгалар булды – өйләнеп аерылышу, баланы югалту. Лаура белән Казанда очрашкач, шомлы, кара көннәр башланды, аннары тәңкәдән мәхрүм калды...

Туктале, менә тагын, күп еллар узгач, тәңкә тагын аның кулында. Нәрсәне аңлата бу? Моның нindидер хикмәте бардыр бит? Әйе, ул аны телевизордан күреп алды, шуннан соң эзли башлады. Очраклы килеп чыктымы? Очраклылыкмы бу? Теге татлы төн дә очраклы хәл иде түгелме? Аны тагын тылсымлы дип саный башларга микәнни инде? Ә бит синең үзеңнән тора барысы да, син үзең хәл итәргә тиеш нишләргә, нинди адым ясарга икәнне. Сер – синең үзеңдә.

Вакыйгаларга, синең хис-кичерешләреңә һәрвакыт нindидер әйберләр, хатлар, символлар, фотосурәтләр һәм синең гадәтләрең бәйле була. Әмма алар кыйммәт түгел, синең җаныңны җылытып, хәтереңдә сакланганы зур бәягә ия. Бу тәңкәнең үсмер чактагы мәхәббәткә ни катнашы бар? 1986 елда чак кына төрмәгә утырмый калганда, бу тәңкәнең роле нидән гыйбарәт иде соң?

Үсмер чакта кабынган ут һаман сүнмәде, аның җылысы гомер азагына кадәр мәңге сакланачак. Равилнең хәзер искиткеч матур гаиләсе бар, шул ук вакытта күңеленең беркайчан салкын җилләр үтеп кермәслек бер почмагында үсмер чактагы айлы төн дә бар.

Әйе, Равилнең җан атуына Лаура ялкынлы хисләр белән җавап бирмәде шикелле... Мәхәббәткә һәрвакыт яраткан кешеңнән тәңгәл җавап, тулы бирем эстәү, табыш-казаныш алу теләге салынган була. Монда беркем, бернәрсә ярдәм итә алмый. Мәхәббәт – үткәннәрне, киләчәкне санга сукмый торган хис, мәхәббәттә гаделлек тә була алмый, аның һәр чагылышында яратучы кешене түбәнсетергә тырышу сизелә. Бәлки, җансыз нәрсәләргә артык күп игътибар биргәнгә шулайдыр?..

Кайчан да булса төзәтеп, тәүбә итеп булыр, гафу итәрләр, кичерерләр дип ышанып, гөнаһлар кылабыз, аннары тәүбә итәбез, урлыйбыз, үтерәбез, аннары ярлыкау сорыйбыз. Без һәрвакыт җимерәбез, аннары яңадан төзеп, торгызып куябыз. Без могҗизалар көтәбез, ә үзебез шул ук вакытта могҗизалар өмет иткән җаныбызны җәрәхәтлибез. Без әллә нәрсәләргә табынабыз, экстрасенсларга, төрле билгеләргә ышанабыз...

Кеше үз-үзенә ышанычын югалтты, ахрысы. Бәлки,үзен яхшы белгәнгә күрә кеше үзенә ышанмыйдыр?.. Кеше билгесез нәрсәгә ышанырга омтыла, аңлата алмаган төшенчәне серле дип кабул итәргә тырыша.

Равил, иксез-чиксез уйларыннан арынып, Венерага шалтыратты һәм Лауранын телефон номерын сорап алды.

Унбер саннан торган телефон номеры менә хәзер үк Лаура белән

тоташтыра ала. Озак кына уйланып торганнан соң, Равил кесә телефонында шул номерны җыйды.

– Алло! Хәерле көн! Исәнмесез. Минем исемем Рауль... Казаннан. Лаура, синме?

– Юк, бу Лаура түгел, – дип җавап бирде аңа хатын-кыз тавышы.

– Бу аның телефон номеры диделәр. Минем Лаура белән сөйләшәсем килгән иде.

– Лаура вафат, узган атнада җирләдек, – дигән биш сүз ерак чакрымнарны узып, Равилнең колагына үтеп керде.

Бер мәлгә дөнья тынып калды.

Равил, Кабан күленә карап, башка вакытта күренмәгән төсмерләрне абайлады, моңарчы беркайчан колагына чалынмаган моңлы көй ишетте.

Лаура бу дөньядан китте. Әмма бергә булган якты айлы төн беркая да китмәде. Ярата алу, сөя белү югалмады. Мәхәббәт аның белән, сөю сәләте аны беркайчан ташламас. Кешедә ул сәләт йә була, йә юк. Аның бәһасез байлыгы бар – хатыны, балалары.

Үзәктә балкып торган мәхәббәт ялкыны сүнмәсен, мәхәббәт хисе саекмасын, аның әле күп еллар үзенең хатынын, балаларын, оныкларын яратасы бар, якын кешеләре белән бергә яшәргә язган киләчәкне «сагыну» бар.

Бу минутларда уйлар бер юнәлештә бармады, алар үзара бәйле түгел, хәтта бер-берсенә комачаулыйлар иде.

Ибраһим хан белән Нурсолтан ханбикәнең кызы Гәүһәршад, фетнә күтәрүдә гаепләнгәннән соң, дәүләт эшләреннән азат ителгән, ә инде руслар Казанны алгач, Кабан күленә сикергән дигән риваять бар. Лаура сөйләгән буенча бу тәңкәне Гәүһәршад үзенеке итәргә теләгән. Дракула суктырган бу тәңкә, Кырым җирләрендә булып, Казанга килеп, аннан тагын дөнья гизеп, Равилнең тормышында да катнашырга өлгерде.

Боларның күбесен кешеләр уйлап чыгарган. Кеше шулай бит ул – үзе уйлап чыгара да үзе шуңа ышана.

Равил, кайчандыр тылсымлы дип саналган тәңкәгә карап, үзалдына: «Беркемнеке дә түгел бу әйбер, – дип куйды. – Тылсымы да юк аның... Кемне саклаган ул?.. Кемгә бәхет китерергә мөмкин мондый әйберләргә ышану?!»

Равил, үзе дә сизмәстән, бар көченә кизәнеп, тәңкәне күлгә ыргытты. Кайчандыр Дракула акчасы булган, Гозело нәселен коткарган, Миреланы саклаган һәм, гасырлар узганнан соң, Лаура бүләк иткән тәңкә су төбенә төшеп китте.

Имеш, укымышлы, гыйлемле ханикә Гәүһәршад өстәвенә сихерчелек, күрәзәчелек сәләтләренә дә ия булган. Кабан күленә ташланыр алдыннан ул дошманнарыннан мәңге үч алып торырга ант иткән, имеш. Кемнән, ничек үч ала икән ул хәзер?..

Бу әкиятне Равил беркайчан үзенең оныкларына сөйләмәячәк.

Унҗиде яшендәге айлы төнне дә сер итеп саклаячак.



Равил
Рахмани

# КАБЫНЫРГА ҖИТӘ СЫҢАР ЧАТКЫ...

## Хәтер

I

Яр буйлары куак кына –
Оя-оя чатыр...
Дала иңләп илгә кайта
Шәҗәрәле Хәтер.

Сары-кызгылт яфраклары –
Безгә дигән хаттыр;
Һәрберсе – йөрәк...
                    җөйләрен
Ятлап укыр чактыр.

Тиздән барысы сибелешеп,
Җиргә төшеп ятар...
Җыерчыклы тарих сере –
Җәрәхәтле Хәтер.

Өсләренә яңгыр явар,
Кырау, чык чылатыр;
Фани дөнья гамьсезлеге
Сагыш-моң кузгатыр.

Тынып калыр аннан җиһан,
Кабат ак кар балкыр...
Язылмаган ап-ак кәгазь
Кемгә нәрсә әйтер?!

...Сулар акмый тормас җирдә,
Кайтыр язлар, кайтыр;
Бозны тишеп чыгар сабак,
Тамырларда – Хәтер!

---

Равил РАХМАНИ (1949) *– әдәбият галиме, тәнкыйтьче, шагыйрь; «Шигъри бишек», «Канатлы дөнья», «Мең чакрымга мең чакрым» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

II

Кардәш булып килеп таптың эзләп,
Йөрәгемә утлар аттың төзәп:
– Биш гасырга авыш кыйблаң төзәт!..
Бу кадәр дә ник син үҗәт, Хәтер?

Нәселең-тамырың, кылган эшең саный,
Күрше карттай кырыс – таяк яный;
Алга чыга йөгереп, арттан калмый, –
Яшең мең ел... холкың – сабый, Хәтер!

Өзеп бәгъреұ, сызлап тора эчтә,
Телә җанны иртәсен дә, кич тә...
Юк, калдырмый урын башка хискә –
Уйдан үткен, моңнан нечкә Хәтер!

Эзәрлекләп, күпме куып барыр...
Ничәвебез туктап, уйга калыр...
Уй төбендә, белмим, нәрсә табар?..
Үз-үзеңнән ник син авыр, Хәтер?!

Кабынырга җитә сыңар чаткы –
Балачактан картлыгыңа чаклы
Чолгый тәнне уты катлы-катлы...
Газабың да – татлы ялкын, Хәтер!

III

Югалтудан вакыт, диләр, дәва –
Фаҗигадән ерагая ара...
Буын арты буын ятып кала,
Хәтер үлми – Хәтер алдан чаба!

Карында ук сине килеп таба:
Нәсел өне күчә җаннан җанга...
Дәһшәт эзе төшә каннан-канга...
Юк, төзәлми... тирәнәя яра.

Барган саен, алда еллар кара,
Асыл затлар поскан кайсы кая...
Йорт-Ватансыз үткән гомер зая –
Җәрәхәттән, сыкрап, Өмет тама.

## Кылганнар турында җыр

«Таңда сәфәр чыгабыз!..» – дип,
Сөйләшепме куйганнар? –
Саба җиле исәр-исмәс...
Сәламләшә кылганнар!

Кая болай ашыгалар,
Хәтәр хәлме тойганнар? –
Бер-берсенең юлын бүлеп,
Йөгерешә кылганнар...
Туган җирдән куганнармы,
Тамырданмы корганнар?!
Ярдан чыккан дәрья булып
Дулкынлана кылганнар...

Дөнья буйлап сибелгәннәр...
Иленнәнме туйганнар?

Гасыр арты гасыр кичеп,
Нәрсә эзли кылганнар?!
Җайдак аттай үргә чаба

Һуннар, кыпчак, болгарлар...
Кырыс тарих түрләрендә
Үлмәс яугир булганнар!
...Инде сүзсез, аксакалдай,
Уйларына чумганнар:
«Кемнәр идек?.. Кем булдык!..» – дип,
Башын чайкый кылганнар.

Эссе сугып, бозда туңып,
Инде мең сыналганнар...
Язмыш җиле җиргә еккан:
Сыгылган – сынмаганнар!

Бигрәк нечкә бәгырьлеләр,
Җаннары – чук кыллардан:
Җиһан сулап куйганга да
Дертләп китә торганнар.
Дәртле, тере дә җырлары...
Тора тоташ моңнардан;
Дала буйлап ятып үкси
Күңелләре тулганнар!..

Җилдә дөрләп янган утка
Әверелә курганнар...
Чыгып заман мәйданына,
Ирек даулый кылганнар!
Уйный – кача,
елый…
шаша,
Бәргәләнә – кол алар...
Көнгә чыкса, мең хәләттә –
Хәтер җебен җуйганнар.
...Килер көнгә күчеп бара, –
Кулын болгый кылганнар;
Киң Рәсәйгә сыймаганнар,
Тәкъдиргә сыенганнар!

## Иделләр кичкән идек...

Без Иделләр кичкән идек,
Ишкәкләр ишкән идек;
Дулкын-дулкын дәрьяларга
Серләрне чишкән идек.
Мәңге бергә булырбыз дип,
Вәгъдәләр эчкән идек;
Язмыш бавын катлам-катлам
Ныгытып ишкән идек...

Ага Идел таудан-тауга,
Тукталмый таңнан-таңга;
Кага тормыш ярдан-ярга, –
Дәрьядай сагыш җанда...
Идел иңләп ага икән,
Хәсрәтен кага икән...
Гомерең буйлап йөзсәң генә,
Ярың тиң сана икән!

## Сөю хакы

Биздереп дөнья гаменнән,
Үзеңне тик уйлатасың;
Чыккысыз сагыш сазына
Керттең гомерем куласасын...
Үзең киттең, алып киттең
Ихтыярым ике кулдан;
Үткәннәрем хатирәсе
Йөртә хәзер мине юлда.

Инде барысы хәл ителгән:
Мең кичереп, мең янган;
Киләчәккә алыр нәрсә –
Күкрәк тулы моң калган...
Сине бәхетле итәргә
Ниләр биреп җиткермәдем...
Төннәремдә җил тәрәздән
Җан даулар дип ник белмәдем?

Иңнән сөйри көннәр, еллар...
Әвәләнәм төн буена;
Күчеп йөрим – атсыз җайдак,
Бер урыннан бер урынга.
Төпсез төннәр чоңгылыннан
Чыгасың да сүз катасың...
Төшләр азмы – аягүрә,
Уяу килеш сызлатасың?..

Адәм тәне чи иттән лә...
Тиз янып сызып беталмый;
Бәргәләнә җан – ирекккә
Күбәләк булып күчалмый:
Кичтән төртеп аударасың,
Таңнан сөйрәп кузгатасың;
Янмый калган көнең... дипме –
Сүнмәс утта аунатасың?!.

## Казан, Мәскәү вакыты

«Бер үк» диләр... Һай, бер түгел –
Казан, Мәскәү вакыты[1]:
Берсендә эш кайный күптән,
Берсе ауный... таң көтеп.
«Бер» диләр дә... Берме икән
Казан, Мәскәү үлчәме?
Бездәге өч – бер түшәме,
Бездәге биш – түшәге?!
Кемнәр «бер» ди... Бик бер түгел –
Шактый төрле холыклар:
Берсе әйбәт кукиш тоткан,
Берсе начар йодрыклар...
«Бер» диләрме... бер ди сиңа
Аларның табигате;
Бар дөньяны яулап алу –
Баскынчак хөррияте.
Гөнаһ кылу ни боларга...
Һәрбер почмак Аллалы;
«Үкенәм...» дип коры чыгу
Мөселманга кайда әле?!
Ник «бер» диләр – бик тә төрле
Шәригате, гадәте...
Коллыкка җырлый мәдхия
Салдафун шигърияте.
Бер түгел шул вакытлары,
Фикер йөртү – Милади;
Бабай яшен кушып саный:
«Мин ул – абый!» – ди, яный...
Баш өстендә әйләндереп
Сәгать угы – күсәкне,
Ул безләргә ничә гасыр
«Хак тарих!» дип күрсәтте:
Кемнең язмыш кызулады,
Кемнең бәхет соңлады...
Чиркәү раслаган вакытны
Ходай хәрәм санады.
Яңа тарих тиз сынады:
Мәкерне һәм сәләтне...
Телгә килде һич кичекми
Гадел Һиҗри сәгате!
«Бер үк», имеш... ник бер булсын
Мәскәү, Казан вакыты?! –
Берсендә әле шайтан таңы,
Берсендә – ай калыкты!

## Мәскәү – алыпсатарлар шәһәре

*Базарда... бар да бар,*
*Әти башы белән әни башы гына юк...*
Халык мәкале

Кулдан килгән һәркем сату итә,
Калганнары – сатып алучы;
Базар – илнең арба-тәгәрмәче,
Тормыш йөген тартып баручы!

Бар да сата...
хикмәт – кем нәрсәсен:
Малын, тәнен, җанын, оятын...
Хәрбиләре яшерен корал сата,
Сәясәтче – илне, әдип – талантын...

Тулып, бушап... кайнап торган базар –
Көннең кырыс яшәү көрәше;
Кемгә – табыш, бәйрәм,
Кемгә – җан асрау,
Кемгә – кәмит,
Кемгә – күз яше...

Мәскәү куйган монда йөз милләтне,
Сату итә... Тел дә әйләнми...

[1] Казан белән Мәскәү арасындагы астрономик вакыт аерымлыгы – 45 минут (автор иск.).

Миллион татар бүген үзен сата...
Әти-әни башын – җәлләми!

Телен сата, илен-җирен сата,
Бабаларын, үткән шөһрәтен...
Елый алмый сүзсез басып торам –
Бигрәк арзан булган милләтем!

## Сөюемне саклап киләм!

Синсез узган сәгатьләрем
Авыр йөк кебек баса.
Бөгелә-сыгыла атлап чыгам
Йокысыз төннәр аша.

Сине күргән минутларым
Якты бер төш ләбаса;
Җилпенеп мин очып үтәм
Атналар, еллар аша.

Барча уйларымның очы
Сиңа барып тоташа.
Бутап көн-төн, яз-көзләрне,
Йөгерәм җәй, кыш аша...

Бата-чума, бәрелә-сугыла,
Язмыштан кача-кача,
Сөюемне саклап киләм
Ярты гомерем аша!

## Кемдер...

Туган телдә сөйләшалмый,
Әрнеп үтте гомер...
Тир түгеп тапкан ашыма –
Ач таракан кемдер!

Хак сүзеңне яз хаталап –
Бар дөньядан көлдер...
Сәрхуш имлясын законлап,
Уяу саклый кемдер!

Сүк үз бабаң, тарихына
Чабаталар кидер –
Тумышыннан күн читектән,
Күн иярдә кемдер?!

Илдә кеше булуың раслап,
Телдән калып йөгер...
Барлыгыңа шик белдерә,
Чырай сыта кемдер!

Үз җиреңдә ятим тоеп,
Эчтән жаның кимер...
Көн дә бәгъреңне бораулап,
Күзәтә күк кемдер.

Балаң белән ике телдә –
Аңлашалмый тилмер!
Бик якынаеп китмәгез дип,
Чабу тарта кемдер...

«Бисмилла» дип эш башласаң,
«Мать» дип күршең бүләр...
Тигез җирдә түмгәк сыман
Аяк чала кемдер...

Өмет булып җиргә кил дә
Һәр көн шуны җимер...
Кол инде сез мәңгегә дип,
Киң елмая кемдер.

Телевизор, радиосы
Көн-төн гөлдер-гөлдер...
Илең түгел, үз өеңдә
Күптән хуҗа кемдер!

Яшәлмәде теләгәнчә,
Зая үтте гомер!
Һәрчак дуслык табынында
Баш тамада кемдер...



Ләбиб
Лерон

# КЫРШАУ

## (Мин дөньяны шулай күрәм)

БӘЯН

*Килер бер көн,*
*Алда, киләчәктә*
*Кичелер бу котсыз, кадерсез төн...*
........................................................
*Күк капусым ачылып киткән иде,*
*Теләкләрем әйтеп өлгермәдем...*
Бакый Урманче

### Пролог

1991 елның 19 августында, ягъни дүшәмбе көнне, СССР дигән илнең югары җитәкчелеге тарафыннан фетнә кубып, тиз арада Мәскәүдә Гадәттән тыш хәл буенча дәүләт комитеты (ГКЧП) оештырылган һәм хәл-вакыйгалар коточкыч тизлектә куерган бер вакытта, Ташкирмән авылында да ике зур яңалык булып алды. Беренче яңалык шул иде: шушы авыл тумасы, туксан яшьлек Мөслимә әби аяк өсте йөргән җиреннән кинәт кенә өзелде дә куйды, яңалыкның икенчесе: әби үлгән көнне авылда ду китереп алтын хәзинә эзләделәр.

### Картина, айсыз мәчет яки Тәрәзә төбендә сукыр лампа

– Әнекәем!

Күргәзмәгә килгәннәрнең барчасы да диярлек, капылт борылып, тавыш иясенә карады. Башындагы кечкенә калфакны һәм аягындагы читекләрне санамаганда, бигүк татарча киенмәгән, яше утыз биш тирәсендә булган туташ-ханым:

– Каян беләм соң моны?! Монда сурәтләнгәннәр бик таныш. Һични аңламыйм! – дип, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, экскурсоводка карашын юнәлтте:

---

Ләбиб ЛЕРОН (1961) – *шагыйрь, прозаик, драматург; Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Сине генә сөям», «Сөяксез тел», «Бәхеткә биш минут кала» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

– Гафу итегез, Клара Камиловна... Сезгә сорау бирергә мөмкинме?

– Мөмкин, әлбәттә!

– Бу картинаның күргәзмәләргә моңарчы куелганы бар идеме?

– Юк, юк! – диде экскурсовод.

– Бәлки бүтән шәһәрдә күргәнмендер?!

– Моның булуы һич мөмкин түгел! Картина беренче тапкыр кичә шушы күргәзмәгә куелды.

Калфаклы туташ-ханым бүтән соравым юк дигән кебек ике кулын ике якка җәйде. Клара Камиловна исә үзенә төбәлгәннәргә күз йөртеп чыкты да картинага таба борылып:

– Биредә узган гасырның җитмешенче-сиксәненче елларындагы авыл урамы сурәтләнгән. Күпчелеге – дүртпочмаклы, әмма араларында алтыпочмаклылары да булган агач өйләр, шул елларга гына хас гади-гадәти эскәмияләр, электр чыбыклары тарттырылган агач баганалар, сугышта аякларын өздереп кайткан инвалидларга гына бирелә торган ике урынлы мотоколяска... Сул өлештәге, арткы пландагы менә бу мәчеткә игътибар итегез әле. Күрәсезме, манара очында ай юк. Мәчет бик күп еллар айсыз торганны аңлата бу. Бәлки ул айны, каһәрле утызынчы елларда ук алып ташлап, юк иткәннәрдер? Шулай булуы бик мөмкин. Ай юк, мәчет бар. Хәтта манара да бар. Мәчетнең манаралы булуы нәрсәгә ишарә? Авылның зурлыгына, аның борынгылыгына ишарәли. Авылда куркусыз, кыю кешеләр яши дип әйтер идем, хәтта усал холыклы, чамадан тыш батыр йөрәкле, чын мәгънәсендә булдыклы кешеләр көн күрә монда дияргә була. Алар айны замана зәхмәтеннән саклый алмасалар да, мәчетне дә, манарасын да саклап кала алганнар. Мәчеткә тиздән ай куелачагына да өмет бар. Манараның киселмәвеннән чыгып, караңгы, шомлы еллардан алып шушы көнгәчә мәчет үз вазифасын башкарган дип, һич икеләнмичә әйтергә мөмкин.

Кызыксынып тыңлыйлармы дигәндәй экскурсовод ханым үзе тирәсенә өелешкән кешеләргә янә бер мәртәбә күз йөгертеп алды. Аннары, баягы туташ-ханымны күз уңында тотарга тырышып, сүзен янә дәвам итте:

– Зәңгәр рәшәткәле койма буенда – менә бу йорт янындагы эскәмиядә утырган әбигә һәм аның янәшәсендәге ап-ак песигә игътибар итегез әле, дуслар! Әбинең өстендә – бәбитәкле ак күлмәк, башында – әбиләрчә бәйләнгән ак яулык, көмеш беләзекле кулында – хөрмә төшеннән ясалган дисбе, аягында – кызыл эчле кәлүш. Әби мәчесен иркәли, аның йоннарын сыйпый. Инде хәзер эскәмиягә карагыз! Күрәсезме, ул киселгән агач төбенә һәм бүкәнгә беркетелгән. Рәссам нигә шулай ясагандыр, әйтә алмыйм. Үзеннән сорыйсы булыр. Йорттагы ике тәрәзәгә дикъкатебезне юнәлтәбез. Икесендә дә – яран гөлләре. Берсендә сукыр лампа да бар. Сукыр лампа нигә? Ут көтмәгәндә сүнгән очракта, әлеге кәрәчинле сукыр лампаны кабызганнар. Хәзер картинаның уң як өлешенә карыйбыз һәм анда бер яшь ананың җиде-сигез яшьләрдәге кызын җитәкләп килгәнен күрәбез. Кыз нидәндер курыкканга охшый – ул, ике учы белән авызын каплап, әнисенә елыша төшкән...

Ошбу урында, экскурсоводның сүзен бүлеп, ир-ат затыннан булган бер җирән бөдрә чәчле иптәш сүз катасы итте:

– Алгы өлештә сурәтләнгән малайны күргәч, балачак искә төште. Без дә кыршау тәгәрәтеп уйный идек...

Экскурсовод ханым аңа карап елмайды да, күзен сирпеп кенә, хуплавын белдереп алды. Аннары янә картинага таба борыла төште:

– Әйе, сез картинаның алгы һәм урта бер җирендә кыска җиңле, шакмаклы күлмәк кигән малай рәсемен күрәсез. Рәссам аның кыршау тәгәрәтеп килгән чагын сурәтләгән. Бер детальгә игътибар итегез: малай башына газетадан ясалган башлык кигән. Башлыктан «стан» дигән язуны укырга була. Шушы язудан чыгып, малайның кәгазь башлыгы «Социалистик Татарстан» дигән газетадан ясалган дип фараз кыла алабыз. Кемнәр белми – әйтәм, кемнәр белә, аларның исенә төшерәм: СССР заманында кайбер татарча журналлар һәм газеталар миллион данәдә бастырылып таратыла иде. Картинаны рәссам тикмәгә генә «Хәвеф алдыннан» дип атамагандыр, күрәсең...

Шактый өлкән яшьтәге, кысык күзле бер мөлаем ханым, алтын кысалы күзлегенең пыяласын яшькелт чүпрәк белән сөртә-сөртә:

– Сүзегезне бүлдергәнем өчен, зинһар, гафу итегез! Күзләрем күреп бетерми... Кем ясаганын беләсем килә иде. Рәссамы хатын-кызмы, әллә ир-атмы? – дип сорады.

– Кадерле дуслар, үзегезне кызыксындырган сораулар булса, кыенсынып тормагыз, сорагыз, сорагыз... Мин җавап бирергә һәрчак әзермен! – диде экскурсовод. – Ә-ә-ә... инде... әлеге картинаны ясаган рәссамга килгәндә, моның авторы – ир-ат. Юк, ир-егет! Үзем дә бутала башладым бугай... Кайсысы дөрес, дуслар: ир-ат дигәнеме, әллә ир-егетме?

– Ир-ат дисәгез дә ярый, ир-егет дисәгез дә була... Бик карт түгелдер бит? Бик карт булса, бабай диярга кирәк! – дип, кемдер шаяртып аласы итте.

– Икесе дә дөрес!

– Яхшы, алайса. Егет кеше дип әйтәм. Бик талантлы егет! Рәссам – Мөнәвир Максатов. Максатовның шушы күргәзмәдә урын алган «Кәбестә тозлау» һәм «Авыл клубы» дигән картиналары да бик үзенчәлекле. Алар турында сүз бераз соңрак булыр. Онытканчы әйтеп куйыйм әле: ике көннән, ягъни җомга көнне, көндезге сәгать икедә шушы күргәзмә залында рәссам белән очрашу булачак. Теләүчеләр булса, рәхим итегез!

Ак калфаклы ханым картинаның авторы Мөнәвир Максатов икәнен бая ук белгән иде. Экскурсовод ханымның авызыннан кабат ишеткәч, Мөнәвир исеме аңа үтә дә таныш кебек тоелды. Каян, ничек белә ул аны?

Клара Камиловнаның соңгы җөмләсе аны аяктан ега язды:

– Картина шуның белән дә үзенчәлекле, Мөнәвир Максатов – сукыр рәссам!

– Сукыр... рәссам?! Шушындый матур рәсемне... сукыр кеше ясасын әле... Ышанасы килми бер дә... Ышанасы килми...

## Мөслимә әби вафаты, саңгырау карга яки Алмагач төбендә хәзинә ята

Ташкирмән авылындагы хәлләргә килгәндә, алар болайрак булды.

Мөнәвирнең бәхетенә күрәдерме, әллә Аллаһның алдан шулай үзенчә сиздерүе булдымы, әбисе үләргә бер көн кала – төш вакытында, аны Изәил дигән дус-иптәше Казаннан ук үзенең сары «Запорожец»ы белән кайтарып киткән иде.

Мөслиматтәй бер дә үләргә җыенган кеше төсле түгел иде. Ул, оныгы

кайту хөрмәтенә дип, инде атна-ун көн чамасы күкәй салырга иренеп йөргән бердәнбер җирән тавыгын (Мөслимәттәй аны, нигәдер, Ыржая дип йөртә иде – «рыжая»ны үзенчә татарчалап әйтүе булгандыр инде) Түбән Очның Бәләкәй Әхәтеннән суйдыртып, култокмачлы аш пешерде. Табаны каз маенда гына чыжлатып, үзе әйтмешли, «вышшай сурт оннан» коймагын өлгертте. Атнаш чишмәсеннән җилдереп дигәндәй су алып кайтты да, Кукмараның Володин дигән атаклы бае кайчандыр аның әтисе Сафагәрәйгә (Мөнәвирнең ерак бабасы була инде) бүләк итеп биргән өч мөһерле җиз самавырның төтен чыга торган торбасына үзе телемләп телгән каен чыралары салып, аларга икенче бер чыра ярдәмендә ут элдереп, җәһәт кенә су кайнатты. Сакчыл татар карчыгы, үзе белән яшьтәш булган көмеш каймалы бирнә сандыгындагы һичкайчан бетми торган запасыннан күз карасыдай кадерләп саклаган кургаш кәгазьгә төрелгән такта чәен алып, аның бер чеметемен сындырды да «Кытайдан килгән аккош»ка – чәчәк сурәте төшерелгән керәч чәйнеккә салды. Өйгә зәңгәр мәтрүшкә катыш тәмле чәй исе таралды...

Кичтән уттай эссе мунча кереп, юлдагы бөтен аруларын калдырып чыккан Мөнәвирнең, иртән бер дә уянасы килмичә, изрәп йоклаган чагы иде. Ниндидер сәер тавыш аны татлы йокысыннан уяныргa мәҗбүр итте. Ул, урыннан торып, кармалана-кармалана, тавыш килгән тарафка атлады.

Мөнәвир белә-белгәннән бирле әбисе, чаршавын тартып куеп, мич кырыендагы такта сәкедә йоклады. Оныгының янына килеп җиткәнен сизепме, Мөслимәттәй, ап-ачык итеп:

– Балакаем... мин үләм... – диде. – Әнә... Газраил үзе... килгән...

Мөнәвир имәнеп китте. Аны курку хисе биләп алды. Моңарчы үлем-китемне якыннан күргәне юк иде аның.

– Балакаем...

Нишләргә? Хәзер нишләргә соң? Аның кадерле әбисе – Мөнәвирне сабый чактан ук үз канаты астына алып тәрбияләгән, яраткан оныгын чын кеше булсын, тормышта үз урынын тапсын дип үстергән газиз әбекәе үлеп ята. Ә ул... Ә ул, баскан урыныннан кузгала алмыйча, тораташтай басып тора...

Соңгы көннәрдә Мөслимәттәй өендә куна-төнә диярлек яткан күрше карчыгы – Саңгырау Бибисара, Мөнәвир кайтканлыктан, кичә үз өенә чыгып киткән иде. Мөнәвир, шул карчыкны исенә төшереп:

– Әбекәй! Үлмәй тор! Мин Бибисараттәйгә чаптым! – дип, ишек тарафына турылап, бәрелә-сугыла, йорттан чыгып китте.

Ул Бибисара кортканы ияртеп кайтып кергәндә, әбисе ыңгырашу катыш гырлавыннан туктап, сулышын сизелер-сизелмәслек кенә ала иде.

– Балакаем... җакынрак кил...

Мөнәвир әбисе яткан сәкегә терәлеп үк басты да иелә төште. Саңгырау Бибисара да якынгарак тартылды һәм: «Ләә иләһә илләллаһ» – дип тәһлил әйтергә кереште.

Мөслимәттәй исә, соңгы сүзләрен әйтеп калырга ашыккандай, сулышын еш-еш ала башлады:

– Үлгәнче... әйтеп калаем... Әнкәең... хатлары... сандыкта... Ачуланма... балакаем... Аннары... алмагач... төбендә... Сафагәрәй... бабаңның... хәзинәсе... күме... е-е-е...

Мөнәвирнең әбисе соңгы сүзен әйтеп бетерә алмады, күзләрен ачкан килеш дөньядан кичте. Аның мөлаем йөзендә елмаю катып калды.

Бибисара кортка, мохтазар булган күршесенең беләзегеннән кан тамырын капшап, карчыкның чынлап та фани дөньядан аерылганлыгына тәмам инангач, мәрхүмәнең күзләрен йомдырып, янә «Ләә иләһә илләллаһ» дип тәһлил әйтте, аннары «Әшһәдүән ләә иләәһә илла-ллааһү үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһүү үә расүүлүһ» дип шәһадәт сүзен ирештерде...

***

...Мөслимә карчыкны зиратта калдырып кайтуга, авылда әйтерсең лә мәхшәр купты.

Кабер казыган егермеләп ир-ат зираттан туп-туры Мөнәвирләргә юнәлде. Барысының да кулында көрәк иде. Мөнәвирне күздә тотып: «Сукыр кеше берни күрмәс» яки «Сукыр кешегә берни дә кирәкми», – диешә-диешә, күз ачып йомган арада яше-карты бакчадагы һәрбер алмагачның – ә алар җәмгысы алтау иде – төбе-тамырын актарып, тирә-юнен казып чыкты.

Мөнәвир, зираттан кайтышлый ук, авыл советы башлыгы булып йөргән Мөхәммәтша Фәрите белән, аның хан заманыннан калган ак «Волга»сына утырып, күрше авылга киткән иде. Хасталанып яткан якын кардәшен – Мөслимәттәйнең бертуган энесен – гражданнар һәм Икенче бөтендөнья сугышын кичеп тә исән калган Ядкәр бабайны мәрхүмә әбисенең өчесенә чакырырга иде исәбе. Юлда булуы сәбәпле, Мөнәвиргә бу хәлләрнең шаһиты булырга туры килмәде.

«Хәзинә» дип күзе-башы тонган, зиһеннәре таралган ирләр берочтан, хуҗа һәм хуҗабикәләрнең аһ-ваһына карамастан, Мөнәвирләрнең ике яктагы һәм бакча арты күршеләренең дә җиләк-җимеш бакчаларын аркылыга-буйга актарып чыкты.

Ни хикмәт, хәзинә дигәннәре табылмады. Киселгән тырнак хәтле алтын кисәге түгел, хет чүлмәк китеге тапкан булсалар да, ярар иде ичмасам, ул чакта безгә кадәр үк кемнәрдер казып алганнар дип, үзләрен юаткан булырлар иде.

«Гомер буе безне укытты: «Денсез булмагыз, динне ихтирам итегез, бисмилла булса да әйтегез, – дип, еллар буе миләребезгә тукый торган иде. Карчыкның бездән шулай үзенчә көлүе, үлгәч тә безгә сабак бирүе булды инде бу», – дип, мәрхүмә әбигә үпкәләрен белдерделәр.

Аны сүктеләр ни, тетмәсеннәр теттеләр ни – кабергә кереп яткан Мөслимәттәйгә хәзер барыбер иде инде. Саңгырау Бибисара корткага да каты эләкте: «Без, чыннан да, шыр җүләр, ата тинтәк икәнбез бит! Шул биләмчегә, саңгырау карга сүзенә ышанырга кирәк бит, ә! Сиңа гына сер итеп әйтәм дигән булып, барыбызга да әйтеп чыккан икән Биби тәре!» – диештеләр.

Көне буе җир казып, тәмам хәлдән тайган, эчәсе килүдән иреннәре кибешкән, бер-берсенең күзенә карамаска тырышкан ирләр көтүе сүзсез генә өйләренә таралышты...

Ә бу мәхшәрнең сәбәпчесе, чынлап та, Бибисара кортка иде. Мөслимәттәйнең яшьтәше һәм яшьлегендә мәгълүм Октябрь түнтәрелешенә

чаклы Сафагәрәй хәзрәтләрдә асрау булып торган Бибисара бу гаиләнең үз кызына әйләнеп беткән иде.

Хәзрәтнең байлыгы кайдадыр яшерелгән булуына Саңгырау Бибисара гомер буена инанып яшәде.

Бибисараның чынлыкта бер дә саңгырау түгеллеген, киресенчә, бик шәп ишеткәнлеген Мөслимәттәй белмәде түгел, бик яхшы белә иде. Әмма аның соңгы минутта бүтән чарасы калмаган иде шул инде – хәзинә турындагы хәбәрне оныгына элекке асраулары алдында әйтергә мәҗбүр булды...

Хәзинәгә килгәндә исә, ул Мөнәвирләр бакчасындагы казып-актарып ташланган җирдән ун-унбиш адымлап читтә – нәкъ күмелгән урынында – шул килеш ятып калды.

## Әкълимә, җүләрләр хастаханәсе яки Фирдәвес – җәннәт дигән сүз

Кунакханәгә кайтуга, Әкълимә душта коенып чыгарга булды. Бүтән көнне күбрәк тә йөрелгән иде югыйсә, ә бүген нишләптер арытты. Кичә соң яткангадыр бәлкем?! Шулайдыр әле ул, уйласаң. Күптән күрешмәгән төсле алар – дүрт ахирәт ханым – кичә төнге уникегә кадәр ләчтит саттылар. Ләчтит дип... Ләчтит тә түгел инде... Дөньяның төрле почмагыннан килгән, татар милләтеннән булган кыз-хатыннар, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, соңгы берике ел эчендә үз башларыннан кичкәнне хәтерләрендә яңартты – бары шул.

Быел да пайтәхеткә җыелды алар – татар хатын-кызларының «Ак калфак» дигән ассоциациясе чакыруы буенча килделәр. Өченче көн – изге Болгарга, Зөя утравына барган иделәр. Монастырь яныннан узган вакытта эчтән үзәк өзгеч ниндидер тавыш ишетелгән кебек булды. Миңа гына ишетелде бугай дип уйлаган иде Әкълимә, юк икән, башкалар да ишеткән. Ассоциация җитәкчесе Рауза ханым: «1993 елга кадәр бу монастырь бинасында психбольница иде. Монда минем бер танышымның Фирдәвес исемле энесе ятты. Вакыт-вакыт шундый тавышлар ишетелә икән диләр иде. Дөрес икән!» – диде.

Рауза ханымның сүзе бетмәгән булып чыкты:

– Фирдәвес исеме җәннәт, җәннәт бакчасы, оҗмах дигәнне аңлата. Әлеге танышым авыру энесенә багышлап шигырь язган иде. (Ул әлеге танышының шагыйрь Зөлфәт Маликов икәнлеген башкаларга әйтеп тормаска булды). Хәтеремдә калганча сөйләп карыйм әле:

Сөйли идең:
– Бер бәләкәй болыт
Үтте безнең утрау өстеннән.
Язгы шомырт сыман иде лә ул! –
Таныдым мин аны төсеннән...

Адашыпмы йөри бу якларда?
Авылга ул көн дә кайтамы?
Нигәдер бик борчулы ул болыт –
Нәрсә булган аңа, әйт, абый!..

– Мин үзем дә югалган бер болыт.
Ни дип юатыйм соң, и энем? –
Беләм ләкин,
Болыт булып купкач,
Бер яумыйча мөмкин түгелен!

Саркыйбыз без үлән суты булып,
Агылабыз тагын күкләрдә –
Аша күккә яшен куәтләре
Яңа күкрәү булып күкрәргә!

...Менә бүген,
Күккә карый торгач,
Сәер тынлыкка мин юлыктым –
Сүзсез калып, офык аръягына
Озаттым мин якташ болытны.

Рауза ханым, төртелмичә-нитмичә, шигырьне яттан сөйләп чыкты.

Кемдер:

– Бу шигырьне чын шагыйрь язган булырга тиеш! Гади кеше болай язалмый! – диде һәм тавыш килгән якка башы белән ишарәләде. – Ә бу йортта акыллы кешеләр яткандыр кебек тоела миңа...

«Ак калфак»ларның һәммәсенә дә моңсу булып китте. Шактый вакыт бер сүз дәшмичә атладылар...

«Энесе... җүләрләр йортында...»

Кемгә-кемгә, әмма Әкълимәгә әлеге сүзләр ук булып кадалды. Дөньяда беркемнең дә кесәсе буш түгел шул. Кайгы-хәсрәт дигәне бер кешенең дә өен читләтеп үтми, иртәме-соңмы ул барыбер килә. Килә икән ул...

«Энесе... җүләрләр йортында...»

Әлеге сүзләр кичәдән бирле эзәрлекли инде Әкълимәне. Аның да бит энесе башкаладагы җүләрләр йортында ятты. Инде вафат. Ун ел булды үлгәненә. Энесенең көтмәгәндә җүләрләнүен табиблар күп укудан дип аңлаттылар. Күп укый иде шул энесе. Тик... Ай-һай, аннан гына булдымы икән... Нәселләренә төшкән берәр рәнҗеш-каргыш сәбәпче булмадымы икән моңа?!

Дөрес, бүтән фараз да булмады түгел. Үзе укыган уку йортында илкөндәге вазгыятькә нисбәтле тиешле-тиешсез сүзләр ычкындырган икән, дип тә сөйләделәр. Шуннан соң аны, җүләрләр йортына ябып, егеткә акылдан яздырта торган укол кадаганнар, имеш...

Әкълимә кинәт кенә бүгенге көнгә кайтты. Күргәзмәдә булганнарын исенә төшерде. Сукыр рәссамның картинасы күз алдына килде...

Мөнәвир. Әйе, бар иде бит аның тормышында да шундый исем йөрткән кеше. Бар иде. Фамилиясе ничек булды икән аның? Кайда икән ул Мөнәвир хәзер? Нинди һөнәр иясе булды икән? Гаиләсе бармы икән? Балалары? Әкълимә шикелле, бәлки, ул да ялгызы гына яшидер, ялгыш арты ялгыш җибәрә-җибәрә, һаман бердәнберен – гомерлек мәхәббәтен эзлидер?!

## Мөслимә әби, имән мичкә һәм тозлы кәбестә

«Бәхетеңнең дә, бәхетсезлегеңнең дә сәбәпчесе кыршау булыр» – бу сүзләрне аңа кайчандыр әбисе әйткән иде...

Бәхетсезлек килгәнгә инде ике дистәдән артык ел үтте. Ә менә бәхет дигәне һаман күренми – кайларда йөри торгандыр ул?

...Мөнәвиргә алты-җиде яшь булгандыр ул чакта. Язга тартым көннәрнең берсендә, көтмәгәндә салкын тидереп, бик каты авырды ул. Температурасы күтәрелде. Аппетиты бетте. Йокысы качты. Әбисе көннәр буена әле мич алдында, әле авыру оныгы янында кайнашты. Коймагын да, тәбикмәген дә, көлчәсен дә пешерде, балан бәлешен дә өлгертте, мичтә бәрәңгесен дә тәгәрәтте. Мөнәвир исә, аһылдап-уһылдап, әйләнеп-тулганып, пружиналы тимер караватта ята бирде. Фельдшер Гөлсимә апа килеп, тиешле даруынфәләнен калдырып: «Мөслиматтәй, башта бусын, аннары менә монысын каптырырсың, җәме?! Өзлексез су җә кайнар чәй эчеп торсын. Эчмәсә, үзең эчерт, җәме!» – дип әйтеп китте. Мөслиматтәй барысын да фельдшер кушканча эшләргә тырышты. Тик менә Мөнәвир генә терелергә ашыкмады...

Тәбикмәгенә дә, коймагына да, гомумән, алдына куелган бер ризык-тәгамгә

дә орынып карамаган оныгын җәлләп, аны кызганудан ни эшләргә дә белмичә, әрле-бирле килде әби кеше, ике-өч көндә бөтенләй ябыгып, суырылып калган Мөнәвирнең кайнар маңгаена (инде ничәнче мәртәбә!) кулын куеп торды:

– Бер нәмә дә кабасың килмәймени соң, балакаем? Әйт кенә, шуны ашарыем диген, хәзер үк апкайтам! Ләвкәдә булмаса, күрше-күләндә бардыр әле... Аллаһы ташламай ул, бирәм дигән колына – чыгарып куяр җулына...

Моңарчы «юк»тан гайре сүз әйтмәгән малайның кипшенгән иреннәре арасыннан өченчеме, әллә дүртенчеме көнне, ниһаять, берничә сүз сытылып чыкты:

– Тозлы кәбестә... ашыйсым килә...

Әби кеше, кай арада өстенә киеп, кай арада кәлүшләрен эләктереп, күз ачып йомганчы, җил капкадан чыгып йөгерде. Исенә килгәндә, уң як күршеләренең ишеген шакый иде инде ул...

Тиз генә хәл ителер кебек тоелган йомышны үтәү озаккарак сузылды. Чөнки тозлы кәбестә, күрше-күләндә генә түгел, гомумән, авылда бөтенләй юк булып чыкты. Качкын урамындагы Габдерәүф Җәмиләсенә ялгышып-нитеп кермәгән булса, сөмсере тәмам коелып, коры кул белән генә кайтасы кеше иде Мөслимәттәй. Габдерәүф Җәмиләсе, кем әйтмешли, күп балалы ана. Медале генә юк. Алар өендә беркайчан да аш пешеп җитми, диләр. Плиткә өстенә кәстерүл менеп утыруга, аның тирәсендә кашыклар, юк ла, бала-чага өерелешә башлый икән...

Ни хикмәт, тозлы кәбестә нәкъ менә шул Җәмиләдә бар булып чыкты. Беркөнне генә Чаллыданмы, Минзәләдәнме, әллә Пучы базарыннанмы, кемдер алып кайтып биргән булган икән.

Мөнәвир тозлы кәбестәне генә тансыклаган булган диярсең, билләһи газыйм: шул ук көнне ул, аякка басып, чытыр чаба да башлады. Кинәт тернәкләнеп киткән оныгына карап, Мөслимәттәй әйтте:

– Аллаһы бирсә, ничек тә имән мичкә юнәтеп, быел көз үзебез кәбестә тозларбыз! – диде...

Мөслимәттәй, ары чабып, бире чабып, ахыр чиктә әллә кемнәрдән белешеп дигәндәй, ниһаfive, яңа мичкәле булды. Әнә ул якында гына кукыраеп утыра. Артык зур да, артык кечкенә дә түгел – мич арасындагы күәс савыты чаклы. «Күбрәк тозласак, зыяны юк, күрше-күләнгә, йә булмаса, сорап килгәннәргә күчтәнәч итеп бирербез», – диде әбисе.

Әбисенең әйткәне фәрештәләрнең «Амин» дигән чагына туры килде бит, эттәгенәсе. Менә алар, әби белән онык, икәүләп, мунча алдында кәбестә тозлап мәш килә. Мөнәвирнең кулында – кечкенә саплы бәләкәй балта. Ул җәймә өстендәге урындык төбе чаклы тактага кәбестә кисәге куеп, шуны чапкалый. Әбисе үтәр-үтмәс пычак белән кишер кыра, мүк җиләгән, агач кысасы шактый таушалган иләккә салып, яньчелеп беткән әлүмин тастагы суда чайкый...

Мөнәвир вакыт-вакыт мичкәгә карап ала. Гаҗәпләнә: бер-берсенә беркетелгән такталар арасыннан ничек су саркып чыкмый икән дип уйлый. Мичкәне кысып торган бу ике тимер түгәрәк нишләп шуып чыкмый икән ди...

Баядан бирле мичкәгә карап-карап алган оныгының уйларын укыгандай, әбисе акрын гына сөйли башлады:

– Минем апам Фатыйма, сугышка хәтлүк, украин җегетенә кияүгә чыкканые. Сугыштан соң алар Донбасста җәшәде.

Менә шул Донбасста татарлар күпләп-күпләп җәшәй. Хәзер дә шулай микән, әйтә алмаем. Авыр эш кайда, безнең халык шунда бит ул. Татарлар шахтада эшләйдерие ул бакытта...

– Фатыйма апа да күмер чаптымы? – дип сорап куйды Мөнәвир.

– Юк инде, нәмәшләп Фатыйма апаң күмер чапсын! Хатын-кыз башкара торган эш түгел бит ул. Күмер чабу – галәмәт авыр хезмәт, балакаем. Авыр эш булганга, пинсәгә дә бик җәшләй чыгалар икән күмер чабучылар. Анда, шахтада, атлар да эшләй икән. Атлар, җаныкайларым, шахтадан тома сукыр булып чыгалар, ди! Җактыга чыгуга, шундук күзләре сукырая икән атларның. Шуңа күрә аларны җир өстенә бик чыгармаска тырышалар, ди. Үлгәнче эшләтәләр дә эшләтәләр икән. Озын-озак караңгыда җәшәгән кеше дә җактыга акрынлап ияләшергә тиеш, жугыйсә, ул да сукыраячак...

– Атлар кызганыч! – дип әйтеп куйды Мөнәвир.

– Атлар да, кешеләр дә жәлке, – дип, оныгын куәтләде әбисе. – Нәмәшләмәк кирәк, балакаем, җәшәргә кирәк бит. Беркемгә дә акчаны да, ризыкны да тиктомалдан китереп бирмәйләр. Эшләргә кирәк! Авыр эшме, җиңелме ул – барыбер эшләргә кирәк. Тормыш итәргә акчасы булмаганга, кешеләр туган җирләрен калдырып, бәхет эзләп, чит җирләргә чыгып китәргә мәҗбүр булган. Менә хәзер без бәхетле илдә җәшәйбез. «Нинди иркен минем туган илем», – дип җырлайбыз. Илебез тыныч, тамагыбыз тук, өстебез бөтен. Рәхәтләнеп җәшә дә җәшә... Сугышлар гына булмасын берүк! Илгә бәла-казалар килмәсен инде... Сугыш булмас, Аллаһы бирса, безнең патшалар да, гиниралнай сиркиритарлар да гомер-гомергә сугышка каршы булды...

Мичкәгә карале, балакаем. Карап торышка гап-гади мичкә бит инде, иеме?!

Бер җылны Фатыйма апалар безгә кунакка кайтты. Хәтерем җалгышмаса, Ысталин үлгән җыл ые. Илле өченче җыл була инде бу. Донбасска кире киткәндә, апа белән хахул җизни мине дә үзләре белән алды. Харкувны да күрсәттеләр, бер килгәч, әйдә, башкалабызны да күреп кит дип, хахул кияү Киеф каласына ук алып барды. Киефне борын-борын заманда Кияү-кала дип җөрткәннәр икән. Монысын шунда очраган бер татар әйткәние. Исемдә калдырганмын бит менә. Хахул кияүнең туган авылында да булдык. Анда бездәге шикелле авыл дип җөртмәйләр, хутыр дип әйтәләр. Менә шул хутырда булган чакта, үзләре пагриб дип йөрткән базларын күрсәттеләр. Ул пагрибтагы мичкәләрнең чуты-саны юк! Хахул кияүнең хахул атасы шул мичкәләргә карап, менә мондыйрак бер тарих сүләде. Исемдә калганча сүлим...

Бер хахул, үзе белән балта остасын алып, урманга бара да шул остадан үзе юан, үзе галәмәт озын бер имәнне, кистереп, җиргә аударта. Шул имәнне үзенә кирәгенчә туратып, бүрәнәгә әйләндертә. Аннары шул бүрәнәне жука, тар такта итеп эшкәрттерә. Шуннан соң тар такталарны түгәрәкләп тездертә дә ике кыршау кидерттерә, төп куйдырта. Нәмә килеп чыга инде, балакаем? Әйе, бик матур мичкә барлыкка килә! Ләкин хуҗа кеше, мичкә җасатса да, аны рәтләп карамай, күбрәк буш тота. Көннәрдән бер көнне мичкә кибә, кыршаулар тутыга, такталар тарала башлый. Кыршауларны бала-чагалар урамда тәгәрәтеп уйнай, такталарны хуҗа кеше утка җага. Шулай итеп, кайчандыр искитмәле булган имән мичкә әрәм була. Бу тарихның хикмәте шунда, Мөнәвиркәем: мичкәне туган ил, ватан дип аңларга кирәк. Имән

такталар – эти-әниләр һәм аларның балалары. Кыршаулар – илне бердәм, тату иткән дус-туганлык. Такталар кыршаулы вакытта – мичкә барые. Кыршаусыз калгач – бернәмә дә калмады. Дуслык, хөрмәт булганда – барча халык бердәм. Дуслык какшаса, хөрмәт бетсә, ил кадәрле ил дә таркала... Менә шундый тарих сүләгән иде хахул кода...

Син, балакаем, шуны онытма: бер әйбергә дә, беркемгә дә артык текәлеп, сокланып җәисә гаепләп карарга җарамай. Менә син баягынак мичкәгә бик озаклап карап тордың. Мин моннан шундый нәтиҗә ясадым һәм аны, сиңа авыр булса да, әйтергә булдым: «Гомер буе мичкә эчендә, җәгыни бер кыса эчендә җәшәгән күк гомер итәрсең. Вәләкин шуны бел: бәхетсезлегеңнең дә, бәхетеңнең дә сәбәпчесе менә шушы кыршау булыр!»

Әбисе кулындагы пычагының кисми торган ягы белән имән мичкәнең ике кыршавына да суккалап алды.

Ул чакта әбисе әйткән сүзләрнең мәгънәсен аңламаган иде Мөнәвир. Аны аңлар өчен вакыт кирәк булган икән...

## Әкълимә, Алехандро һәм гуантанамера

Берәүләргә – көн дә бәйрәм, көн дә туй, берәүләргә – көн дә сагыш, көн дә уй. Татар халык мәкале шулай ди. Халык әйтсә, хак әйтә дә соң...

Көн күрке – кояш, күңел күрке – уйлар. «Күңел күрке – уйлар», диләр дә, бер дә алай ук түгел икән...

Соңгы вакытта Әкълимә ялгызы калудан шөлли башлады. Ялгызлык шомландыра бит ул, теләсәң-теләмәсәң дә, уйландыра. Ә уй – ялгыз хатын өчен бер дә әйбәт нәрсә түгел. Башыңны уй басса... Хет юрганыңа төренеп, капланып, томаланып ят – файдасыз! Ялгызлыктан, уйланудан качарга теләп, дус-иптәш булыр, күңелгә тынычлык бирер дип, берчакны мәче дә асрап караган иде дә... Тик... Аның да, мәшәкатьтән гайре файдасы булмады...

Керәсе ризык тешеңне сындырып керер дигән шикелле, уй да, әгәр килер булса, бөтен тынычлыгыңны җимереп килер һәм бөтен барлыгыңны биләп алыр. Бәхетсезлек тә шулай бит: һич көтмәгәндә килә дә төшә. Әгәр бәхетсезлек, афәт дигәннәре бер-бер артлы килсә, кайгы ишелеп төште диләр... Аллаһым сакласын берүк!..

Хәер, бәхетсезлек Әкълимәне дә читләтеп үтмәде, килде аңа да, ничек кенә килде әле – болыт-болыт булып ишелеп төште...

Кайчан башланды соң бу бәхетсезлек галәмәтләре, сәбәбенең башында ни-нәрсә иде? Әкълимә чамалый сыман үзе, ләкин дөрес чамалыймы – әйтә алмый, анысын бер Аллаһ кына белә...

Сиксәненче еллар башында, университетта укыганда, Кубадан һәм Алманиядән килгән студентлар белән бергә бер тулай торакта яшәргә туры килде Әкълимәгә. Шуларның кайберләре, аеруча Куба егетләре белән тиз арада танышып та өлгерде ул.

Луис дигәне – гудрон кебек кап-кара, араларында иң өлкәне, утыз ике яшь икән инде үзенә, башкаларга караганда буйга тәбәнәк, җае чыккан саен Фидель Кастро белән ике тапкыр күрешүен сөйли, иң шат күңеллесе дә шул булмадымы икән әле.

Пабло – метис, бүтәннәрдән бигүк кара булмавы белән аерылып тора,

ул да буй мәсьәләсендә башкалардан шактый кайтыш, күп сөйләшергә яратмый, йөргән кызы бар – үз кавеменнән.

Феликс. Бөдрә чәчле, озын буйлы. Дүңгәләк баш дип йөртә иде аны Әкълимә.

Алехандро. Ул да Луис кебек кап-кара. Аерма шунда: Луис – кәтүк булса, Алехандро – колга, багана.

Лино – Алехандро шикелле үк озын егет, тик башында «дүңгәләге» генә юк – чәчен һәрвакыт кыска итеп тота...

Күрше тавыгы күркә булып күренә шул. Казан марҗалары, алардан да битәр авылдан килгән татар кызлары Азатлык утравыннан килгән әлеге егет-җилән тирәсендә күбәләкләр кебек бөтерелә башлады. Мин кемнән ким әле дигән төсле, Әкълимә дә шуларның берсен – Алехандро дигәнен күз уңыннан ычкындырмаска тырышты һәм көннәрдән беркөнне үз дигәненә ирешеп тә куйды. Елмаюлы комплиментлар, мәгънәле ым-ишарәләр һәм, әлбәттә, көн саен диярлек табадан төшкән өчпочмак-пәрәмәчләр, коймак-тәбикмәкләр, шәңгә-дучмаклар үз эшен эшләде: Алехандро – Әкълимәдән, Әкълимә Алехандродан башка яшәүне күз алдына да китерәлмәс хәлгә килде. Болар икәү үзара әвәрә килгән арада, Луисны – әтисе татар, әнисе марҗа булган Наташа исемле бер сары кәтәнә, Феликсны – Саба кызы Гөлбирә, Линоны Мөслим кызы Фасия эләктереп-каптырып алган иде инде.

Үзләренә яр итеп кара чутырларны сайлаган, кубаларның «Гуантанамера» дигән атаклы җырын тиз арада ятлап өлгергән татар кызлары, тулай торакның «Кызыл почмак» дигән бүлмәсендә узган төрле бәйрәм-сәйрәмнәрдә, халыкларның дуслыкларына нисбәтле кичә-фәләннәрдә, сөйгәннәренә кушылып, тән-гәүдәләрен көй рәвешенә туры китереп селкетә-дерелдәтә җырлый да башлады:

Гуантанамера, гуахира гуантанамера,  
Гуантанамера, гуахира гуантанамера...

«Гуантанамера» сүзе «Гуантанамодан килгән кыз» дигәнне аңлата икән.

Әлеге җыр сүзләре XIX гасырда яшәгән Куба шагыйре Хосе Мартиның «Гуантанамера» дигән поэмасыннан алынган, имеш. Көе, төрле музыкантлар тарафыннан үзгәртелеп, чарлана торгач, җыр азатлык символына әйләнгән, имеш. Әкълимә бу җырны француз җырчысы Джо Дассен җырлавында тыңларга ярата иде. Аннары аны, СССРда беренчеләрдән булып, Мөслим Магомаев җырлый башлады. Аның җырлавы да Әкълимәнең күңеленә хуш килде...

Куба егете Алехандро акыллы, рәхмәтле егет булып чыкты – безнең кызларга җавап йөзеннән, акцент белән булса да, «Ай, былбылым»ны җырларга өйрәнде, университетның Актлар залында узган концертта шуны җырлады да хәтта!

Татарча җырларга никадәр тырышмасын, Алехандроның җырлавы барыбер испанча-урысча килеп чыга иде:

Ай бильбилим, бай бильбилим,  
Агидильди тань ата-а-а...  
Таньнар ата, озили узик,  
Ерьлата да ельата-а-а...

Университетны тәмамлауга, гашыйк парлар кайсы кая таралышып бетте – бер ишләре аерылышты да үзенә янә яр тапты, икенче берләре, бигрәк тә кыз-хатыннар, бәбкә чыгарырга җыенган каз шикелле, ояларында утырып, ялгызлыкны кочып, каңгыраеп калды, өченчеләре – Актаныш кызы Гөлфирә шикеллесе, мәхәббәттән күзе-башы тоныпмы, әллә күпләр шикелле чит илдә яшәп карыйсы килепме, ахырын-нисен уйлап тормастан, аспирантураны тәмамлаган гарәп егетенә ияреп, Сүриягә үк китеп барды...

Әкълимәне дә Алехандро үзенең туган иленә – Кубага алып китте.

Совет илендә белем алып, фәнни коммунизмны тирәнтен өйрәнеп кайткан егет диңгез академиясендә укыта башлады, еш кына корабларга утырып, эшлекле сәяхәтләргә китә торган булды. Белемле, тырыш егеткә вазифа арты вазифа өстәлде һәм ул тора-бара өйдә сирәк кунакка әйләнде.

Баштагы мәлләрдә: «Менә кайда ул романтика – утрау, диңгез, кояш, искиткеч табигать!» – дип сөенгән Әкълимә, кикриге шиңгән әтәч хәлендә калды – Кубада иренең туганнарында яшәгән яшь хатынның көндәлек мәшәкате артканнан-арта барды, ялгызлыктан, сагыштан күңелен авыр уйлар биләп алды.

Бәхет кояшы болыт артыннан чыгарга өлгермичә калды.

СССР дигән ил таркалды. Азык-төлеккә кытлык башланып, илдә хәерчелек чәчәк атты. Пропискасы булмаган кешеләргә талон бирелмәде һәм алар кибеттән ит-май-казы ише ризык-тәгамны ала алмыйча изаланды...

СССРдагы үзгәрешләр Кубага да китереп сукты. Анда да «бөек держава»дагы хәлләр кабатланды.

Алехандро, хезмәт хакын айлар буе ала алмаганлыктан, академиядән китәргә мәҗбүр булды. Эшсезлектән каңгырап, кая барырга белмичә йөргән көннәрдә сәясәт дигән чоңгыл аны бөтереп алды, һәм ул баш-аягы белән шуңа кереп чумды. Айлар буе өенә кайтып кермәгән Алехандроны көтеп утыру мәгънәсез бер эшкә әйләнде. Галәм диңгезендә чайкалган җилкәнсез бихисап илләр белән бергә аларның гаиләсе дә упкын читенә килеп терәлгән иде...

Очын-очка ялгап, тырышып-тырмашып яшәргә маташкан Әкълимәгә, көтмәгәндә-уйламаганда, үз иленнән күңелсез хәбәр килеп иреште: әнисен – аның кадерле әнкәсен исеме өч хәрефтән торган явыз чир, аягыннан егып салып, түшәккә яткызган икән.

Шундук Алехандрога хәбәр итеп, тиз генә юлга җыенып, җиде яшьлек кызлары Лусианы, вакытлыча гына дип, иренең туганнары карамагында калдырып, Әкълимә ватанына очты һәм...

...башта әнисен, аннары студент энесен җирләү сәбәпле һәм янә шулар ише берничә кайгы-хәсрәт, илдә-көндәге куркыныч хәл-вакыйгалар аркасында, өч елга якын чамасы туган илендә тоткарланырга мәҗбүр булды.

Ул Кубага кабат кайтканда, сәясәттә уңышлар казанган һәм Гаванада түрә булып алган Алехандроның, яшь кенә бер мулаткага өйләнеп һәм Әкълимәдән инде тәмам бизеп өлгергән Лусианы үзләре янына алдырып, матур гына көн итеп яткан чагы иде. Алехандроның күңелендә үзенә тамчы да урын калмаганлыгын аңлады Әкълимә, аңлады һәм, чарасызлыктан, кычкырып, юк, акырып елап җибәрде...

Әйе, бәхет кояшы болыт артыннан чыгу түгел, күренергә әле уйламый да иде.

Әкълимә, туган җиренең газиз туфрагын тырмардай булып, бәргәләнде, үрсәләнде. Каяндыр, ерактан (бәлки яшьлегеннән?!), үчекләгән сыман, җыр ишетелгәндәй тоелды аңа:

«Гуантанамера, гуахира гуантанамера...»

Якында гына, эчтә, бәгырен нидер өзеп алган кебек булды:

Ай былбылым, вай былбылым,
Агыйделдә таң ата...
Таңнар ата, өзелә үзәк,
Җырлата да җылата-а-а...

## Давыл, күрәзәче Мөслимә яки Ай егылып төшкән көн

Мөнәвирнең әбисендә күрәзәлек итү сәләте бар иде. Үзенең әтисе Сафагәрәйнең, ягъни Мөнәвирнең ерак бабасының үлем көнен дә дөрес әйткән булган әбисе. Ул чакта бәләкәй булган әле ул – унике-унөч яшьләрдә генә. Басудан әти-әнисе белән бергә көлтә бәйләп кайткан чакта артларыннан яңгыр болыты куып җиткән – күк күкрәп, яшен яшьни башлаган. Мөслимә юл читендәге бер ялгыз карамага таба йөгергән. Ул әлеге карамага килеп җиттем дигәндә генә, агачны яшен сукмасынмы!..

Аңсыз кызын өенә әтисе Сафагәрәй, үзенең җиләненә төреп, күтәреп алып кайткан. Атна-ун көн күзен ача алмаган кызыкай. Дөм сукыр калдым бит, сукыр кызга хәзер кем карасын инде дип, үсмер Мөслимә сәке тырмап җылаган. Менә шул бәхетсез көннәрнең берсендә, өйдәгеләрнең барысын да шаккатырып, кыз бала болай дип әйтеп ташлаган, имеш: «Әткәй, синең гомерең бар әле, җәшәйсең әле, әмма көпә-көндез ай җыгылып төшкән көнне син бу дөнҗадан кичәрсең!» – дигән. «Саташа балакай, зиһененә зыян килмәсә җарый инде...» – дип уйлап, Мөслимә өчен бик борчылганнар, пошаманга төшеп алганнар.

Кызының сөйләшүен дәвам иттерәсе килептерме инде, ырым-шырымга ышанмаган гына түгел, гомумән, күрәзәлек итүне яисә фал ачуны зур гөнаһлардан санаган әтисе:

«Ай җыгылып төшкәч, исән калган кешеләр кап-караңгы төндә ничек җәшәр суң? – дип сораган. – Төнлә бөтен кеше дә карый торган бер ай бит ул, бердәнбер! Җолдызлар айсыз нәмәшләр? Алар да харап булырлармы?»

Мөслимә бер сүз дә дәшмәгән.

Әнисе Сөмбелбикә, үзенең дә язмышын беләсе килептерме, сүзне куертып аласы иткән:

– Кызым, мин кайчан китәрмен икән бу фани дөнҗакайлардан? – дип сораган.

– Әнкәй, әткәйдән суң җегерме ике җыл җәшәйсең әле... Илле икедә, чана җулы төшкәч, сине дә алып китәрләр, – дип җаваплаган Мөслимә.

«Ай җыгылып төшкән көнне...» дигәннән...

Бервакыт Мөслимәнең энекәше Ядкәр – ул чакта аңа җиде яшьләр чамасы булгандыр – әсәренеп, өйгә кайтып керде дә:

– Әткәй кайда? Исәнме ул? – дип кычкырып җибәрде. Түр башында

чәй эчеп утырган әтисен күргәч, чишенеп тә тормастан, ыргылып, әтисен барып кочаклады.

– Ни булды, улыкаем? Бер-бер бәла-казага тарымагансыңдыр бит?! – дип сорады әти кеше, улының төсе качкан чыраена гаҗәпсенеп карап.

– Анда... күлдә... ай... чалкан ята... Ай җыгылып төшкән!.. – диде Ядкәр, елаудан көчкә тыелып, еш-еш сулап.

Бераздан аңлашылды: авыл уртасындагы күпер аша чыгып барган чакта, су өстендәге ай сурәтенә кинәт күзе төшеп, Ядкәр шундук Мөслимә апасының сүзләрен исенә төшергән һәм, әтисе үлгәндер инде дип уйлап, бик каты борчылып, өйләренә элдергән.

Әле Мөслимәгә, әле Ядкәргә, әле әтиләренә карап, барысы да рәхәтләнеп көлгән иде шул чакта.

Көндәлек ыгы-зыгыга кушылып, бер көйгә яши торгач, көннәрдән беркөнне Мөслимәнең күзләре ачылып китте – ул якты дөньяны күрә башлады, шөкер.

Әмма да ләкин... Әкәмәт дими ни дисең инде – кызның юраганы юш килә бит тәки: утызынчы елның җәендә, нәкъ «ай җыгылып төшкән» көнне, ягъни Ташкирмән мәчетенең аен күрше авыл кешесе кисеп төшергән чакта, бу кайгыны күтәрә алмыйча, әтисе – авыл мулласы Сафагәрәй – йөрәк өянәгеннән кинәт җан тәслим кыла. Әнисе Сөмбелбикә абыстай исә, кызы Мөслимә фаразлаганча, илле икенче елның зәмһәрир гыйнварында бакыйлыкка күчә... Кем белә, әгәр Сафагәрәй хәзрәт тагы өч-дүрт ел яшәгән булса, алар гаиләсен, бәлки, башка язмыш көткән булыр иде: әйтик, «кулак» тамгасы салып, ерак Себергә яисә ачы язмышка дучар ителгән меңәрләгән татар мулласы белән бергә Магнит стансасына сөргән булырлар иде...

## Олы юлдан пырахут килә яки Нур Балалайкин

Мөнәвир яза-сыза белгәнче үк рәсем ясарга һәм такмак-такмаза чыгарырга һәвәс иде. Тәүге рәсемнәрен ул әбисенең чигүле алъяпкычындагы, өйдәге ак сөлге-тастымаллардагы, ястык-мендәр тышлыкларындагы, төрле кульяулыклардагы аллы-гөлле чәчәкләргә карап ясады. Бер гөлгә дә битараф булмавы, барча чәчәкне дә яратуы шуннан киләм.

Һәр атнакич җитте исә, аулак өйгә дип, әбисе янына берничә ахирәте килер иде. Ул әбекәйләр, чигү чигеп, бәйләм бәйләп, яшьлекләрен искә төшереп, төрле җырулар җырлап, такмак-такмазалар әйтеп, авыл яңалыкларын бәян итеп, үзара шаярып-көлеп, кич буе утырырлар, вакыт-вакыт, Мөнәвиргә дә дикъкатьләрен юнәлтеп, аның башыннан сыйпап, аркасыннан сөеп алырлар иде.

Мөслимәттәй, оныгын үсендереп, аны мактап аласы килептерме, ахирәтләре кергән саен:

– Минем Мөнәвир балакаем искитмәле итеп бер кочак рәсем җасады бит әле. Аллаһы бирса, мин әйткәние диярсез, Бакый Урманче күек бик зур рәссам булачак Мөнәвиркәем. Җәле, улыкаем-багалмам, матур апаларыңа күрсәтеп җиффәр әле кичә-бүген җасаган кәртинкәләреңне! Таң калсынар әле, менәтерәк! – дип әйтер иде.

Берсеннән-берсе мөлаем, матур һәм сөйкемле әби-апалар, тышлыгына «Альбом для рисования» дип язылган дәфтәрнең һәр битен ачкан саен:

– И-и-и... Кара инде моны! Бигрәкләр дә килештереп җасаган шул балакай...

– Бәтинкәсен көнгә ике мәртәбә буяп йөргән безнең киномеханик Марсилның, «бүген сугыш турында индийский кина була» дип, җегет белән кызны кочаклаштырып, ордым-бәрдем җасаган белдерүләре ише генә түгел инде болар... Настаяшший кәртинәләр!

– Әйтәсе дә юк! Койган да куйган! – дип, малайны мактап куярлар иде.

Әбисе исә, бер кырыйда канәгать елмаеп:

– Ие, ие, тач үзебезнең Бакый Урманченың «Сирин чәчкәсе» дигән кәртинкәсе күек инде! Мондай да матур чәчкәләр «Салтык болыны» кәртинәсендә генә бар! – дип, ахирәтләренең һәр әйткәнен җөпләп торыр иде.

Әбисенең «Урманчы» дип Бакый Урманче исемен тәкърарлап торуында хикмәт бар. Бервакытны, 1980 нче еллар башында булса кирәк, аңа (ул чакта сиксән яшь тулган булган икән инде әбисенә) Казанга барырга һәм шунда чакта мәшһүр рәссамга багышланган күргәзмәдә булырга туры килгән. Үзеннән нибары дүрт яшькә генә олы булган Бакый Урманчены шунда очраткан ул. Кемдер аңа Урманченың фотосурәте төшерелгән һәм кыскача биографисе язылган открытка сыман зәңгәрсу кәгазь тоттырган. Әбисе әллә шуннан укып, әллә берәрсеннән ишетеп, рәссамның атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсендә укыганлыгын белеп алган. Әтисе Сафагәрәйнең дә кайчандыр шул мәдрәсәне бетергәнлеген исенә төшергән дә, җаен-форсатын туры китереп, рәссамга шул хакта сүз каткан. Сүз арты сүз киткән һәм мәшһүр Урманче чордашына үзенең рәсемнәре тупланган альбомын бүләк иткән. Анысы бер хәл, әле ул альбомга үз кулы белән дүртьюллык шигырь дә язган. Ул шигырьне хәтерли әле Мөнәвир:

Күңел яшь, картайдым сагыш белән,
Хафаландым бер яман табыш белән.
Кайгы-хәсрәт күпләргә таныш, беләм.
Минем кайгым ил белән, халкым белән...

Мөнәвир-балакайның «кәртинкәләре» белән танышу тәмам булганнан соң, әби-апалар малайдан такмак әйтүен сорарлар иде. Ул ялындырып тормый, чатнатып сөйли башлый:

Лилин бабай маңгай чәчен
Ал тасма белән үргән.
Кырык яшьтә дөнҗа бутап,
Илле җәшендә үлгән!

– Тагы, тагы сүлә! – дисәләр, малайның такмагы әзер:

Син дә мине җаратасың,
Мин дә сине сөямен...
Бармы әллә мин белмәгән
Бер сөйкемле сөягең?!

– Хәзер үзең чыгарганны сүлә инде! – дисәләр, теленә иң беренче килгәнне әйтә дә сала:

Олы юлдан пырахут килә,
Тузаннарны туздырып.

Үсеп житкәч, өй салдырам –
Бар кешедән уздырып!

Әбиләр көлешә, әбиләрнең кәефе күтәренке:

– Маладис, балакаем! – диләр.

– Тукай күек булырсың әле син дә! – диләр.

– Амин, шулай була күрсен берүк! – дип, Мөслимәттәй яулык очы белән генә күз яшен сөртеп ала.

Мактаудан Мөнәвиргә рәхәт булып китә, аның тагы сөйлисе килә:

Гырлап йокларга була,
Мырлап җәшәргә була...
Туган жиркәйләрне данлап,
Җырлап җәшәргә була!

Әбиләр, юри-морый:

– Мөнәвир балакай түгелдер, боларны үзең чыгаргансыңдыр син, Мөслимәттәй?! – дигән булалар. Мөнәвир үпкәләми, әбиләрнең бер-берсенә күз кысып алганын күрә бит ул – шаяртканнарын аңлый. Әбисе исә:

– Булмаганны! Мөнәвир балакаем өлешенә керергә кем дип белдегез мине! – дип, онытын кочагына алып кыса. Шулчагында нигәдер күзләре дымлана әбисенең...

И, ул балачакның рәхәт мизгелләре!.. Бер көнгә генә булса да, кайтып килергә иде балачакка... Юк, булмый шул кайтып – әлләниләр эшләсәң дә, хәтта терсәгеңне тешләсәң дә... Бердәнбер юаныч, ул да булса – хәтер- хатирә!

Хәтер... Хатирә... Тәүге укытучылар... Беренче рәсемнәр... Беренче шигъри тәҗрибәләр...

Рәсем дәресеннән Миргалим абый Гапсәламов укытты аларны. Аның уң кулындагы баш бармагы, тавык йомыркасы зурлыгында булып, һәрчак ялтырап, алсуланып торыр иде. Кайчандыр урман кискәндә төзәлмәслек җәрәхәт алган икән бармагы. Шул юан бармак аркасында, дүртенче сыйныфта укыганда, чиреккә рәсемнән өчле чыгып, Мөнәвир ударник булалмыйча калган иде.

Бармак аркасында дип... Дөресрәге, Мөнәвирнең үз теле аркасында булды инде ул.

Өченчедә укыган чак. «Балалар, бүген мәктәпкә тикшерүчеләр килде. Шаулашмагыз, үзегезне ипле тотыгыз. Безгә дә керәчәкләр!» – дип, класс җитәкчесе Сания апа алдан ук кисәтеп куйган иде. Тикшерүчеләр белән бергә юан бармаклы укытучы абый да буласын белеп алган Мөнәвир коридордан атылып керде дә парталар арасыннан арткы рәттәге урынына бара-бара: «Шым булыгыз! Юан бармаклы абый керә хәзер!» – дип кычкырды.

– Юан бармак? Нишләп юан микән? – диде кайсыдыр.

– Күп белмә, тиз картаерсың! Юан бармагы белән маңгаеңа берне чиртсә...

Малай сүзен әйтеп бетерә алмады, кемдер аның уң колагыннан тартты. Мөнәвир кизәнергә дип кулын күтәргән иде, каршысында усал йөзле, юан бармаклы укытучы басып торганын күреп:

– Абау! – дигәнен сизми дә калды...

Дүртенчедә укыган чакта менә шул Миргалим абый Мөнәвирләр классына рәсемнән керә башлады. Дәрескә кергән саен, ничек ясарга икәнлеген күрсәтеп, тактага башта үзе акбур белән нинди дә булса рәсем ясый. Дәреснең калган өлешендә, хәзер үзегез эшләгез дип, йә алма, йә кырлы стакан, йә урындык ясарга куша. Мөнәвиргә боларны ясау берни тормый – ә дигәнче эшли дә куя. Тик менә рәсем янына куелган кызыл билгеләр генә, бер-икесен исәпкә алмаганда, һәрвакыт «өчле» булды...

Малайга икенче чиректә дә ударник булу тәтемәде. Әмма аңа карап кына аның күңеле кителмәде, кәефсезләнеп йөрмәде. Борчылмады да (үзе гаепле бит: әбисе әйтмешли, ни чәчсәң, шуны урырсың). Киресенчә, ул тагы да каударланып, тагы да дәртләнеп-илһамланып, кәгазьгә сурәт арты сурәт төшерде. Бу вакытта Мөнәвир ясап җибәргән рәсемнәр «Ялкын» журналында берәм-берәм дөнья күрә башлаган иде инде...

Әлеге журналда беренче булып басылып чыккан «Сау булыгыз, торналар!» рәсеме әле дә аның күз алдында тора: сап-сары яфраклы каеннар, ак болытлы күк йөзеннән өчпочмак хасил итеп торналар очып бара, аркасына букча аскан малай (аны Мөнәвир дип уйларга кирәк) аларга кул болгый...

Әйе, малайны арты белән бастырып ясаган иде Мөнәвир. Баштагы мәлләрдә нигәдер кеше йөзен ясый алмый интекте ул. Шуңа күрә, малай-шалайны, кыз-кыркынны гел арткы яктан гына ясап куя торган иде. Тора-бара, төрле картиналарга карап, сыйныфташларын күзәтеп, үзлегеннән дигәндәй, кеше йөзен ясарга өйрәнде.

Ул арада тәүге шигырьләре һәм мәктәп тормышыннан алып язылган мәкалә-хәбәрләре дә әле район газетасында, әле балалар өчен чыга торган «Яшь ленинчы» газетасында пәйда була барды. Сигезьюллык «Хыял» дигән шигыренең беренче строфасы ничек башланган иде әле?

Гөрләп аккан гөрләвектән
Ямьле яз исе килә.
Бөтен кеше таң калырлык
Рәсем ясыйсы килә!

Мөнәвирләрне татар теленнән һәм әдәбиятыннан башта Әбүгали абый, аннары Әбүсөгыть абый укытты. Туры килүен әйт: икесенең дә исеме «Әбү» дип башлана икән, Әбүгалисина шикелле...

Мөнәвирнең алтынчы сыйныфта укыган чагы иде. Язган-сызганнарының басылып чыкканнары гына да бер кечкенә блокнотлык булды инде. Мәктәптә рәссам-шагыйрь дигән аты таралып өлгерде. Китапханәдән кайтып кергәне юк, күп белә. Язучы халкының яисә сәнгать кешеләренең кайберләре, исем-фамилияләрен үзгәртеп йә кыскартып, дөм сукыр шагыйрь Гомер кебек исемен генә калдырган, йә булмаса, туган җирләренең исемнәрен үзләренә кушамат итеп тә алган икән: мәсәлән, Габдулла Мөхәммәтгариф улы Гарипов бөек Габдулла Тукай булып киткән, Хәсән Туфан дигән зур шагыйрь башта Хизбулла Гөлзизин булган, Габделбакый Урманчиев Бакый Урманче дигән атаклы рәссамга әйләнгән, зур художник Леонардо да Винчи үз фамилиясен шәһәрдән алган, Гәрәй Рәхим дигән шагыйрь, баксаң, дөньяга Григорий Родионов булып туган икән. Габдрахман Аллаһбирдиев –

Габдрахман Минский, Кайбыч районында туган артистка Галия Кайбицкая бар әле, Мирсәяф Әмиров Мирсәй Әмир икән, Ленин бабай, Сталин, Молотов, Дәрдемәнд, Муса Җәлил, Фатих Хөсни, Нур Баян...

Кыскасы, хикмәт инде!..

Алтынчы сыйныф укучысы һәм бер блокнот тулы шигырь иясе Мөнәвир Мәгъсутовның да шундый шөһрәтле исем-атка хәзердән үк ия буласы килеп китте. Һәм ул беркөнне дәфтәр тышына «Әбүмөнәвир Ташкирмәнченең татар әдәбияты дәресеннән өйгә эш дәфтәре» дип язып куйды. Ике көннән әлеге сүзләр, Әбүгали абый тарафыннан кызыл кара белән аркылы-торкылы сызылып, шулар янына «Зур язучы булгач, шундый исем алырсың», дигән кәлимә белән сырланып, хуҗасына кире кайтып иреште. Шуннан соң бүтән мондый юк-бар эш белән шөгыльләнмәскә, мөгез-мазар чыгармаска булды Мөнәвир...

Нур Баян дигәннән, әдәбият дәресендә булган бер мәзәк хәлне исенә төшерде Мөнәвир...

Беркөнне Әбүгали абый урынына укытырга татар әдәбиятыннан бөтенләй хәбәре булмаган Ханисә апа керде. Элек тә, Әбүгали абый каядыр киткән чакта, шулай кергәне бар иде инде аның. Укучылар гына Ханисә апа дип йөртә инде аны, укытучылар исә «Ханисә Мөдәррисовна» дип дәшә. Мөнәвир нигәдер өнәп бетерми аны, үзе булмаганда Ханисә апаны «теге Сапа Мөдәррисе кызы» дип кенә җиффәрә. Малайның усаллыгына, чәнечкеле теленә исең китәрлек! Шулай әйтергә каян, кемнән өйрәнгән диген, мәктәптә дә, авылда да беркем алай дип әйтми югыйсә.

«Сапа Мөдәррисе кызы»ның үзе укыта торган фәне – зоология. Өстәвенә ул – мәктәп директорының укыту-тәрбия эшләре буенча урынбасары. Бер керүендә (Әбүгали абый Казанга белем күтәрергә киткән иде) Ханисә Мөдәррисовна укучыларга Мостай Кәримнең «Россиян мин» дигән шигырен ятлап килергә кушты. Кемнәр сәнгатьле итеп сөйли, шуларга «бишле» куям, ә кем иптәшләреннән уздырып сөйли, шул укучы Октябрь бәйрәмендә сәхнәдән сөйләячәк, районда узачак смотр концертында катнашачак дип тә әйтте. Алдагы дәрескә Мөнәвирдән кала укучыларның барысы да шигырьне ятлап килгән иде. Хәтта гомергә ыкы-мыкы килгән Фәндәвис тә бу юлы тотлыкмыйча сөйләде.

Сыйныфташларның барысы да, куллар күтәреп сөйләп, дүртле-бишле ала торгач, ниһаять, чират Мөнәвиргә килеп төртелде. Ул ашыкмыйча гына урыныннан торды да укытучыга туп-туры карап:

– Мин җатламадым! – диде.

Ханисә Мөдәррисовна әллә ишетеп бетермәдеме, әле бу сүзләрне көтмәгән идеме:

– Кабатла әле, Мәгъсутов! Ни дидең? Башкалар да ишетсен! – дип әйтеп куйды.

– Мин... җатламадым... – диде янә Мөнәвир.

– «Җатламадым» дип түгел, «ятламадым» дип әйтергә кирәк, Мәгъсутов! Татар әдәбияты дәресендә без – Нәмәкәй базарында түгел! Йә, сәбәбен белик инде... Ник «җатламадың»? Көтүдә булдыңмы син? Хәтә, көне буе бәйдә торган кәҗәгездән башка, сезнең мал-туарыгыз юк бугай... Акыл тешеңне алдырырга бардыңмы? Хәер, син аны әллә кайчан ук алдыргансың

шикелле... Абзардан тавык тиресе чыгарып хәлдән тайдыңмы? Йә, синең җавабыңны көтәбез, Мәгъсутов!

– Мин бит рус та, башкорт та түгел! Мин – татар! – диде Мөнәвир.

Класста кемнеңдер борын тартып куйганы ишетелде.

– Шуннан ни? – «Сапа Мөдәррисе кызы» малайның каршына ук килеп басты. – Зато, россиян без! Син дә, мин дә, ул да... Барыбыз да – россияннар!

– Шигырьдә минем милләтем турында әйтелмәгән... Шуңа җатлап тормаска булдым...

– Ничек инде? Һе! Ятлап тормаска булган берәү... Рус белән башкорт сиңа дус һәм иптәш түгелмени?!

– Дус... һәм иптәш... Ләкин җатламыйм барыбер! Татар дип язылган булса, бер хәл ие...

– Кара син аны, ә! Беләсеңме, кем син? Син – милләтче! Син – шовинист! Син... Син... Сорап торалар ди хәзер синнән... Ятлыйсың да сөйлисең! Әйттем-бетте!

– Җатламыйм барыбер! Аннары минем җәш килеш беркем белән дә кабердәш буласым килми! Минем җәшисем килә! – диде Мөнәвир.

– Әле син шулаймы? Син илебез алып барган политикага каршы киләсеңме? Хәзер барысын да директорга җиткерәм! Иманыңны укытабыз без синең! Тамырыңны корытабыз! Кудыртам мәктәптән! Мулла оныгы!.. Кулак калдыгы!.. «Икеле» сиңа! Менә мо-о-ондый зур һәм менә мо-о-ондый жирный «икеле»!..

Ханисә апа, имән бармагын һавада биетә-биетә, күз карашы белән Мөнәвирне «ашап» алды да, үзе белән алып кергән класс журналын өстәлдә онытып калдырып, дулап, тузынып, класстан чыгып китте.

Класс гөж килде. Алда зур гауга булыр, давыл кубар сыман иде. Тик нишләптер ул-бу булмыйча калды. Давылның ни сәбәптән купмыйча калуы Мөнәвиргә бүгенгәчә сер булып калды...

...Менә тагы әдәбият дәресе. Мөнәвир, тыңлыйсы килсә дә, килмәсә дә, укытучы сөйләгәнне сеңдереп утырырга мәҗбүр.

Ханисә Мөдәррисовна сөйли:

– Киләсе дәрестә Нур Баян дигән язучы турында әбизәтелне сораячакмын. Сезнең дәреслектә аның турында берни дә юк. Югары классларга гына кирә әле ул. Эзләнегез, табыгыз, укыгыз, белегез! Сезгә өйгә эш бу. Без татар совет язучыларыннан Нур Баянны да әбизәтелне белергә тиеш. Нур Баян ул шагыйрь генә түгел, Ватан өчен башын салган солдат та!

«Минем ике бабам да сугыштан кайтмаган... Кызык, аларның шигырь язып караганы булды микән?» – дип уйлап куйган иде шул чагында Мөнәвир.

– Гапсаматов! Шәкүров! Күрмәде дип уйламагыз тагы, барыгызны да күрәм мин. Сәгать буе сыер кебек күшәп утырдыгыз. Тәртибегезгә «икеле»! Мәгъсутов, сиңа әйтәм! Ат кебек кешнәргә җыенып, тешеңне ыржайтып утырма! Синнән иң беренче булып сораячакмын! Әйтте диярсең!

Икенче дәрестә әллә әйткәнен онытты, әлле башта укучыларның барысын берьюлы тинтерәтеп алырга булды, белмәссең, Ханисә Мөдәррисовна бөтен класска мөрәҗәгать итеп:

– Йә, үткән дәрестә кайсы язучы турында сөйләдем инде мин сезгә?

Кайсыгыз беренче булып, дөрес итеп җавап бирә, шуңа зур «бишле» куячакмын. Жирный «бишле»!

Куллар дәррәү... күтәрелмәде. Укучыларның күбесе алда утырганнарның артына поса төште. Мөнәвир, гадәттәгечә, яшеренеп тормады.

– Җә, Гапсаматов, син әйтеп кара!

– Үткән дәрестә без... җазучы... э-э-э... җазучы... Кояш... Юк... Ниндидер... уен коралы инде... Оныттым, апа...

– Узган дәрес буе сыер урынына күшәгәнеңнең нәтиҗәсе инде бу... Утыр, «икеле»! Җә, Шәкүров, син әйтеп кара!

– Минем бит... апа... теге... Безнең бит кичә сыерыбыз чүт үлмәде... Көтүдән күбенеп кайткан иде... Витбырач килде дә отвёртка сыман әйбер белән корсагын тиште...

Укытучы аңа кулын селтәде:

– Утыр, Шәкүров! «Икеле» сиңа да! Мәгъсутов!

«Нур Баян» дип әйтергә җыенган иде Мөнәвир, әмма авызыннан бөтенләй икенче исем атылып чыкты:

– Нур Гайсин! Юк... Ялгыш әйттем... Нур... Нур...

– Балалыйсың бит инде, Мәгъсутов! Җәтрәк бул! Белгәнеңне беләм бит...

– Нур... Байконур... Юк... Нур Балалайкин!

Класс дәррәү пырхылдарга тотынды. Дәрес тагы өзелде.

Җә, бу юлы кем тартты инде Мөнәвирнең тел чабуыннан?!

...Балконда, яңгыр шыбырдаганын тыңлый-тыңлый, шуларны исенә төшереп ятты ул.

Мөнәвир, гомумән, бәләкәй чакларында да, үсә төшкәч тә, җәй көннәрендә бигрәк тә, верандада йоклауны хуп күрә иде. Яңгыр шыбырдап ява, ә син рәхәтләнеп, изрәп йоклыйсың. Әбисе сөйләвеннән чыгып, җәннәтнең рәхәт бер җир икәнен чамалаган Мөнәвиргә веранда шул җәннәтнең бер почмагы булып тоела иде. Анда йоклауның татлылыгын, рәхәтлеген сүз белән генә аңлатып бетерерлек түгел...

Яңгыр яуган вакытта шулай рәхәтләнеп йоклауның хикмәте бар икән бит. Бактың исә, бик борынгы бабаларыбыз, яңгыр болыты килгәнен күреп яисә явасын алдан чамалап, чатырларын кая туры килсә, шунда тиз генә кора торган булганнар. Чөнки яңгыр яуган чакта ерткыч хайваннар корбан эзләп – ауга, дошманнар исә яуга чыкмаган. Яңгыр туктаганын, көн аязганын көткән барысы да... Менә кайда икән бит хикмәт! Хәер, моңа ышану яисә ышанмау – һәркемнең үз эше. Әмма моның шулай булуын Мөнәвир бөтен күңеле, җаны-тәне белән тоя...

### Туган көн яки Бәхет адәм кыяфәтлеме?
### (Мөнәвирнең көндәлегеннән)

*2002 ел, 15 октябрь.*

Сишәмбе. Бүген – минем туган көн: 40 яшь тулды. Бу якты дөньяларга килеп, ни кырдым, ни кылдым соң әле мин?

Шалтыратып, иң якын дусларым котлады. Кайбер сыйныфташларым да тәбрикләп алды. Рәхмәт аларга онытмаганнары өчен. Димәк, алар хәтерли мине, исләрендә тота. Ә мин, Мөнәвир, хәтерлимме аларны, барысы да

исемдәме? Хәтер – тишек иләк, сабакташларымның бер ишен онытып барам түгелме соң инде?

Быел августта әбекәемнең каберен дә зиярәт итә алмадым. Берочтан Ядкәр бабайның да каберен күреп килермен дигән идем, булмады инде – сырхауланып, фатирда ятарга туры килде. Аннан соң да Ташкирмәнгә кайтырга бер дә җай чыкмады...

Әни кайда – исәнме ул, вафат булса, җәсәде кай җирләрдә ята икән: әлегәчә берни белмим. Әти исән-сау булырга тиеш, моңарчы исән иде кебек... Авылдан гаиләсе белән күчеп киткәч, Чиләбе якларында яши дигәннәр иде... Аралар өзек – юл өзеклеге...

Сукыр кеше кемгә кирәк соң ул? Хәер, кайбер ата-аналарга нормаль балалар да кирәкми – ташлыйлар да китәләр... Оныталар аннары...

Хәтер. Хәтерсезлек. Хәтер дигәннән... Карале, бүген Хәтер көне бит! Казанны яклап сугышканда башларын салган каһарман бабайларны искә алу көне. Кырык бер көн буе сугышкан икән бабаларыбыз – ахыргача көрәшкәннәр, ахыргача...

Милләтпәрвәрләр бүген дә җыелгандыр инде, искә алганнардыр. Ә мин менә ничәмә ел рәттән андый чараларга йөрүдән мәхрүм. Үзем генә бара алмыйм, берәрсеннән үтенсәң, аны мәшәкатьләү булыр иде. Кеше борчырга яратмыйм шул мин. Нәкъ үзебезчә – нәкъ әби сөйләшкәнчә: «җаратмыйм» дип «җазасым» килде бу урында...

Кичерегез, бабайлар, кичерегез безне – хәтерсезләрне. Без сезнең лаеклы дәвамчыларыгыз була алмадык. Лаеклы алмаш чыкмады бездән. Без, яраткан шагыйрем Зөлфәт әйтмешли, адаштырылган буын... Минем шикелле – сукыр, мәсләксез буын... Безне исәнгерәтеп алырга кирәк, тик ничек итеп, анысын белмим... Әмма исәнгерәтергә, сискәндерергә кирәк безләрне... Әмма сугыш белән түгел... Сугыш белән түгел әмма... Сугыш аждаһа кебек ул – кемлегеңә, яшеңә, ни уйлавыңа, аек фикер йөртүеңә карап тормый, уптым каба да йота...

Кая бара дөнья? Нишләргә җыена Кешелек? Кайчан да булса бу фани дөньяда тәртип булырмы? Юктыр, булмастыр инде дим кайчакта, төшенкелеккә бирелеп. Яхшыга өметләнеп яшибез, әмма баздан йә саздан чыга алган юк әле. Яктыга өметләнгән булабыз, ләкин көннәрнең, тормышның яктырырга исәбе юк – һаман караңгыланганнан-караңгылана гына бара...

Кеше гомеренең бәясе сукыр бер тиенгә дә тормый хәзер.

«Килер бер вакыт, чиста су белән тынычлыкны кешеләр акчага да эзләп таба алмаслар» дип әйтә торган иде әбекәем. Эшләр шуңа бара сыман...

Кешенең күңеле күксегән, йөрәге мүкләнгән, җаны сөрсегән заманнар килде. Бәндә дигәннәре, байлыкка сатылып, акча колына әверелде. Муллыкка чумып яшәгән бай кардәшкә үзеннән күпкә кайтыш тормышта көн иткән фәкыйрь туганы кирәкми хәзер. Кирәге чыккан очракта да ул аны хезмәтче сыйфатында гына күрәчәк, кара эшләрендә генә файдаланачак. Комсызлык ул нык булып күренгән туганлык җепләрен дә өзәргә сәләтле.

Мин көн дә шул хакта уйланам. Уйланырга вакытым җитәрлек минем. Яшәргә дигән вакытым гына күпме калгандыр...

Бәхет адәм кыяфәтле булса, шуның чыраен бер мизгелгә генә булса да

күрергә иде дим. Бер мизгелгә генә, бары тик бер мизгелгә генә... Могҗиза булып, күзләрем шуны күреп өлгерсен иде дим...

Беркайчан да: «Мин бәхетле!» – дип кычкырып әйтергә ярамый. Ярамый алай әйтергә, ярамый. Ялгыш күңеленнән әйтсәң дә, ахырдан шөкереңне әйтергә онытмаска кирәк... Үзеңне шулкадәр бәхетле итеп тойсаң да, ул турыда уйларга да ярамый хәтта. Шулай. Мин, унбер яшьлек малай, бәхет турында уйладым гына... «Бәхет менә шушы буладыр инде ул!» – дип, бер секунд кына уйлап өлгердем... һәм... шул мизгелдә дөньям караңгыланды... Бушлыкка – караңгыдан гына торган киләчәгемә очтым...

Көндәлегемдәге бу җөмләләрне мин юлдан читкә чыкмас өчен дәфтәргә линейка куеп язам. Акрын языла, кул һәм бармаклар арый, әмма барыбыр язам. Тик тормаска, ни дә булса эшләргә кирәк дим! Эшсез һәм хәрәкәтсез җүләрләнүең бар. Урын өстендә тик яту байчура Обломовка гына килешкән ул. Ул да ахыр чиктә... Бу урында «дөмеккән» димәкче идем, үз уемнан оялып, кире уйладым һәм берни язмаска булдым...

Рәсем ясау да алҗыта. Күзле кеше бер сәгатьтә ясыйсы эш белән мин өч көн утырам. Их, димен, күзләрем яхшы күрсә, кыска гына вакыт эчендә әлләр ниләр эшләп, әллә ниләр башкарып чыгар идем дим!

## Мөнәвирнең төше, Акылбикә яки Бакый Урманче белән әңгәмә

Унбер яшенә кадәр төш күргәне булмады Мөнәвирнең. Бәлки күргән дә булгандыр, ләкин аларны хәтерләми ул. Ә менә тормышындагы теге кара көннән соң аңа һәрдаим нинди дә булса төш керә – аклы-каралары, төслеләре, кыскалары, озыннары, куркынычлары, рәхәтләре... Бер үк төшне дәвамлап та күргәне булды аның – хәтта өчәр көн рәттән.

Бүген менә Бакый Урманче белән бер ханым керде аның төшенә...

Төшнең мондыен – бу рәвешлесен күргәне юк иде әле Мөнәвирнең. Гаҗәеп төш! Бәлки ул төш булмагандыр да әле, өн булгандыр – Мөнәвир йокылы-уяулы халәттә генә булгандыр...

...Таң атып килә, имеш. Офык чите алсуланганнан-алсулана бара, әмма кояш үзе күренми әле. Каяндыр тавыш ишетелгәндәй булды. Кемдер сак кына аның җилкәсенә орынды да: «Тор, уян! Йоклап ятар чак түгел!» – диде шикелле. Бәлки алай дип тә әйтмәгәндер, Мөнәвиргә шулай тоелгандыр гына...

«Уяныргa вакыттыр шул инде», – дип уйлап, Мөнәвир күзләрен ачмакчы булды, әмма керфекләре бер-берсенә ябышкан һәм каты береккән кебек иде, шуңадырмы, никадәр генә тырышса да, күзләрен ача алмады.

«Әле һаман да йоклавыммы бу, әллә йокылы-уяулы ятуым гынамы?!»

– Син йокламыйсың... Син күптән уяндың инде...

Кем әйтте моны? Әүвәлге тавышмы? Юк, ул тавышка бер дә охшамаган...

Кинәт дөнья яктырып киткән кебек булды – күз кабаклары аша яктылык үтеп кермәкче инде әллә. Әмма тирә-юнен аклык камап, сарып алганын, ниндидер бер рәхәт җылылык бөркелгәнен ул бөтен җаны-тәне белән сизде, тойды...

Мөнәвиргә рәхәт иде. Ул янә күзләрен ачарга теләде. Бармаклары белән күз

төпләрен угалый торгач, ниһаять, керфекләрен бер-берсеннән аерып җибәрде. Әмма барыбер күзләрен ача алмады. Әйтерсең, кемдер аларны күз бәйләшле уен уйнагандагы шикелле яулык белән нык итеп кысып, бәйләп куйган...

Мөнәвир башта үзен ниндидер телестудиядә дип хис итте. Анда да бит баш очындагы яктырткычлардан яктылык, җылылык бөркелә...

Юк, бу – башка җир, бу бернинди дә студиягә охшамаган. Монда табигатьтә булмаган ниндидер хуш ис килә, әйтеп, аңлатып булмый торган шундый бер илаһи ис!

«Әллә соң мин ялгыш җәннәткә эләктемме?!»

Мөнәвир үз уеннан үзе куркып китте. Болай уйларга ярыймы соң? Көфер уй түгелме бу? «Көфер уйны башыңа кертә күрмә берүк!» – бусы әбисенең исән чакта еш әйтә торган сүзе. Исән чакта... Әллә үлгәч әйтә аламы ул андый сүзне? Әйе, әйтә ала – төшеңә керсә... Сөйләшәсе килсә...

Кинодагы шикелле кадрлар алышынып алды. Алсулык, аклык юкка чыкты. Болытлар йөзеп үтте. Дулкыннар уйнаклагандай булды. Кайнар аш тулы кәстрүл тоткан бер хатын-кыз аның каршына килеп басты. Кул токмачы салып пешерелгәнгә охшый... Ханымны күргәне булмаса да, аның йөзе, бигрәк тә күзләре таныш кебек күренде.

Кадрлар алышынды. Кемдер Мөнәвиргә ак күмәч тоттырды. «Ак күмәч кирәкми, миңа фонарь бирегез, һич югы фонарик та ярый!» – дип әйтә, имеш...

Менә ул, ак күмәч тотып, айлы сукмактан бара... Еракта ниндидер ак шәүлә шәйләнә... Ул бара, шәүлә аңа килә кебек... Шәүлә зурайганнан-зурая бара... Шулчак Мөнәвиргә янында кемдер бар кебек тоелды... Ул да аның белән бергә янәшә атлап бара сыман... Уң ягына борылып караган иде... Ул! Йа Аллаһ! Ул... аңа ап-ачык булып күренде! Кайчандыр ул гашыйк булган ак бантиклы кыз бит бу! Юк, юк! Ялгыш күренгән икән күзенә... Ак бантиклы кыз түгел, ак калфаклы ханым икән бит бу! Күзләре... Аһ, ул күзләре... Шундый якыннар, шундый танышлар...

– Мин бу, таныдыңмы? Кайчандыр син мине югалткан идең... Менә... табылдым мин!

– Кем син, табылдык ханым? Мин сине таныйм да... танымыйм да кебек...

– Балачагыңда югалткаң энҗе бөртегең мин...

Мөнәвир күмәчен ханымга сузды:

– Мә, ал!

– Ул сиңа дигән күмәч! Минеке үземдә... Менә ул! – Ханымның кулында Мөнәвирнекенә охшаган күмәч пәйда булды.

Менә ханым артына таба чигенә башлады.

– Китмә, зинһар! – дип кычкырды, юк, ялварды аңа Мөнәвир.

– Мә, минем күмәчемне дә тотып тор әле... Курыкма, мин ерак китмим! Чишмәдән су алып кына киләм дә... аннары... мәңгегә яныңда калам...

Ак калфаклы ханымның иңсәсендә көянтә пәйда булды. Чиләкләр зеңгелдәп алды... Бермәлне ул чиләкләрдәге су мөлдерәмә булып күренде...

– Мин синең көянтәңне дә, су тулы чиләкләреңне дә күрәм!

– Күрмәскә! Син бит сукыр түгел!

Чынлап та, Мөнәвир бит сукыр түгел икән! Күрә икән бит ул. Күзләрен ниндидер пәрдә генә каплаган булган. Шуны әллә кайчан ук алып ташлыйсы булган да соң...

– Син айдагы Зөһрә кызга охшагансың... Әллә айдан төштеңме?

– Юк... Айдан төшмәдем... Мин – синең уйларыңның чынбарлыгы. Әгәр син булмасаң, мин күптән үлгән булыр идем. Син мине хәтереңдә, хыялыңда яшәттең. Инде упкынга тәгәрәдем дигәндә, син мине тотып кала идең. Караңгылык чоңгылы бөтереп алган чакта, ниндидер көч-кодрәт мине өскә тартып ала иде. Ул көч, ул кодрәт дигәнем син булган икән бит. Синең хыялың, хәтерең булган ул!

– Исемең ничек синең, Ак калфак?

– Акылбикә мин, ханым-солтаным... Ә син... Үзең әйтмәсәң дә беләм... Син – Бәхетбай... Бәхет иясе! Син – нурлы кеше...

Акылбикә... Бәхетбай... Акылбикә... Бәхетбай...

Алар икесе шулай бик озак сөйләшерләр кебек иде. Ләкин бу бит – төш. Төш исә кинәт көтмәгәндә үзгәреп куючан йә өзелүчән була...

Кадрлар янә алышынды. Каршында кабат якты, айлы сукмак, Ак Шәүлә пәйда булды. Ак Шәүлә, ак йөзле, ак чәчле татар бабаена әйләнеп, инде хәзер аның янында – зур кәнәфидә утыра... Кәнәфидән дә аклык, яктылык сибелә сыман...

Әбисе сөйләгәннән чамалап алды.... Бу бит... бу бит... Бакый Урманче!

– Ялгышмадың, егетем, мин нәкъ син уйлаган кеше...

Мөнәвир гаҗәпләнүеннән ни әйтергә белмичә торды. Аннары кыюлана төшеп, телен эшкә җикте:

– Сезне... әбием бик мактый иде... Күрәсем килгән иде... Сөйләшәсем килгән иде...

– Син дип сөйләш... Монда мин үзем генә... Башың яшь булса да, күпме кичергән егет син... Сине белгәнемә аптырама... Безне исләрендә, хәтерләрендә тотканнарны без дә онытмыйбыз... Йә, ни турында сөйләшмәкче идең, энем?

– Мин... Сезне күргәч... сүзләремне... онытып җибәрдем...

– Күрәм, Мәгъсутов... Хәзер Максатов бит әле... Сине авыр уйлар баскан... Юллар чатында торган чагың... Кыйблаңны табалмыйсың... Кая барырга белмисең, бәргәләнәсең, өзгәләнәсең... Синең яшеңдә мин дә шундый халәтләр кичермеш идем...

Каушап калган Мөнәвиргә акрынлап, куәт-дәрман иңгәндәй булды. Ул, тик торганчы ни дә булса эшләргә кирәк дигән сыман, җилкәсен хәрәкәтләндереп, күп ятудан катып калган тәнен язып алды, кулларын кушырды. Аннары, гәүдәсен турайта төшеп, мәшһүр рәссамның күзләренә карады (әйе, әйе, күзләренә карады!):

– Мин – көчсез, зәгыйфь бәндә... Чынлап та, мин – мәсләксез, кыйбласыз җан иясе... Үземне бу томанлы дөньяда сукыр бөҗәк... кеп-кечкенә бер борча... хәтта... гафу итегез... бет итеп хис итәм... Кайчан мине таптап изәрләр, кайчан мине сытып ташларлар икән дип уйлыйм... Караңгылыктан яктылыкка чыгарга күпме генә тырышсам да, һаман караңгылыкка килеп юлыгам...

– Ә син һәрвакыт якты уйлар гына уйларга тырыш... Кем кушты сиңа гел кара уйларга гына төренеп яшәргә? Сиңа акыл бирмәкче булам... Соң... Синең яшьтә мин дә шундый идем ләса. Безнең дәвернең еллары нинди иде дә, заманасы нинди иде! Золым хакимлек иткән карагруһ еллар...

Миңа тиздән вә тиздән кырык тулыр.
Яшьлегем – моңнар тулы хатирәләр.

Бүген сиңа да – кырык яшь. Уйлар өермәсе, бөтереп алып, сине дә әллә кайларга илтеп ыргыта. Аңлыйм, бик кыен сиңа. Ялгызлык, читкә җибәрмичә, сине үз кыршавында тота, өстәвенә – хасталыгың... Илдәге, көндәлек тормыштагы олы вә кече вакыйгалар сине төрле тарафтан йолыккалый... Беләм, чамалыйм... Эшең гел ал да гөл бармый, кулыңның бер нәрсәгә тотынасы килмәгән чаклары бихисап... Күңелеңдә дә, гавам күгендә дә Бөек Төшенкелек, Зәгыйфь Чарасызлык хөкем сөрә... Бөтен тирә-юньне Өметсезлек Томаны каплап алган...

Әлбәттә, кара уйлар белән син һичкайчан якты дөньяга чыга алмаячаксың! Һичкайчан! Андый уйларыңнан арын һәм яктылыкка омтылудан туктама! Гашыйк булып яшә!

Кешене мәхәббәт яшәтә, картайтмый яшәртә. Ярат – үткәнеңне, бүгенгеңне, киләчәгеңне!

Хыялыңны эшкә җик! Бәлки син мине гел яктылыкның кочагында гына яшәгәндер дип уйлыйсыңдыр?! Алай уйласаң, бик ялгышасың...

Куркынычмы үлем?
Кичегеп күнгәч күңел,
Юк, куркыныч түгел.

Аңлагансыңдыр инде, мин синең белән «шигер» кушып сөйләшәм. Шигер, дим, чөнки мин шулай әйтергә күнеккәнмен... Кайчандыр гомер елларымда үзем сырлаган юллар болар:

Мин дә шагыйрь –
Күңелемдә дәрт вә шигърият тулган.
Гүя урман.
Кайвакыт җилләр исә, шаулый урман...

Сыгылып төшкән чакларым, чәчләремне йолкыр вакытларым минем дә күп булды. Шундый авырлыкларны кичкән мәлләрдә шигергә сыгындым. Аның кочагы миңа әнкәмнеке төсле тоелды. Аның җылысы миңа яшәргә көч бирде. Күңелемне җавапсыз сораулар биләп алганда, таяныч эзләп изаланганда, шигер юатучым, дустым, иптәшем булды...

– Бакый ага, мин адаштым бугай... Яшәп тә карамадым бит әле... Инде көч-җегәрем бетеп килгән төсле... Сезнең буынны да, безне дә коммунизмда яшәрсез, рәхәт гомер итәрсез дип өметләндерделәр...

– Мин, энем, ул коммунизм дигән сафсатага беркайчан да ышанмадым. Атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен бетергән шәкерт буларак, мин бары тик Аллаһыга гына инанып яшәдем. Коммунистлар вәгъдә иткән коммунизмга күпләр алданды. Аны оҗмах итеп күз алдына китерүчеләр булды. Күпләр үзләре күзаллаган шул оҗмахта яшим дип тә уйлады: мәдәният сарае хәтле йортлар салдырдылар, аларны биек коймалар артына яшерделәр. Аллаһ барын оныткан түрәләр-байчуралар янында «хур кызлары» бөтерелде... Ә бит оҗмахның мәңгелек дөньяда гына булуын һәм аңа теләсә кем эләгә алмаганын беләбез югыйсә...

– Бакый ага, гафу... Миңа тормышта юл күрсәтүчем, таянычым әбием иде. Әбием әнием дә, әтием дә булды миңа. Ул үлгәннән соң мин тома ятим калдым.

– Аңлыйм сине. Минем дә әбием – тәтә әнкәм бар иде...

Гүя әле дә кул изәп, саубуллашып
Торасың күпер катар, газиз әбкәм...

Күпер катар дигәнне син аңламыйсыңдыр инде. «Күпер янында» дигән сүз ул...

Тәтә әнкәмне югалткач, синең төсле мин дә бик кайгырдым, бик юксындым, еллар буе әбиемне оныта алмадым, еш исемә төшерә идем...

Мин, энем, сиңа үтемле киңәшләр дә бирәлмәм, ахры... Мин яшәгән дәвернең син яшәгән заманнан әллә ни аермасы юк. Шул ук бәндәләр, шул ук этләр... Аларның йөзләре, чырайлары гына бүтән... Гамәлләре дә шул ук – яшәү өчен көрәш, җан тартыш. Тормышка мин һәрвакыт реаль карадым... Күргәнемне башкаларга матурлап-бизәп сөйләмәдем. Ягъни ничек бар, шулай күрдем, күргәнемне бозмыйча бәян иттем. Ут-суны, хәсрәт дәрьясын кичкән, тоткынлык газабын татыган, ничәмә мәртәбә үлем белән якалашкан кеше буларак, минем дә киләчәккә әллә ни ышанычым юк иде. Теге хәвефле, афәтле елларда бигрәк тә...

Әмма шуны онытма: һәркем бәхеткә лаек. Тик яткан кешегә бәхет беркайчан да килми. Бәхетне читтән, ерактан эзләргә дә кирәкми. Бәхет ул якында гына – синең яныңда гына. Аны тоя һәм күрә белү лязем. Ләкин бәхетне күзле кеше дә яисә сукыр да күрергә мөмкин дигән сүз түгел бу. Бәхетне күңел күзе булганнар гына күрә ала. Бәхет ул – үз кыршавың-гәүдәң эчендә – йөрәгеңдә! Аны йолкып алып та, кемгәдер бүләк итеп тә булмый. Аңа шөкер итеп кенә була...

...Шул мизгелдә Мөнәвир уянып китте шикелле. Үзе дә сизмәстән, уң кулының учын сизелер-сизелмәс кенә типкән йөрәге турысына куйды...

## Мөнәвир, кыр батыры Лемар яки Эшләрең хөрти, Вәсилә!

Мөнәвир, урыныннан торасы килмичә, байтак вакыт уйланып ятты. Күргән төше аны тәмам иләсләндергән иде. Сабый чагын, әбисен, әнисен, әтисен исенә төшерде...

Әнисенең үзен түгел, йөзен дә хәтерләми ул. Кәртечкәсеннән генә кыяфәте нинди икәнлеген чамалый. Бәләкәй чакта әбисе, вакыт-вакыт сандыктан алып, берүк җырта күрмә дип, кызының, ягъни Мөнәвирнең әнисенең кәртечкәләрен күрсәтеп ала торган иде. Матур булган аның әнисе. Зифа буйлы, яшькелт күзле, карасу чәчле. Ике бит очында мәхәббәт чокыры да бар. Куе чәчен толымлап үреп, күкрәгенә салып төшкән бер сурәтен Мөнәвир аеруча исендә калдырган иде. «Кадерле әнкәемә – истәлек өчен! Комсомолга кергән көнне төшелде...» дип язылган иде бугай кәртечкә артына. Димәк, ул вакытта әнисенә ундүрт яшь тирәсе булган.

Әтисен исә, киресенчә, Мөнәвир бик яхшы хәтерли. Яшь чагыннан ук алдынгы тракторчы иде. Районда икеме-өчме тапкыр кыр батыры да булды хәтта. Ул вакытта җиңүчеләргә сары язулы кызыл тасма кидерәләр иде. Берсендә бераз кәгеп алган әтисе, Мөнәвирләргә килеп, шул тасманы күрсәтеп китте. Шулчакта әти кеше, Мөслимәттәйгә үпкәсен белдереп:

– Әби, турысын әйткәнгә ачуланма, җәме... Син гомер буе киребеткән кеше булдың... «Үги ана кулына калдырыр хәлем юк, үзем карап үстерәм!» – дигән булып, малайны тәки миңа кире кайтармадың, – дигән иде. – Әгәр син, үз сүзеңне сүз итеп, аяк терәп карышмаган булсаң, мин малайдан менә дигән кеше ясай идем! Күреп торасың, мин дә төшеп калганнардан түгел... Миндә дә үҗәтлек җитәрлек... Барыбер чемпиун ясаем малайдан... Районда гына түгел, бөтен риспубликада, юк, бөтен дөнҗада данлыклы җегет итәм мин аны!

Әбисенең җавап итеп әйткәне дә мәңге онытырлык түгел:

– Синең, Лемар кияү, өеңдә болай да бала-чага җитәрлек... Әүвәле алардан кеше ясарга тырыш! Атаң Мәгъсут синнән кеше ясады бит менә. Бәләкәй чагыңда бик тәртипсез иең бит! Атаң булмаса, бөтенләй юлдан язасы иең... Ярай атаң булды, эш белән тәрбияләде үзеңне... Масайма... Үзеңнекеләрне кара син, җәме! Ә инде Мөнәвир балакаема килгәндә, мин аны ким-хур итмәм, Аллаһы ярдәме белән акыллы кеше итеп үстерермен, борчылма, җәме! Чимпиун булырмы, юкмы, анысы балакаемның үзеннән тора инде...

Өйгә кергәндә зур булып күренгән этисе чыгып киткәндә кечерәеп калган төсле иде. Мөнәвирнең җилкәсенә кулын салып, ул:

– Улыкаем, җиңәсеңә ышансаң гына ярышка чык! – диде. – Әбиең – миравой кеше синең! Анаң гына менә... кайталмады... Их!..

Әтисе кулын селтәп алды да ишеккә юнәлде. Аның күзләре яшьләнгәнен Мөнәвир искәреп калды. Үзенең дә күңеле тулган иде. Әтисе кергәндә ничек басып торган булса, чыгып киткәндә шул килеш торып калды ул...

Язмышның ачы шаяруы булдымы икән, әллә Аллаһы Тәгалә шулай теләгәндерме, Мөнәвиргә бер яшь тулып килгәндә, көтмәгәндә-уйламаганда, хәсрәт аларның ишеген каккан.

Әлбәттә, Мөнәвир хәсрәт килүен хәтерләми, ул турыда әбисеннән ишетеп кенә белә.

Бала әнисе авылда сатучы булып эшләгәндә килә. Чираттагы бер ревизия вакытында, тикшерүче адәм аны растрата ясауда гаепли һәм: «Эшләрең хөрти, Вәсилә, сине таш капчык көтә!» – дип ычкындыра. Чынлап та, ул заманда растрата өчен төрмәгә еш утыртканнар.

Хәленең мөшкел булуын аңлаган Вәсилә, ире Лемар белән киңәш-табыш итешкәннән соң, әнисенә дә әйтеп тормыйча, шул ук кичне авылдан чыгып качкан. Кая юл аласын ире түгел, үзе дә белмәгән Вәсилә, юл газапларын кичә-кичә, көннәрнең берендә Ташкент каласына килеп төшкән. Эзләнә-сорана торгач, чыбык очы туганы булган Асия апасының кайда яшәгәнлеген ачыклап, шуларга барып егылган...

Мөнәвирнең әнисен эзләтеп караганнар, бер җирдән дә таба алмагач, утыртырга беркайчан да соң түгел, кайтса-нитсә, эшне күтәрербез дигәннәр.

Шулай итеп, озакламый кайтырмын дип киткән әнисе Ташкент каласында яшәп калган. Әбисе әйтүенчә, әни кеше бер үзбәккә кияүгә чыккан, аңа дүртме-бишме бала тапкан. Хәзер инде ул, бик теләсә дә, кабат туган якларына кайта алмаган. Шуннан бирле Мөнәвирнең – әнисен, әнисенең улын бер тапкыр да күргәне булмады.

Юк, ятим балачагы өчен әнисен гаепләмәде ул, аңа үпкә дә сакламады – язмышы белән килеште Мөнәвир. Әнисен кызганган, җәлләгән чаклары да булмады түгел. Үзең тудырган балаңны, сине дөньяга иңдергән газиз анаңны,

туган авылыңны – кендек каның тамган җирне кайтып күрә алма инде! Кеше өчен моннан да зур җәза булырга мөмкинме?

Хатлар язган булган икән әнисе. Сандыкта җиде хаты сакланып калган – әбисе яшереп куйган булган: бала күңеле өзгәләнмәсен, болай да күпне кичергән, ятимлек ачысын татыган йөрәге парә-парә килмәсен дигәндер инде – ул хатлар хакында үләр алдыннан гына әйтте оныгына...

Һәр хаты саен әнисе Мөнәвирне үлеп сагынганын, әмма теләсә дә, иренең көнчелеге аркасында көрәшә алмаячагын, үзенә җавап бирергә кирәкмәгәнлеген әйтеп язган булган. Әнисенең бер хатыннан тагы шул ачыкланды: кибеттә бернинди дә растрата булмаган икән, барысы да тикшерүче бәндәнең мәкерле планыннан чыккан нәрсәләр: адәм актыгы әнисенә кызыккан булган икән, теләгенә ирешә алмагач, алдау-куркыту юлына баскан...

Әтисе исә гаиләсе белән Ташкирмәндә – Качкын урамында яшәде. Җитмешенче еллар башында ул, гаиләсен алып, Чиләбе якларына китте. Кайчандыр үзе тракторчылыкка укыган Пласт шәһәренә барып урнашкан икән. Болар турында да ул әбисеннән ишетеп белгән иде.

Мөнәвир әбисе белән бергә яшәде. Әти-әниле яшьтәшләренә кызыгып үсте. Әмма беркайчан да алардан көнләшмәде. Яшьтиләре әтиләре яисә әниләре белән бергә ат арбасына утырып киткәндә, малайның күз төпләре дымланып ала иде.

Әти белән бергә... Әни янәшәсендә... Их, бер генә мәртәбә... Язмаган икән... Бәхетеңне кәҗә сөзсә, нишли дә алмыйсың икән...

Тагы шул бик нык исендә калды Мөнәвирнең: беркайчан да ямаулы кием кигәне булмады аның. Әбисе сүзендә торды – кимсенеп яшәмәсен дип, һәр уку елы алдыннан сөекле оныгына өр-яңа мәктәп формасы, баш киеме, берничә күлмәк һәм ботинка сатып ала торган иде. Чөлкәләрне, ягъни оекбашларны үзе бәйләде. Киез каталарны гел яңартып торды, искеләреннән исә олтанлык ясатты.

Чынлап та, әтисе әйтмешли, аның әбисе миравой иде. Күп ишеткәне булды Мөнәвирнең: әнисе тәрбиясендә генә үскән бала иркә була, тормыш итәргә әзер булмый, имеш. Андыйларны, бигрәк тә егет-җиләнне «маменькин сын», ягъни «әни малае» дип йөртәләр, ә менә әби канаты астыннан чыкканнар, соңыннан нинди генә һөнәр иясе булуга карамастан, үз эшенең остасы була, зур уңышларга ирешә, төрле сынауларны җиңел кичә, беркайчан югалып калмый. Дөрес, аларны (шул исәптән Мөнәвирне дә) бер сыйфат берләштерә кебек – еш кына төшенкелек чире белән авырыйлар, шул чирдән терелә алмыйча, шактый иза чигәләр...

Әмма ул, әгәр аның ихтыярыннан торса, беркемне дә әнисеннән, әтисеннән аерып алмас, әбисе яисә бабасы белән генә яшәттермәс иде. Бәхетле гаилә – тулы гаилә. Мөнәвир кайчан да булса андый бәхетне татырмы? Булырмы аның да гаиләсе? Моны бары бер Аллаһ кына белә...

### Әкълимә, Мөнәвир яки Җомга көн

Бүген җомга көн түгелме соң? Әкълимә кесә телефонын кулына алды. Әйе шул, җомга икән бит бүген. Сәгать көндезге бер тулып килә икән инде...

Кубада яшәгәндә, вакыт төшенчәсен югалткан иде ул. Илгә кайтып, мәрәкәләнеп шактый йөргәннән соң, Әкълимә Әстерханда төпләнеп яши башлады. Әмма, ни гаҗәп, вакыт мәсьәләсендә хәлләре бер дә шәптән булмады. Куба вакытына ияләшеп беткәнгәдерме, илгә кайткач, шактый вакыт аңгыраеп йөрде, саташып бетте. Көндезләрен үтереп йоклыйсы килде, төннәрен йоклый алмыйча газапланды. Иң кыены – мәктәптә, балаларга дәрес биргәндә була иде. Балаларга берәр бирем бирә дә үзе дә сизмәстән, өстәлгә башын салып йоклый да китә... Балалар көлешкәнгә уяна да беравык үзенең кайда икәнлеген аңышмыйча тора...

Сәгать көндезгә бер. Димәк, хәзерге вакытта Кубада иртәнге сәгать өч. Вакыт аермасы күпме була инде?..

Туктале, сәгать ничә булды әле? Әһә, бер! Әнекәем! Онытa язган бит! Бүген... бүген очрашу көне ләбаса! Күргәзмәдә! Рәссам белән! Мөнәвир Максатов! Бүлмәдәш кызлар: «Тик ятканчы, кибетләрне әйләнеп кайтыйк әле!» – дип, таң тишегеннән үк чыгып киттеләр бугай инде. Аны да кыстап караганнар иде, ул: «Нишләптер башым авыртып тора әле, бераз ятып торыйм булмаса», – дип, алар белән бармыйча калды.

Әкълимә, чәчен-башын тиз генә рәткә китереп, кабалана-кабалана киенә башлады...

Тинтәк баш! Шуны онытырга кирәк бит, ә! Такси чакыртмыйча булмый инде хәзер. Өстәлдә яткан, тышына «Татарстан» кунакханәсе. Белешмәләр» дип язылган кушбитле кенәгәне ачып, Әкълимә аннан үзенә кирәкле номерны эзләп тапты да телефонындагы төймәләргә баскаларга тотынды...

***

Нәкъ шушы вакытта Мөнәвирнең телефоны шалтырады. Рәссамнар берлегеннән икән. Берлек рәисенең сәркатибе Мәрьям тавышы: «Мөнәвир Лемарович! Хәерле көн! Сезне күргәзмә залына алып килергә дип машина җибәрдек. Шофёр сезне ишегалдыгызда көтәчәк!», – диде. Ул рәхмәт әйтергә дә өлгермәде, сәркатип кыз телефонын куйды.

Мөнәвир Казанның Серов урамында яши. Ул яшәгән йортта яшәүчеләрнең күпчелеге – ярдәмгә мохтаҗ, караучысы булмаган сукырлар. Мөнәвир дә шулар рәтенә керә инде, ягъни мәсәлән. Шунысы бик әйбәт: бу урамда сукырлар җәмгыяте дә, сукырлар өчен көйләнгән махсус китапханә дә бар. Йомышы төшсә йә берәр четерекле мәсьәләне хәл итәргә кирәк булса, ул гел шуларга мөрәҗәгать итә: телефоныннан шалтырата яки, алып баручы булганда (кайчакта ул социаль яклау бүлегеннән килгән хезмәткәр була), аның белән барып килә...

Күргәзмә залы да, Рәссамнар берлеге дә бер тирәдә – Мөштәри урамында урнашкан. Димәк, анда барып җитү өчен ким дигәндә ярты сәгать вакыт кирәк. Машина кайчан килә әле, өлгереп булырмы? Хәер, шофёр үзе беләдер. Кем әйтмешли, шофёр халкының монда беренче генә килүе түгел.

Мөнәвир кара күзлеген киде. Ак кепкасының козырёгын шул күзлегенә үк төшереп куйды. Бернәрсә дә онытылып калмады шикелле. Инде кузгалырга вакыт!..

***

...Башкаланың төрле урамнары аша килгән ике машина күргәзмә залы урнашкан бинага нәкъ берүк вакытта аллы-артлы килеп туктады.

Алдагы машинадан – кара күзлекле Мөнәвир, арттагысыннан ак калфаклы Әкълимә чыкты. Шофёр, Мөнәвирнең беләгеннән җиңелчә генә тотып, зур пыяла ишеккә таба алып китте. Әкълимә исә, кызу-кызу атлап, алдындагы бу икәү артыннан килә иде. Шофёр (димәк, Мөнәвир дә) туктап калып, ак калфаклы туташ-ханымны уздырып җибәрде. Әкълимә, ир-атларга күз дә салып тормастан, рәхмәтен әйтеп, фойега үтте.

Артык игътибар итмәсеннәр дип, Мөнәвир шофёрдан үзен бер читкәрәк илтеп куюын сорады. Әкълимә исә бу вакытта рәссам Мөнәвир Максатовның теге көнне үзен аеруча тәэсирләндергән картинасы янында басып тора иде инде...

***

Бер мәлне Әкълимә як-ягына карап алды. Шулчак ул бер читтә ялгызы гына басып торган күзлекле ир-егеткә дикъкать итте. Әлеге ир-егет каршындагы картинага текәлеп, катып калгандай, басып тора иде. «Бу да минем сыман үзенә бик ошаган картина тапкан, ахрысы. Бер ноктага текәлгән күк болай бик озак басып тормас иде!» – дип уйлап алды ул.

Залда күргәзмәгә килүчеләр ишәя төште. Бер кыз белән егет Әкълимә янына килеп басты. Кыяфәте татарга охшаган егет, кызның җилкәсенә кулын салып:

– Камилушка, еще раз взгляни-ка... Эта картина мне почему-то очень нравится... – диде.

– Саидчик! Мне тут ничего не нравится... Пошли лучше в какое-нибудь кафе...

– Ладно, Татишка... Куда скажешь, туда и поедем...

Яшь пар ары китеп барды.

Әкълимә янә теге күзлекле ир-атка карады. Чынлап та, ул баядан бирле, каршындагы картинага карап, торaташ басып тора. Һәйкәл, диярсең – селкенми дә!

Әкълимәнең кызыксынуы көчәйде. Янына барып, әлеге ир-атка аның сүз катасы килеп китте...

***

Мөнәвиргә кемдер аны күзәтә сыман тоелды – карашы белән баш миен бораулаган кебек инде менә. Мондый хәлнең аның белән бер булганы бар иде инде.

Бер елны аларны, үзе шикелле берничә кешене, рәсми тел белән әйткәндә, физик кимчелекләре булганнарны, дәвалап карау максатыннан, Алман иленә – Берлин каласына алып бардылар. Шундагы хастаханәләрнең берсендә дәваланып яткан чакта, аңа төрек милләтеннән булган бер мөселман кешесе (исеме Дәмирул иде шикелле) очрап, калада мәчет барлыгын, бу әшәке чир белән авырып киткәнгә кадәр, ул һәр атнаны шунда җомга намазын укырга йөрүен әйтте. Ул тагы: «Әллә кайлардан ук Берлинга килеп җиткәнсең икән инде, «Әхмәдия» мәчетен күрмичә китмә!» – дигән иде.

Дәвалау курслары тәмамлангач, кайтырга бер көн кала аларның буш вакыты булып алды. Форсаттан файдаланып, Мөнәвир үзен шул мәчеткә алып баруларын үтенде. Егетнең теләгән кире какмадылар, немесчә дә, урысча да иркен сөйләшкән юлдаш табып, аларны җиңел машинага утыртып җибәрделәр...

Казаннан Берлинга очар алдыннан Изәил дусты аңа лалә чәчәге чигелгән куе зәңгәр түбәтәй тоттырып:

– Үземә дип сатып алган идем... Һаман кияргә җай чыкмый... Берлинда да мөселманнар бар дип әйтәләр... Кем белә, алай-болай берәр татар очрап, үзеңне кунакка чакырса... Дөньяныкын белмәссең... Мә, ал моны, киеп кара да салып куй букчаңа, – дигән иде.

Дустының әйткәне фәрештәләрнең «Амин» дигән чагына туры килгән, күрәсең – менә шул мәчеткә барганда, түбәтәйнең кирәге чыгып куйды бит.

Соңыннан, Казанга кайткач, дус-ишләреннән сорашып, әлеге мәчетнең тарихын белде Мөнәвир. 1923 – 1925 елларда кирпечтән төзелгән «Әхмәдия» мәчете булып чыкты ул. Аллаһ йорты башта агачтан булган икән. Алман империясе аны 1915 елда «Ярымай лагере»ндагы мөселман әсирләр өчен салдырган булган. Биеклеге 32 метр булган мәчетнең манарасы да, гөмбәзе дә Бөек Ватан сугышы вакытында җимерелгән булган.

Менә шул мәчеткә кергәч, ул бер читкә барып утырды да кайчандыр әбисе өйрәткән догаларны эченнән укырга кереште.

Шунда чакта гаҗәп һәм мәзәк хәл булды да инде. Догаларын укып бетереп, китәргә җыенган гына иде кинәт тукталып калды. Кемдер аны күзәтә кебек тоелды. Бүгенге шикелле. Берни күрмәсә дә, уңга һәм сулга каранган булды ул. Бер мәлне кемдер аңа дәште:

– Әссәламегаләйкем!

Мөнәвир тавыш иясенә борылды:

– Вәгаләйкемәссәлам!

– Борчыганым өчен гафу итегез, әфәндем... Кыяфәтегез татарга охшаган... Кай яклардан сез?

– Татарстаннан мин... Казаннан!

Таныш түгел кешенең йөзе балкып китте. Мөнәвир аны күрмәде, әлбәттә.

– Һай, рәхмәт төшкере! Илдәшем, якташым икәнсез! Шулай фаразлаган идем... Гафу, хөрмәтлем... Кара күзлектәнсез... Әллә сез...

– Әйе... Берлинга күзләремне күрсәтергә килгән идем... Сез үзегез кем буласыз? Монда нинди юллар китерде үзегезне?

– Хөҗҗәт абыең булам... Мин дә Татарстаннан... Парижда гомер кичмешмен... Ун көнлек сәфәрдәмен, дөнья гизеп йөрүем... Язмышым катмарлы... Сезгә бер дә кызык булмастыр... Бик теләсәгез, бәян итәрмен... Тик... Минем сезгә әүвәл бик зур үтенечем бар иде... Ачуланмагыз, зинһар...

– Тыңлыйм сезне, абый!

– Түбәтәегез бик матур, энем! Килешеп тора сезгә! Әткәемнең яшь чагын хәтерләттегез... Мулла иде әткәем... Утыз икенче елда... Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун... Зинһар, кардәшем, сатыгыз миңа түбәтәегезне! Акчасыннан тормам... Күпме сорыйсыз, шулкадәр бирәм!

– Ачуланмагыз, абый. Теләсәм дә, сата алмыйм! Дустымныкы ул. Сәфәр чыгар алдыннан биреп кенә торган иде... Түбәтәен калдырып кайтсам, гафу итмәс ул мине...

– Кардәшем, туганкаем, үтенеп сорыйм сездән... Икеләтә, өчләтә түлим... Дустыгызга аңлатырсыз, битәрләмәс... Миңа ватанымны, газиз туган җиремне, туганнарымны, авылдашларымны искә төшереп торыр иде бу түбәтәй... Кадерле әткәемнең төсе итеп саклармын... Зинһар өчен...

Мөнәвирнең күңеле йомшарды. Ул беркавым уйланып торды да башыннан түбәтәен алып:

– Миннән бүләк булсын... Мәгез, абый! Башыгызда тузсын! – диде һәм аны милләттәшенә сузды.

Хөҗҗәт абый сөенеченнән нишләргә белмәде. Түбәтәйне әле башына киде, әле кулларына алып, аны әйләндерә-әйләндерә карады.

– Энем, ал! Карышып маташма... Мине шатландырганың өчен Аллаһы Тәгалә сиңа әҗер-савапларны меңе белән кайтарсын!

Мөнәвир алмаска күпме генә тырышса да, агай үзенекен итте – акчаны ватандашының түш кесәсенә үк тыгып куйды.

Агайны сөендерүдән Мөнәвирнең үзенең дә күңеле булган иде...

Тумышы белән Мөслим якларыннан булуы, әсирлек газапларын кичүе, француз партизаннарына кушылуы, илгә кайтса, хыянәтче ярлыгы тагарлар дип, Парижда яшәп калуы, француз кызы белән кавышып, бер ир бала һәм ике кыз үстерүләре, күптән түгел генә хатыны вафат булуы, туган илен күрү кабат насыйп булмавы турында сөйләгән иде аңа Хөҗҗәт агай.

Инде менә янә шундый бер халәттә Мөнәвир...

***

– Исәнмесез!

Мөнәвиргә тавыш таныш кебек тоелды.

– Исәнмесез! Тыңлыйм сезне, абы... Гафу итегез... Ялгыш... Бер абыйны искә төшереп тора идем...

– Бу картинага бик озак карап торасыз... Күңелегезгә хуш килгән, ахрысы?!

– Ә... Әйе... Бик матур рәсем... Миңа ошый... Талантлы кеше ясаганы күренеп тора...

Әкълимә теге юлы да рәссам Максатовның бу картинасына дикъкать иткән иде.

– Үзенчәлекле рәсем. Безнең якларда да кәбестәне шулайрак тозлыйлар иде. Имән мичкә дә бик таныш... Ачык төсләрне аеруча ярата икән рәссам. Малайны бик килештереп ясаган, әйемегез?! Әби кеше дә нәкъ татар карчыгы инде!

– Сезне кем дип белик, туташ? – дип Мөнәвир, әңгәмәдәшенә таба борылды.

Шулчак Әкълимә чүт кычкырып җибәрмәде – бу күзлекле кеше Мөнәвир Максатов үзе түгелме соң?

– Ханым, дисәгез, дөрескәрәк туры килер...

Шулай диде дә ул шикләнеп кенә сорыйсы итте:

– Гафу итегез... Сез... алай-болай... рәссам Максатов түгелдер бит?!

– Әйе, Мөнәвир дигән кеше мин булам инде...

Беркөнне күргән төшен исенә төшереп, Мөнәвир шаяртасы итте:

– Ә сез... ялгышмасам... Акылбикә?! Шулай бит?!

Әкълимәнең күзләре зурайды. Аптыравы йөзенә чыкты хәтта:

– Мине... болай... Әкълимә дип йөртәләр йөртүен...

Мөнәвир, шаярткан булып:

– Төшемә кергән идегез... Акылбикә булып... Әкълимә исеме дә – чук гүзәл! – диде.

– Сирәк очрый торган исем дип, әтием куштырган булган...

Бу ханым Мөнәвиргә әллә кайчангы танышы кебек тоелды, аның Акылбикә-Әкълимә белән озын-озак сөйләшеп торасы килде. Ләкин син дигәнчә генә булса икән ул...

Әкълимәнең дә уе шундыйрак иде – аның да Мөнәвир белән озаклап сөйләшәсе, «Хәвеф алдыннан» дигән картинасы турында рәссамнан сораштырасы – рәсемдә сурәтләнгән урамның кайсы авылныкы икәнен, таныш йөзләрнең кемнәрнеке булуын ачыклыйсы килгән иде.

Ул арада, бер туташ килеп, Мөнәвиргә сүз катты:

– Гафу итегез! Сүзегезне бүләм инде... Мөнәвир Лемарович, конференц-залга чакырабыз Сезне. Халык Сезне көтә!

Туташ Мөнәвирне култыклап ук алды да:

– Мөнәвир Лемарович, киттек! – диде.

Мөнәвир, Әкълимәгә мөрәҗәгать итеп:

– Акылбикә, ашыкмасагыз, очрашуга Сезне дә чакырам! – диде.

– Мин шуңа дип килгән идем дә инде, – диде Әкълимә һәм Мөнәвирнең икенче беләгеннән култыклады...

***

Очрашудан соң, алар икәү генә калып, кәһвә йота-йота, күптәнге танышлар шикелле шактый озак чөкердәште.

«Күптәнге танышлар шикелле...»

Монда «шикелле» артык... Бу икәү, чынлап та, күптәнге танышлар булып чыкты. Танышлар гына да түгел – кайчандыр бер-берсенә күзләре төшкән булган икән бит аларның! Нишләптер, язмыш кына бу икәүгә арты белән белән борылган ул чакта... Икесен ике якка аерып, тормышның сикәлтәле юлларына кертеп җибәргән...

***

Хәвеф алдыннан...

Мөнәвир ул көнне яхшы хәтерли.

Күк йөзе иртәннән үк аяз иде. Сыңар болыт әсәре дә юк иде хәтта. Мөнәвир, мунча алдындагы буш мичкәне ишегалдына алып чыкты. Алар күптәннән инде кәбестә тозламыйлар, шуңа күрә мичкәнең кирәге дә шуның кадәре генә иде.

Соңгы вакытта авыл малайлары кыршау тәгәрәтешле уйнарга һәвәсләнде. Кем кайдан кыршау таба, шуны урамда тәгәрәтеп йөри. Мөнәвир дә кыршау тәгәрәтүнең остасына әйләнде. Дөрес, аның үз кыршавы юк-югын. Гадәттә, ул дус малайларыннан алып торып уйный.

Мунча алдындагы мичкә кыршавына бик озак кызыгып йөрде Мөнәвир. Әмма мичкәгә кагылырга кыймады. Бик тә кадерле мичкә иде шул.

Беркөнне Мөнәвир тәвәккәлләде – ни булса, шул булыр дип, мичкәнең кыршавын салдырып алды. Моны эшләргә этәрүче сәбәп җитди иде... Ул сәбәп – кунак кызы Әкълимә!

Ул җәйне әбисе Мөнәвирне, өйдә ялгызы гына утырмасын дип, Качкын урамындагы Кифаяттәйләргә алып барган иде. Шунда баргач, Чаллыдан кунакка кайткан бер кызны күреп, таң калды Мөнәвир. Әкълимә исемле икән. Мөнәвирдән бер-ике яшькә кечерәк булгандыр. Иллә дә матур кыз иде ул! Малай, аңа гашыйк булып, Кифаяттәйләрдән тәмам иләс-миләсләнеп кайтты. Ашый да, йоклый да алмас булды. Уенда гел шул Әкълимә иде. Юк-бар сәбәп табып, әбисен кыстап, берничә мәртәбә бардылар Кифаяттәйләргә. Әкълимә белән үзара сүз дә алыша башлаганнар иде. Кыз да Мөнәвиргә ияләшеп килә иде сыман...

Беркөнне ул әбисеннән ишетеп кунак кызының әнисе белән бергә кире Чаллыга китәргә җыенуын белде. Бигрәк авыр хәбәр булды ул Мөнәвиргә...

Кыршау тәгәрәтә-тәгәрәтә, Качкын урамына ук барып, Кифаяттәйләр яныннан әллә ничә мәртәбә узды. Малайның тыз-бызланып йөргәнен тәрәзәсеннән күреп торгандырмы, бермәлне Кифаяттәй аңа форточкадан хәбәр салды:

– Мөнәвир бәбкәм! Әкълимә әнкәсе белән кибеттә киткәние... Шунда бар! Бүген өйләдән соң китә инде кунак кызы...

Мөнәвир, Кафияттәйгә рәхмәт әйтергә дә онытып, кыршауны тоткан килеш урам буйлап чабып китте.

Үзләренең урамына керүгә, ерактан ук күреп алды ул Әкълимә белән аның әнисен.

Менә хәзер күрсен әле Әкълимә аның кыршауны ничек оста тәгәрәткәнен! Онытмасын – исендә калдырсын Мөнәвирне. «Искиткеч шәп малай калды Ташкирмәндә! Кыршауны Мөнәвир шикелле оста тәгәрәтүче бүтән юк, мин аны үз күзләрем белән күрдем!» – дип әйтерлек булсын...

Менә бер мәлне дөнья тып-тын калган кебек булды. Урамда алар икесе генә – Мөнәвир һәм Әкълимә. Малай, Әкълимәдән күзен алмыйча, алга томырылды. Менә... менә... Әкълимә янына килеп җитәчәк ул хәзер.

Юк, язмаган икән... Әкълимәнең кинәт ачыргаланып кычкыруыннан ниндидер хәвеф якынлашканын сизеп, Мөнәвир башын уң ягына борды...

Калганын хәтерләми Мөнәвир... Берни дә хәтерләми... Юк, дүрт сан калган икән исендә... Машинаның номеры... Бер... биш... биш...ике... Калганын соңыннан әбисе сөйләде... Мөнәвир хастаханәдә сызланып, чиләнеп яткан чакта...

Медведевка авылына баручы «Москвич» машинасы чөеп аткан икән Мөнәвирне. Шофёры дөм исерек булган, имеш... Мәскәүдән хатынының авылына кунакка кайтып барган чагы булган... Электр баганасына сыланып, машинасы кап урталай бөгелгән диделәр. Ниндидер могҗиза белән генә үзе исән калган...

Күпмедер елдан соң Мөнәвиргә кемдер әйтте шикелле: «Сине машинасы белән бәрдергән кешене Мәскәүдә күрдем. Чиркәүдән чыгып килә иде. Түшенә депутат значогы таккан. Зур түрә булып алган, күрәсең, «Лексус»та гына йөри. Телевизордан күренгәли ул, безнең халыкка, җөмһүриятебезгә каршы сөйли гел...»

Әле беркөнне телевизордан Мөнәвирнең колагына бер хәбәр ишетелеп калды. Мәскәүнең байлар гына яши торган Рублёвка дигән бистәсендә бер депутатны атып үтергәннәр. Аның исем-фамилиясе таныш кебек тоелды Мөнәвиргә. Уе-гаме башкада булгангамы, әллә моның ише яңалыклар көн саен яңгырап торгангамы, әүвәлгеләре кебек бу хәбәр дә аның бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты...

## Эпилог

*Теләкнең канатларын*
*Хәйран җәеп,*
*Өметләр күгенә күтәрелдем...*
Бакый Урманче

Тормыш елгасы үз җаена ага бирде – көн артыннан көн, ел артыннан ел үтте...

Кешеләр үзгәрде, кешеләр белән бергә дөнья да үзгәрде. Бәндәләр, милләтләр, халыклар, илләр арасына салкын җил йөгерде. Адәм балалары бер-берсеннән, табигатьтән читләште.

Нанотехнология, компьютеризация, гаджет, смартфон, айфон, глобаль катаклизмнар, хаким-тираннар, зомбилар, коллар һәм акча, байлык, акча, байлык...

Әхлак һәм әдәп төшенчәләре үзгә төсмер алды. Иң аянычы – кеше дигәнең хәтерен, киләчәккә өмет-ышанычын җуя бара.

Кеше кайгырмаска, борчылмаска өйрәнде. Күңелләрне битарафлык биләп алды. Аллаһ колы булырга тиешле адәм баласы акча колына әйләнеп бара...

Дөнья – театр, һәр кеше – артист хәзер. Уйлауга караганда, уйнауны хуп күрә кеше.

Кешенең фани дөньяга килгән көне – гомер чишмәсенең башы. Гомер, инеш-елга булып ага торгач, көннәрдән беркөнне бакыйлыктагы Мәңгелек йокы диңгезенә килеп кушыла.

Һәр туган көн, юк, һәр яңа көн – гомер кыскаруга ишарә.

Җирдә яшәү өчен көрәш бара. Һәр көн, һәр сәгать, һәр мизгел этеш-төртешләрдән, орыш-бәрелешләрдән тора.

Ләкин ничек кенә булса да, төшенкелеккә бирелмәскә кирәк. Дөньяның иң караңгы җирендә дә яктылык бар дип яшәргә кирәк.

Тудыңмы – яшә, мескен булма, горур бул, абынсаң – егылмаска, егылсаң – еламаска тырыш, һәрчак матурлыкка, биеклеккә омтыл, наданга кушылма, акыллыга тартыл, явызлыкны түгел, яхшылыкны дус ит, буйсынып яшәүгә караганда, ирекле булуга ни җитә, һичкайчан күңелеңдәге өметеңне сүндермә, шул чагында гына теләгәнеңә, максатыңа ирешерсең.

Елакны – кыерсыталар, күндәмне – тотып сыталар, ялагай-куштанны кешегә дә санамыйлар, көчле рухлыларны ега алмыйлар, сындыра алмыйлар – аларны бөгеп булмый, андыйлар аякларында нык басып торучан була, соң минутларында да кеше булып калалар.

Гыйлем коесының төбенә төшеп җиткән кеше юк. Әгәр кем дә булса шул кое төбенә төшеп җиттем дип уйлый икән, сөенергә ашыкмасын, әүвәл аяк астына ныклап карасын – анда ул йозаклы капкач барлыгын күрмичә калмас.

***

Көн артыннан көн, ел артыннан ел үтте – Тормыш елгасы, бөдрә-көдрә дулкыннарын ярларына кага-кага, үз җаена ага бирде...

Әкълимә, аерылышуы никадәр кыен булса да, Әстерханны, андагы таныш-белешләрен, дус-ишләрен, яраткан эшен, җанга якын булган укучыларын, ахирәтләрен, коллегаларын, күңеленә һәрвакыт ниндидер бер рәхәтлек биреп торган тарихи Татар урамын, шул урамдагы мәһабәт мәчетләрне, Әстерхандагы милләттәшләребезне җыйнап-берләштереп торган Татар үзәген, үзебезнең тел-лөгатьне ничек тә сакларга тырышкан Татар базарын калдырып, мәхәббәте хакына туган якларына кайтырга ният итте.

Ике гашыйк җан, Мөнәвир белән Әкълимә, кавышып, соңлап табылган бәхет кошын кулдан ычкындырмаска тырышып, башкалада яши башлады.

Күпмедер вакыттан соң бу икәү, җиде кат үлчәп дигәндәй, ныклы бер фикергә килеп, балачакларындагы матур хатирәләрне күңел сандыгында кадерләп саклаган Ташкирмәнгә кайтып төште. Мөнәвирнең бала вакыты, үсмер чагы узган, кайчандыр канаты зәгыйфьләнгән малайны катмарлы тормышның аязучан-болытлы күгенә очырып җибәргән җыйнак вә ыспай йортта бүген тормыш кайный – бәхетле парның, юктан да тәм табып, Аллаһыга шөкерана кылып, тыйнак кына гомер итеп яткан мәле.

Күптән түгел генә аларның сөекле нарасые дөньяга аваз салды. Тупырдап торган малайга Азат дип исем куштылар. Гаилә тормышы тагы да түгәрәкләнә төште.

Җан тартмаса да, кан тарта дигәндәй, Әкълимәнең Кубадагы кызы Лусиа да, әнисенең туган иленә кайтып, Казанда яши башлады. Ипи-тозлык кына сөйләшә белгән кыз инде анасы телендә хәйран гына сукалый, «Ай былбылым»ны акцентсыз җырларга өйрәнеп килә. «Халыклар дуслыгы йорты»нда биюче булып эшли. Җае чыккан саен Ташкирмәнгә кайтырга тырыша балакай. Ул да, кем әйтмешли, башлы-күзле булырга – үзе шикелле бөдрә чәчле Ирек исемле татар егетенә – Сөн елгасы буенда үскән Актаныш баласына кияүгә чыгарга йөри. Аларның да бәхеткәйләре булсын инде берүк!

Александрода шикәр чире тапканнар. Татлы-тәмлене бик ярата иде шул бахыр. Әле менә Лусиа белән Ирекнең туена килергә җыена икән. Ни әйтсәң дә, ата кеше бит – килсен, кызын күреп, аның өчен шатланып, куанып китәр.

Мөнәвирнең Изәил дусты мәчеткә йөри. Техника җене кагылган егет хәзерге вакытта үзе шикелле диндар егет-җилән белән бергә иске мәчетләрне торгызу-тернәкләндерү эшләрен башкара.

Авылга кайтуга, беренче эш итеп мәчеткә барды Мөнәвир. Аллаһ йортына ул үзенчә өлеш кертергә булды – Иран нәкышчылары үрнәгендә шамаилләр язарга кереште. Берничә эшен мәчет диварына илтеп элде дә инде.

Беркөнне аларга Зөләйха апа килде. Зөләйха апа – Госман абыйның карчыгы була инде. Госман абый исә – яшьлегендә тимерче булган, озак еллар комбайнчы булып эшләгән агай, ниндидер чир белән хасталанып пенсиягә чыккач, умарта тота башлаган иде. Үзәге Ташкирмән авылы булган «Коммунизмга» колхозының алдынгы комбайнчысы иде. Хәзер

ул туксан яшьләр тирәсендәдер, мөгаен. Бәләкәй чакларында да, үсмер вакытында да Мөнәвир аларга еш бара торган иде. Әбисе белән бергә, әлбәттә. Госман абый аңа: «Бал кортлары безнең сөйләшкәнне аңлый, алар теләсә кемне чакмый, картаймыш көнеңдә, бәлкем, син дә умартачы булып куярсың, килеп йөр, теләсә кайсы вакытта кил!» – дисә дә, Мөнәвир үзе генә барырга кыенсына иде.

Госман абый кушуы белән Зөләйха апа аны чакырырга килгән икән.

Менә ул умартачы өендә, карт янында басып тора. Әкълимә – аш бүлмәсендә, Зөләйха апа белән чышын-пышын килеп, ни хакындадыр сөйләшәләр, ара-тирә көлешеп тә алгалыйлар. Госман абый урында ята, вакыт-вакыт көрсенгәндәй итә, сулыш алуы да икенче төрле – чирле кешеләрнеке кебек.

– Басып торма, утыр! – диде Госман абый, кулы белән ишарәләгәндәй итеп. – Нигәдер хәлем китеп тора әле, Мөнәвир энем. Җанашларым янына да чыгалмадым, борчыла торганнардыр инде – бабалары күренмәгәч...

– Гел чытыр чабарга димәгән инде, Госман абый... Бераз ял итеп алырга да кирәк! – диде Мөнәвир. Аннары шаярта төшеп, өлкәннәрчә әйтеп куясы итте. – Дөньяны куган булабыз инде без дә... Тоттырмый икән бит ул, нәгаләт!

Әңгәмәдәшенең, аны якын итеп, хәленә керергә тырышып сөйләшүенә картның күңеле булды, үзе дә шаяртып алырга уйлады:

– Җал итәргә тегендә өлгерербез... Ул тоттырмас дөнҗакайның чабуыннан бер эләктергән идем инде мин... Җиләне генә иске, сүсәргән булып чыкты – кәлтә җыланы күек чабуын өзеп качты, шәрә җирен корт чаккыры!

Көлештеләр. Аларның көлүенә Әкълимә белән Зөләйха түти дә игътибар итте: икесе тиң, ишек яңагына сөялеп, сөенеп, бер тын бу икәүгә карап тордылар.

Кинәт картның йөзе җитдиләнде. Ул баш астындагы ястыгын җилкәсе белән арткарак шудыра төште, аны бераз калкытып, утырган күк итенеп куйды.

– Минем сиңа бер гозерем барые бит әле, апаем...

– Тыңлыйм, Госман абый.

– Дөнҗа хәлен белеп булмай... Бүген бар, иртәгә юк дигәндәй...

– Ашыкма әле, Госман абый...

– Мин ашыкмаем да бит... Әнә анда ашыктыралар! – Госман карт кулы белән түшәмгә ишарәләде. – Безнең җанда басып тора күек... Газраилны әйтәм... Сулыш алганы ишетелә...

– Госман абый, бал кортларың турында уйла син... Начар уй кертмә, яктылары, яхшылары гына булсын башыңда... Җир җимертеп яшибез әле... Мин әйтте диярсең!..

– Менә шул бал кортлары турында уйлаем да инде хәзер, – диде Госман карт. – Таратасы килмәй бит җанашкайларымны... Сүз сөрешемне чамалайсыңдыр... Кортларымны сиңа тапшырасым килә, Мөнәвир энем... Берүк каршы килмә, җаме...

Көтелмәгән хәбәрдән Мөнәвир ыкы-мыкы килеп алды:

– Мин... Ни бит... Мин бит... Кортлар карый белмәем... Аннары... Күз кирәк бит бу эшкә, Госман абый... Мин бит... Үзең беләсең...

– Күзле кеше дә абына... Өйрәнерсең! Син – җегәрле җегет, булдырасыңа ышанам!

Әйтте – бетте. Өзеп әйтте Госман абый – артка чигенерлек урын калдырмады.

Икенче көнне таң вакыты кергәндә, Госман абый өзелде.

Мәрхүм белән хушлашырга Мөнәвир белән Әкълимә дә килде.

Алар ишегалдына керүгә, баш очында бал кортларының гөжләгәне, гүләгәне ишетелде.

– Әкәмә-ә-әт! Карагыз әле өскә! – диде кемдер. – Кортлар, болыт-болыт булып, бер төштә асылынып торалар!

Ишегалдындагылар, башларын чөйгән килеш, үзара гәпләшә башлады:

– Госман абый белән шулай үзләренчә хушлашуыдыр инде аларның...

– Кортларда да адәм акыллары булыр икән!

– Бал корты кешедән акыллырак ул, беләсең килсә!

– Минем ишеткәнем бар... Әгәр аларның умартасын актара башласаң, алар күче белән сиңа ябыша, берсе дә качып калмый, үлемнән дә курыкмыйлар...

– Безнең халыкка менә шул бал кортларыннан сабак алырга кирәк тә бит...

– Байлык дип, акчага күзләре тонып кына яшәми шул алар. Шуңа да бал кортлары алар, акча кортлары түгел!

Сүзгә мәчет юлында йөрүче кушылды булса кирәк, ул болай диде:

– «Бал кортларына һичкем дәрес бирә алмас, ләкин кешеләр бал кортларыннан дәрес алырлар», – диелә «Нәхел» сүрәсендә...

– Бал кортының агуы да шифа бит аның!

– Тынычландык, җәмәгать! Хәзер җеназа намазын укыйбыз. Хәзрәт артына тигез рәтләр булып басыгыз!

– Җәмәгать, мәрхүмнең дөньялыкта кемгә дә булса бурычы калмадымы?

Бусы хәзрәт тавышы иде булса кирәк. Җыелган халык аңа дәррәү җавап кайтарды:

– Ю-ю-у-у-ук!

– Илаһи ният кылдым җеназа намазын укымакка... Сүбехәәнәкә әллааһүммә үә бихәмдикә үә тәбәәракәс-смүкә...

Бераздан, мәет салынган колашаны күтәреп, ишегалдыннан чыктылар да зиратка таба киттеләр.

– Кара, кара, бал кортлары да иярде!

– Могҗиза инде бу, могҗиза! Әпәйт безгә сабак! Ата-анасын, туганнарын озатышырга да кайтмый бит хәзер кайберәүләр... Кортлар булып кортлар менә... Аңламассың бу дөнҗаны...

Мөнәвир дә халык агымына иярде. Кемдер аның беләгеннән эләктереп алды...

Бал кортлары, әүвәлгечә, бер болыт булып, зиратка кадәр озата барды. Әлеге шаккатмалы хәлнең дәвамы менә шул зиратта булды.

Мәрхүмне ләхеткә иңдергәч, җеназага килүчеләрнең кайберләре, уң куллары белән балчык алып, кабер эченә ташлады. Шуннан соң, бер-берсен алыштыра-алыштыра, көрәкләрнең төрле рәвешлесен – сапкаваен, очлысын, тигез башлысын тоткан ир-атлар кабергә балчык атарга кереште.

Мәрхүмнең баш очы турысына аның исем-аты, гомер вакыты язылган тактаны бастырып куйгач, туфрак өеме кабер төсен алды.

Көрәк тоткан кешеләр күмү эшен тәмамлап бераз читкә тайпылуга, шуны гына көтеп торгандай, баш очындагы кортлар, берәм-берәм уктай очып, кабер өстенә төшеп кадала башлады...

Бу гаҗәеп күренешнең шаһиты булган халык, бер мәлгә өнсез-тынсыз калып, ни әйтергә белми торды. Берничә кешенең күз төбендә яшь тамчысы пәйда булды...

***

Рәсемнәрен ул әүвәлгечә – үз ысулларын кулланып ясый: бармаклары белән чамалап, күпсанлы энәләрне киндергә кадап. Аннары, ул бит бөтенләй үк сукыр түгел әле, лезвие калынлыгы гына булса да, күрә аның күзләре, томанлы гына итеп булса да, киндер өстен шәйли...

Әле өмет дигәннәре дә бөтенләй үк юк түгел – Казан табибларыннан сөенечле хәбәр килде. Яңа операция көтелә... Куанычлы булыр сыман ул, Аллаһы боерса...

Төшенә әбисе кергән иде беркөнне. Ап-ак киемнән. Әбисе төшкә керсә, сөенечкә була торган иде. Моңарчы...

Ә теге картинадагы әбисе утырып төшкән эскәмиягә килгәндә... Ул инде, искереп-тузып, күптән юкка чыккан иде. Элекке урынын чамалап, Мөнәвир шунда – кайчандыр алмагач үсеп утырган, хәзер исә бер каты тамыры йодрык кадәре генә булып күренгән төшкә, яңа эскәмия ясап куйды. Мөнәвир бу урынның хикмәтле икәнен, биредә... хәзинә ятканын күптән төшенгән иде. «Хәвеф алдыннан» дигән картинасын ясаган чакта ук...


Мөнәвир, иске мунча алдына кереп, куллары белән капшаштыра-капшаштыра, нәрсәдер эзләде. Ниһаять, ул идәннән тимер кыршауны табып алды. Имән мичкәнең такталары да шул тирәдә генә таралып ята иде.

Әгәр... бер кыршавын алмаган булса... мичкә таралмаган булыр иде... Аның да язмышы җимерелмәгән булыр иде... Илләр дә таркалмаган булыр иде бәлки... Хәер, боларның барысы да Аллаһ ихтыяры белән эшләнә – җил дә исми, яфрак та селкенми Аның кодрәтеннән башка...

Мөнәвир Мөслимә әбинең сүзләрен исенә төшерде: «Бәхетсезлегеңнең дә, бәхетеңнең дә сәбәпчесе кыршау булыр!»

Мөнәвир, кыршауны кулына тотып, мунча алдыннан чыкты. «Тагын бер шундый кыршау ясатырга кирәк... Бүген үк!» – дип уйлады ул.

Баш очында – кояш, күңелен рәхәт хисләр биләп алган иде аның.



Дамир
Гарифуллин

# ГОМЕР ФАСЫЛЛАРЫН ОЗАТАМЫН...

***

Кайчакларда матур уйлар уйлап,
Таңга гына карап юл чыгасың.
Тигез генә барган җирләрдә дә
Тирән упкыннарга юлыгасың.

Ни уйларга өлгерми дә калып,
Эһ дигәнче түбән убыласың.
Белмибез шул, дуслар, белмибез бит,
Белмибез бит кайчан егыласын.

Ис китми лә, тормыш казанында
Язмыш, әйдә, һаман тугыласын.
Ярап тора икән белмәвең дә
Әҗәл кайчан килеп сугыласын.

Картлык маңгаена язганнардыр
Мең тураеп, мең кат сыгыласын.
Җаның барда әле барыбер дә
Матур уйлар уйлап юл чыгасың.

Өмет йөртә Адәм балаларын,
Нәрсә кирәк тагын юлчыга соң?
Белеп торам инде, ни дисәм дә,
Йөрәгемне ярып моң чыгасын.

Белеп торам инде, ул моңга да
Сандугачлар бердәм кушыласын.
Өзеләсен сизәм җырыбызның,
Ә җырламый ничек җан чыдасын?!

Ут суламый күкрәк ни суласын?!
Белеп булмый алда ни буласын.

---

Дамир ГАРИФУЛЛИН (1939) – *шагыйрь, археограф; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Чыгарсыңмы каршы алырга», «Сарман энциклопедиясе», «Җырларым, шигырьләрем...» һ.б. китаплар авторы. Сарманда яши.*

## Татар – гаҗәп халык

Татар бит ул гаҗәп халык инде,
Капламаган йөзен битлеккә.
Уй-хыялы киңлекләргә ашкан,
Тотканда да үзен читлектә.

Җыр җырлаган татар, аяк-кулы
Богауланып беткән чакта да.
Җыр язган ул җәллад түмәрендә
Соң минуты җиткән чакта да.

Өметсезлек ишелеп килгәндә дә,
Юк, өметен татар өзмәгән.
Маңгай тире белән җир сугарган,
Каны белән таңны бизәгән.

Татар бит ул хәрәмләшә белми,
Ярдәмләшә белә кемгә дә.
Илгә килгән бәла-казаларның
Иң авырын сала иңгә дә.

Читлекләрдә аны тотсалар да,
Ул бит өйрәнмәгән этлеккә.
Сибелсә дә, җиргә чәчелсә дә,
Капламаган йөзен битлеккә.

***

Озын-озак гомерем юлларыннан
Егетләрчә атлап барам мин.
Аңлый алмыйм: киләчәгем өчен
Әллә шатлык, әллә яра мин.

Хыял чаба салават күпереннән,
Бата-бата ап-ак күбеккә.
Җиде төсен түшәп юлларыма
Сәфәр чыгам җиде кат күккә.

Җиде төннең җиде уртасында
Җидегән йолдыз белән очрашам.
Иң-иң матур йолдыз – Җир анадан
Сарманымның хәлен сорашам.

Кояш белән бергә кочаклашып
Күтәреләм зәңгәр тауларга.
Ак болытның ябышып ялларына,
Китеп барам шатлык ауларга.

Нурга чумып салават күперенең,
Толымнарын үрәм җидедән.
Төшләремне өнгә әверелдереп
Озатып кала мине Җидегән.

Йолдызларга бик бай күк гөмбәзе,
Күрмәдем тик көмеш, алтынны.
Кочагыма йолдыз чүпләп җыям
Бүләкләргә сөйгән халкымны.

Җан ярасын алар дәваласын,
Шатлык кына бүләк итсеннәр.
Оҗмахларга илткән юллардагы
Сиратлардан җиңел үтсеннәр.

Кылдан нечкә сират күперләре
Күңелем кылларына тартымдыр.
Моңнарымның нинди икәнлеген
Бәяләүче сөйгән халкымдыр...

Гомер фасылларын озатамын
Язлар назын саклап юлымда.
Табигатьнең шигъри тезгеннәре
Һаман әле, һаман кулымда.

## Миңа җитә

Ни сорыйсың килсә – сора диеп,
Үтәрбез, дип, миңа әйтсәләр,
Сорамамдыр берни, миңа җитә:
Алсу таңнар иртән атсалар.

Миңа җитә: йомшак җилләр иссә,
Кояш чыкса иртән елмаеп.
Яр астыннан чишмә бәреп торса,
Юк, йөремәм, җирдә моңаеп.

Миңа җитә: сала-калаларда
Гармуннарның моңы тынмаса.
Кеше шундый инде: шатлыкта да,
Кайгыда да аны моң баса.

Миңа җитә: бала-чагаларның,
Оныкларның күңеле шат булса.
Берсен-берсе сөеп яшәсәләр,
Намус-вөҗданнары саф булса.

Миңа җитә: көткән яңгыр килсә,
Күкне ярып яшен яшьнәсә.
Вакытыннан алда әҗәл килеп:
«Әйдә, киттек», – диеп дәшмәсә.

Миңа җитә: бәхет дигәннәре
Килеп торганда да тамчылап.
Җәяү чабам, машинам да юк дип,
Үз-үземне йөрмим камчылап.

Миңа җитә: болын-кырлардагы
Чәчкә гөлләрнең дә дәвасы.
Шифа тоям җанда, тирән итеп
Суласам да Сарман һавасын.

Миңа җитә: гомер буйларыма
Ипи торса табын түремдә.
Мин канәгать: айга менмәсәм дә,
Гомер үтсә туган җиремдә.

***

Котып бозы эреп бара, диләр,
Шатлыкмы бу, әллә кайгымы?
Гамьсезлекне агызып китсен иде
Боз яралткан сулар агымы.

Су ташкыны белән китсен иде
Җир-анага булган мәнсезлек.
Ул чагында бар да матур булыр,
Урын алмас иде ямьсезлек.

Әйтә алмыйм әле, кешелекнең
Шуны кабул итәр чагымы?
Котып бозы эреп бара, диләр,
Шатлыкмы бу, әллә кайгымы?

***

Сырлы-сырлы дөнья,
Кырлы-кырлы,
Шома түгел, түгел түгәрәк.
Ырлы-мырлы йөреп упкыннарга
Төшеп бара кеше, тәгәрәп.

Тотынып кал, Кешем,
Тотынып кал,
Бөркет булып омтыл тауларга.
Хәрәкәттә булып һәлакәттән
Бәхетеңне кирәк дауларга.

Нурлый-нурлый илне,
Җырлый-җырлый
Могҗизалар тудыр җиреңдә.
Түгәрәкли кырлы дөньяларны –
Урының булыр сыйлы түреңдә.

***

Тармы күңелең, әллә киңме күңелең,
Шуны күреп сине таныйлар.
Йә сокланып, сиңа баш ияләр,
Йә мескенгә сине саныйлар.

Күңелнең бит аның үзенә хас
Бөркет даны, былбыл җаны бар.
Тармы күңелең, әллә киңме күңелең –
Шуннан сине, шуннан таныйлар.

## Буш уй

Ялгыз булгач – ялгыз ятам инде,
Уйлар дәрьясына батам инде.
Ике килсә гомер дия-дия,
Үз-үземә акыл сатам инде.

Яши белер идем дигән булып,
Үз-үземә янә сабак бирәм.
Чебен генә, безләп, кара төндә
Мине эзләп оча ара-тирә...

***

Эшләп-эшләп кесә такыр булды,
Ис китмәде инде анысына.
Берәүнең дә әле акча тотып
Барасы юк Аллаһ каршына.

Фани дөнья белән бакый дөнья
Галәм өчен игез түгелләр.
Соңгысында һәркем тигез була,
Тәүгесендә тигез түгелләр.

***

Без унике бала булганбыз да,
Сау-сәламәт үскән сигезебез.
Сигезебез сигез якка очтык,
Бушап калды үскән нигезебез.

Очар өчен туган кош баласы
Калмыйдыр шул үскән ояда.
Сайрап яшәдек без, кемгә дә теш
Кайрап яшәмәдек дөньяда.

***

Җил-давылда авып калды микән,
Яшен сукты микән ул талны.
Чери-чери җирнең кочагында
Туфрак белән тәмам буталды.

...Шул урында күрдем бер яшь талның
Борын төртеп, үсеп китүен.
Шулдыр инде, шулдыр Яшәү үзе –
Шәҗәрәнең дәвам итүе.

***

Фокусчы түгел мин, орлыгын
Чәчмичә игеннәр игәлмим.
Күз буып энәсез һәм җепсез
Бернинди чигүләр чигәлмим.

Эшлим дә эшлим мин туктаусыз,
Көнме ул, төнме ул – искәрмим.
Тик беләм: хәзинә тавына
Мин әле энҗеләр өстәрмен.

Җиңелә-җиңелә җиңәргә
Өйрәнеп киләмен – сабыр мин.
Күрерсез: халкымның җанына
Гомергә сүнмәс ут салырмын.

Шул уттан берочтан илһамлы,
Иманлы булачак барчагыз.
Бәхеткә илтәчәк юлыгыз,
Шул утны сүндерми барсагыз.

***

Гадәт микән, белмим, түгел микән –
Ашыгам мин юлга чыктым исә.
Буыннарым саен хәл йөгерә
Аягыма таңгы чык тисә.

Офык артларына яшеренгән
Офыкларны килә айкыйсым.
Йөрәк чапкан чакта бу дөньяда
Җир гизүдән, әйтче, кем туйсын?!

Кабаланып һаман ашыгам мин –
Гадәтме бу, әллә чир микән?
Бабай дисәләр дә, кайберәүләр,
Мин һаман да йөгерек ир икән.

Ата-баба салган киң юллардан
Мин һаман да алга чабармын.
Әҗәл чыкса юлга, аны алдап,
Урап китәр юлны табармын.

Илдус
Диндаров

# АК ТӨННӘРНЕҢ КАРА КӨННӘРЕ

ПОВЕСТЬ

## 8. Ябырылды сугыш козгыны

Гафурларның ихлас күңелле, һәйбәт күршеләре – кареллар киткәннән соң озын кыш та ахырына якынлашты. Биредәге беренче язны да каршыладылар. Бирегә килеп урнашканнарына бер ел! Инде менә җәй җитте. Янә ак төннәр хакимлек иткән чор... Иң ямьле көннәр... Сөенеч өстенә сөенеч: Гафур Ваассилаларның өйләренә кайтып, аркылы-торкылы такталар кадакланган сыңар тәрәзәне ачып мәш килгәннәрен күрде. Ваассила буйга нык тартылган, көрәйгән. Өсте-башы рәтле, аягында – модный туфлиләр. Урысча төртелгәләп сөйләве буенча тегендә бик яхшы йортта яшиләр икән алар. Ни турында гына сорашсаң да, «Яхшы», «Корошо» дип, ак тешләрен елтыратып елмая гына. Гел нарат сагызы чәйнәп йөргәнгәме, тешләре чынаяктай ап-ак аның. Гафурга да бер уч сагыз тоттырды. Ике көн буе урманда чаптылар, күлдә коендылар, кармак салдылар. Әти-әниләр кич утырды. Влади абзый, сакал-мыегын һәйбәтләп китәргәч, яшәреп киткән кебек. Ул халык иҗаты кооперативында эшли, карел каеныннан юнып, төрле сыннар ясый, акчасы да шактый мул төшә икән...

Гаҗәеп матур көн бүген. Зурлар әйтмешли, мондый көнне сатып та алалмассың. Гафур гадәттәгедән иртәрәк торды. Өйдәгеләрне уятмыйм дип, бик сак кыланса да, шылт иткәнгә дә уяу әнисен алдап буламы соң?! Ул, дивар сәгатенә күз төшерүгә, гаять гаҗәпсенеп:

– Нигә дип таң тишегеннән сикереп тордың әле? – дип сорады.

– Васыйллар китә... Выборгка озатып кайтыймчы, әни?

– И-и... Әйе шул... И хәтер дигәнең... Тишек чиләк... Исемнән дә чыгып киткән... Бар, улым, бар, бүген әллә ни эшең юк барыбер... Менә шушы күчтәнәчне бирерсең үзләренә. Сәлам әйттеләр әти белән әни диген...

Влади абзый белән Ваассила күптән җыенып беткәннәр. Гафур килүгә, кузгалдылар да. Баруы җиңел, шәһәргә нибарысы өч-дүрт чакрымны шоссе буйлап кына үтәсе. Тимер юл вокзалына кергәч, Блади ага билет кассасына барып басты.

Якшәмбе көн булгангадыр, халык шактый күп. Байтагы – яшьләр.

---

*Ахыры. Башы узган санда.*

Барысының да күңелләре күтәренке. Перронда җыр-музыка яңгырап тора. Поезд килгәч, аккордеон тавышы көчәеп, шау-шуны, яшь кызларның шыпырт кына суган суы сыгуын, хушлашу авазларын күмеп китте. Ә безнең ике яшүсмер ирләрчә тыенкы гына аерылыштылар. Һаман да шул бер-берсенең телен нечкәләп белмәүләре, русчалатып такы-токы гына маташтыру аркасында инде. Әлбәттә, Гафур карелча «Юаага тервехексе, Ваассила!» (Сау бул, Ваассила!) дигәнен җиренә җиткереп, авызын тутырып әйтте. Ә дустының, Гафурдан өйрәнгәнчә: «Сaaу был!» дип хушлашуы нәкъ татарча яңгырады. Блади абзый гына берни эндәшмәде. Аның күңеле тулган иде бугай. Гафурның аркасыннан какты да тизрәк читкә борылды, күзләрендәге яшен күрсәтүдән тыелды. Аталы-уллы эчкерсез, яхшы күңелле кешеләр белән бүтән һичкайчан күрешмәячәген малай да сиземләде һәм авыр сулап куйды... Поезд киткәндә, үзе дә сизмәстән иреннәре: «Сау бул, Васыйл!» – дип пышылдады аның.

Гафур бераз күңелен күтәрү өчен туңдырма сатып алды да, вокзалдан бераз читтәрәк чатыр аллея хасил иткән агачлар арасына кереп, эскәмиягә утырды. Кичә таң әтәчләре кычкырганчы балык тотулары бушка узмаган икән шул: бик арыткан. Малай күзен генә йомган иде кебек, йоклап та키телгән. Яшь тән татлы йокыда изелде, һәм малай төш күрә башлады. Имеш, аның туган авылына ниндидер эшелон туктаган да паровоз каты итеп акырта. Гафурның әти-әнисе, шул поездга утырып, каядыр китеп баралар, тик анда Гафур гына юк, имеш тә, әнисе «Гафуу-ур, син кайда?» – дип гасабиланып дәшә, кычкыра... Ул да түгел, ачуланып, малайның күлмәгеннән тарта, йолкый... Малай, сискәнеп, күзләрен ачса, янында картузына тимер юлчыларның җиз эмблемасын таккан агай басып тора һәм, дорфа кыланып, аның җиңеннән тарткалый.

– Син нәрсә, ятасың монда сыер кебек җәелеп! – диде ул, ачулы күзләре белән малайны бораулый-бораулый.

– А што? – диде малай, киреләнеп.

– А то, что – война-а-а! Понимаешь – война-а-а-! – дип сузды тегесе һәм ашыга-ашыга китеп тә барды. Гафур шунда гына аңына килде һәм вокзалга таба йөгерде. Анда – мәхшәр, буталыш, гауга, кыямәт! Халык, елаша-елаша, бер-берсен эзләп ыгы-зыгы килә. Ул арада ачы сирена тавышына бер көтү гаскәриләр халыкны ниндидер караңгы подвалга куып кертә башлады. Бомбадан саклана торган «убежище» дигәннәре шул икән. Андагы алма да төшмәслек тыгызлыкта команда булганчы шактый гына әлсерәп утырдылар. Һәрхәлдә тәмам миңгерәгән Гафурга шулай тоелды, һәм ул, бу «зиндан»нан котылуга, тизрәк авылына таба сыпыртты. Юк икән шул, каладан тиз генә ычкынып булмый икән. Аны бер-ике урам чатын үтүгә, хәрбиләр патруле токтарлады да, җилтерәтеп, каядыр алып та китте. Ни өчен шул рәвешле киләп сарып йөрүен сораштылар, мәсьәлә ачыклангач, пропуск дигән кәгазь тоттырдылар. Малай шәһәр читенә чыкты һәм рәт-рәт кызылармеецлар утырган куе яшел төстәге машиналар, тук атларны иярләгән җайдаклар, ажгырып торган танклар каядыр ашыккан юл кырыеннан өйләренә таба чапты...

Хуторда аны ниндидер шомлы, сәер, хәвефле, хәтәр тынлык каршылады. Йөрәге күкрәк читлегеннән чыгардай булып каты типкән хәлдә өйләренә

кайтса, ишек төбендә ач тавыклар кырылдый да, араннан Миләшнең ашарга сорап, тавышы тәмам карлыгып мөгрәве генә ишетелә. Авылда һичкем юк. Йөрәге жу итеп куйды Гафурның. Күзләренә бөялгән яшьләрен сөртергә дә онытып, авыл Советына таба йөгерде. Кизү торучы Әгъләм абзый борын тишекләре киңәйгән, тәмам куркынган малайны күрүгә:

– Кайда йөрисең, син, ә?! Әтиләреңне сугышка алып киттеләр, чап җәтрәк военкоматка! – диде дә, бар, ычкын, сөрәеп торма монда дигән күк кулын селтәп, яман да дерелдәп шалтыраган телефонга үрелде. Болай да мөлдерәп тулган күңел чишмәсенең чайпалып түгелүенә шул коточкыч хәбәр җитә калды, Гафур ирексездән елап җибәрде. Аяк асты җимерелгән кебек булды. Инде нишләргә? Яңадан шәһәргә барсаң, аны анда үткәрмәячәкләр. Юк, болай боламык булып торып булмый, күрше хутордагы авылдашларын күрсен, белешсен әле ул...

Гафур олы юл чатына барып өлгермәде, борылыштан килеп чыккан йөк машинасы авыл советы янында туктады. Аннан хатын-кыз, бала-чага коелды. Һәм нинди бәхет: алар арасында шәмәхә алъяпкычлы газиз әнисе дә бар иде.

– Улым, – дип, күптән күрешмәгәндәй, каты итеп малаен кочты да ана күңел йомшаруына юл бирде. Аннары берникадәр тынычлана төшеп: – Әтиең китте бит инде, улым! Хәким җизнәң дә!.. Сугышка алдылар... Бәхилләшеп тә калалмадың, ичмасам... Каяле... Мә, моны сиңа әтиең биреп калдырды, – дип, кулына балык сурәте төшерелгән матур пластмас тартма тоттырды. Бу – әтисенең соңгы бүләге – балык тоту өчен төрле үлчәмдәге кармаклар, бер төргәк капрун кыл иде... Теге чакта «мәскәүски кармак» турында биргән әманәтен, соң булса да, үтәргә тырышкан инде әтисе... Соңгы минутларында да яраткан улын исендә тоткан...

Әле генә ирләрен, әти-абыйларын, сөйгән ярларын билгесезлеккә озатып, военкоматтан кайтып төшкән иләс-миләс кыяфәтле хатын-кызлар берни турында да рәтле-башлы фикер алышырлык халәттә түгелләр иде. Шунда ук юл читендә чүмәшеп, башларын як-якка чайкый-чайкый, гаҗизлектән аптырап, көрсенеп, нишләргә белмәгән моңсу кыяфәттә утыра бирделәр. Бераздан ымлашып кына үзара саубуллаштылар да хуторларына, өйләренә таба юнәлделәр.

Өммегөлсем апаның кайгы-хәсрәте аның белән генә чикләнмәгән иде шул. Атна-ун көн элек кенә Фираясы ике баласы белән Татарстанга, туган авылына, әнисенең Фәгыйлә апасы янына кунакка кайтып киткән иде. Юл газапларын күрә-күрә... Ана шуңа нык борчыла, ут эчендә яна: исән-сау кайтып җитә алдылармы икән? Кызын, оныкчаларын шундый авыр юлга үзләрен ялгыз гына гомердә дә җибәрми иде дә бит. Авырлыга калды шул Өммегөлсем апа – бер-ике айдан бәбәй көтә... Ул тирән итеп көрсенеп куйды:

– Барыбер Фираямның кайтып китүе яхшы булды әле. Мондагы хәлләрдән, ичмасам, котылып калды. Кем белә, алда башларыбыз ни күрәчәкне...

## 9. Бер рәхәтнең мең михнәте

Фин-карел җирендә бер елдан артык мул, рәтле, җитеш, рәхәт тормышта яшәү азагына якынлашты, ахрысы. Ямьле ак төннәр балкышын искәртмәстән кара көннәр алыштырган кебек булды. Бер

рәхәте, бер михнәте дигәндәй, тормыш арты белән борылды да куйды Бәшировларга – болын хәтле зур йортта икәү генә утырдылар да калдылар! Менә-менә кемнеңдер, килеп, алга таба ни кылырга кирәклеген әйтүен, бер-бер киңәш бирүен көткән сыман, исәпсез-нисез каңгырып утыру гына иде бу. Рамазан абзыйдан барлыгы ике хат (берсен юлда салган) килде дә шуның белән вәссәлам. Фронттан җибәргәнендә: «Авылга кайтырга тырышыгыз!» дип, кистереп язылган иде.

Ә сугыш кырыннан берсеннән-берсе яман хәбәрләр килеп тора. Өммегөлсем апаларда авылдаш хатыннар-ахирәтләр җыелышалар да солдат хатларын кат-кат укыйлар, таушала төшкән кәгазь кисәкләреннән ниндидер мәгънә эзләгәндәй, кулдан-кулга йөртеп, әйләндереп-тулгандырып карыйлар. Төрлечә фараз кылалар, төшләрен сөйләп, яхшыга юрыйлар. Аннары авылга кузгалыргамы, әллә бераз көтебрәк торыргамы дип, уртак фикергә килә алмыйча, уйлый-уйлый миләре түнеп, берәм-берәм таралышалар. Ирләре сугышка алу яшеннән үткәннәр гаиләләре белән шаулашмый, мыштым гына кайту юлына төштеләр. Кәпик Садыйк кебекләре: «Бу сугыш электәгесе кебек озакка бармас. Күрерсез, берәр айдан «тып» итеп кайтып та төшәрләр солдатларыбыз!» – дип, үзенчә өмет чаткылары тарата. Белеп сөйләвеме, әллә картлыгы белән тискәреләнүеме – һич аңламассың аныкын. Ә Ленинградтан ишетелгән яңалык әллә ни куанырлык түгел иде. Финляндия дә Гитлерга кушылган ди әнә. Кул сузымындагы чик аша гына бит алар. Колхозларның кинәттән таркалуы да азык-төлекне кысуга китерде. Ни алдынгы «Балкыш» колхозы да халыкка бер уч икмәк тә өләшә алмый калды. Авыл советындагылар: «Сохари киптерегез. Ул бәрәкәтле дә, озакка да җитә», – дип кенә җиффәрәләр. Өммегөлсем апа янә дус хатыннар белән, булган сөт-маен җыеп, әчегәнче дип, базарда сатып кайтты. Җәй азагында тоз-шырпы, сабын кыйбатлана дигән имеш-мимешне ишетеп, бу юлы базарга Гафурны гына ияртте.

Выборгны танымыйча тордылар, тәрәзәләргә аркылы-торкылы кәгазьләр ябыштырылган, зур биналар каршында капчыкларга нидер, коммы яисә туфракмы тутырып, әрдәнә-әрдәнә баррикада ише нәрсәләр өеп куйганнар... Универсаль кибет каршында аны-моны караштырып торганда, көтмәгәндә чаттан ниндидер сәер колонна килеп чыкты. Ул таркау сафларда винтовкалы берничә кызылармеец сагы астында, чит-ят хәрби киемдәге, битләрен пумаладай сакал-мыек баскан кешеләр узып бара. Өммегөлсем апа, кинәт кемнедер таныган шикелле, авызын каплап, тын гына, күкрәк тавышы белән ахылдап куйды да, төсе китеп, тирә-юненә каранды. Аннары Гафурны ләм-мим сүзсез генә кулыннан өстерәп, икенче чатка борылды. Улының: «Ни булды, әни?» – дигәнен ишетмәмешкә салышып, хәтсез баргач кына, кешесез җирдә туктап хәл алды.

– Уф, үләм дип торам!.. Ислам абыйга охшаса да охшар икән. Әллә ул түгелме, ялгышаммы? Юк, әтиеңнеке кебек уң як кашының читендә миңе бар иде. Ислам абый булды, ахрысы. И, Аллам! – дип, ашыга-ашыга сөйләп китте аннары әнисе. Ул хәрби әсирләр, финнар арасындамы Рамазан абзыйның абыйсы Исламны хәтерләп калган, имеш. Базарга барганчы тынычлана алмады Өммегөлсем апа. Юк кына бәягә ашамлыкларын сатып котылды да, башкасына гамь салмыйча, кайтыр юлына борылды. Гафур

аның мондый капылт ваемсызлыгының сәбәбен сорашса да, әллә ни җәелеп китми. Ә кич белән генә чәй янында:

– Улым, Миләшне сатыйк та, Аллага тапшырып, Кызыл Таңга, Фәгыйлә апаларыңа кайтыйк без, – дип, хуплау сүзе йә булмаса башка төрле уңай чара көткәндәй, Гафурга текәлде. Яңа гына ундүртен тутырган үсмердән нинди киңәш-табыш булырга мөмкин? Үзе дә тормышның җаен-көен белми торган, башында исәр җилләр уйнаклаган яшьтә генә бит әле ул.

Шулай дисәң дә, беркөнне Гелияләр хуторына дип чыккан җиреннән үзенә күрә сөенечле хәбәр белән кайтып керде:

– Әни! Садыйк абзый Миләшне үзем сатып алам ди.

Өммегөлсем апа:

– Ниемә кирәк булды икән аңа, үзләре кайтырга җыенмыйлар микәнни? – дип аптырады аптыравын, әмма алдын-артын озак уйлап торыр чак түгел иде. Гафур, сыерны бау белән җитәкләп, Садыйк абзыйга илтеп тә бирде. Садыйк карт күпмегә сатасың дип мәшәкатьләнеп сорап та тормады:

– Мә, улым, рәхәтләнегез! – дип, берничә кәгазь акча тоттырды да шуның белән шул. «Бик арзанга төште бугай» дип баш ватты Гафур, чөнки әнисенең ул тәти кәгазьләрне санаганда кәефсезләнүеннән үк алыш-бирешнең сатучы файдасына түгеллеген чамалады... Әнисе аны-моны әйтмәде, Гафур да моңа әллә ни уфтанмады. Бу якларның элекке яме беткән иде инде аның өчен, Гелияләрнең ашыгыч рәвештә туган илгә җыенып киткәннәрен белгәч тә... Садыйк абзыйга килсәк, соңгы көненә чаклы нәрсәгәдер өметләнеп, дошман хөкемендә калган өлкән авылдашының язмышы фаҗигале тәмамлана шул. Еллар үткәч ачыкланганча, дошман солдатлары аның сыерын чалалар. Карт, хәләл малын яклап, талаучыларның берсенә сәнәк белән ташлана да...

...Кайтырга хәстәрләнү мәшәкате әллә ни озакка сузылмады. Икесенә ике капчык, капчык янында икешәр букча дигәндәй, шул рәвешле күтәренеп, Выборгка чыгып та китте аналы-уллы. Гафур, үзен хәзер әтисе урынына калган ир-атка исәпләп, юл йөрү авырлыгын үзенең сыек, арык җилкәсенә алырга тырышты.

Билет кассасы янында гарасат купкан диярсең! Бер-берсен тыгызлап, укмашып баскан халыкны күргәч, Өммегөлсем апа, хәле бетеп, бөтенләй коелып төште.

– Кит, кит, булмаганны, кысылып үләрсең монда! Әйдә, улым, бераз көтеп торыйк, – дип, гадәтенчә сабыр гына бер почмакка барып чүмәште. Гәрчә күпме генә тилмереп көтсәң дә, халык ташкынының бетәсе юк иде. Берсе китә, икесе өстәлә. Шунда Гафурга, үзенең чаялыгын, гаярьлеген күрсәтеп, сыналыр вакыт килде.

– Син, әни, утырып тор, мин хәзер! – диде дә чират торган кешеләр арасына кереп чумды. Аның авырттырып аркасына төяләр, аягын таптап изәләр... Кемдер сырган бишмәтенең җилкәсеннән эләктерергә маташты, ә ул исә, күзен йомып, чукрак кеше кебек алга таба, касса тишеге тарафына үрмәләвен белде.

– Куда лезешь, нахал! – дип, кара яулыклы хатын чәрелдәде, шыр сөяк терсәге белән малайның касыгына төртә-төртә.

– Ишь ты! Мал да удал! – дип, мыскыллап көлеп куйды кып-кызыл почык борынлы, карсак ир.

Аларның ризасызлык белән ачулы гүләшүен озын буйлы, башына

таушала төшкән будёновка чәпәгән уртача яшьтәге кеше үзенең торбадан чыккан гөрелдәвек тавышы белән өзде. Ул:

– Оглоеды, имейте совесть, пропустите мальца! – дип аваз салгач, җәнҗал чыгаручыларның, әллә, чыннан да, Гафурның кечкенә буйлы, чандыр гәүдәсенә карап, «Кем белән булашабыз соң!» дигән кебек, намусларына көч килде, әллә каланча кебек буй-сынлы яклаучыдан шүрләп калдылар, һәрхәлдә малайны, этә-төртә, юл сабып, «бәхет» иңдерә торган касса тишегенә китереп үк куйдылар. Гафур, ундүрттә булса да, яшенә күрә шактый кайтыш гәүдәсе өчен гарьләнә, кеше алдында бу кимчелеген гайрәтле тавыш белән, гаярьлек күрсәтеп капларга тырыша иде. «Малай» дип эндәшкәндә бик хурлана, җаны сызлана. Бу юлы исә әнә аның яшьрәк күренүе файдага гына булды. «Малец» дип атауларын да каршы килми генә буена йотты.

Әле поездның эченә кереп утырасы бар, анда бит билетка атланып очып үтә алмыйсың. Кеше өстенә кеше өелеп, чәбәләнгән төенне тишеп кара! Ярый, Гафур үзе аяк астыннан йөреп чирканчык алды, күнекте, ә менә әнисен, һаман да юаш, сабыр, тотнаклы булып калган әнисен вагонга ничек кертергә? Соңгы айларда ул сыйфатлары тагы да өстенлек ала барды Өммегөлсем апаның. Гәүдәсе ничектер авыраебрак, юанаебрак киткәнен малай да сизә иде. Хатыннар гәбендә дә ишеткәне бар: әнисе бәбәй көтә икән аның. Шунлыктан кеше-карадан мөмкин кадәр читтәрәк калырга тырыша ана. Хәзер дә әнә зәңгәр җирлеккә зур-зур алчәчәкләр төшкән күлмәге, иренең кәчтүме аша шактый беленеп торган корсагын күрсәтмәскә теләгәндәй, кул сумкасы белән каплабрак тора. Үзе Гафурның, балакаеның, вагонга үтү өчен ничекләр өзгәләнүен, мичкәдәге балыктай бәргәләнүен күреп, аны бик каты җәлли иде.

Күрше вагонның проводнигы – арыган кыяфәтле, береткасы читеннән бер учлам чал чәче чыгып торган олы яшьтәге хатын җәһәт кенә килде дә, билетларын күргәч, икесен дә әйберләре белән үз вагонына алды.

Вагонга кереп урнашкач, иркен сулыш алып, ялыгу катыш канәгатьлек белән елмаештылар. Гүя нужаның иң ачысы, камчылысы артта калды, алдагысы әллә була, әллә юк сыман иде. Тирә-юньдәге сөйләшүләргә колак салдылар. Тәрәзә буенда утырган күзлекле, ыспай кара кәчтүмле кеше белән хәрби китель кигән пеләш башлы ир-ат тын гына сөйләшеп утыралар.

– Сводка буенча нинди хәбәрләр бар? – дип сорады күзлеклесе.

– Мактанырлык түгел шул. Ленинградка үрмәли, хәшәрәт! – диде икенчесе, һәм үзе дә сизмәстән, аның куллары йодрыкланды, яңаклары тартышып куйды.

Гафур, әнисенең җилкәсенә сыена төшеп, күзләрен йомган гына иде, паровозның хәвефле-кисәтүле тавышына сискәнеп китте. Ул да түгел, тормозлар тешкә тиярлек дәрәҗәдә ачы итеп чинашып куйды, вагоннар бер-берсенә каты орынып чакылдап бәрелделәр дә туктап калдылар. Көтелмәгән бу хәрәкәттән кешеләр егылып китмәс өчен бер-берсенә авышып, үзара тотынышырга мәҗбүр булдылар. Тыштан сызгырып төшкән бомба, көчле шартлау тавышлары бәреп керде, җир тетрәде, пыяла ватыклары чылтыраганы ишетелде. Бу гарасат һәркемне аңсыз-өнсез итте. Әмма күпләре, тораташ булып, урыннарына сеңеп утыруларын белделәр.

Мондый чакта кем булса да андый куркыныч халәттән чыгарырга, нидер әйтергә тиеш иде.

– Тизрәк урамга! Живо! – дип кычкырды хәрби киемле. Кара кәчтүмле: – Кая әйберләрегез? – дип, Өммегөлсем апаның капчыгын эләктерде дә, үзен алга үткәреп, чыгарга булышты. Капчык-төенчекләр белән әвәрә килгән Гафур да алардан калмады.

Поезд Ленинградка җитәр-җитмәс бер стансада туктап калган икән. Хәер, аның инде поезд дип әйтерлеге дә юк иде. Бер-бер артлы күктән коелган бомбалар явы аны – янып торган гигант факелга, якын-тирәдәге биналарны исә каракучкыл-кызыл ялкын чорнаган хәрабәгә әверелдергән иде. Караңгы күк йөзе яшен яшьнәгәндәге кебек гөлт тә гөлт яктырып китә, аның яктысында үкереп, улап очкан дошман самолётлары ялт-йолт күренеп ала. Каядыр зениткалар ухылдап куя. Кара тәреле гыйфритләр, ниһаять, юкка чыкты. Өммегөлсем апа башта Гафурны капшап тапты, аннары капчык-букчаларын барларга кереште. Барысы да үз урынында иде. Әмма алар шул минуттан иң кадерле нәрсәләрен югалткан, инде мәңге табып булмаслык кешеләр сыман хәвефләнеп, тагын да җитдиләнделәр. Йөзләреннән соңгы елмаю билгеләре нәкъ шул чакта юып, сөртеп алгандай җуелды. Рәхимсез сугыш шул рәвешле Гафурларның артыннан куа килеп, тәки куып тотты һәм үзенең тотыклары итте.

Кара тәреле самолётлар үзләренең кара, әшәке эшләрен бетерделәр дә киттеләр. Ә алардан соң һич гаепсез хатын-кызның, карт-корының, бала-чаганың үле гәүдәләре, дөрләп янган биналар, каралты-кура, күмергә әйләнгән эшелон скелеты торып калды. Вокзал дигәне әле дә ут эчендә, янында кемнәрдер кайнаша, ялкынын сүндереп мәш киләләр. Тирә-юнь кан-яшь белән чыланды, нарасыйларның үксегән, йөрәк парәләрен югалткан аналарның илереп елаган, яралыларның ыңгырашып кычкырган тавышларына күмелде. Башлары әйләнеп, миләре тонган, миңгерәгән аналы-уллы капчык-букчалары өстендә, ни кылырга белмичә аптырап, озак утырдылар. Өммегөлсем апа бөтенләй йончыган, күзләре йомык. Моңарчы мылтык-шылтык, туп аткан тавышны ишетмәгән авыл хатынына күп кирәкме соң?! Әмма хикмәт аларда гына түгел иде. Аның үз хәле – хәл. Кешегә сөйләп аңлатырлык түгел. Бигрәк тә газиз баласына.

Гафур янә дилбегәне үз кулына алырга туры килүен аңлады. Иң элек ул бомбалар явыннан исән-имин калган агач алачык ышыгына әйберләрен ташып куйды, әнисен җитәкләп китереп, капчыклар өстенә утыртты. Инде яктыра да башлады. Станса алай ук кара күмергә калмаган икән әле. Читтәрәк анда-санда зур йортлар, кечкенә ызбалар караеп күренә.

– Җеп өзәрлек тә хәлем юк, улым. Әйдә, берәрсенә кереп ял итеп алыйк, – диде ана, күгәреп кипшенгән иреннәрен ялый-ялый. Тордылар, йөкләрен кулларына алып, иңнәренә асып киттеләр теләнчеләр сыман урам буйлап. Бәлагә тарыганнар бер алар гына түгел иде шул. Берәм-берәм дә, төркемләп тә, өй саен туктап, «на постой» сорашучылар бихисап. Бер хатынның икенчесенә «Ленинградка чаклы алты чакрым» дигән сүзләре колагына эләгеп калды Гафурның. Әнисе белән хәзер үк тәпиләп шул тиклем юлга кузгалу турында хыялланырга гына кала иде.

Бер генә өйдә дә энә төртерлек урын булмагач, һичнинди чарасыз, иске

генә ызба янындагы арба ышыгына барып аудылар болар. Өммегөлсем апа авыр итеп сулый, күз кабаклары күгәреп тора. Ул инде бөтен нәрсәгә битараф төсле иде. Шул чакта ызба ишеге ачылып китте дә аннан хәрби гимнастёрка-чалбар кигән утыз-кырык яшьләрендәге чибәр хатын күренде.

– Әйдәгез, әйдә, керегез монда, – диде ул русча. Өммегөлсем апа кымшанып та карамагач, җил-җил атлап килде дә, аны тартып диярлек аягына бастырып, өйгә җитәкләде: – Ә, син, егет, әйберләреңне калдырма, – дип елмайды. Ананы ул саклык белән генә әйдәкләде, чөнки аның йөкле булуын шундук чамалап алды.

Өйдә тагын чал мыеклы, какча битле солдат, бәләкәй генә өстәл янында уч төбендәге көзгегә карап, пәке белән кырынып утыра иде... Сарафанлы хуҗабикә мич почмагында ризык хәзерләү белән мәшгуль. Гимнастёркалы хатын Өммегөлсем апаны ызбадагы бердәнбер ятакка илтеп яткырды да хуҗа хатын ягына борылып:

– Авыры бар. Сигез айдан да ким түгелдер, – диде кайгыртучан, ягымлы тавыш белән. Бераздан Гафур белән әнисе, чәй эчеп, капчыктагы коры-сары белән тамак ялгап, яхшы күңелле кешеләрнең кызыксынучан сорауларын булдыра алганча җавапладылар. Кич җиткәч, Гафур идәнгә мул итеп җәелгән салам өстенә ауды.

Юлчылар таң атканчы ук уяндылар. Өммегөлсем апаның хәле берникадәр рәтләнгән кебек иде. Менә ишек ачылды һәм теге карт солдат кайтып керде:

– Атны җиктем, хәзер кузгалабыз, Маша!

Әлеге чибәр хатын, гимнастёркасын каеш белән буып, иңенә кызыл хач сурәте төшерелгән киез сумкасын асты. Өммегөлсем апаның хәл-әхвәлен сорашып, Ленинградка таба юнәлүләрен аңлатты. Маша олаучы Ваня абзый белән поездга авыр яралыларны салып җибәргән булганнар икән.

– Слава богу, санитар поезды бомбёжкага кадәр китеп өлгерде, – дип яктырып сөйләнде Маша. – Югыйсә көне-төне бомбага тотып, сулыш алырга да бирмиләр каһәр төшкән фашист козгыннары!

– Ваня абзыйның олавы Ленин шәһәренә таба сәфәр чыкты. Олы юл халык белән чуарланган иде. Машинада, атта, җәяүләп, яше-карты, олысы-кечесе, хәрбиләр, гражданскилар бер тарафка хәрәкәт итә.

Көн чалт аяз. Һавасын сулап туймаслык җәйге матур көнне ниндидер бәла-каза, бәхетсезлек турында уйлап та бирмисең. Бурлы ат җигелгән арба шома юлдан, келтер-келтер килеп, ипле генә тәгәри. Ирексездән күз кабаклары авырая, авырая... Гафур йоклап китмәс өчен үзен көчләп күзен ача, әнисенең хәлен чамалап, тирә-ягын караштыргалый. Олаучы Ваня дәдәйнең үзен гадәтенчә эче пошмас кешедәй тотуы сокландыра иде малайны. Ул кичә, Гафур әнисе белән килеп кергәндә, сакал-мыегын үткен пәке белән төзәткәләп утыра иде. Инде бүген дә иртә таңнан аның шул эш белән мәшгульлеге йокы аралаш күзенә чалынды Гафурның. Хәзер дә Маша апа белән юк-барны сөйләшеп, көлешеп баралар. Әйтерсең, тирә-якта куркыныч афәтнең әсәре дә юк. Эх, шулар кебек, һичнидән шүрләмичә, аһ-вах килмичә, кешелеклелегеңне җуймыйча яшәргә!

Кинәт Ваня дәдәй, сүзен өзеп, нидәндер борчулы кыяфәт белән ерактагы офыкка текәлде. Ул якта күтәрелеп килгән якты кояш күзләрне чагылдыра, аны-моны шәйләрлек түгел иде. Фәкать бал корты безелдәгән кебек кенә

ишетелгән тавыш минут саен көчәеп, самолёт гөрелтесенә әверелде. Ул да булмый, тирә-якны тетрәтеп, бомбалар шартлый башлады.

– Тизрәк, юл кырыена! – дип, бөтенләй үзгәргән чит-ят тавыш белән кычкырды олаучы, атын туктатып. Алар шәфкать туташы белән хәрби кешеләр шул: ни арада юл буендагы чокырга сикереп тә өлгергәннәр. Гафурга исә, әнисенә булышып, юл читенә барып ауганчы әллә никадәр вакыт үткән кебек тоелды. Шул арада кара тәреле самолёт икенче тарафтан килеп чыкты, һәм якында гына тагын бомбалар төшеп шартлады. Менә тагын бер самолёт, «фчт» та «фст» итеп сәер сызгыртып, астагыларны пулялар яңгыры белән коеп, баш түбәсенә тияр-тимәс очып узды. Гафурның күз алдыннан, кинода өзелгән тасмадагы кадр кебек, бурлы атның, үлем ачысы белән кешнәп, күккә ашарга теләгәндәй алгы аяклары белән ыргылуы, әнисенең җирдә яткан хәлдә, чиксез әрнеп, бертуктаусыз кычкыруы, Маша апаның сумкасын ача-ача, аңа ташлануы күренешләре үтеп китте. Ул, һушына килгәндә, коты алынып, үзен-үзе белештермичә әнисенең кәчтүм якасын тарткалый иде:

– Әнием, нәрсә булды сиңа, кай җиреңавырта?!

Ни өчендер башын як-якка бәргәләгән әнисе дәшмәде. Маша апасы исә:

– Не мешай, отойди! – дип, аңардан көтәргә мөмкин булмаган ягымсыз тавыш белән акырып салды. Әнисенең дә өзгәләнеп каты ыңгырашуы аша:

– Улым, кит!.. Читкәрәк кит, зинһар!.. – дигәне, ниһаять, колак пәрдәсен бәреп керде малайның. Маша үзенекен эшли бирде. Менә ул, Өммегөлсем апа янында булашып, Ваня дәдәйгә кычкырды:

– Фляжку давай сюда! Быстро!

Самолётларның, эшләрен бетереп, каядыр олагуларын да сизми калды малай, аның бөтен барлыгын кычкырып елаган бала тавышы биләп алды. Көтелмәгән ул чит өн әнисе тарафыннан килә иде. Маша апа, киресенчә, елмая-елмая торып баскан, аның кулында шул ят тавыш килгән төргәк иде. Маша читтәрәк миңгерәп чүмәшкән малайга карап:

– Ну вот, братец, кил, сеңлең белән таныш! – диде. Дөресен әйткәндә, күз ачып йомганчы үлем белән яшәү арасында яшен тизлегендә узган вакыйга-күренешләрдән Гафурның башы-күзе томаланган, әлеге яңалыкны зиһенне эшкәртеп өлгермәгән иде әле. Яңа туган сеңлесенә мөнәсәбәтле ул хәбәр бераздан гына авырлык белән барып иреште аңына.

Әнисе ыңгырашудан туктаган, ятып тора, үзе, баласын-йөрәк парәсен кулында тибрәткән Машадан көнләшкәндәй, күзен дә алмый, аңа таба кулын сузып елмаерга итә иде. Ваня дәдәй исә бармакларын салам белән сөрткәли, каты яралардан үлеп каткан атының дирбиясен йолкып-йолкып җыештыра.

Калганын төштәге сыман гына, өзек-торык кына хәтерли Гафур. Ничек машина туктатып, әрҗәсенә менеп утырышуларын да, әнисенең талчыккан, әмма ачылып киткән якты йөз белән яңа туган баласын имезүен дә... Бара торгач, имчәк баласының җыерчыклы, кызгылт йөзенә әллә ни исе китми генә күз ташлагач, малай сорап куйды:

– Әни, аңа нинди исем кушабыз соң?

Өммегөлсем апа, көлемсерәүле күзләре белән янәшәдә утырган Машага яратып, сөеп карап, аның гимнастёрка җиңеннән сыйпый-сыйпый:

– Менә Маша апаң кебек рәхимле-шәфкатьле кеше булып үссен өчен Шәфика атлы булыр. Исеме сиңа ошыймы? – диде.

Туган сеңлесен беренче һәм соңгы тапкыр күрүе булган икән шул Гафурның. Ленинград тарафына акрын гына, үрмәләгәндәй барган кәрван янә ут-ялкын эчендә калды. Бу юлы дошман самолётлары тагы да ишәйгән иде. Әле берсе, бомбасын ташлап, баш очыннан очып уза, әле икенчесе... өченчесе... дүртенчесе... Үзләре, «фст», «фчт» итеп сайрап, җирдәгеләргә пулемёттан сиптереп үтәләр иде. Колонна бер мизгелдә таркалды, тегендә-монда ялкын үрләгән автомобильләр, ат арбалары күбәйде, тирә-як тоташ утлы кырга әйләнде.

– «Юнкерслар» болар, тәмам каныктылар, сволочи! – дип, үз-үзенә сөйләнеп куйды аналы-уллы белән чокыр эчендә бергә туры килгән Ваня дәдәй. Аннары калганын хәтерләми Гафур: соңгы мизгелдә карт солдатның чиктән тыш аптыраулы карашы гына исендә калды. Кинәт янәшәдә генә шартлаган чираттагы бомба хасил иткән һава дулкыны малайны, очыртып, читкә атып бәргән иде. Шуның белән барысы да бетте...

* * *

...Авыр һәм гасабилы төш күреп ята Гафур. Бу газаптан котылырга теләп, күзләрен ачмакчы була да, күз кабакларына гер эленгәнмени, тетрәнеп кенә куялар. Бугазын албастыдай нидер буып ала, тын алырга да бирми. Ниһаять, томанга эретелгән керфекләре аша, сизелер-сизелмәс кенә әнисенең йөзен күрде һәм аның ягымлы тавышын ишетте:

– Мальчик пришел в себя!

Туктале, ни өчен соң әле әнисе аның белән русча сөйләшә? Әллә мине танымыймы? «Әнием, бу бит мин – Гафур», – дип кычкырмакчы була, ләкин тавышы гына чыкмый. Кинәт көчле яктылык сирпелде, һәм ул күзләрен ачты. Соры томан аша гына өстенә иелгән хатын-кызны күреп алды. Юк, бу әнисе түгел иде. Кем бу? Кайда ята соң ул?

Малай як-ягына каранды. Башын күтәреп тормакчы булды, әмма, шулчак бөтен башын, гәүдәсен шундый көчле авырту биләп алды ки, күзләреннән очкыннар чәчелде.

Бераздан ул тирә-юньне ачыграк күрә башлады. Менә теге коңгырт күзле, сөйкемле апа, башыннан сыйпап нидер сөйли, тик ул һични ишетми.

– Әнием кайда, әнием? – дип, кара янган иреннәрен көчкә селкетә малай. Үзенә исә каты кычкырып сорагандай тоела. Ә ул исә телдән язган, дөм саңгыраланып ишетүдән мәхрүм иде. Көчле шартлаудан каты контузия алып, аяк-куллары да имгәнгән иде аның.

Коңгырт күзле, ак халатлы хатын, стаканнан чәй эчергәннән соң, аның хәлен, халәтен сынап карагандай:

– Исемең ничек? – дип сорады. Малай аның соравын ишетмәде, шулай да аның иреннәренең ничек тибрәнүенә карап, ни турында сораганын аңлап алды.

– Гафур, – дип пышылдады. Аннары янә тилмереп әйтте:

– Әниемне чакырыгыз!

Малайның бөтенләй чукраклануын, сөйләшә алмавын тәмам ачыклаганнан соң, коңгырт күзле шәфкать туташы, авыр сулап, читкә

борылды. Ярый әле, күзләренә зарар тимәгән дип сөенде ул. Торып басты. Аны башка яралы авырулар күтәреп тора иде. Малайга исә уйланырга, үткәннәрне искә төшереп юанырга гына калды.

Әйе, ул кичәге бомбалар тозагыннан соң әнисен дә, сеңлесен дә югалтты. Башын селкетә алмаган килеш, күз карашы төшкән сыңар тәрәзә аркылы тәбәнәк йортны күрде. Бу әле Ленинград түгел, анда шундый кечкенә, тәбәнәк кенә йортлар була алмый дигән карарга килде.

Дөрес чамалады Гафур. Шәһәр яны бистәсендәге хәрби госпитальләрнең берсенә килеп эләккән иде ул. Берничә көнме шулай яткач (ә ул вакытны анык кына белүдән гаҗиз иде), биредә тагын ниндидер ыгы-зыгы купты, һәм аны, носилкага салып, каядыр күтәреп киттеләр. Машинадамы, арбадамы җай гына тирбәлеп бару йокыга оетты. Күзләрен ачканда, ул инде үзенең яңа җирдә ятканын күреп алды. Биредәге бүлмә яктырак та, иркенрәк тә иде. Аның инде колаклары ачыла төшкән, һәрчак тоташ гөжелдәү арасыннан тавышларны тонык кына ишетә башлаган иде. Авылдагы инештә коенганда, су астына төшкән хәлдә яр буендагы кешеләрнең сөйләшүләрен ишетеп торган кебек. Ул инде аякларын да, кулларын да селкетә ала, тик менә башының сызлавына түзәрлек түгел. Малайның бәгыре өзгәләнеп ыңгырашуын ишетеп, бүлмәдәге кешеләрнең берсе янына килеп утырды.

– Нәрсә, егет, бик авыртамы? – диде башы-маңгае марля белән уралган кеше, ихластан хәленә кереп.

– Ничего, туйга кадәр төзәлер, – дип, юатып, тимер тешләрен балкытып елмаеп куйды аннары. – Аның каравы, мәктәпкә барасы түгел, ә?! Бүген бит инде сентябрьнең алтысы...

Вакытны чамалау әмәле әнә шулай керә башлады Гафурның аңына. Көн саен каядыр, бик еракта нидер шартлый, дөберди. Ә беркөнне яралыларның аякта басып торырга сәләтлеләре, тәрәзә буена җыелып, шаулаша-шаулаша бәхәсләшеп, нидер тамаша кылдылар. – Юк, бу ул якта түгел, Бадаев складлары тирәсендә дөмбәсли, – дип бәхәсләшә берсе.

– Әйе, әйе, нәкъ шулай! Бадаевский келәтләре шунда, Новодевичья зираты артында, – дип җөпләде аны икенчесе.

Бертуктаусыз гүләп торган шартлау тавышлары тынгач, тимер тешле абзый малай янына килде һәм бәхәснең ни турында барганын аңлатуны кирәк тапты:

– Бадаев келәтләре яна. Анда шәһәрнең бөтен азык-төлек запасы тупланган бит. Харап иттеләр барысын да кабахәтләр! Ач калдырдылар ни тиклем халыкны, – диде ул, нәфрәтләнеп, озак кына тынычлана алмыйча сүгенеп.

Гафурга ул ниндидер череп беткән бай турында сөйли кебек тоелды. Шуңа күрә үзе дә сизмәстән:

– Кем соң ул Бадаев дигәне? – дип сорады һәм… шуның белән аның теле дә ачылып китте.

– Патша вакытында Дәүләт думасы депутаты булып торган атаклы большевик, – дип, ихтирам белән телгә алды аны әңгәмәдәше.

Ни хикмәт, 8 сентябрьдәге әнә шул көчле янгыннан соң Ленин шәһәрендә ризыкка кытлык башлана да инде. Ике-өч айдан соң бераз тернәкләнеп, аягына баскан малайны Некрасов урамындагы балалар йортына күчерделәр.

## 10. Ятимнәр йортында

Балалар йорты кайчандыр чиркәү булган галәмәт зур сарайның ишегалдында урнашкан булып чыкты. Кышын бөтен җирне кар-буран тутырган вакыт иде бу. Гафурның үзеннән дә биек булып өелгән кар көртләре арасындагы тар сукмак белән килеп таптылар алар ул бәләкәй йортны. Чираттагы госпитальдән озата килгән чатан солдат көч-хәл белән бинаның ишеген каерып ачты да үзе белән ияртеп килгән малайны эчкә үткәреп җибәрде.

Шактый җәяү килеп өшегән Гафурның инде җылыга туенам дигән уйнияте җилгә очты. Биредә тыштагыдан артык түгел иде. Солдат та, аның кәгазен мөдиргә тапшырып, шыксыз йорттан җәтрәк кыяклау ягын карады. Мөдир – җылы тун, итекләр кигән, бүрекле кемсә – тупас, калын тавыш белән:

– Әнә, күрәсеңме ишекне? Кер дә ят шунда буш урынга! – диде. Беренче карашка кайсы җенестән булуын анык кына билгеләп булмаслык ул кеше – хатын-кызлар затыннан иде. Хатын-кыз күргәч, Гафур кинәттән әнисен сагынып искә төшерде дә, сулыгып, тирән итеп сулыш алды.

Кар тавына тәмам сеңеп беткән тәбәнәк кенә йорт кәмәше дә димәссең үзен: коридор буйлап ишегенә тәртип саны сугылган берничә бүлмә тезелеп киткән. Гафур эләккән бүлмә 5 нче иде. Керүгә, тәрәзәләре бозланып каткан, тыштан кар көртләре томалаган бүлмәдә беравык һични күрми торды. Күзләреияләшкәч кенә, унга якын тимер караватны шәйләде Гафур. Аларда баштанаяк берүк төсле соры одеял бөркәнеп яткан бәләкәй гәүдәләрне чамаларга мөмкин. Гафур буш урыннарның тәрәзәдән ерагына букчасын куеп ятуга, караваты иләмсез ыңгырашып, шыгырдап куйды.

Ул тавышка күрше ятактагы тузгак чәчле, ябыгудан күзләре генә утырып калган бер малай башын калкытты.

– Кичә үлгән Максим урыны, – дип белдерде ул гамьсез генә карлыккан тавыш белән. Аннары одеялын башыннан ук төренеп ятты. Яхшырак ябынса да, таманга гына туры килә, бүлмәдә котып суыгы.

Төшке аш вакыты җитте бугай, коридордан «Обед!» дигән тавышка һәммәсенә дә җан керде. Кашыкларын алып, ишегенә «Столовая» дип язылган гадәти генә бүлмәгә җыелдылар. Биредә – кухня тирәсендә, пар чыгып торгангамы, берникадәр җылырак төсле иде. Җәмгысы утызлап бала озын өстәл янында урын алды. Чама белән алты яшьтән башлап Гафур яшендәгеләренә чаклы бар иде монда. Яңа килгән малайга да сабына ниндидер сан ермачланган әлүмин кашык тоттырдылар. Һәм ул шулпа сымаграк аш, ризык көтте. Һәрхәлдә, моңарчы госпитальләрдә әбәттә шулай була торган иде.

Ә монда? Кат-кат киенгән ике хатын ятимнәрнең алларына калай кружка белән чәйгә охшаш сыекча өләшеп чыкты. Балалар шул чәй савытына ябышып, кулларын җылыта-җылыта, һаман нидер көттеләр. «Ашмы? Нинди булыр икән ул: кәбестә шулпасымы яисә итле бәрәңгеме?» – дип уйланды Гафур. Тәҗрибәсез иде шул әле ул, дөнья күрмәгән. Ленинградның иң дәһшәтле, ачлык белән киселгән чоры иде бу. Эшләмәүчеләргә һәм дә балаларга бирелә торган паёк көненә төп-төгәл 125 граммга гына тарта иде. Гафурның алдына баланың кул битенә сыешлы ипи китереп куйгач, ул үз күзенә үзе ышанмады.

Ә бүтәннәр, шундый ук ипи кыерчыгын әләктерүгә, чәйдән башка гына эшен бетереп тә куйдылар. Гафурның һаман да ашамыйча, нәзберекләп, катып калуына гаҗәпләнгән балаларның берсе, кан тамырлары күренеп торган кәкре агач ботагыдай кулын сузды да, тегенең икмәген каптырып, йотып та куйды. Беркем һични дәшмәде, теге балага кызыгып карап тордылар әле. Гафурның, бу хәлдән өнсез-тынсыз булып, чәй шыпырдатудан башка чарасы калмады. Яңа гына килгән башы белән Гафур тәнендә чыкмаган җанын асраган ул сигез-тугыз яшьлек балага нәрсә дип әйтсен дә нинди җәза бирә алсын ди инде?!

## 11. Бүген чират кемнеке?

Бүген Гафур, ниндидер зур сөенеч көткән кебек, үзендә гайре табигый күтәренкелек тоеп уянды. Ул хис гел ашыйсы килү теләгән дә артка чигендерде. Туган авылында бәйрәм таңында шулай була торган иде, һич сәбәпсезгә күңел җилкенүе, эчке талпыну...

Аның балалар йортында яши башлавына өченчеме, дүртенчеме ай китте... Элеккечә ачлык тырнагыннан котылу өчен, яшәү хакына көрәшү, тартышу белән тулы гомер иде бу. Дөрес, февраль аеннан көнлек икмәк нормасын күпмегәдер арттырдылар. Чеметем генә май, кеше башыннан тагын бер уч ярма өстәп бирә башладылар. Моны тәрбиячеләр Ладога күле аша «Тормыш юлы» дигән нәрсәнең ачылуы белән аңлаттылар. Менә бүген балаларга тары ярмасыннан пешерелгән зур кәстрүлдән кайнар ботка өләшәчәкләр һәм шуның өстенә, бушап калган ул кәстрүлне ялап чистарту бәхете чират буенча Гафурга елмайды. Шуңа да йөрәге ярсып тибеп тора икән бит аның. Тамак кайгысы барлык нәрсәләрдән дә өстенрәк иде шул. Гафур әнисе белән сеңлесен юксыну хисенең дә кими төшүен сизә иде хәтта. Юк, ул аларны көн дә уянуга искә төшереп ала. Әмма әнисе сыйлаган ашамлыклар белән бәйле рәвештә генә хәтергә килә иде алар. Туйганчы ашау хәсрәте барысын да җиңә иде шул.

Шәүлә төсле булып калган бала-чага акрын гына кыймылдый, хәрәкәтләнә, аягына баса, йөри башлады. Әгәр җанга тансык ботка көтеп тормаса, урыннан кубарга һичкем дә мәҗбүр итә алмас иде аларны. Ашханәгә керер алдыннан корышып, бөрешеп беткән кулларны юасы бар икән әле. Бармакларына аннан-моннан салкын су тидергәч, мөмкин кадәр ашыгып, сөйрәлеп, өстәл янына барып кунакладылар. Барып җитүе генә озак булды булуын. Җылымса чәйгә ияртеп, кул яссуы кадәр икмәк белән ике-өч кашык ботканы күз ачып йомганчы ач карынга озаттылар да. Иртәнге аш шуның белән тәмам, әмма балалар өстәл яныннан торып китәргә ашыкмыйлар, нидер көтәләр. Ниһаять, тәрбияче-мөдир, Гафурның исемен әйтеп, әле генә боткадан бушаган кәстрүлне аның ике кулына тоттырды. Уннарча күз Гафурга көнләшеп карый, уннарча күз аның һәр хәрәкәтен күзәтә, балаларның күбесе, үзләре дә сизмәстән бугазларын хәрәкәтләндереп, төкерекләрен йотып куялар иде.

Гафур үзенең караваты янындагы күршесе Диманың, тәрбиячеләр үзара «картлач» дип кенә йөрткән, чыннан да, ябыгуның иң соңгы дәрәҗәсенә җитеп, тегәрҗептәй нәзек муен тирәсендә, иягендә сакал кебек берничә озын ак төк күренә башлаган җиде яшьлек малайның үзенә текәлгән коточкыч

карашын күтәрә алмады, сүзсез генә кәстрүлне аңа сузды. Тегесе кәстрүлне Гафурның кулларыннан тартып диярлек алды да, ашыгу-пошыгуыннан танавын буяп, савытны яларга, бармаклары белән сыдырып-сыдырып алырга тотынды. Ашап туймаган ялап-ялманып туймас дигән хакыйкатьне кая куясың?! Диманың һаман да ачкүзләнеп, башы белән кәстрүл төбенә үк төшәргә итүен күреп, тәрбияче суда югандай ялт иткән савытны сукрана-сукрана тартып алды. Гафурга ни өчендер ачу белән карап:

– Бу айда синең чиратың үтте, татар малае! – диде.

Гафурның көтеп алган куанычы шулай тәмамланды. Инде хәзер аларга төшке ашка, әбәткә хәтле җан асрыйсы калды. Аннары кичке аш турында хыялга бирелеп ятачаклар. Эреле-ваклы ятимнәр, ятимәләр, күбесе күптәннән «картлач бала» хәленә төшкән ач нарасыйлар салкын ятакларына барып аудылар. Гафурның исә мөдирнең нәфрәтле йөзе күз алдыннан китми дә китми генә бит. Аның турында уйлаган саен уйлата иде. Ни өчендер тәүге көннән үк Гафурга үчле булды ул убырлы. Малайның исем-фамилиясе бүтәнчәрәк булгангамы? Ач кешенең ачуы яман дисәң, ике иякле, түм-түгәрәк, кабартма битләре бу хатынның һич кенә дә ашауга кысылуын күрсәтмиләр бит. Шулай да бүтән өч тәрбиячедән нык аерыла ул. Нина апасы да, Валя апасы да, бер үк вакытта экспедитор вазифасын башкаручы Соня апасы да чиктән тыш ябыклар, яңаклары суырылып эчкә баткан. Балалар кебек үк ризыкка туенганнары юклыгы әллә кайдан сизелеп тора. Әмма ләкин яхшы, рәхимле кеше сыйфатлары төс-кыяфәтләрендә, үз-үзләрен тотышларында, якты чырайларында чагыла иде.

Икенче көнне Гафур ятагы янына сөйкемле, элеккеге матурлыгы чем-кара күзләрендә, туры, килешле борынында һәм коңгырт куе чәчләрендә сакланып калган Соня апасы килде дә:

– Әйдә, минем белән базага барабыз, – диде. Малай нинди базга төшәсе дип төпченеп тормады, бәрәңге базынадыр инде дип фараз кылды. Ул булдыралганча җәһәт кенә урыныннан сикереп торган итте.

Балаларныкыннан азга гына зуррак агач чана өстерәп, Нарва заставасына таба кузгалдылар. Гафур Соня апа мине башкалардан өлкәнрәк булганга сайлагандыр дип уйлаган иде. Кар көртләрен ерып, ишегалдын узуга, күп кеше йөргәнлектән, беләүләнеп шомарган сукмакка чыккач, Соня апасы, малайның тузып беткән шарфын рәтли-рәтли:

– Синең атың Гафурмы әле, иркәм? – дип, саф татарча сорап куймасынмы. Малай, көтелмәгән ихлас җылы мөнәсәбәттән аптырап, тотлыга-тотлыга:

– Ә-ә?.. Әйе, – дигән сүзне телен көчкә тибрәтеп әйтә алды. Аның, әнисен югалтып, Ленинградка килеп эләккәннән бирле ана телендә бер кәлимә сүз ишеткәне юк иде ләбаса. Искә-аңга килеп, ашыга-ашыга:

– Апа, сез Казаннан мәллә? – диде.

– Юк, үскәнем, мин Ырынбур ягыннан. Үзем Сания атлы булам.

Такыр сукмак бетеп, кеше таптап өлгермәгән, карлы өлеше белән алышынгач, тук кешеләр өчен авыр буш чана кәмәше кулларын өзәрдәй булып артка тарта. Шунлыктан, юлның бу төшендә, сулышлары кабып, дәшмичә генә бардылар. Чанага бер атналык азык-төлек салып кайтырга чыкканда да, ихтыярсыз сүз ялганмады, сөйләшергә авырыксындылар. Уфылдап бара торгач, Сания апа:

– Бераз сулыш алыйк! – дип тукталды да, сәләмә киемнәре арасыннан ике-өч кабымлык икмәк телеме чыгарып, малайга сузды.

– Мә, энем! Алда тагы да кыен булачак...

Малай кыстатып тормады, ипине җәлт кенә капкалап ашап бетерде. Шуннан соң гына, Сания апасының читкәрәк борылып, ни рәвешле нәүмизләнеп басып торуыннан бу ризыкны үз авызыннан өзеп бирүен төшенде. Гафурга ничектер оят булып китте. Сания апасы исә бераз еламсыраган тавыш белән:

– Әниең бармы соң синең? – дип сорады.

Малай кыскача гына үзенең маҗараларын сөйләп бирде.

Сания апасы:

– Әниең исән калган булырга тиеш, энем. Табылыр, һичшиксез табылыр! – дип юатты.

Инде ярты юлны үткәннәр генә иде, искәртмәгәндә бәла-казага тарыдылар. Такыр сукмактан шома гына шуып барган уңайдан чана чабулап китте һәм сикелтәле-түмгәкле төштә кинәт ауды. Капчыктагы азык-төлек, кәнфит-мазар кар өстенә чәчелде. Сания җан ачысы белән ахылдап куйды. Моңа кадәр дә боларның йөген ач күзләре белән йотылып озатып калган халык бу хәзинәне шундук чолгап-сырып алды. Менә-менә болар тәмле-томлы ризыкка умарта күчедәй ябырылачак иде. Шунда Гафур ризыкны гына түгел, яраткан апасын яклап, үзен-үзе белештермичә: «Тимәгез!» – дип илереп, кулларын як-якка җәеп, капчык өстенә егылды. Шул арада: «А ну, отойди!» – дигән каты тавыш ишетелде һәм моряк киемендәге егет:

– Күрмисезмени, детдомовские! – диде. Кешеләр төркеме теләр-теләмәс кенә таралды. Нинди генә ач булсалар да, алар читкә чәчелгән, тәгәрәгән бер генә кәнфиткә дә тимәделәр. Чөнки ятим балалар өлешенә керү вөҗданның азаккы чиге, иң зур гөнаһ булып санала иде. Сания апа шатлыгыннан Гафурның иңеннән кочып алды. Кирәк чакта менә ничек кыю, батыр малай бит ул дип, сүзсез генә мактавы иде аның. Алар арасында ничектер туганнар арасында гына була торган эчкерсез якынлык, кардәшлек тойгысы урнашты. Татар каны чит җирдә бер-берсенә ныграк тарта түгелме икән әле ул?! Милләттәшең белән очрашу куанычы күңелләрне бөтенләе белән эретеп ташлавы да хак. Кыйммәтле йөкне, яшәү чыганагын, арып-талып, тәмам алҗып кайтарып тапшыргач, ишектән кергәндә фәрештә булып күренә башлаган Сания апасы:

– Икенче юлы да сине аппарам, барырсыңмы? – диде. Малай, тиз-тиз генә баш кагып, ризалыгын белдерде. Ул бүген үзен күкнең җиденче катында кебек бәхетле итеп сизде.

## 12. Барысы да фронт өчен

Ачмы син, тукмы, вакыт үзенекен итә. Менә инде кояш та җәйгә таба тәгәри. Шуңа да карамастан, иске ертык капчыктан коелып барган ашлык бөртекләре кебек, ачлыктан, гаҗизлектән балалар да бер-бер артлы үлеп, тормыш арбасыннан билгесезлек базына төшеп кала, җир йөзеннән җуела барды. Гафурның күршесе Дима үлде, аның артыннан тагы ике малай; янәшәдәге бүлмәдән берьюлы дүрт кызчыкны Пискарёв зиратына озаттылар.

Ә аннары Гафур ул бәхетсез бәләкәй затларның чутын да югалтты. Көн саен иртән торгач, тагын кем җан тәслим кылган икән дип калтыранып китә торган булды. Калтыранмас иде дә, Ирдәүкә мәетләрне чанага салып, зиратка илтүне олырак дип исәпләнгән Гафур белән бер яшькә зуррак Глебның икесенең өстенә йөкләде бит, караҗан. Эчең-эчкә ябышканда, кайчагында хәтта кашык күтәрерлек хәлең калмаганда, зур чана тартып барулары әҗәл белән бер иде. Мөдир бу читен эшне гел татар малае җилкәсенә салуны Сания апасына үч итеп тә эшли иде бугай. Тегесе Гафурны яклап сүз ката калса: «Азык-төлек базасына бик ашкынып чаба, монда ни ярамаган?» – дип, авызын каплый да куя. Ярый әле, карлар эреп, асфальт юллар ачылгач, үлекләрне махсус машина белән төяп китә башладылар.

Җәйгә чыкканда, үз туганыдай газиз, кадерле, чиксез якын кешегә әверелгән Соня-Сания апасын каядыр бүтән эшкә җибәрделәр. Ирдәүкәнең бәйләнүенә түземе төкәнгән, күңеле корыган булса кирәк. Ирдәүкә булмаганда, очраклы рәвештә тәрбиячеләрнең колакка-колак чыш-пышыннан үлгән балалар паёгын яшереп баручы мөдирнең кыңгыр эшен нәкъ менә Сания апасы фаш иткәнен ишетте Гафур. Менә нидә икән хикмәт! Курку белмәс, батыр йөрәкле яраткан апасына соклануын кем беләндер бүлешәсе килеп китте аның. Ә кем белән?!

Җәй җиткәч тә, балалар йортындагы хәлләр әллә ни үзгәрмәде. Ипинең көндәлек күләмен тагын киметтеләр. Хәзер ул шырпы кабы тиклем генә булып калды. Ирдәүкә анысын да күпсенә башлады кебек. «Дармоедлар, фронт өчен, җиңү хакына нинди файдагыз бар соң сезнең?», – дип, бичара ятим балалар өстенә җикеренеп, аларны битәрләү, рәнҗетү, кыерсыту берни дә тормый иде аның өчен. Кайдандыр ишетеп, «боевое задание» гамәлен казып чыгаручы да ул иде.

Урамнарда бераз юл кипшенүгә, тәрбиячеләр җитәкчелегендә һәркем көнлек «задание» буенча снаряд, патрон гильзалары җыеп, эчен-тышын чистартып-ялтыратып тапшырырга тиеш иде. Норманы тутырмасаң, үзеңә үпкәлә, икмәкнең бер өлешен кисеп калалар. Шәһәрне дошман күктән дә, җирдән дә каты утка тоткан кыямәттә норманы үтәү хакына урамнарда селкенеп йөрү куркыныч иде. Әнә ич, «кара тәреләр» бомбалар яудырганда, махсус яшеренү урынына качып өлгермәгән өч бала шул гильзалар аркасында һәлак булды. Ирдәүкәнең исе дә китмәде. «Ризык күбрәк тамар калганнарына», – дип кенә куйды.

Гафурга карата элеккечә этләнүе дә кимемәде. Заданиенең дә аңа саллырагы, җелегеңне суыра торганы тиде. Гафур уртын канатырлык итеп, тешен кысып түзде, үзенекен барыбер үтәп килде. Ачлыктан, витамин җитмәгәнлектән күзләре тоныкланып, тавык күзе сырхавы белән интеккән бүтән бала-чагадан аермалы буларак, ул гильзаларны ничектер җәһәтрәк таба иде. Хикмәт шунда, көтү-көтү булып, итәк-чабуга тагылышып йөрми, күрше урамнарга да барып җитешә ул. Менә бүген дә үзләреннән еragрак җиргә килеп чыкты. Һи, монда-а-а! Адым саен! Малай, тизләнеп, үзенчә җитез кыланып, һәр гильзаның эчен сулышы белән өрә-өрә чистартып букчасына тутырганда, кемнеңдер көзгедәй ялтыраткан күн итекләренә юлыкты... Башын күтәреп караса, кызгану катыш кызыксыну белән итекләр иясе командир абый карап

тора икән. Ул коры сөяккә калган, чандыр малайны күтәреп торгызды да: «Нишлисең?» – дип сорады.

– Гильза җыябыз, фронт өчен! – дип, Ирдәүкә өйрәткәнчә җавап кайтарды малай.

– Для фронта?! Похвально! – диде хәрби кеше. – Ә кем сиңа моны эшләргә кушты?

Малай сүзсез генә балалар йорты ягына күрсәтте. Хәрби кеше исә:

– Әйдәле, күрик әле, ничек яшисез икән? – дип, малай артыннан иярде.

Ирдәүкә бүлмәсенә кереп киткән хәрби артыннан кан калтырап калды бала-чага. «Заданиене тагын арттыра икән», – диештеләр. Ул яктан каты-каты, ачулы тавышлар яңгырап торды. Ул гел ир-атныкы иде. Нәтиҗәсе көтелмәгәнчә булды. Ирдәүкәне эштән кудылар бугай, бүтән күзгә чалынмады. «Задание» үтәү дә бетте. Паёк күләмен тагын илле граммга арттырдылар.

## 13. «Сезнең балагыз түгел ул!»

Гильзалар җыюдан котылгач, иркенәеп киткән балалар, ярымкараңгы шыксыз бүлмәләрдән гарык булып, урамга, кояш нурларында иркәләнеп утырырга гадәтләнделәр. Нәкъ җылыга туймаган карт-коры инде болар. Тире һәм сөяктән генә оешкан бу «картлач балалар»ны үзләренең дә алардан әллә ни артык җире булмаган үткән-сүткән кешеләр, жәлләп, баш чайкый иде. Тротуар буена боек чыпчыклар кебек тезелешкән балалар исә андый гына кызганулы карашларны игътибарга алудан күптән узган, бөтен дөньясына битараф иделәр. Һичкем, һичнәрсә кызыктырмый иде аларны. Хәтта ашау кайгысы да күңелдән җуела башлагандыр инде!

Менә, балалар каршына чәчәкле яулык бәйләгән, ир-ат җилкәсенә генә таман алагаем озын шинель кигән, авыр күн итекле, бәләкәй, көпшәк гәүдәсен ике яктан ике култык таягы белән терәтеп, бер хатын килеп басты. Ачлыктан төпкә баткан нурсыз күзләре белән балаларның һәркайсын бер-бер артлы карый да, янә җеп бөртекләп, берәм-берәм күз карашыннан үткәрә. Ни кирәк аңа, ни эзли ул – һичкем илтифат итми әле. Бетмәс монда аның ише ач сукбайлар, җыен әтрәк-әләм!

Кинәт хатынның бер култыксасы, шапылдап, асфальт җиргә төште дә, һәммәсе ирексездән дәррәү сискәнеп куйды. Яше анык булмаган әби-хатын үзе дә камырдай гәүдәсе белән җиргә таба бөтенләй сыгылды һәм аның бәгыреннән бер генә сүз саркып чыкты: «Улым!»

– Улым... – дип кабатлады ана кеше, кояш нурларында изрәгән Гафурга туп-туры карап. Аның ифрат тилмереп әйткән сүзе таш җанны да уятырлык иде. Әмма Гафур, күпме өметләнеп караса да, аны танымады. Йолкыш кыяфәтле, ак чәчләре яулыгыннан бүселеп чыккан, зур күзләре белән ашардай булып караган бу иләмсез хатын ничек Гафурның әнисе булсын ди. Аның әнисе матур, чибәр, зифа буйлы... Юк, Гафур танымады, һичкемгә дә охшата алмады аны. Бары тик ана гына, күңел күзе белән үз баласын таныды, ялгышмады. Бу Өммегөлсем апа иде. Ул, иңрәп, газиз баласын күкрәгенә кочуга, Гафур аның яулыгыннан бишектән үк якын, таныш исне сиземләп алды төсле. Әйе, бу һични белән дә бутап булмаслык татлы туган өй исе, әнисенең хуш исе иде. Малай тетрәгән, сөенеченнән

каушаган, ни кылырга белми иде, әмма бу могҗизалы очрашу бер генә тамчы күзе яшен дә сытып чыгаралмады. Аның күз яшьләре күптән кипкән иде. «Әнием» – дип кенә пышылдый алды Гафур. Өммегөлсем апа исә бу ярты елда беренче тапкырдыр, мөгаен, мышык-мышык елап ук җибәрде.

Иланһи бер мизгел иде бу: чиктән тыш ябык, әни дигән сүзне күптән оныткан мәгъсум балалар үзләре ише малайның әнисе белән кавышуына шаһит булдылар. Аларның да күңел төпләреннән ана дигән кадерле, газиз затка бәйләнешле матур хатирәләр, якты тойгылар уянды, калкып чыкты кебек. Бу нарасыйларның һәркайсының газизләрдән-газиз үз әнисе, яклаучысы булган бит, булган!

– Әнием, син кайдан болай, ничек таба алдың мине? – дип сорады, ниһаять, искә-аңга килгән Гафур.

– И-и, улым!.. Алары соңыннан... Әйдә, хәзер нәчәлникларыңа әйт тә китәбез, – дип кабаланды әнисе.

Әмма сөйләве, фараз кылуы гына ансат икән ул, ә менә кеше кадәр кешенең язмышын хәл иткәндә, кәгазь, документ дигәннәре алга чыга да бөтенесен дә буташтырып, бетереп ташлый. Үзара мөнәсәбәткә шәхес турындагы таныклык килеп керсә, аның юклыгы да мәгълүм булса, «Бер кәгазьсез – сүз мәгънәсез» дигән төслерәк инде... «Кәгазең юк икән, син – әкәм-төкәм» дигәне дә бар. Ягъни мәсәлән, документсыз-нисез синең белән сөйләшеп тә тормыйлар.

Яңа мөдир, киң җилкәле, зур башлы ир уртасы кеше, үз карамагындагы бала, ягъни мәсәлән, Гафур турында сүз катуга, Өммегөлсем ападан иң әүвәл документ таләп итте. «Сез аның үз балагыз икәнен ничек исбатлый аласыз? Моңарчы кайда идегез? Кайда эшлисез?» кебек сораулар белән күмеп ташлады. Кырыс тавышлы зур нәчәлник алдында каушап калган бичара ана рәтләп сөйли дә алмас булды, сүзләренең буталчыклыгы белән үк мөдирдә шик-шөбһә уятты. Ниһаять, тәрбияче аның кулына стакан белән су биргәч, Өммегөлсем апа, тынычлана төшеп, былтыр бомбёжка вакытында каты яраланып, бар әйбере белән документларын югалтуын, хәзер оборона заводында каравылчы булып эшләвен әйтә алды. Әмма мөдирнең үз туксаны туксан иде, төптән уйлап караганда, яңа гына җаваплы вазифада эшли башлаган кешенең барыннан да битәр кәгазь документка табынуы табигый иде ул болгавыр дәвердә.

– Шулай да булсын ди. Эшегездән берәр таныклык китермичә ышана алмыйм, – дип, кырт кисеп әйтте ул. Үзе Өммегөлсем апаны без белән чәнечкәндәй тишеп карап утырды.

– Соң, алайса, зинһар, улымның күлмәген салдырып карагыз! Уң як калак сөяге астында кечкенә генә җәрәхәт эзе бар аның! Балачакта рәшәткә кадагына эләгеп... – дип иңрәп кычкырды Өммегөлсем апа. Бүлмәдәге тәрбиячеләр дә, анага теләктәшлек белдереп, баш кактылар. Гафурның өстен тиз генә чишендереп карасалар, нәкъ шулай, әллә кайчангы яра эзенең кызарып торуы күзгә ташланды. Тәрбиячеләрнең дә үтенечен аяк астына салып таптаудан тайчынды яңа килгән мөдир, балигъ булмаган Бәширов Гафур Рамазан улын әнисе карамагына тапшырды. Җитмәсә, рәхиме килеп, тантаналы төстә малайга ике көнлек ризык – 300 грамм

икмәк бирергә карар итте. Әмма ни өчендер малай турындагы белешмәне кайтарып бирергә онытты ул. Каушавыннан Өммегөлсем апа да ул хакта хәтереннән чыгарган иде.

## 14. Сагынычлы хат

Капкадан чыгуга, ятимнәр йорты тирәсеннән мөмкин кадәр җәтрәк югалырга омтылды аналы-уллы. Аннан чыгып, малайны кире борырга мөмкиннәр төсле тоелды аларга. Каршы очраучылардан да берәрсе «документ!» дип, якасыннан тотып алыр кебек иде һаман...

Тавык кетәгедәй тәбәнәк бина күздән югалгач кына, Өммегөлсем апа, сулышы кабып, уфылдап, юл читендәге эскәмия өстенә ауды, янына Гафурны итәгеннән тартып утыртты. Икесе дә, ачлыкны онытып торып, шул рәвешле тын гына очрашу шатлыгын кичерә иделәр. Моны бәхеткә санау Ходайның һәр бирмеш көнендә фәкать ашыйсы килү теләге белән җәфаланган, үлем белән тартышкан мескен адәмнәргә карата туры килеп тә бетми торгандыр бәлки. Әмма икесенең дә очрашу рәхәтен татулары хак иде... Кинәт ана, чыраен сытып, имгәк аягын ышкырга кереште. Сул аягының тубыгында канлы җәрәхәт кутырлап тора икән. Шул яра Гафурга былтыр станса янындагы фаҗигане искә төшерде:

– Әни, сеңлем кайда соң? – дип, аның күзләренә тутырып карады ул, сабыйны вакытлыча кемнәрдәдер калдырып кына торуына өметләнеп. – И, балам, Шәфикабыз юк бит инде... – дип, йөрәк сулкылдавын басар өчен бер генә үксеп алды ана: авыр хәсрәттән еларга да көче калмаган иде аның. Йөрәк сызлавын эченә йоткач, фаҗигале хикәятен дәвам иттерде:

– Теге вакытта бит бомба шартлаганнан соң, аңымны җуйганмын. Үземне белештерерлек хәлгә килгәндә, нарасыем... кан эчендә җан биреп ята... Үземнең сул аягым өзелгән дип торам башта, ярый әле, зарары күп булмады... Гафур, Гафур дип, күпме кычкырсам да, син табылмадың... Үлүчеләр, җәрәхәт алучылар хәтсез иде бит анда. Кыямәт көнендәгедәй, чистый. Ут, төтен... Һичнәрсә аерырлык түгел. Ваня абзаң белән Маша апаң да үлеп калдылар шул төштә. И-и, яхшы кешеләр дә иде мәрхүмнәр... Шул... Мине янәдән теге стансадагы бүлнискә кайтарып салдылар... Аннан тагын каядыр күчерделәр. Өч ай яттым аякка баса алмыйча тинтерәп. Рәтләнә башлагач, сине эзләргә тотындым. Балалар приютыннан эзләргә киңәш бирделәр. Берсен-бер калдырмадым, һәммәсен дә айкап чыктым, улым. Ачтан үлмәс өчен, оборона заводына эшкә кердем.

Гафур күңеленә тынгылык бирмәгән «Хәзер кая барырбыз соң?» дигән авыр соравын үзе дә сизмәстән телдән үк ычкындырып ташлаган икән.

– Бер дә хафаланма, балам, менә дигән фатирда торам мин. Әйдә, киттек, моннан ерак түгел ул, – дип, җилләнеп тормакчы булган иде дә, авыртудан сыны катып, кире урынына ауды ана. Ул үз җаена төшкәнче, аяк өянәге үткәнче, байтак вакыт узды. Гафур, абелхәят суы тапкандай куанып, кесәсеннән балалар йортының соңгы истәлеге – ике ипи кисәген тартып чыгарды:

– Мә, аша әле шуны, көч-хәл керер, – диде.

Тамак ялгап алгандай иттеләр. Шундый изге, татлы минутлар иде бу, әйтерсең, өйләрендә кетердәп торган бәлеш төбе кимереп утыралар...

Маяковский урамындагы бишкатлы ташпулатның икенче катына менгәндә, әнисе, адым саен туктала-туктала, җанланып сөйләнде:

– Цех башлыгы Андри Андреич урнаштырды мине монда. Хуҗалары эвакуасиядә, ди. Монда, улым, фатирларның күбесе буп-буш. Ташлап чыккан йорт кебек инде. Теләсә кайсына кер дә утыр!

Авыр, затлы ишекне ачып кергәч, ике бүлмәле фатирның да шәрәләнеп, шыр ялангач торуы күзгә ташланды. Бар булганы – башы түшәмгә терәлгән иләмсез юан шкаф та ике тимер тапчан белән ике урындык.

– Хәзер менә чәй кайнатып алырбыз, – дип, хәрәкәтләре ничектер шәбәеп киткән әнисе мәгълүм «буржуйка» тирәсендә кайнаша башлады. Гафур зур каланың асыл фатирына һич батмый торган тимер мич кәмәшенә гаҗәпсенеп карап торды. Капылт кына аның карел якларына поездда барганнары исенә төште. Аннан соң кимендә йөз ел үткән кебек...

Малай уйларыннан бүленеп:

– Әни, син ятып тор. Мин үзем, – дип, мич ягу эшен, мавыгып, үз карамагына алды. Бераздан корсагына иске газета кисәкләре, ватык-чытык җиһаз калдыгын йоткан мич, бу ягулыкка күңеле булгандай, тигез генә гөжли башлады. Чәй янында ике телем каткан ипи белән Өммегөлсем апаның Гафурга дип күз карасыдай саклап тоткан берничә прәннеге, биш-алты кәнфите куелды. Гафурның бу «байлыктан» күзләре яна башлады хәтта. Әнисе аны шул рәвешле сөендерә алуыннан үзе дә галәмәт куанып:

– Аша, улым, аша! Сиңа дип атап калдырганием! – дип, кайчандыр авылдагы сыман кыстый-кыстый ашатты. Шунда өйдәге түгәрәк табын, газиз әтисе хәтерендә янә яңарды малайның:

– Әти кайда икән хәзер? Исәнме икән? Ичмасам, хат-хәбәре дә юк, – дип күңелсезләнде ул.

– Кая дип язсын соң, улым? Йолкыш булып, теләсә кайда куна-төнә аунап йөр дә. Бу адресны белми бит әле ул! Менә хәзер икәүләшеп хат язарбыз, – диде Өммегөлсем апа, улына беренче кат күргәндәй яратып карады да ипи кыерчыгын аның алдына куйды. Улының тумыштан кечкенә буйлы, чандыр гәүдәсе ярты ел эчендә төенчек кебек бөрешеп калуын, ундүрт яшенә чыккач та, иң күбе тугыз-ун яшьтә булып күренүен күңеле белән сыкрап, әрнеп кабул итмичә мөмкин түгел иде. Малай исә әнисенең кызганулы карашын сизмичә, үз уйлары белән мәшгуль. Әтисенең теге вакытта, авылда чакта, әле ерак юлга җыенганда, үзенә төбәп: «Яңа җирләрдә кармакка керкә балыгы гына каптырырсың рәхәт чигеп», – дип, теләк теләгәне капылт кына хәтеренә килде менә. Тәкъдирендә хәтсез кыен-җәбер, хәсрәт күргән ата кеше, туган туфракта табылмаган бәхетне, кармакка эләктергәндәй, бәлки шунда, яңа җирләрдә тотарбыз койрыгыннан дигән сыман, шул рәвешле үзенең яшерен татлы хыялларын да кушып әйтмәде микән ул ихлас теләкләргә? Югыйсә бу кадәр дә талпынып ашкынмас иде әтисе чит-ят төбәккә, кулдан ычкынган бәхет кошы шәүләсе артыннан. Азагы бер дә күңелле очланмады бит. Әнисе белән үзенең бүгенге четерекле, авыр хәлләре алга таба тагы да мөшкелләнергә тора әле монда... Чикнең актыгына килеп терәлделәр... Зурая барган саен шуны да ачык тойды Гафур: шатлык дигәне бик тиз генә килә дә китә икән; хәсрәт-кайгы исә гел синең тирәңдә, өстеңә ябырылу өчен үзенә җайлы вакытны көтеп кенә тора.

Җиңел сөякле малай, авыр уйларыннан айнып, көрсенеп куйды да, әнисе әйтеп торган сүзләрне үзенчә төзәткәләп, фронттагы әтисенә хат язарга утырды... Ул әнисенең бөтен әйберләрен-документларын, барысын да шушы болгавыр мәхшәрдә югалтып бетергән сурәттә дә, фронттан җибәрелгән солдат хатын бөтидәй саклап йөртүенә шаклар катты. Менә хәзер шул таушалган кәгазьдә теркәлгән адрес буенча яза да инде сәлам хатын.

«Сагынычлы хат башы, хат алуга, язгыз каршы», – дип, килешле генә башлап җибәрде дә Гафур, чуктин-чук сәламнәр юллап, бер дәфтәр битенә генә сыешлы итеп, әнисе белән үзенең бүгенге хәлләрен кыскача гына тасвирлады. Әмма әнисе белән икесенең хәзерге аяныч көнитеше турында ләм-мим. Аннары әтисенең сау-сәламәтлеген сорашты. Әнисе әйтеп торганча, «Кышын аякларың өшемиме?» дип тә өстәде. Әнисе биреп җибәргән бәйләгән йон оекларны гел киеп йөрергә киңәш итте. Хәким җизнәсенә дә, очраткач, ялкынлы сәлам әйтүен сорады. Фашистларны әнисе белән үзе өчен дә каты тукмарга кушты да хатны янә сагынычлы, кайнар сәламнәр белән бетерде. Кәгазь битен өчпочмак рәвешендә төреп, аның тышкы ягына хәрби часть номерын сырлады да әтисенең исем-фамилиясен язып куйды.

– Почта яшниге кайда икән монда? – дип, әнисе алдында җәһәт кыланып, урамга чыгып китте. Почта тартмасын тиз генә табалмады Гафур. Күршедәге йорт, снаряд төшепме, бомбаданмы, ялып-җимерелеп хәрабәгә әверелгән. Ни гаҗәп, бинаның җәрәхәтләнми калган почмагындагы почта әрҗәсе генә һични булмагандай төзек-имин килеш, бары тик аз гына кыйшаеп эленеп тора иде. Әмма малай аны хат белән куандырмады (әллә алалар аны моннан почтальоннар, әллә юк), шактый гына талчыга башласа да, бүтәнен эзләп китте. Бәхеткә, күрше урамдагы ак кирпеч йорт төзек, почта әрҗәсе дә урынында иде. Сагынычлы сәлам хаты Рамазан абзый сугыша торган ерак якларга, фронтка очты...

## 15. Бадаев күчтәнәче

Икенче көнне иртән соңгы ипи кисәген кайнаган суга манып ашадылар. Өммегөлсем апа эшкә китте. Гафур озата барам дип ни угаланса да, әнисе ризалашмады:

– Йөрмә, улым, юкка көч түгеп. Бераз рәтлән... Менә хәл керсен әле... Мин кичкә генә кайтам, – дип әйтеп чыгып китте. Ул атлаган саен култык таякларының тукылдап-шыгырдавы шактый гомер ишетелеп торды. Бик авырлык белән йөри шул әнисе, йөрү түгел – өстерәлү инде бу. Нишлисең, ачлыктан котылу өчен нинди генә корбаннарга бармыйсың. Ике кешегә бер азык-төлек карточкасы белән күпмегә хәтле сузарлар, белгән юк...

Ялгыз калган малай эч пошудан ике бүлмәне дә җентекләп карап әйләнде. Бер почмакта яткан рәсемле журналны кулына алып, ятакка барып ауды. Йокымсырап киткән генә иде, кем әйтмешли, урта авылда этләр өрә башлагач уянды. Тагын ач карынлы корсак кайгысы биләп алды аны. Ул, торып, хет кайнаган су чөмерергә дип, мич янына барса, ни күрсен, кәгазьгә төргән шырпы кабы шае гына ипи катысы тора. Моны иртән, үз авызыннан өзеп, әнисе шыпырт кына улына куеп калдырган иде. Гафур корсагын шуның белән алдады да, хәлсезләнеп, тагын тапчанга сузылды.

Әнисе кичен, арып-талып, соң гына кайтып керде. Алай да кәефе ярыйсы гына кебек иде үзенең. «Хәзер, балам, хәзер!» – дип, өметләндергеч, кәефле тавыш белән сөйләнә-сөйләнә, шинель кесәсеннән бәләкәй генә төенчек тартып чыгарды. Рус матрёшкаларын сүткәндәй, ул әйберне аралап, аның артыннан газета кәгазенә төргән тагын берсен ачып җибәргәч, ниһаять, йодрык хәтле ипи, каракучкыл төстәге кәнфиткә охшаган нәрсә килеп чыкты.

– Монысы – Бадаев кучтәнәче! – дип кенә көлемсерәп аңлатты Өммегөлсем апа, таштай каты нәрсәне пычак белән кискәләргә маташып.

Кара туфрак белән катыш бу әйберне авызга алуга, утта янган шикәр тәмен, бераз карамель тәмен тойды кебек Гафур.

Госпитальдә каты бомбёжкалар вакытында шул исемне еш атауларын да искә төшерде. Әйе, дошман Бадаев складларын бомбалар белән яндырып көлгә калдыргач, андагы меңнәрчә тонна шикәр эреп туфракка сеңә. Шуны халык куптарып, чистартып кимереп йөри. Шәһәр советы шул массаны махсус команда белән җыйдырып, кондитер фабрикасында эшкәртеп, кәнфит рәвешенә китереп, кибетләрдә сатуны оештыра. Халык бу тәгамне «Бадаев кучтәнәче» дип шаяртып мактый-мактый ала. Чөнки бөтен кыйммәте-хикмәте, аның арулыгы-чисталыгында түгел, ә туклану матдәсендә. Бу ризык, ачтан үлеп баручы адәмнәргә күпме булса да калория өстәп, яшәү көче бирде. Алга таба да хәтсез кешене үлем якасыннан тартып алырга ярдәм итүе хак түгелмени шул татлы кара җирнең?!

– Теш үтми үтүен, ләкин суырып йөрергә үтереп биргән инде. Заводтан бирделәр, рәхмәт яугыры, паёкка өстәп! – диде ана, улының бу чит-ят азыктан бик разый булуына куанып. – Аллаһы теләсә, иртәгә исполкомга барабыз да сиңа да ипи паёгы ясатабыз, улым, бер дә кайгырма!

Ул көнне Өммегөлсем апа эшкә бармады. Киттеләр аналы-уллы райисполком дигән учреждениегә. Тиз генә очлап чыгарбыз дигән теләкләре гамәлгә ашмады, эшләре уңмады. Китап зурлыгындагы ачык уем аша гына аралашучы тоташ кара кашлы, шундый ук кара төкләр өске иреннәре өстенә дә тибеп чыккан хатын, гозерләрен аңлаткач, гамьсез, төксе йөзен кыйшайтып, тупас тавыш белән:

– Таныклыгы бармы?! Берәр белешмә?! – дип, бер-ике сүз генә атты да башын янә өстәлгә кадады. Ананың тагын бутала-чутала нидер аңлатырга маташуы бушка китте. Теге хатын таш кирмән төсле каты, битараф иде. Өммегөлсем апа бик тә талкыткач кына, чыраен һич үзгәртмичә, Некрасов урамындагы балалар йортында теркәлгәннәр исемлеген актарды. Аннан Бәширов Гафурның фамилиясен эзләп тапты булса кирәк һәм «Улың бит паёгын шуннан ала!» – дип, боларны өнсез итте. Тагын нидер аңлатудан гаҗиз иде ана. Мыеклы хатын да касса тишеген шап итеп ябып куйды.

Икесе дә, тәмам хәлдән таеп, рәнҗеп, урамга чыгып утырдылар. Инде нишләргә? Дөреслек эзләп, Некрасовкадагы балалар йортына бару турында уйламады хәсрәтле ана, анда барса, улын алып калуларыннан шүрли иде. Гафур да пошаманга төште. Шулай әлсерәп, мәлҗерәп утырганда, әлеге бинадан чыгып барган ниндидер хатын-кыз тукталды да гадәттән тыш гаҗәпсенеп:

– Гафур, бу син түгелме соң?! – диде. Малай торып, күзләрен тутырып карады һәм ирексездән еламсыраган, кызганыч тавыш белән:

– Сания апа! – дип кенә әйтә алды. Аның күзләрендә очрашу шатлыгыннанмы, әллә хәленең мөшкеллеген тоюданмы, яшь бөртекләре ялтырады. Аяныч хәлләре турында ике-өч сүз катуга, барысын да аңлады элекке тәрбияче. Үзалдына: «Учёттан төшермичә, баланың өлешен алып яталар, димәк!» – дип куйды да тәвәккәл, кыю кыяфәт белән янә бинага кереп китте. Сания апа кем белән, ни сөйләшеп, ничек эшне көйләгәндер, анысы караңгы, әмма ләкин Гафурның законлы паёгын бирдерүгә иреште. Ул анда азык-төлек бүлегендә эшли булып чыкты. Өммегөлсем апа, ничекләр генә рәхмәтләрен белдерергә белмичә, әле аның җиңенә ябышты, әле иңенә... Шәфкатьле хатынны оялтып, уңайсыз хәлгә куеп бетерде, менә-менә аның алдына тезләнер дәрәҗәсенә житте кебек. Бәшировларны хәзергә ач үлемнән йолып калган, йолкып алган үзебезнең татар кызы, гүзәл табигатьле Сания иде шул ул!

## 16. Үз кызыбыз булыр!

Гафурга да икмәк карточкасын әмәлләгәч, Бәшировларның эшләре көйләнде дияргә булыр иде. Юк шул әле, тешләрен ыржайткан әҗәл беразга гына чигенде. Каядыр яшеренеп, үз вакытын көтеп кенә тора кебек ул. Бөтенләй аның хөкеменә калмас өчен ипине сак тотарга, валчыгын да сарыф итмәскә тырышалар. Аз-азлап, кош-корт сыман чеметеп кенә капкалыйлар. Күңелдә исә гел ашыйсы, әллә ни дә түгел, нибары бер туйганчы кара ипи ашыйсы килү теләге тыпырчына!

Өммегөлсем апа эшкә йөрүен дәвам итә. Аңарга эшчеләр паёгы тиеш, шунысы хакына түзә, өстерәлеп булса да, бара-кайта. Гафур, ир-егет башы белән әнисенең бердәнбер паёгына аркаланып ятудан ифрат уңайсызланып, оялып, әллә ниләр уйлап бетерә. Ә гаҗизлектән гасаби уйлану-борчулар, үз чиратында, контузия кәсафәтен – вакыт-вакыт коточкыч баш авырту өянәген кузгата иде малайның. Соңгы арада аның бу хәләте, төзәлмәс чире кузгалу аеруча ешайды. Йокысыз төннәрдә улының баш сызлавыннан тешләрен шыгырдатып изалануын, боргаланып-борсаланып ятуын әнисе дә күреп, белеп тора. Шуңа күрә улының оборона заводына барып, эш сорау ниятен хупламый гына түгел, катгый төстә каршы иде. Шулай да предприятиенең сәламәтлек пунктында эшләүче яхшы танышы Вера Петровнаның кылларын тарткалап карады Өммегөлсем апа. Янәсе, бомбёжкадан соң нык биртелгән кеше теге яки бу хезмәткә сәләтлеме?

– Контузиядән соңмы? – дип кайтарып сорады табибә, хәйранга калып. – Кимендә ярты ел интенсив дәвалану таләп ителә! Ну, безнең шартларда, үзегез күреп торасыз, бу мөмкин дә түгел. Так что...

Шулай итеп, Гафурның заводта эшләве билгесез вакытка чаклы кичектерелә килде. Кая монда хезмәт турында сүз йөртү, малай үзе туклыклы, яхшы карауга, дәвамлы дәвага мохтаҗ иде.

Әмма нык ихтыярлы, игелекле, үҗәт Гафур, һичнинди хезмәттән дә баш тартмады, йөз җыермады. Киресенчә, үзенә карата адәм имгәге дигән сүзне ишетмәс өчен генә дә теләсә нәрсә эшләргә әзер иде. Фашистлар шәһәрне бомбага тотканда, тирә-якта ут, үлем шәүләсе уйнаклаганда, башкалар белән беррәттән түбәгә менеп баса. Дошман самолёты ташлаган кабызгыч

бомбаларны сагалап, түбәгә эләккән һәрберсен җәһәт кенә тимер кыскыч белән каптырып, сулы бакка яисә комлы әрҗәгә батырып сүндерергә өйрәнде ул. Кизү торулар еш була. Кайчагында көн саен уннарча һөҗүм ясый иде фашист тәреләре. Әлегә йортлары исән-имин, бөтен тора. Үзләренә дә зыян-зәвер тигәне юк, шөкер! Юкса бит, котырынулы андый һөҗүмнәр вакытында әнисе белән икесе дә бомбадан саклану урынына төшеп яшеренүдән туктадылар.

Барыннан да битәр хезмәт куючы әнисен мөмкин кадәр ач тотмаска яскана, бер-бер чарасын табарга омтыла иде Гафур. Менә бүген дә, ул эшкә киткәч, якын-тирәдәге урамнарны әйләнеп чыгарга булды. Җәй башы бит, берәр төрле ашарга яраклы үлән-чүлән табылмасмы дигән уй-хыялы бар иде аның. Өметләнеп чыкты чыгуын, әмма ләкин күзгә кырып салырлык үлән сабагы очратса икән! Ни сәбәпле эзләнеп йөргәнен белеп алган бер бабай аңа «Таврический сад»ка барырга киңәш итте. Малайның буй-сынын җентекләбрәк күз карашыннан үткәргәч, пошына биреп, мәгънәле генә: «Барып җитә алсаң!» – диде.

Еракмы, якынмы дип сорап тормады малай, бөтен җаны-тәне белән шул тарафка ашкынды. Какы, балтырган сыман үсемлек тә булуы ихтимал бит анда. Үзләренең авылындагы болында никадәр күп үсә иде алар: һи, иренмичә җыеп кына өлгер! Шактый озак теркелдәргә туры килде малайга. Ач кешенең атлавы инде аның! Үзенә генә кызу-кызу барган кебек. Көн узып, кич җиткән иде инде. Зарар юк, көн төнгә алышса да, көндезгедәй яп-якты. Ак төннәр балкышы лабаса!

Дөрестән дә, инде һичкемне сорашып борчымыйча, тәки үзе эзләп тапты ул мәшһүр Таврическийны. Караучысыз калган гөлбакчада, дөрестән дә, биек һәм куе булып котырып үскән чүп үләннәре хакимлек итә. Балачак дусты – кычыткан да күзгә керергә тора әнә. Какы, балтырган, юа, кузгалак, кәҗә сакалы, тәтемәсә, кычыткан кайнатып эчсәң дә, шәп бит! Гафур, сөенә-сөенә, байтак кына үлән җыйды. Күлмәген салып, җиңнәрен бер-берсенә бәйләде дә, капчык сыман нәрсә ясап, шуңа тутырды. Утырып, ниһаять, үзе дә ямь-яшел үлән кыягын чәйнәп карады. Аны чемченеп күңеле булгач, кычыткан яфрагын авыз итте, аның кыяр тәмен хәтерләткән таныш тәме дә сагындырган икән. Тук булмаса да, ничектер тамагын тынычландырган сыман булды. Тагын киләсе булыр дип ниятләп, малай кайту юлына төште.

Гафур, бакчадан чыгып, Смольный ягына борылгач, ике катлы бер бинаның ишеккә таба сөзәк күтәрелеп киткән баскычында кулына чүпрәк курчак тоткан биш-алты яшьләрендәге кызчыкны күреп алды. Малай бераз хәл алырга утырган гына иде, теге бәләкәч:

– Ә син минем әниемне күрмәдеңме? – дип сорады. Гафур, аптырап, «юк» диюдән кала ни әйтсен инде?! Әмма шул ук вакытта аның аяныч хәленә үзенең битараф, ваемсыз кала алмавын да аңлады. Бик кызганыч булып китте бит әле сабый, аңа карап, капылт кына үзенең үлгән сеңлесен дә исенә төшергәч, малайның йөрәген нидер чәнчеп-чәнчеп куйды.

– Ә ул барыбер килә! – дип, кем беләндер бәхәсләшкәндәй, матур кара күзләре белән томырылып карады бала.

Димәк, моның анасы: «Хәзер киләм!» дип китеп югалган да гаип булган. Ачлыктан интегеп, шул рәвешле балаларын артык кашыкка санап, аннан котылу өчен адаштырып калдыручылар турында еш ишетергә туры килә

иде ул чорда. Балалар йортлары шундый «табылдыклар» белән шыгрым тулы. Гафурның башына: «Бу баланы да берәр ятимнәр йортына илтергәме икән әллә?» дигән уй килде.

Ул шулай да бина эченә кереп карарга булды. Бәлки, кызчыкның әнисе шунда гозер белән килгәндер дә берәр бәлагә юлыккандыр. Бина эчендә кеше заты күренмәде. Үтәли җилдә ачык калган ишек кенә чыелдап ачыла да ябыла иде. Кире урамга чыкса, бала янында таягына таянып сәнҗереп беткән бер карчык тора, нидер сораша.

– Төштән бирле шушында утыра ул, бахыр. Приютка илтергә дә бит үзен. Ә минем хәлне күреп торасың. Ташлама инде син аны, улым! – дип, малайга ышаныч белән карады шәфкатьле әбекәй.

Шул кайгыртучан, ихлас сүзләр җитә калды малайга. Ул, ике дә уйлап тормастан, бу четерекле мәсьәләне чишү юлын тапкан кебек:

– Әйдә, әниең янына барабыз! – диде дә баланы үзе белән алып китте. Бер кулына капчык сыман йөк, икенчесе белән кызчыкның бәләкәй кулыннан тотып ияртеп баруы ансат булмады, билгеле. Ач кешеләргә бер дә хас булмаганча, маңгаена бөрчек-бөрчек тир тибеп чыкты хәтта.

Ниһаять, мең бәла белән өйләренә кайтып җиттеләр. Әнисе гөбе кебек шешкән яралы аягы белән мәшгуль иде. Гафур фатирга керешли үк, аның каршына табылдык кызны бастырып:

– Әнием, адашкан ул, бездә калып торсын әле, иртәгә балалар йортына үзем илтәм, – диде.

– И юләр, юләр! Бүген-иртәгә үзебез ни ашарбыз икән дими, – диде ана, ризасызлык белдереп. Аннары үзләре өчен ризык турында кайгыртып, көнне төнгә ялгап, алмаштырып йөргән улына сынап карагач, уңайсызланып, үз хәленә кайтып төште:

– Ярар инде, бер нарасыйны ничек тә сыйдырырбыз әле. Исеме ничек?

Гафур, әнисенең ачуы басылганга куанып, тиз генә кечкенә кызга иелә төште дә шул ук сорауны кабатлады.

– Галя, – диде кызчык һәм курчагын суза биребрәк:

– Ә ул Маня исемле, – дип тә өстәде. Аның сабыйларча пайпылдавын ишеткәч, «Кара, Галя атлы, безнеңчә Галия кебегрәк икән. «Гелия» исеменә дә охшап тора», – дип уйлана калды Гафур, гадәтенчә. Шунысы белән генә дә бәләкәч тагы да якын, кадерле булып китте күңеленә. Бу нәни кызчыкта таныш чалымнар да төсмерләгән кебек булды ул.

Өммегөлсем апа:

– Ярый, исән булсын инде, балакаем! Үз кызыбыз урынына, – дип йомгак ясады да, күз яшьләрен авырдан гына тыеп, Галяны кочагына алды.

Шул мәлне Галяның йон кофтасы кесәсендә нидер кыштырдады һәм бер газета кисәгенә карандаш белән ашыгып сырланган язу килеп чыкты. Укып карасалар, анда: «Галя, г.рожд. 1936», – дигән сүзләр язылган иде.

«Баласын язмыш кочагына ташлаган мәрхәмәтсез ана кеше генә шулай салкын акыл белән яза ала. Сабыен эзләп табу турында уйлап та бакмаган ялмавыз. Адресын да калдырмаган. Берәр рәхимлесе үзенә сыендырыр әле дигәндер», – дип нәфрәтләнде Өммегөлсем апа, газета кисәген кулына бер алып, бер читкә куеп. Кыска гына мәгълүмат кызчыкка хөкем карары кебек иде. Ул бүгеннән тома ятимә хәлендә.

Кичен кычыткан кайнатып эчтеләр. Тамакны алдарга ярый, бөтенләй үк юк эше түгел. Кечкелтем ипи янында аш төрләндерү кебек булып китте әле бу. Әллә ни мактарлыгы булмаса да, зәңгеләдән файдасы бар. Быел болай да шул чирдән нарат ылысын кайнатып эчәргә кушалар, бу эшне шәһәр күләмендә җәелдереп җибәргәннәр иде.

Галяны урынга яткыргач, Өммегөлсем апа сүз арасында гына әйтелгән кебек:

– Улым, аягым бер уңайланмый бит, эшкә дә баралмасам, нишләрбез? Ничек тә үз ягыбызга кайтырга кирәк безгә. Ладога күле аша юл ачылган, ди әнә. Рөхсәт кәгазе алсак, юлга чыгар идек, – диде.

Берничә көннән райисполком ягына кузгалырга торганда гына, әче сирена тавышы бөтен теләкне челпәрәмә китерде. Бу һава һөҗүме башкаларыннан көчлерәк иде. Якында шартлаган бомбалар җиле ничәмә катлы таш йортны такта алачыктай дерелдәтеп тора, фатир түшәменә җитешле авыр шкафны аяклары өстендә «биетә» хәтта. Бераздан «отбой» булды. Ана белән улы, бисмилла әйтеп, чыгып киттеләр, ниһаять. Галя изрәп йоклый калды. Әмма бер уңмаса уңмый икән, урам чатына да барып өлгермәделәр: янә бомбёжка башланды! Гадәттә, өйдә чагында бомбадан саклану урынына йөрүдән ваз кичкән Өммегөлсем апа белән Гафурны кызыл чүпрәкле кешеләр көчләп диярлек шул киң, тирән базга, подвалга төрткәләп керттеләр. «Фатирда нәни бала калды!» – дип ялварганны колакларына да элмәделәр.

Монда озак кына утырдылар. Башкалар да түземсезлек күрсәтә. «Эх, ак төннәр булмаса икән ул! Кара төннәрдә яхшырак, тынычрак!» – дип, хыялын бүлешкәндәй әйтеп куйды шунда берәү. Аны бу минутларда эчтән генә һәрберсе хуплагандыр, мөгаен. Әйе, төн караңгылыгында дошман каланы алай ук еш бомбага тотарга базмый иде. Тыныч тормышта соклану уяткан атаклы ак төннәр хәзер шәһәр кешеләренең яшәешенә шул рәвешле шактый караңгы күләгә төшерә, кирәкмәс бер нәрсә сыман баш казыгына әйләнгән иде.

Отбой булуга, «Тизрәк бала янына йөгер!» – диде әнисе, Гафурны кымтырыклап. Гафур кайтып керсә, Галя өйдә юк иде! Эче жу итеп куйды. Аннан каранды малай, моннан. Кызчык һичкайда күренми иде. «Галя» дип кычкырынып тавышы карлыкты хәтта. Үтешли генә, шкафның ишеген ачып караса, Галя мәче баласыдай бөгәрләнгән дә йоклый бирә. Бомбалар шартлавыннан коты алынып, шунда кереп качкан да балакай шкафның тирбәлү уңаена йоклап та киткән, күрәсең. Сулышы кабып кайткан Өммегөлсем апа лап итеп тапчанга ауды… Куанычыннан нарасыйны кочып, як-ягына чайкалып, озак кына тирбәтеп утырды.

## 17. «Тормыш юлы» өчен тартыш

Үзалдыңа ният итү, план кору, исәп-хисап – бер нәрсә, чынбарлык, яшәү кануннары – икенче нәрсә. Әнә, Бәшировларның пропуск алуга ымсынуларын аяусыз рәвештә кире кактылар, тәртәләрен тиз бордылар райисполкомда. «Мы не можем!» – дип, катгый, кырыс төстә ике-өч кенә сүз аттылар өсләренә. Райкомдагы Эвакуация буенча комиссиягә кереп карарга киңәш итте бер миһербанлысы. Андагы олпат гәүдәле абзыйлар исә йомшак итеп, итагатьле генә:

– Хорошо, гозерегезне ишеттек, нәүбәтегез җиткәч чакырырбыз, – диделәр. Барган саен шул ук җавап белән «сыйлап» озата торган булдылар.

Беткән баш беткән, иң азакта якташлары Сания апаны күрергә ясканды аналы-уллы. Азык-төлек бүлеге исә хәрби пост кебегрәк «секретный», яшерен урын булып, читләргә анда керү катгый тыела икән. Шулай да ничектер әрсезләнеп үтеп керделәр ул җиргә. Сания апа турында сорашуга, анда эшләүчеләр шөгыльләреннән бер мизгел дә туктамыйча, тып-тыныч кына: «Ул үлде», – дип әйткәч, бөтенләй аңгы-миңге калдылар Бәшировлар. Башларына тукмак белән суккандай:

– Нәрсә?! Ничек үлде? – дип, ифрат аптырап, баскан җирләрендә сакау булып каттылар. Онга төшкән кандала кебек акшарланган чиновник хатын үз нәүбәтендә гаҗәпләнүеннән акайды:

– Вот интересно! Как, как... Ачлыктан!

Башка сыймаслык, шуның ише дәһшәтле сораулар озак вакытлар күңелдән китмичә, газаплап йөртте ана белән улны. Ничек үләргә мөмкин ул әүлиядәй изге җан? Ничек? Ни рәвешле? Ашамлыклар бүлә торган урында эшләпме?! Су буенда утырып, суга тилмерү кебек була бит инде бу! Күрәсең, чумаралы эш дип, намусына тап төшермәгән, вөҗданын алга сөргән илаһи зат булган ул Сания – татар кызы. Үз мәнфәгатен кайгыртып, бүтәннәрнең өлешенә кул тидермәгән фәрештә! Үз гомерен саклап калу өчен дә! Һич кенә дә Сания апаның вафатына ышанырлык түгел иде. Ничек ышанасың, аларның туган төбәккә кайтырга булышуда бердәнбер терәкләре, таянычлары иде бит.

Блокада шул рәвешле һәркемнең кешелек сыйфатларын аерымачык, җете итеп күрсәтә килә. Биредә элек-электән бай күңелле яхшы, игелекле, ихлас кайгыртучан, шәфкатьле булган кеше бөтен барлыгы белән тагы да күркәмләнеп, матураеп ачыла; яманы, явызы, мәрхәмәтсезе, имансызы исә алама холкы-табигате белән торган саен тупаслана бара, явызлана төшә, зәһәрлегенә йомылып ката икән... Йомышың төшсә, җен-пәриләре кузгалып, аяусызланып, усалланып, зәңкиләнеп бетә андыйлар...

Билгесезлек упкыны янындагы төсле, куркулы-шомлану көн итеш белән тагын берничә ай үтеп китте. Кыш башланды. Бусы – тагын да зәмһәрире, салкынлыгы белән 40 градуска җитә торганы. Комсыз буржуйка миченә ягулыклары беткәч, ул албастыдай, зур авызын ачып караеп тора, аннан мәңгелек боз суыгы бәрә... Гафур бомба-снаряд төшеп хәрабәгә калган йортларны айкап, актарып, шкаф, урындык, комод, өстәл ише мебель калдыгын, иске газета-журнал төпләмәләрен, баскыч култыксаларын күтәреп кайта торган булды. Әмма ләкин андый ягулыкны аулап йөрүчеләр бер ул гына түгел иде шул... Берсендә чүпрәк-чапрак арасыннан балачак хыялы булган музыка коралы – зур гына баян тартып чыгарды. Ап-ак төймәләре саргаеп, эчкә таба батып беткән, аллы-гөлле күреге ерткаланган музыка тартмасы, кулга алуга, үз хәленнән зарлангандай, бер генә ыңгырашып куйды. Рәте юк, көй чыгарырлык түгел иде инде. Гафур дулкынланудан калтыранган бармаклары белән ничек кенә баскалап карамасын, бүтән бер аваз да, аһәң дә чыкмады аннан. Яксаң да, зәһәр исеннән гайре әллә ни файдасы булмаган ул авыр баянны барыбер күтәреп кайтты. Әмма комсыз «буржуйка» авызына тыгарга кулы

бармады Гафурның. Гамәлгә ашмаган матур хыял истәлеге кебек, шкаф эчендә нәүмиз булып ятты да ятты баян...

Ярый, суыгына ничек тә түзәрсең. Ә сусыз ярты көн дә торып булмый. Якын-тирәдәге колонкалар бозланып каткан. Дүртенче катта гомер сөрүче карт белән карчык суны Нева елгасыннан ташырга гына кала диештеләр. Гафурның алардан ике бидон сорап (берсен хуҗалары өчен), шул тарафка юл тотудан бүтән чарасы юк иде. Әнисе, аның ай-ваена карамыйча, башын-битен үзенең кыршылып беткән шәле белән чорнады. Малай, хатын-кыз кыяфәтенә кердем ләса болай дип гарьләнсә дә, салкында туңмас өчен иң кулае шул булды.

Иртән чыккан бала төштән соң гына, Бакыр җайдак турысындагы ярдан төшеп, бәкедән бидоннарына «зәмзәм» суын тутырып алу бәхетенә иреште. Алуын-алды, әле бит биш-алты басмалы баскычтан менәсе дә бар. Әнә, бер агай шуннан үрмәләгәндәй күтәрелгәндә, чиләгендәге суын чайпалдыра-чайпалдыра түгеп бетерде. Болай да шадраланып бозланып каткан басмалар тагын да шомара төште.

Баскыч тирәсендә тынны куырып алырлык суыкта бөкрәйгән халык төркеме хәзер үк менеп китәргә батырчылык итмәгәнгә генә, шул рәвешле аптырап тик басып тора кебек иде. Юк икән, бу зирәк кешеләр авызы ачык торган савыттагы мөлдерәмә суның берникадәр чирап туңып, боз элпәсе белән каплануын көтеп тора икән. Алай иткәч, савыт-сабадагы су, чайкалса да, түгелми, ди. Тормыш, нужа тәҗрибәсе өйрәткән уңган-булганнардан кайберләренең хәтта шушы чиллә суыгында да күлмәкме-нимеме юып азапланганын үз күзләре белән күрде Гафур. Өлкәннәрнең, карт-корының шундый батырлыгы, тапкырлыгы көч-куәт биргән кебек булды малайга: ул алардан киммени?! Ул бит әле яшьрәк тә! Ихтыяр көчен бер ноктага туплап, авырттырганчы тешен кысып, менеп китте баскыч буйлап. Башта саклык белән бер бидонын менгезде, аннары – икенчесен. Чыннан да, бидоннардагы боз белән каплана башлаган суның тамчысы да чайкалып түгелмәде...

Эт булганчы арып-талып, чатнама салкында шакырдап кайтып керсә, бүлмә тагын да суынган кебек иде. Үзәккә, сөяк җелегенә үтә торган гынамы соң?! Икенче бүлмәне әллә кайчан бикләп куйдылар, юкса. Сулыш алу җылысы да әрәм-шәрәм китмәсен дип инде. Аяктан калып, заводка йөрүдән туктарга мәҗбүр булгач, әнисен иждивенец паёгына гына куйдылар. Өч тамак бит инде алар хәзер. Сөйкемле, матур кызчыкны балалар йортына тапшырырга кыюлыклары җитмәде башта. Аннары Галяга шул хәтле күнделәр, аны читкә тибәреп аерылышу уйларына да килмәде. Дөрес эшләделәр микән соң?! Аңа сөт-май ише тансык азык эләкмәгәч, шәм кебек көннән-көн сыза, сүрелә барды бичара.

Гафур, соңгы урындык аягын ваткалап яисә кәгазь учламасын мичкә якканда, ялкын көлтәләренең биегәнен карый-карый төрле уйларга бирелүчән булды. Кеше дә бит шушы мич сыман: утын, ягъни ягулык салып торсаң гына, ялкынын дөрләтеп яна, ялкыны булмаса – сүнә, бетәшә. Әмма кеше – җансыз мич, учак түгел. Аның ихтыяр көче бар, ябык тәндә яшәү дәрте бар!

Шулай да адәм баласына һәр көнне тиешле ягулык-калория дә таләп ителә бит. Җәмгысы 250 грамм ипи өч җанны асрарлыкмы соң?! Карынны котыртып, авыз итәргә генә җитешле ләбаса. Анысын да җелегеңә үтәрлек

ачы җилдә, кибеткә зур чират торып, талаша-тартыша алырга туры килә. Шунда торган җирендә өшеп, туңып үлүчеләр дә хәтсез. Кайсылары суыкта басып торудан тәмам туеп, түземе төкәнеп, буш кул белән кайтып та киткәлиләр. Салкын фатирда, даладагы төсле япа-ялгыз калып, ачтан үлүне артыграк күрәләр бахырлар...

Малай, андыйлар хәленә калмас өчен, үзенчә тапкырлык күрсәтә. Ул хәзер ярты кирпечне (тулы бер кирпечне күтәрергә хәленнән килми) мичтә җылыта да, аны киемнәре эченә, күкрәк турысына куеп, чиратка баса торган булды. Шул ысул да күпмедер вакыт җылыны саклый сыман. Учына үз нәүбәтенең тәртип санын яздыргач, малай кайта да, теге суынган кирпечне мич өстендә җылытып, янә кибеткә китә. Күпме вакыт басып торырга булса да, үз чиратын көтеп ала торган иде. Әнисе белән кечкенә сеңлесе хакына эшләнелә иде бу. Галяның ипи тотып кайткан Гафурны күрүгә, зәгыйфь тавыш белән: «Абый кайтты!» – дип шатланып каршылавы өчен генә дә барысын да кичерәсең. Ул балакайның татарча матур гына тәтелди башлавы да күңелне җылытып тора иде. Әнисе исә улына рәхмәтен, керфекләрен кагып, чиксез яратулы карашы белән белдерә. «Үзе какча булса да, күңеле көр әле баламның», – дип сөенеп куйгалый ул. Кайгыртучан, йомшак, саф күңелле, тугры улы булмаса – нишләр иде?!

Өммегөлсем хәзер шешкән аягын бөтенләй онытты, үз тәкъдире белән тулысынча килешкәне күренеп тора, соңгы ипи кыерчыгын да: «Сез – яшьләр, сезнең үсәсегез бар!» – итенгәләп, ничек тә Галя белән Гафурга төртү ягын карый иде. Малай мондагы эшләрнең хөртиләнүен күреп, айга ике тапкыр эвакуация комиссиясенә барып белешеп тора. Барган саен: «Көтегез!» – дип кире боралар. Соңгы баруында, күзлеген прастуй тегәрҗеп белән ике колагына аскангамы, гадирәк, рәхимлерәк булып күренгән агайларның берсенә әнисенең саулыгы турында тәфсиллләбрәк сөйләп бирүгә иреште. Ул исә, сабырсызланып, икенче бүлмәнең ишегенә таба шыр кычкырып салды:

– Серафима Петровна, бу малай белән барып кара әле! Нәрсә анда...

Ак халатлы хатынны бәхет өләшүче кешегә тиңләгәндәй куана-куана ияртеп кайтты малай. Өстенә һәйбәт җылы кайры тун кигән табибә фатирда зыкы суык булуын замша перчаткаларын салгач кына сизде бугай. Анысына исе китмәде, ә менә Өммегөлсем апаның аягындагы аксыл-кара чүпрәкләрне ачып җибәргәч, борынын җыерды, тизрәк кайнар су кайнатып бирергә боерды. Эшен бетергәч, малайның кулына ниндидер май, бер-ике бинт тоттырды, шешне көн саен чистартып, юып бәйләргә кушты. Ни хикмәт, шул майның сихәте тидеме, берничә көннән аяк шеше кайтып-кибеп, җәрәхәт элпә белән капланды. Шул вакыттан соң әнисенең дә, малайның үзененең дә күзләренә йокы керә башлады.

Әмма бәла үзе генә, ялгыз йөрми икән шул. Яра өстенә тоз дигән кебек, бишмәт ише ертык, юка кием белән, кепкадан гына әле ипи чиратында, әле рөхсәт кәгазе артыннан чапкан малай беркөнне каты суык тидереп кайтты. Температурасы күтәрелде. Һични белештерми, ике көн тәне кызышып, аңсыз ятты. Тәмам миңгерәүләнгән хәлдә бик интегеп тын ала, сулышы чыжылдап чыга иде. Кайчагында никтер башын күтәреп, утлы күмер кебек көйрәгән күзләре белән тирә-ягын сөзеп карап ала да яңадан мендәргә ава.

Өммегөлсем апа бу бәладән соң бөтенләй куырылып төште. Үлән кайнатып эчереп тә, белгән догаларын укыштырып та бетерде. Авызына валчык та ипи капмаска әйләнде улы-таянычы. Ана кеше, ничекләр итеп булса да, көч-хәл белән райисполкомга үзе өстерәлергә мәҗбүр булды. Теге вакытта үзен дәвалаган табибә, Гафурның температурасын үлчәп, уң як күкрәген тыңлап карауга, башын чайкап куйды, сыңар юату сүзе дә әйтмәде. Ул инде үлем-китемне күп күргән, авыруның туганнары, якыннары алдында хәтер-фәлән саклап торудан узган иде. «Малаегызның хәле шәптән түгел, үпкәсе шешкән, бераздан менә бу таблетканы бирерсез», – дип, бер-ике көннән тагын килергә вәгъдә биреп, ашыгып чыгып китте. Ничәдер көн аңсыз ятканын да белештермәде Гафур. «Эло», – дип, «тормыш» дип, татар, карел сүзләрен катыштырып, әллә ниләр сөйләп, саташып ятуы белән Өммегөлсем апаның бөтенләй котын алды. Аның сузып-сузып ыңгырашуыннан бәгыре өзелеп, сызлануларын бөтен йөрәгенә алып, баш очыннан китмәде хәсрәтле ана. «Бетте балам! Тәмам үлем исереклегенә биреште», – дип, соңгы өметен өзеп уйланган чаклары аз булмады.

Тагын өч көннән килде табиб. Авыруда әллә ни алгарыш тапмады. «Кризис үтмәгән, бүген-иртәгә китеп бара инде бу», – дип йомгак ясады ул үзалдына. Ә малай температура күтәрелү сәбәпле, томанлы кызыл элпә аша табибның өмет уятмый торган төксе, томса карашын күреп үртәлде. Әнисенең чарасыздан ялварулы күзләрен күрде. Маңгаенда бәләкәй Галяның салкын кулын тойды. Һәм аның күңелендә бу гаделсезлеккә, табибәнең битараф кул селтәвенә каршы ниндидер кайнар ризасызлык дулкыны күтәрелде. Ул кемнәргәдер үч итеп, әнисе белән сабый хакына ничек тә терелергә, яшәргә булды. Аппетиты бетеп, сыңар валчык икмәк капмаган авыру, иреннәрен көчкә тибрәтеп, ашарга сорады. Әнисе кайнаган суда чылатып биргән ипи кисәген үзен көчле-көчле суырды, аз-азлап, берәмтекләп йотты. Элек кире борган шифалы үлән суын үзе сорап эчте. Ихтыяр көче кузгалган кешенең яшисе килә аның. Эченнән генә, «Яшәргә, яшәргә кирәк!» – дигән сүзләрне кабатлый, йөрәгендә өмет уты кабына. Шуны гына сүндермисе иде.

Тагын бер-ике көннән соң аның үлемен теркәргә генә дип килгән табибәне шаккаттырып, шәүләсе генә калган кечкенә сеңлесе белән нидер сөйләшеп ята иде Гафур. Табибә үз күзенә үзе ышанмыйча, малайның күкрәгенә салкын төребкәсен куеп, әледән-әле күчергәләп, озаклап тыңлап карады: малайның үпкәсендә хырылдау билгеләре беткән иде. «Могҗиза! Ничек булды соң бу!» – дип, үз-үзенә сөйләнде ак халатлы табибә. Билгеле, авыруны якыннарының изге теләге генә түгел, аның ныклы, бирешмәс холкы, тормышны яратуы, яшисе килү тойгысы аякка бастыруын белмәде, аңламады табибә. Әмма чыгып барганда, ниндидер көч аны Гафурга борылып, тагын бер кат ихтирам белән карарга мәҗбүр итте. Ә бит шул ук чир белән түшәккә егылган күпме хаста, яше-карты алларында ашарга ризык була торып та үлеп китәләр. Нидән гыйбарәт икән бу аерма дип, табигать кануннары хакында уйлана-уйлана китте үзен тәҗрибәле табиблардан санаган ханым.

Әйе, ачлыктан интеккән адәмнәрнең ни өчен кинәт беркөнне ризыкка битараф калуын, гайрәте чигүен, азыкка тартылуы, кырт киселүен

аңлап, төшенеп бетә торган түгел. Ә бит шулай да була икән ул. Адәм баласы, туйганчы ашыйсы килү тойгысыннан бик озак азапланганнан, җәфаланганнан соң, ниндидер кызыл чикне үтеп, бер мәлне җаны-тәне шундый хәлгә килеп җитә, терәлә ки, ашауга дәрте сүнеп, ашамлыкка омтылыш, тәм хисе югала, җуела. Ахыр чиктә кешедә яшәү дәрте-дәрманы сүнә. Бөтенесенә дә буйсынып, әҗәлен көтә дигән сүз бу. Ә менә Гафур үз вакытында андый начар хисләр тозагыннан котыла, арына белде. Бу инде кешеләрне, тормышны яратуның, бар дөньяга мәхәббәт хисенең җиңүе иде!

Баласының терелеп китүе өчен никадәр җан аткан, өстерәлеп, дүрт аяклап булса да, ике җан хакына кибеткә ипи артыннан йөргән ана, Гафур тәмам савыккач, яшәү теләге йомшарып булса кирәк, инде үзе түшәк хастасы булды. Бу юлы мантый алмады. Соңгы тапкырында кибеткә дип барган Өммегөлсем апа ипи карточкаларын, чын мәгънәсендә бер айлык яшәү чыганагын югалтып кайткан иде. Юлны кыскартам дип, хәрабәләр аркылы чыкканда, кирпеч өеменә абынып егылган карчыкны ике яшь егет күтәреп торгызганнар гына иде югыйсә. Кибеттә кесәсенә тыгылса... барысы да бетте... Менә шул хәл бөтенләй кешелектән чыгарды да инде аларны. Атна буе шиңеп, корып беткән үлән-чүлән генә күшәп, имеп яткан кешеләр әҗәл сулышын сизеп-тоеп торалар. Һәркайсы фатирның караңгы почмагындагы ачлыкның ыржайган кара тешләрен аермачык күрә төсле. Бәләкәй Галяның ач карашы белән өтеп алгандай:

– Әнием, без үләбезме инде? – дип, олыларча сорау бирүе бөтенләй өнсез итә иде.

– Син бер дә курыкма, кызым, юк, без үлмибез, йоклап кына китәбез, – дия башлады үлеме җиткәнен сизенгән ана, нарасыйны юатып.

Гафур да, күпме генә карышмасын, ачлыкның соңгы чигенә җиткән, аны да әҗәл аяк-кулларын бәйләп алган. Ул да һәрнәрсәне кара томан аша гына күрә... Вакыт кимәленең исәп-хисабын югалткан чагы. Шул рәвешле күпме көн ятканын хәтерләми, кинәт кайсыдыр хатын-кызның колагына иелеп:

– Торыгыз, чиратыгыз җитте! – диюгә, кул бармакларын кыймылдатып, үзенең тере икәнлеген сиздерде. Үзенең миеннән һаман да томан эчендәге кебек: «Кая чират? Үлемгәме, бүтәнгәме?» дигән сәер уйлар йөгереп үтте. Ихтыяр көче сүнмәгән яшүсмер егет янә яктылыкка, тормышка таба омтылды... Авырлык белән күз кабакларын ачкач, иң элек башына җылы бүрек, өстенә йолдызлар тагылган зәңгәр погонлы шинель кигән, елмаеп торган ир-атны шәйләп алды. «Әти кайткан», – дип, аңгыраюдан битараф кына уйлап куйды ул. Күзләреннән кара элпә тартылып, карашы яктыргач кына, ялгышын аңлады. Бу – бөтенләй чит, ябь-яшь егет, бер як авыз читеннән колакка таба сузылган яралы җәрәхәте генә елмайган сыман итеп күрсәтә икән аны.

– Ну, исәнме, браток! Мин Николай булам! – диде офицер, бу юлы дөрестән дә дусларча авызын киң итеп ерып.

Ә ул төс-кыяфәте белән үк яхшы, көләч кешегә охшаган, күзләре дә гел елмаюлы иде аның:

– Вот... Мин – фатир хуҗасы – кайтып керсәм, күрәм, понимаешь ли, үлем белән сугышып ятасыз монда. Көчләр явно тигез түгел. Ну, мин дә сезнең якка килеп кушылгач, без явыз курнос танаудан өстен чыктык

та җиңү яуладык! Ну, аңарчы кайбер ашыгыч чаралар күрергә туры килде, – диде ул.

Котылгысыз үлем якасында калган ачларны соңгы мизгелдә әҗәл авызыннан тартып алган, коткарган шушы очучы-офицер фатиры икән бу. Ленинградка командировкага килгән дә, өйгә сугылып чыгыйм әле дип керсә, өч кеше өч җирдә таралып, аңсыз ятасыз, ди. Райисполкомга барып, бөтен службаны аякка бастырган. Шул арада Бәшировларның нәкъ шушы көннәрдә эвакуацияләнү чираты җиткәнен дә ачыклаганнар, имеш, чиновниклар. «Торыгыз», – дип аваз салучы хатын-кыз шуларның берсе икән.

Николай биштәреннән бер кирпеч ярым ипи, үзе ни өчендер шаярып «Второй фронт» дип атаган ике-өч ит тушёнкасы, сало чыгарып салды. «Чур! Азыкка сразу атака ясамаска, баштан аз-азлап кына кабарга!» – дип, уенын-чынын кушып кисәтергә дә онытмады. Ризыкны саклык белән, мыскаллап кына ашап, ике көннән өчесе дә берникадәр тернәкләнеп хәлләнгәч, Николай райисполкомга чаклы үзе озатып куйды. Фәкать мәрхәмәтле капитан аркасында гына өчесенең дә шул кыяматтән башлары исән чыкты. Әҗәл сәгатенә туры килмәгәннәр икән бит!

Эвакуация комиссиясендә исә «тормыш юлында», ягъни Ладога күлендә сезнең гомерегезгә куркыныч янавы ихтимал; юлга дошман гел төрле коралллардан аткалап тора, эвакуациядән исән-имин чыгуыгыз үзегезнең шәхси җаваплылыкка йөкләнә дип каты кисәтеп, ниндидер амбар кенәгәсенә югарыдагы таләпләргә риза булуларын белдергән имзаларын төшерттеләр. Өммегөлсем апа, калтыравык кулына каләм тоттыргач, әллә ниләр уйлап бетерде. «Йә, Аллам, сорап-нитеп торган булалар бит әле, янәсе, анда, боз өстендә сезнең тормышка куркыныч яный, дип. Ә монда, паёксыз-нисез утырып калган ярым тере бичараларга рәхәтмени, берни дә янамыймыни?! Гомеркәйләре нечкәдән-нечкә кыл, үткеннән-үткен кылыч өстендә тора бит аларның. Алыгыз гына үзегез белән, калдырмагыз гына үлем кочагында, туган җиремә кайтып үлсәм дә, үкенече булмас!» – дип, татарча сөйләнде ул.

### 18. Яшибез болай булгач!

«Тормыш юлы» аша «Зур җир»гә эвакуациягә озатыласы бала-чаганы, карт-корыны бәләкәй автобуска төягәндә, һичнинди ыгы-зыгы, этеш-төртеш, гауга, бәхәс-мәгәзнең әсәре дә булмады. Азрак кагылсаң да, аварга, борыннарыннан тотсаң, җаннары чыгарга торган бу бичаралар аңа сәләтлеме соң инде?! Үзләрен дә әле автобуска сабый баладай күтәреп, арка кочтырып кертергә, урнаштырырга туры килде. Ленинград камалышыннан котылу шатлыгы да сизелмәде хәтта көлсу төскә кергән, сөяк белән тиредән оешкан, суырылып төшкән бит-йөзләреннән.

Автобус кар көртләренә чумган шәһәр урамнары буйлап коңгыздай үрмәләгәндә, Гафур тәрәзәдән күзе төшкән кадәр карап, күзәтеп барды. Аның үзенчә шәһәр белән саубуллашуы булгандыр инде. Урамнарда шактый гына вакыт әле уңга, әле сулга борылгалап, киртәләрне әйләнгәләп үткәч, алга таба күз күреме кадәр җәелгән, алагаем киң үзәнлек иркенә чыктылар. Бу – «Тормыш юлы» – Ладога күле иде. Озату пунктында аларны полуторка

дигән ачык машинага күчереп утырттылар, документларын кабат тикшереп, пассажирларга күз йөртеп алгач, йөк автомобиле әллә кая хәтле сузылган кәрванда үз нәүбәте белән кузгалды. Аның кабина ишекләре шыр ачык: ул-бу була калса, эчтәгеләр сикереп төшеп калу өчен шулай эшләнә.

Машиналар, автобуслар, тагын шундый ук транспорт берәмлекләре бер-берсенең койрыгына тагылып, тыгызламыйча, хәтсез ара калдырып бара. Тизлек әллә ни зур түгел, боз өстен капшап барган кебек кенә кыймылдыйлар. Утыргычларында шулай ипле генә тирбәлеп, селкенгәләп барган мәлдә, Гафур алдагы машинаның кинәт язгы боз өстеннән убылып, күз алдында су төбенә чумып китүен күрде. Кемдер ах итте, шуның белән янә тынлык урнашты. Шофёр – каралып беткән ак кайры тун кигән абзый, гадәти хәлгә очрагандай, тизлеген киметмичә, теге фаҗига урынын урап узып кына китте. Гафур, үтеп барышлый, баткан машинаның фаралары су астында да янып торганын күреп имәнде. Һич көтмәгәндә булды бит бу коточкыч хәл! Димәк, теләсә кайсы машинаның яки олауның теләсә кайсы вакытта йомшара төшкән язгы боз астына китүе ихтимал. Гафур, хәзер үк куркыныч янагандай, Галяны кысып кочагына алып утырган әнисенә карап алды. Тәмам эштән чыккан ана боларның барысыннан да бихәбәр, иләс-миләс, черем итеп утыра, бәләкәч исә сабыйлар йокысында иде.

Алдарак тагын да зуррак каза көтеп торган икән әле. Утыз-утыз ике чакрымлы боз юлын күпмедер үткәннән соң, Гафурлар машинасының борын төбендә генә (һәрхәлдә аңа шулай тоелды) кинәт нидер гөрселдәде, кибән хәтле ут-ялкын күтәрелеп, көлтәләре төрле якка чәчрәде. Җай гына барган машинаның алгы тәрәзәсе коелып төште, ул күзгә күренмәс киртәгә төртелгәндәй, шып туктады. Шофёр, бераз ял итеп алыйм әле дигән кебек, башын руль өстенә салган, ярдәмгә чакыргандай, машинаның бертуктаусыз сигналы улый иде. Кемдер: «Барыгыз да төшегез! Тизрәк!» – дип кычкырды. Чөнки гөрселдәүләр тавышы инде хәзер бер-ике генә түгел, анда-санда ут чүмәләләре югарыга таба чөелеп кенә торды. Аларга зениткаларның озынча нечкә ут сызыклары кушылды. Гафур, Галяны кулына алып, борт аша кемгәдер сузды. Аннары бала кебек кенә калган әнисен төшерде. Алды чәрдәкләнгән машинаны кирәкмәс тимер-томыр өеме кебек бер читкә эшереп куйдылар. Үлгән йөртүчесен җылыту палаткасы янына сузып салдылар. Балаларны да шул ук палаткага җыеп керттеләр. Биредә шактый җылы, уңай иде. Кулларына кайнар чәйле кружкалар тоттыргач, иң көйсезләре дә шыңшудан туктады. Җылы ботка, майлы ипи кисәге бөтенләй рәхәтлеккә чумдырды эвакуацияләнүче халыкны.

Бераздан икенче бер йөк машинасына утырта башлагач, сабыйлар, палаткадан суык боз өстенә чыгарга теләмичә тискәреләнеп, озата баручыларга, юлда эшләүчеләргә шактый гына мәшәкать тудырып алдылар. Ярый, ничек кирәк алай менеп утырыштылар. Өсте бөркәүле булмаганга – чөнки анда моңа кадәр нindидер әрҗәләр булып, балалы аналар хакына бушатылган йөк автомобиле генә иде – тәмуг салкыны, кар катыш җил уйнап тора бирде. Сызылып киткән кара мыеклы шофёр: «Ныклап тотыныгыз, безгә җәтрәк барырга кирәк!» – диде дә машинасын куарга тотынды! Алда юл тараеп бер машина сыешлы гына калган юлның үтә куркыныч өлеше иде. Дошман утка тотуны көчәйткәнгә, һәрбер машина йөртүче, уңга-сулга

карамый, афәтле урынны җитезрәк узарга омтыла иде. Дәһшәтле гөрселдәп шартлаулар ешайган саен, әрҗәдәгеләр шырпы кабы эчендәге борчаклар шикелле берсе өстенә берсе өелешә, икенче урынга чәчелеп барып төшә иде. Көчсез, зәгыйфь җаннарның кычкырып тавыш бирүен һичкем тыңламый, ничек кычкырсалар да, аларны, чебен безелдәведәй, ишетерлек түгел. Менә тагын каты сикертте дә, машина борты аша ниндидер кара әйбер очып төшеп калды. Әрҗә кырыена ябышкан яшь ана, шундук аска сикерергә омтылып, «Балам!», – дип илереп кычкырды. Озатучылар аның кулын каерып дигәндәй, урынына утыртып, үгетләп тынычландырырга тырыштылар. Бу фаҗига күз ачып йомганчы булып алды. Күпләр аңышмый да калдылар. Тик кайсыдыр:

– Ник туктатып алмыйсыз баласын? Бәлки исәндер әле! – дип, ризасызлык белдерде.


– Ярамый! Инструкция! – дип, сүзне кыска тотты озата баручылар. Меңнәрнең гомере хакына берәүне корбан итмичә булмый дигән боерык белән эш итте алар. Дөрестән дә, бер чакрымга сузылган кәрванны иңгә бер машина сыешлы гына тар боз юлында туктату хәтәр эш иде. Гафур үзе дә ник баланы төшеп алмадылар икән дип баш ваткан иде. Әмма төптәнрәк уйлагач, озатучылар хаклы дигән фикергә килде. Билгеле, малай иң элек, үзләренең исән-сау һәм бөтен калуларына шат иде. Нишлисең, тормыш кануннары шундыйрак. Һәркемнең күлмәге үзенә якынрак. Уйларын бүлеп, әнисенең:

– Җитәбезме әле, улым? – дигән саңгырау тавышы ишетелде. Каян белсен инде аны Гафур. Ул да шул ук билгесезлек хәлендә. Күзләрең әлҗе-мөлҗе килгәнче тирә-юньгә карансаң да, һични күрерлек түгел. Шулай да, шактый гына бара торгач, малай алдарак ниндидер каралты-кураны күреп алды. Бу – «Тормыш юлы»нда чакрым саен исәнлек-иминлек өчен җаваплы кешеләр хезмәтенә бик тә зарур, кирәкле корылмалар, палаткалар, ягулык пунктлары түгел иде инде. Бусы инде ике катлы йорт кебек зур бина иде. Андыйлар каты җир өстендә генә төзелә. Димәк, куркынычлы боз юлындагы сәфәр тәмам.

– Күлне үттек, әнием! Болай булгач, яшибез! – дип, үзе дә сизмәстән кычкырып салды Гафур. Аңа гына шулай каты акырган сыман тоелды, чынында исә тавышы янәшәдә утыручы әнисенең колагына гына барып ирешә бугай.

Озын юл чакрымнары, изалану-җәфа галәмәте моның белән генә бетмәде әле! Алда аларны күп киртәләр, нужаның, михнәтнең тагын да авыры, газаплысы – ачысы, югалтуларның иң үкенечлесе көтеп тора. Болары турында Гафур да, Өммегөлсем апа да әлегә белми иде. Һәй, аларын кем уйлаган да кем кайгырткан хәзер! Туган якка кайткач, барлык кайгы-хәсрәт вак-төяк кенә булып кала! Туган җир – синең таянычың, терәгең, сине үзенә сыендыручы. Юкка гына өзелеп җырламыйлармыни: «Анда кайтсам, мин дә башка, анда мин дә – сандугач!» – дип?! Алда – газиз туган җирем, туганнар, кан-кардәшләр, алда – кояшлы төбәгем, матур, ямьле авылым!

Ике катлы эвакуацияләү йортына килеп кергәч, Гафур иң элек үзен бимазалаган сорауга җавап тапты. Зур залдагы диварга эленгән стенд-календарьда «1943 ел, 2 апрель» дигән саннар балкып тора иде.



Эльвина Миңнуллина (Мөхәммәдиева) Байлар Сабасыннан. Кечкенәдән татар, рус һәм инглиз телендә әсәрләр укып үскән, үзе дә каләм тибрәтә башлаган. Татарча гына түгел, рус һәм инглиз телләрендә дә тәҗрибәләре бар, тәрҗемә итү белән мавыга. Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында татар һәм инлиз телләре буенча педагогик белем ала. Уку дәверендә күп кенә шигырьләр яза, алар «Идел», «Ялкын» журналларында дөнья күрә. «Огонь Победы в памяти поколений», «Горю поэзии огнём», «Иделем акчарлагы», «Сәләткә нур булган йолдызлар» конкурсларында җиңүләр яулый, «Яңа исем» проектында катнаша. Бүгенге көндә актив иҗатта, татар-инглиз-рус телләрендә прозада һәм поэзиядә тәрҗемә белән шөгыльләнә, балалар өчен ике телдә китап яза.

Эльвина Миңнуллина

# ТОРМЫШ УЛ – АЯУСЫЗ БОМБА...

## Җыентык

Синдә батам. Берүк коткармагыз.
Теләп керәм төпсез упкынга.
Син океан сыман, мин – бер утрау,
Сыенамын синең дулкынга.

Синең үзгә тормыш фәлсәфәңне
Аңлата алмас миңа хәтта Кант та.
Синең дөнья бәйсез бер ил икән,
Мин ул илдә адашкан эмигрантка.

Һәрбер кеше ул – табышмак, диләр.
Һәм мин сине чишәргә тиешмен.
Башкаларны караштан укысам,
Синең караш миңа бирешми.

«Син – аномалия, мин – бер прототип» –
Диагнозын куя йолдызнамә.
Синең кискен тәвәккәллеккә
Йолдызлар да ялкау тезләнә.

Юлымнан тайпылып адашкач,
Синдә таптым үземә сыентык.
Һәрбер кеше ул – табышмак, диләр.
Тик син табышмак түгел... Җыентык.

***

Бу битараф шәһәр үзәгендә
Берьялгызым басып торам.
Телисеңме, көзге сурәтеңдә
Шәүләң булам?!
Узган көздә кискән чәчләремне
Кысып үрәм.
Бу битараф кеше агымында
Мин тик сине эзлим...
Сине күрәм.

Бу битараф шәһәр үзәгендә
Язлар гөрли бүген.
Кысып үргән чәчләремне шуңа
сүтәм.
Сине ялгыш кына күрсәм,
Читләп үтәм.
Язда калам.
Синле көзгә кермәм
бүтән.

***

**С**урәтеңне сүтеп җыям –
**А**шыктырам вакыт агышын.
**Г**ашыйк итеп салкын яңгырлардан
**Ы**шыклатты синең тавышың.
**Н**азга күмәм сине. Һәм күмеләм.
**А**раларны кат-кат сүтеп җыеп,
**М**ин кабаттан сиңа үреләм.

## Минем әсәр

Ничә телдә мәхәббәт җырланса да,
Үз телеңдә матуррак җырлана.
Чит илләргә гашыйк күзләрең дә
Татар күз яше белән дымлана.
Тормыш.
Сәхнәләштерелмәгән спектакль.
Актёрлары – король һәм тузлар.
Мәхәббәт каласы Париж булса әгәр,
Димәк, «сөя белә» бары французлар.
Сюжет кысаларына сыешмыймын.
Экспозиция булсын прологта.
Вакыйгалар катламын үстермичә,
Кульминация килсен.
Нокта.
Хисләр дулкынында шигырь туа.
Тусын, әйдә.
Лирик чигенеш.
Минем дөнья –
Минем әсәремдә
Бер генә түгел, байтак чишелеш.
Читлек, богаулардан качам.
Шашам.
Күмеләмен сөю һәм назга.
Мәхәббәт каласы Париж булса әгәр,
Француженка булам беразга.
Тормыш – спектакль.
Жанрын һәрберебез
Үзе сайлый, үзе салачак.
Минем әсәрдәге күренешләр
Хэппи энд булганчы барачак.
Һәрбер кеше үз юлын табачак.

## Тәртипсез шигырь

Чынбарлыкны таныр-танымас
«Зулейхалар» күзләрен ачканда,
Мин, киресенчә, ябам.
Мин – консерватор.
Һәм реалист. Шунлыктан да
Искедән яңалык табам.

Светофор төсләре чикле һәм төгәл.
Яшәеш ул башка. Чагыштырма.
Ул – комбо.
Мин – тыныч яшәп яткан Хиросима,
Ә тормыш ул сәер һәм күп вакытта...
Тормыш ул – аяусыз бомба.

Бауман буйлап кешеләр агыла.
Урамнар – коннект[1]. Киселәләр.
Тоташ.
Шушы туктаусыз, ялгыз...
Битараф агымда
Кешеләр төрле һәм шундый
Охшаш.

Бауман буйлап кешеләр агыла.
Таш биналар – кысан читлекләр.
Уйлар чуалган, хисләр тәртипсез.
Үзгәрә тора тик битлекләр.

Чынбарлыкны таныр-танымас
Кешеләр дөньядан читләшкән.
Кешеләр төрле һәм шундый охшаш.
Кешеләр битлеккә ияләшкән.

Кешеләр читлеккә ияләшкән.

***

Син – панацея
Һәм иң тирән ярам да.
Син – агу да миңа,
Дәвам да.

[1] Яшьләр сленгында «очрашу», «аралашу» дигәнне аңлата.

***

Минем халәт – тоташ бер сыкрану:
Фаталистлар арасында динсез,
Гөнаһлылар арасында савапсыз,
Синең янәшәңдә синсез.

***

Чиксезлекнең тамгаларын санап
Үз дөньямнан эзсез куылам.
Үз агуым белән агуланам.
Үз чылбырларыма буылам.

***

Син – табиб.
Мин – дәваңа мохтаҗ бер юлчы.
Син – палач.
Мин – үлемгә дучар сугышчы.

***

Иске-яңа тормыш дәрьясында
Мин – ялкау турист.
Консерваторлар арасында
Мин – футурист.

***

Көпә-көндез шәһәр уртасында
тәгәрмәчләр асфальт белән яратышалар.
Бөкедәге усал машиналар
беренчелек өчен ярышалар.

Тукталышта берсе «маршрутка»сын көткән арада
«Старбакс» каһвәсе белән җылыта кулларын.
Каршыдагы күпкатлы бер бинада
тынгысыз әни мәктәпкә озата улларын.

Ә мин (шаһит) карап кына торам
һәм югалам кеше агымында.
Мин ышанам. Мин ышанам бары
бу шәһәрдә синең барлыгыңа.

Бу дөньяда синең барлыгыңа!

***

Араларга чикләр сызып,
Үзең салдың килешсез эмбарго.
Хисләр белән акыл көрәшендә
Йөрәгеңдә бераз урын бармы?

***

Капма-каршы хисләр көрәшендә мин – пацифист.



Рабит
Батулла

# МИҢ

ХИКӘЯ

*Булган хәл. Исемнәр үзгәртеп бирелде.*

Алар гаиләсендә миңле балалар гына яши. Ул Миңтаһир абзыйның борынгы нәселеннән, әллә кайчангы токымыннан килә. Миңтаһир абзыйның атасында да, бабасында да – икесенең дә уң күз янында коңгырт миң булган. Миңтаһир да уң күзеннән бераз астарак зур гына миң белән туган. Миңтаһирның беренче баласы да нәкъ шундый миң белән дөньяга килде. Шуңа күрә аның исеме дә Миңсалих булды. Икенче улы Миңвахит та, хәтта игезәк кыз балаларының да битләрендә миң иде. Кызларның берсенә – Миңсылу, икенчесенә Миңсәрия исеме куштылар. Тулы, таза, матур гаилә иде бу.

Бу миң Миңтаһирның горурлыгы була килде. Ул Миңтаһир нәселенең борыгы тамгасы, бәхет мөһере булып санала иде. Игезәк кыз балалары Миңсылу белән Миңсәриягә карап сокланмаган кеше юк. Алар – матур балалар. Миңсылуның миңе Миңсәриянекенә караганда зуррак та, караңгырак та иде. Җитмәсә, шул куе коңгырт миң уртасында берничә төк тә бар иде. Миңсылу сабый чагында бу аермага игътибар итмәде. Әмма үсмер яшенә җиткәч, ул көзгегә еш карый һәм канәгатьсез кала иде. Сигезенче сыйныфта укыган чакта малайлар кызларның чәченнән тарта, чеметкәли, тоткалый башладылар. Ни өчендер Миңсылуга малайлар ул кадәр ябышмый, Миңсәрия тирәсендә өерләре белән йөри. Бары тик сыйныфташлары арасыннан Карамыш исемле үсмер генә аны чит итми, ул Миңсылуны хөрмәт итә, бәлки әле ярата да башлагандыр. Миңсылуның тыныч холкы, сабырлыгы Карамышка ошый иде, ахрысы. Ул Миңсылуга гел ярдәм итәргә атлыгып тора, кызның каләме идәнгә төшеп китсә, шундук каләмне алып, хуҗабикәсенә тапшыра. Чаңгы ярышында Миңсылу ни өчендер артта калган, аның бер чаңгысының шөрепләре бушаган булып чыкты, Карамыш эшне аңлап, тиз генә Миңсылу янына килеп, кызның чаңгысын җайлады. Кыз икенче булып килде. Аның ярдәмчеллеген Миңсылу бик ярата. Алар аерылмас дус булып китте. Унынчыга җиткәч,

мәктәптә бию кичәләре, дискотекалар оештыралар иде, күлмәк модалары күргәзмәсе дә булгалый, бу күргәзмәләрдә бигрәк тә кызлар бик теләп катнаша. Бигрәк тә игезәк кызлар уңыш казана иде.

Бер тапкыр Миңсылу сыйныф җитәкчесе Салиха апа белән театр түгәрәген оештыручы Саттар абыйның сөйләшкәнен ишетте. Миңсылу ашханәдә кизү тора иде. Ул, соңгы табак-савытларны юып, ашчы апаларга тапшырып чыгып барганда, балалар ясаган рәсемнәр күргәзмәсе киштәләре артында кемнәрнеңдер сөйләшкәнен ишетеп туктады.

– Төбәк мәркәзендә мода киемнәре күргәзмәсе булачак, безнең мәктәп шул күргәзмәдә катнашачак, – диде Салиха апа. – Әзерләнергә кирәк.

– Әзерләнербез, – диде Саттар абый. – Ләкин Миңсылу Миңвәлиеваны күргәзмәгә чыгарабызмы?

– Борчылмагыз, Саттар әфәнде, Сез аны сәхнәнең уң ягыннан чыгарыгыз, шулвакыт аның уң битендәге кара миңе күренмәс!

Миңсылу киштә артындагы әңгәмәне тыңлап бетермәде, китеп барды. Ул башын кая куярга белмәде, класска кайтты, аның күзенә беркем дә күренми иде инде, карындашы Миңсәрия аның хәлен сорашты, ул җавап бирмәде, дусты Карамыш та аны юата алмады. Ул, өстәлгә ике кулын куеп, учына башын салып елый башлады. Бу елауның сәбәбен беркем дә белмәде.

Мода киемнәре күргәзмәсенә репетиция вакытында режиссёр Саттар абый бөтен кеше алдында аңа:

– Миңсылу! Син уң яктан чыгарсың! – дигәч, артта торучы кызларның берсе әйтеп куйды:

– Миңсылуның уң битендәге йонлы миңе күренмәсен өчен Саттар абый шулай куша! – диде.

Менә шуннан башланды инде Миңсылу өчен ахырзаман. Ул күргәзмәдән кайтып китәргә дә уйлаган иде. Ничек итсә итте, түзде, кием күргәзмәсенең композициясен бозарга базмады, ул сул яктан чыкты, уң ягындагы миңне күрсәтмәскә тырышты, ләкин кием күрсәтү тәмамлангач, игезәк сыңарын да көтмичә, өенә кайтып китте. Карамыш аны озата барырга уйлаган иде дә, Миңсылу аңа игътибар итмичә, аерым йөгерде. Ул ата-анасына белгертмәскә тырышып, кызлар бүлмәсенә кереп бикләнде. Атасы да, анасы да, абыйсы да, Миңсәрия дә ишекне шакып карады, аларга соңрак килеп кушылган Карамыш шакыгач та, Миңсылу ишекне ачмады.

Өйдәгеләр дә, Карамыш та аптыраушта иде. Бераздан, тынычлангач, елап, шешенеп беткән Миңсылу бүлмәсеннән чыкты да башкаларга сүз әйтмәстән, юыну бүлмәсенә кереп китте. Озак кына юынгач чыкты.

– Ни булды, кызым? – диде анасы.

– Берәрсе рәнҗеттеме әллә? – диде атасы.

Миңсылу җавап кайтармады. Бары тик диванга утырып йөзен каплады. Карамыш сак кына аның янына килеп утырды да сүз башлады.

– Миңсылу! – диде ул. – Сиңа ни булды соң?

Миңсылу кинәт битен ачты, сикереп торды да анасына, өстәл тирәли утырганнарга ачык, таләпчән тавыш белән әйтте:

– Әти, әни! Мин менә бу – нәселдән килгән кара миңне кистерәм! – диде.

Барысы да аптыраган иде.

– Ничек? – дип сорады анасы.

– Шулай! – диде Миңсылу. – Пластик операция ясатам. Туйдым кешеләрнең миңа күз акайтып карауларыннан.

Кызны беренче тапкыр күргән кебек, ата-ана, туганнары, Карамыш сүзсез торды.

– Кызым! – диде ата кеше. – Без бөтенебез дә миңле! Беребезнең дә Ходай биргән миңне алдыру турында башыбызга да китергәнебез булмады. Әнә Миңсәриянең дә шул ук урында миңе бар!

– Аныкы минеке кебек кара да, ямьсез дә, йонлы да түгел!

Карамыш Миңсылуның иңенә кулы белән чак кына кагылып әйтте:

– Җаным, мин сине яратам, шушы килеш яратам, нигә кирәк ул пластика! Ата-анаң сине ярата, мин яратам, синең башкаларга тагын да матуррак булып күренәсең киләме? Синең миңең бер дә ямьсез түгел!

Миңсылу каушап калды кебек, Карамышның сүзләре аны аптырашка калдырды сыман. Чыннан да, кем өчен соң ул тагын да матуррак булырга тели?

– Мине бу килеш модель итеп алмаячаклар, ә минем модель буласым килә! – диде Миңсылу.

– Тилергән кызый! – диде атасы. – Миңгә кагылырга ярамый, пычак белән дә, энә белән дә, миңне кисәргә ярамый, аның тамыры тирән, балам.

– Ә мин аны каплатам! – диде кыз. – Мин бу турыда күп укыдым инде, башка урыннан тире кисеп, миңне каплап була. Петербургта андый операцияне бик уңышлы ясыйлар. Пычак та, энә дә кирәк булмаячак.

Кыз теләгендә бик нык торды. Сөйләшә, ялвара торгач, ризалаштылар. Җәйге ялда Миңсылуны Петербургка җибәрергә булдылар. Ләкин Карамыш күңеле белән моңа риза түгел иде. Әнисе белән Петербургка китеп барды. Петербург клиникасында аларны кочак җәеп каршы алдылар. Кочак җәймәслекмени, аларга акча, аларга тәҗрибә кирәк, һәм берничә көн тикшергәннән соң, Миңсылуга операция ясадылар. Кызның йомшак җиреннән тире кисеп алып, миңне каплап куйдылар. Наркоздан айныгач, Миңсылуның үз йөзен күрәсе килде.

– Иртәрәк әле, – диде хирург, – тире үзләшеп бетсен, ул башта ямау булып күренер, соңрак, тора-бара, ярты ел дәвамында нәкъ йөзең рәвешенә керер!

Чыннан да, Казанга кайткач, якын туганнары да, таныш-белешләре дә Миңсылуның йөзе үзгәргәнен күреп шаккатты, ләкин кара миң урынында сары тап күреп, Карамышның гына кәефе китте.

Август азакларында, чыннан да, Миңсылуның йөзе чистарып китте сыман. Карамыш сөенде, Миңсылу да бик куанды. Ләкин көзге салкыннар килгәч, салкын һавада, Миңсылу йөзендәге ямау күгелҗем-шәмәхә төскә керә. Җылыга кергәч, тире астына үлек җыелган кебек, гайре табигый бер сары төс ала, менә-менә бу тире ярылып, аның астыннан эрен сытылып чыгар кебек. Кыз ябыкты, йөзе сулыкты, элеккеге гүзәллеге дә әллә кая китте.

Кыш быел аеруча салкын килде, Миңсылу, салкынга чыкса да, җылыга керсә дә, үзен бик начар хис итә. Һәм ул елаудан тукамый, өйдәгеләргә дә Карамышка да рәт юк. Ул көйсезләнгәннән-көйсезләнә бара. Тамагына – ашамый, йокысы качты, унберенчене көч-хәл белән тәмамлады. Анда уку кайгысы да, институтка керү кайгысыда юк иде инде. Аның төп максаты – каһәр суккан миңне бетерү иде.

Миңсылу миңен каплап торган тиресен ерткалардай була иде, җитмәсә, шушы урын үтереп кычыта, миңне кашыйсы, тырныйсы килә. Миңсылу аның саен үрсәләнә, көйсезләнә, төн йокламый йөреп чыга.

Тупыл агачының яшь үсентеләре асфальтны шартлатып өскә чыккан кебек, миң дә томаланып яшәргә теләми, йомшак җиреннән кисеп алган тире чатный башлады, эчтән аны куәтле миң этә. Чатнаган урын эренли, начар ис чыгара иде.

Янә Петербургка киттеләр. Табиблар өске тирене кубардылар, тире астыннан кара миң калкып чыкты, ул тагын да калынайган, зурайган. Миңсылу шушы миңгә нәфрәтле иде. Үз йөзен көзгедә күргәч, ул акылдан язар дәрәҗәгә җитте.

Табиблар икенче юлдан китте, алар миңгә дарулар сөртә башладылар. Озак вакыт узуга карамастан, бу дарулар да нәтиҗә бирмәде. Ана белән кыз тагын кайтып китте. Ярты елдан тагын килергә куштылар: яки лазер терапиясе уздырырга, яки сыек азот белән миңне катырып, үлгән миңне скальпель белән тазартырга килештеләр. Әлегә кәбестәне иттарткычтан яки миксердан чыгарып, ике ай буе шул измәне миңгә каплап йокларга, ике айдан соң зәйтүн мае белән лимон сутын болгатып, биткә сылап, шулай дәваланырга куштылар.

Карамыш сөйгән кызына табибларның төгәл диагноз куя алмаулары, үзләренең дә ни кылырга белмәүләре турында әйтте, ул сөеклесеннән бу шикле операцияләрне туктатуын үтенгән иде, Миңсылу ярсып кычкырып, Карамышны өеннән куып чыгарды. Миңсылу барысына да ачулы иде.

Лазер терапиясе куркыныч операция иде. Уңышлы чыккан очракта да соңрак аның уңай нәтиҗәсе турында беркем дә белми. Табибларга тәҗрибә ясарлык кеше булсын, ә тәҗрибә мәйданы – Миңсылуны миңе иде.

Сыек азот белән миңне катырып, үлгән миңне тураклап скальпель белән чистарту да бик куркыныч гамәл иде. Бу юлы Петербургка анасы бармады, ул авырып, урынга ятты. Миңсылу ялгызы гына китте, таныш юл, таныш табиблар дигәндәй.

Киңәшә торгач, лазерны сайладылар. Операция уңышлы узды кебек. Миң урынында аз гына җөй калган икән. Анысы да тора-бара томаланыр диделәр. Кыз канәгать иде, ул тынычлана төште, йокысы кайтты, ашый башлады. Хастаханәдә байтак кына ятканнан соң, янә Казанга кайтып китте.

Өйдә гаугалар кимеде, кызның кәефе әйбәт, миң урынындагы җөе дә әллә ни күзгә бәрелеп тормый. Ул институтка керергә имтиханнарга әзерләнә башлады. Карамыш аңа рәхәтләнеп ярдәм итәргә алынды.

Тормышлар шулай рәткә керде дигәндә генә, Миңсылу бөтен гаилә җыелып беткәч, шатланып кайтып керде дә яңа паспортын өстәлгә ташлады:

– Укыгыз, көнләшегез, мин хәзер Миңсылу түгел! – дип кычкырды кыз.

Атасы паспортны алды, укыды, аның йөзе чытылды, ул бер сүз әйтмичә генә паспортны Карамышка сузды, Карамыш кычкырып, паспортта язылганнарны укый башлады:

– Таһир кызы Луиза Вәлиева!

Бөтенесе дә тораташ булып катты.

– Бу ни була соң, кызым? – диде ана кеше.

– Шул була! – диде кыз. – «Миң» исемен җенем сөйми иде, Миңсылу, Миңтаһир, Миңлебикә, Җонлыбикә...

Карамыш сабыр гына әйтте:

– Карале, синең аттестатыңда «Миңсылу Миңтаһир кызы Миңлевәлиева» дип язылган. Беләсеңме, сиңа нинди кәгазь мәшәкатьләре аша узарга кирәк булачак, борын төбендә керү имтиханнары тора, син быел кәгазьләреңне алыштырып өлгермәячәксең.

Миңсылу агарынды-күгәренде дә тузына башлады:

– Сез бөтенегез дә миңа каршы! Кермәсәм кермәмен институтыгызга, ләкин мин «миңле» булып йөрмәячәкмен! Күз астымдагы миңне дә, Миңсылу дигәннәрен дә җенем сөйми!

Кыз диванга ауды, ул ярсып-ярсып еларга тотынды. Карамыш ипләп кенә чыгып китте.

Гаиләдә аптыраганнар, йөдәгәннәр, өйдә хәзер Луиза баш. Аның кәефе булса – тәртип, аның кәефе булмаса – кара буран.

Карамыш та аларга сирәк килә. Карамышның туганнары әйтеп карады:

– Син, Карамыш туган, Миңсылу янына... Луиза янына йөрмә, җаның тыныч булыр, – диделәр.

Ләкин Карамыш Миңсылуны һаман ярата, ул аны бик кызгана иде.

Шулай тагын бер ел узды, ләкин Луиза институтка керә алмады. Чөнки Луизаның миң урынындагы җөй бетәргә йөз тотмады, киресенчә, җөй урынында миң тагын калка башлады. Луиза көн саен көзгегә карый, көн саен миңенең яңадан чыга башлаганын күрә, ул тагын җенләнә, сүгенә, битен кыйный, шушы җенләнүләр вакытында ул миң урынын пычак белән яргалап бетерде. Өйдәгеләр курка калды, бөтен өй канга баткан иде. Луиза битен каплап, урамга йөгереп чыкты. Кешеләр җенләнгән Луизаны көчкә тота алдылар. Берсе телефоныннан ашыгыч ярдәм чакырды, аны хастаханәгә алып киттеләр.

Иң беренче булып хастаханәгә Карамыш килде. Ләкин табиблар аңа Миңсылуны күрсәтмәделәр. Ата-анасын да, башка туганнарын да хаста янына уздырмадылар. Ләкин беленде ки, Луиза чираттагы тикшерүләр вакытында табиб өстәлендә яткан кайчыны алып, миңен ермачлап бетергән икән, яралары төзәлгәч, ул көзгегә карап, тагын миңен тырнаклары белән яргалаган. Шулай итеп, Миңсылу–Луиза бөтенләй акылыннан язды. Бер җенләнгән вакытында бичара үзен үзе үтергән. Аның мәетен ата-анасына кайтарып биргәндә, Карамыш күрде: Миңсылуның уң күзе астындагы миңе тагын да зурайган, тагын да карарак төс алган иде. Аны нәселдән килгән миңе белән гүргә иңдерделәр. Карамыш, бөтенесе кайтып киткәч тә, урыныннан кузгалмады. Ул яңа кабер янына чүгәләп утырган килеш озак кына белгәннәрен укыды. Ул сөеклесен коткара алмаганына үкенде, озак утырды, караңгы төшә башлагач кына, бәхилләшеп, зираттан чыкты.

Бичара кызның атасы кабернең баш тактасына «Миңтаһир кызы Миңсылу Миңлевәлиева. 1980 – 2000» дип яздырды.

Ата кеше тактаны утырткач, кабер янында озак кына уйланып торды да:

– Авыр туфрагың җиңел булсын, кызым! – дип, каберстаннан чыкты.

*Шагыйрь, публицист һәм тәрҗемәче Илкар Төркуглы (Исаев) 1962 елны Азәрбайҗанның Кадебәк районы Алнабат авылында дөньяга килә. Югары белем ала. Ул – ике шигырь һәм өч тәрҗемә китаплары авторы; Азәрбайҗан һәм Төркиянең язучылар берлекләре, шулай ук Иран төрекмәннәре язучыларының берлек әгъзасы; Чукуров исемендәге язучылар ассоциациясе башлыгы, Азәрбайҗандагы Юридик үзәк директоры. Азәрбайҗан Җөмһүрияте Президенты премиясе иясе.*



Илкар
Төркуглы

# ОЛЫС НИГЕЗЕНДӘ, ТЕЛЕНДӘ ЯШИ...

## Дусларым алтын-көмештән өстен!

Яхшылык юлын ташлар бумасын,
Сусыл агачлар утта янмасын!
Ниемә кирәк кашлы йөзекләр?
Дусларым алтын-көмештән өстен!

Бул син олының, кеченең дусты,
Тәңре дә чөйде күккә дуслыкны!
Бүлмәдем «дус»ны иҗеккә хәтта,
Дуслык тормышта сүзләрдән өстен!

Хак яктысына йоммагыз күзне,
Куймагыз өтер яки һәм сүзен!
Җәлеп итмәгез хәерсез эшкә!
Хаклык юлында үлемем өстен!

Күңелем күзе электән якты,
Җанымны учак урынына яктым!
Күрсәгез минем ялганлаганны –
Сөйләрсез! Гөнаһ – үземнән өстен!

Сайлап, аз-азлап, Раббыбыз шулай
Агын, карасын бирә – һәр төсен!
Тамчы да узмас дус арасыннан,
Янган учактан кызуы өстен!

Яхшылык юлын ташлар бумасын,
Сусыл агачлар утта янмасын!
Ниемә кирәк кашлы йөзекләр?
Дусларым алтын-көмештән өстен!

## Картаябыз

Томанга терәлгән тауларың түбәсе.
Әй «Кәкил» – туган як, бәхил бул, көтмә син!
Йөздәге елмаю сурәтен теркәргә
Паспортның лимиты чыккандыр, күрәмсең...

Хат язып сәламлим гомерлек дусларны,
Әйтелгән тостларны хәтердә яңартам.
Язларны, җәйләрне каршылыйм сагынып,
Кадерле һәр фасыл, һәр туган яңа таң!

Борынгы сәйранлык шаукымы сүрелде,
Авазлар шау-шуы чыңлатмый колакны.
Мангалның төтене ысламый мыекны...
Сакаллы – өянке тәкъдирем түгелме?

Күзләргә ташланмый безләрдән өлкәннәр.
Алдала, бакчага олактыр башымны!
Җимеше өлгергән, гөлләре сулганнар –
Атамнар-анамнар шул багка талпынды.

Чинарга эленгән балачак дустыңны –
Яшьтәшең – таганны калдырып китәсе...
Үзенә ияртеп, сагышың, шатлыгың
Ишеген шакыр күк һәр көннең иртәсе!

Һәммәсе үтәдер. Шатлыгың, зарың да,
Һәм дөнья малы да иярмәс кабергә.
Әҗәткә алынган гомерне Әҗәлгә
Кайтарыр чак җитәр, шом салып бәгырьгә.

Томанга терәлгән тауларың түбәсе.
Әй «Кәкил» – туган як, бәхил бул, көтмә син!
Йөздәге елмаю сурәтен теркәргә
Паспортның лимиты чыккандыр, күрәмсең...

## Килермен

Олыс нигезендә, телендә яши!
Чакыру-өнең ишетсәм – киләм!
Газиз халкымда кардәшлек хисе,
Тарих, тамырлар уртагын беләм.

Язудан гына түгел лә бәхет.
Китмәм сафыбыз бозганнар белән.
Казанлыларга суздым кулымны.
Татар абыем, кабаттан киләм!

Муса Җәлилнең яшидер сүзе,
Сүнмәгән учак, балкыйдыр кузы.
Яшәешегез үз кулыгызда,
Мин киләм, кардәш! Тәңре юл суза.

Борынгы Идел коя һаман да,
Үзе ул – тоткын, үзе ул – ауда.
Түбәдә уйный яшен камчылар,
Йөзгә-йөз килеп, барам томанда.

Һәр батыр менгән атның биленә.
Тарих язылган каһан телендә.
Габдулла Тукай туган телендә
Җыр алып киләм сиңа бүген дә!

Бозылмас юлым, поезд кичекмәс!
Исемем Орхан – күчкән татардан!
Күңелем янә Болгарны кичкән,
Сабан туена киләм кабаттан!

Кичәге көн ул – Олыс тарихы,
Үткәннән дәрес алган – алдынгы.
Төркуглы килер әле тагын бер,
Корылган көндә бәйрәм табыны!

**Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ** *тәрҗемәсе*



*Сирожиддин Рауф 1967 елда Үзбәкстанның Кашкадарья өлкәсе Карши шәһәрендә туа. Ташкент дәүләт университетының журналистика һәм юридик факультетларын тәмамлый. «Кашкадарья», «Туркистон», «Биржа», «Җамият», «Хәят вә канун» газета-журналларында эшли.*

*Үзбәкстан Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе була.*

*Хәзерге вакытта «Шәрык йолдызы» һәм «Звезда Востока» журналларының баш мөхәррире. Сигез китап авторы.*

Сирожиддин
Рауф

# ЯШӘҮ ҖЫРЫ

## Зоминтау

Зоминтау –
Син җирнең казыгы.
Энҗеле чыршылар – яшел сер.
Аларга гасырлар кагылмый,
Һәммәсе һәмишә яшелдер.

Тауларның түбәсен иркәләп,
Күк йөзен яктырта кояш, ай.
Ә аста чишмәләр челтери,
Көмеш су – тереклек җырыдай.

Канаты җәелгән болытлар
Бәрелеп яра алмас ташларга.
Күр, алмаз канатлы бөркетләр
Омтыла күкләргә ашарга.

Йотлыгып йотамын һаваны,
Сүрелгән кебек дәрт учагы.
Юк, теләк уяна! Тауларның
Киңлеге бәгъремә күчәдер.

Зоминтау –
Син бит җан азыгы!

## Сорау

Бәхетлемсең?
Син дөньяда барсың,
Барлыгың да судагы эздәй.
Үз-үзеңне күбрәк яратасың,
Яшәү юк күк үзеңнән бизми.

Бәхетлемсең?
Бары сине генә
Көннәр килә шикелле юллап.
Гомер үтә, ә син сизмисең дә
Бер могҗиза көтәсең еллап.

Бәхетлемсең?
Нәфсең сөлек сыман! –
Йөрәк каны җитмәс аңарга.
Калебеңә коллык ят булгачтын
Кала хәсрәт-утта янарга.

Бәхетлемсең? –
Сүзләр җилдә тузгыр.
Җаның сөю кабул итмәде.
Гомерләр дә тик золымда узар,
Аерылу үчсез үтмәде.

Бәхетлемсең?
Мәхшәр көненәчә
Мәңгелек бу сорау йөдәтер.
Терсәк тешләп булмаганны белгән
Сөю йөрткән ялгыз йөрәктер.

***

Әле таң атмады, нигәдер, нигәдер,
Төн арты төн килде шикелле.
– Бүгенгең иртәгә төн булыр, беләмсең? –
Өметле сөюем эндәшеп, шик өрде.

Хисемне тыярга җитмәде көчләрем,
Һич дәрья булмастыр: күз яшькә тулышты.
Мәхәббәт сарае патшасы итәрлек
Түгелдер газабым дигән уй елышты.

Беләмен, әлбәттә, күрәчәк шушыдыр,
Тәкъдиргә, язмышка кем генә буйсынмас.
Гәрчә, мин башкарак бәхеткә лаек дип,
Күңелне биләгән өметле уй тынмас.

Баш иеп килгәндә тик аның каршына,
Кайда ул чәчемнән сыйпаган җылы кул?
Шулкадәр якындыр, еракта булса да,
Башымны идергән бары тик ул бит! Ул!

## Агач турында баллада

Агач беркөн канат чыгарды,
Нәфис, йомшак, төсле ул канат.
Талпынуы – очыш өчендер,
Тамыры җирдән булырмы азат?

Юк, ireккә ирек куелмас! –
Шушы иде җилнең хөкеме.
Күтәралмый дөнья йөкләрен
Канатлары бер-бер тетелде.

Тәкъдир белән озак килеште,
Өметләре чөнки тереләр.
Чын хакыйкать ачы!
Хыялда
Күзен ачкан яңа бөреләр.

Аксакаллар кебек тыныч ул,
Күңелендә бер моң яралды, –
Сабырлыгы өчен бүләктәй –
Яшәү җыры! Җанда шул калды.

***

Син ниләр боерсаң – мин риза,
Караңгы шикләрне куамын.
Мөгаен, тавышсыз курай күк
Тоелам дип уйлап куямын.

Гомерне исрафлар итмичә,
Һич бушка үтмәсен вакытым.

Кызган һәм көттерми кулың суз,
Син кызыл иренле якутым.

Сулышың, карашың тоям күк,
Аерылу аяусыз, җан туңа.
Сораулар борчыса, җавабым:
Йөрәкне ташлыймын учыңа!

***

Бисмиллаһ – һәр сүзнең башында булсын,
Энҗе һәм мәрҗән ташыдай торсын.
Олы хәзинә – әйтелмәгән сүз,
Әйтелгәннәре игелек кылсын.

***

Күкләр – ерак, ә җир якын булды – сөйдем,
Җанда хыял котырынды – сөйдем.
Мәхәббәттән мин хәбәрдар түгел идем,
Гөнаһлы заттай ташка әвереледем – сөйдем.

***

Хикмәтле сүз әйтсәм дүрт юлда,
Тоелыр гүзәллек күргәндәй.
Күңелне иркәләр ул сүзләр
Гөлләрдән тукылган келәмдәй.

***


Син минем саклаучы догамдыр тормышта,
Синсез һич көнемә яктылык җитмәс күк.
Мин сине тапкачтын үземне таныдым,
Ул бәхет һичкайчан калдырып китмәс күк.

**Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА** *тәрҗемәсе*

# *Татарстан Язучылар берлеге оешуга – 90 ел*




*Совет язучыларының Беренче Бөтенсоюз съездыннан соң. 1934 ел.*




*Гомәр Бәшировның Язучылар берлегендә рәислек чоры. Алгы планда: Гариф Гобәй, Абдулла Әхмәт, Гомәр Бәширов, Зәки Нури. 1950 нче еллар.*



*Татарстан Язучылар берлегендә очрашу. Сулдан уңга: Вакыйф Нуруллин, Ренат Харис, Туфан Миңнуллин, Рәис Беляев (партия һәм дәүләт эшлеклесе), Мостай Кәрим, Әхәт Гаффар. 1989 ел.*




*Язучылар ел йомгаклары җыелышыннан соң. 2014 ел.*



*Аксакаллар белән очрашу. Сулдан уңга: Гәрәй Рәхим, Рабит Батулла, Разил Вәлиев, Ркаил Зәйдулла. 2019 ел.*



*Язучылар Яңа Кырлайда. 2023 ел.*

# ЧОР РУХЫН, ЗАМАН СУЛЫШЫН ТОЕП

*Тел галиме Фәрит Юсуповка 85 яшь тулу уңаеннан*

Себер киңлекләренә зыярәт кылырга насыйп булып, бигүк яңа булмаган киндер биштәрен җилкәсенә җайлап урнаштырып, бер кулына диктофонын, икенчесенә рәсемгә төшерү аппаратын тоткан һәм төрле яшьтәге, бигрәк тә өлкәнрәк кешеләр белән сөйләшеп, дөресрәге, сөйләштереп йөрүчене күрсәгез, туктап исәнләшегез, ул 85 яшьлеген уздыру мәшәкатьләре белән йөрисе урынга дус-ишләреннән, туган-тумачасыннан «качып киткән» атаклы тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Халыкара төрек лингвистика җәмгыяте әгъзасы Фәрит Юсупов булыр!

Аның тормыш юлына, иҗтимагый халәтенә «үтеп барышлый» гына күз төшерсәң дә, исең-акылың китмәле: Себер татарлары иҗатын, башка диалектларны колачлаган күпсанлы китаплар авторы, Алабуга педагогика институтының чит телләр факультеты деканы (10 ел), Милли мәктәпләр институты директоры (11 ел), озак еллар дәвамында Төркия мәгариф министрлыгының өлкән фәнни-гамәли киңәшчесе һәм Традицион мирасны өйрәнү үзәгенең өлкән хезмәткәре... Шул ук вакытта Фәрит «энекәш» (ул фани дөньяга миннән бер яшькә соңрак аваз салган) нинди генә баш әйләндергеч олы дәрәҗәләргә ирешмәсен, язмыш аның табыну чыганагы – «яшьлек мәхәббәте» – Себер татарлары язмышы, шул төбәкләрне бизәгән милләттәшләребезнең рухи-мәдәни мирасларын, авыз иҗатларын язып алу, саклау һәм фәнни-гамәли әйләнешкә кертү... Әлеге хыял-омтылышын тормышка ашыруда Фәритне Себер суыклары, ком котыруын алыштырган тымызык кар бураннары, дошманнардан, талаучылардан качып, «бәхет эзләп», күлләр, ерганаклар арасына качып-посып урнашкан авылларга җәяүләп, көймәләргә, салларга утырып барулар, ат, трактор арбаларында газап чигүләр дә тиктормас максатчан галимне туктата, ниятеннән чигендерә алмыйлар.

Халык хәтере саклаган әдәби тарихи ядкарьләрне язып, күчереп алынган рухи-мәдәни байлыкны туплау олы гамәленең яртысын тәшкил итсә, аларны түкми-чәчми китап рәвешендә халыкның үзенә кайтару олы хезмәтнең икенче максаты булып тора. Мин шәхсән андый үҗәт фольклорчыны хәтерләмим! Үзе шәкли тарафтан тел галиме статусында саналса да, әдәби анализны бик күбебездән тирәнрәк ясаучы, төпле нәтиҗәләр чыгара белүче галим икәнен төрле дәрәҗәләрдә расларга әзермен.

Галимнең иҗаты, ирешкән үрләре белән тирәнрәк таныштыру ниятендә укучыга, нигездә, аңа багышланган берничә ачыкламыш «юлланма»ны тәкъдим итәм. Аларның назари нигезләрен шулай ук Ф.Юсупов хезмәтләре һәм фаразлары тәшкил итә.

### Яшьлегемдә яшьнәрмен

Хәзерге яшьләр өчен «теге заман» саналган 1956 елны Татарстанның (ул вакытта әле Татарстан АССР) төрле районнарыннан, Оренбург өлкәсеннән, Чувашиядән килеп, гаҗәеп зур конкурс үтеп, 1944 елда ачылган татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керү бәхетенә ирештек. Ышанычың-таянычың бары тик мәктәптә алган белемең генә булган чор. «Бәхетеңне» компьютер төймәләренә басып кына табып була торган мәкерле елларның, моңлы, ямьле яңгырашлы телебезнең мәктәп, югары уку йортлары системасыннан алып ташлану кебек көннәрнең килүен күз алдына да китерә алмый идек әле.

Башка елларда бүлеккә егетләр күбрәк керсә, 1956 елда кызлар талантлырак бу-

лып чыкты. Кабул ителгән 25 талибнең җидесе генә ир-егет идек. Шулай да төркемгә без «хуҗа» булырга тиеш дип, укулар башлануга кәнәфи бүлешә башладык. Аксыл-сары чәчле, түгәрәк, бетчәлерәк битле, ифрат хәрәкәтчән, беренче партага, укытучыга якынрак утырырга яраткан Илдар Әүхәдиевне староста итеп тәгаенләдек. Үзебезне журналына нәкъ дөресен язып куйган, хәтта дәрескә йөрмәгән өчен стипендиядән коры калдырганга, без аңа Чиновник дигән кушамат тактык. Гарәп телен яхшы үзләштергән чиновнигыбыз гарәп илләрендә эшләп, анда да үз кеше булып китте.



*Профессорлар Фәрит Юсупов, Тәлгат Галиуллин, Васил Гарифуллин.*

Бер ел мәктәпнең комсомол эшендә тәҗрибә туплап килгән, «р» хәрефен яһүдиләрчә әйтүче Шәүкәт Сәйфетдиновка төркемнең комсоргы булырга Ходай үзе фатихасын биргән диярсең. Эшче сыйныфы дәрәҗәле чорда Свердловск өлкәсендә алюминий комы эретеп кайткан Тәлгат Галиуллинга профсоюз эше эләкте. Балык Бистәсе егете Әнвәр Мөхәмәтҗановның юанычы – иске булса да, тальянкасы бар, ул аны ким-хур итеп, ач калдырмаячак. Флюс Нуриәхмәтов, Тәкәнеш военкомы кызы, группаның иң чибәр (А.Гыйләҗевның булачак хатыны Нәкыядән кала) Галия Хәсәновага гашыйк булып, аның күзенә чалынырга тырышып, чалбар балакларын тарайттырып, ботинкалары астына күннәр өстәтеп йөри торгач, стиляга булып китте. Бер ифрат үзенчәлекле егетебез, соңыннан шагыйрь булып киткән Равил Сәйфетдинов тумышы, бөтен булмышы белән шигърият кешесе иде. Сыйныфыбызның барча 17 кызына мәхәббәттә аңлашып (дөресе, шигырь багышлап), үз бердәнберен табып, туган төбәге атаклы Мулла Иле авылында озак еллар урта мәктәп директоры булып эшләде, соңрак шунда ук мулла вазифасын үтәде. Матур, тезмә сүздән аерылмады, аны безнең чорның Кандалые (мулла-шагыйрь) дип атасаң да, арттыру булмас иде дә, соңгарак калдык, ул фани дөньяны калдырып китте.

Безнең хакимият бүлешүләрдән бер студент – Яшел Үзәннең Караужа авылы егете, уртачадан аз гына калкурак, чандыр гәүдәле Фәрит Юсупов кына, көлемсерәп, читтәрәк торуны мәгъкуль күрде. Аның зыялы токымнан икәнлеге үз-үзен тәртипле тотышыннан, зәвыклылыгыннан сизелеп тора иде. Шимбә, ял көннәрендә туган авылына кайтып килә. Без, бер бүлмәдә яисә күршедә яшәүчеләр, аның сәфәреннән канәгать, чөнки ул әнисе яныннан, бәрәңгесен, ипиен, ара-тирә маен, каймагын да кыстырып килә. Кысмырлык галәмәте юк үзендә, каяндыр соңрак кайтып, ач калып, сорамыйча алсаң да, берни сизмәгәндәй елмаеп кына куя. Офицер әтисе сугышта үлеп, әнисе ике улын берүзе үстергән гаилә үзе дә артык мул яшәмәгәндер дип фаразлыйм хәзерге акылым белән.

Фәрит исемле группадашыбызга бездән ике курска өлкәнрәк укыган, шигырьләре матбугатта күренә башлаган әдәби түгәрәк старостасы Нурмөхәммәт Хисамов вәкарьлек белән (шуңа хакы булганлыкны ул соңрак та раслады) егетебезгә ихластан, бу бәясенә күп мәгънә салып, «Әлифбадан төшкән» дигән бәя бирде. Иллә күрәзәчелек сеңдерелгән булган икән үзенә Хак Тәгаләбездән. Фәрит гомеренең бер өлешен татар шивәләрендә (диалектларында) аерым авазларның әйтелешен өйрәнүгә багышлады.

Мәсәлән, аның аспиранты Мәдинә Саттарова «а» авазының төрле диалектларда яңгыраш үзенчәлекләрен өйрәнеп, кандидатлык диссертациясе яклады. Без вакытның кадерен белмичә, танцы-мансыга әрәм иткәндә, Фәрит инглиз, төрек телләрен өйрәнүгә багышлады. Беренче курс ахырында үзенең гомерлек шөгылен тапты – күренекле галимә Диләрә Тумашевага ияреп, Себергә экспедициягә чыгып китте һәм әле дә аннан кайтып кергәне юк.

## Һәркемнең үз язмышы

1961 елда университет дипломнарын «кулга төшергәч», тормыш җиле төрлебезне төрле якка очырды. Тумыштан ифрат талантлы Оренбург төбәге егете Рим Алабуга пединститутында берничә ел укытып, гаиләле булып, Радиокомитет кешесе булып китте, озак еллар дәвамында баш мөхәррир вазифасын яратып башкарды. Шәүкәт үзен комсомолга, аннан «Коммунист Татарии»гә багышлады, мин берничә ел дәрелфөнүн белән ТӘһСИ арасында буталып йөргәннән соң, 20 елга Алабуга педагогика институтына барып төпләндем. Әнвәр Мөхәммәтҗанов, тальянкасын кыстырып, туган ягына укытучылык эшенә тәвәккәлләде.

Гафу, гафу, укучым. Сүзебез елмаюлы йөзле Фәрит турында иде ләбаса. Ул Себер татарлары телен, тарихын, иҗатын өйрәнүне бер дәкыйкага да туктатмыйча, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтындагы фәнни эшенә хилафлык китермичә, кандидатлык диссертациясен яклап алды.

1971 елда мине Алабуга педагогика институтына ректор итеп сайлагач, төрле яклардан, бигрәк тә Казаннан галимнәрне чакырып, институтны дәрәҗәле укытучылар белән ныгыту эшенә керештем. Мин шунда, Фәритнең студент елларында ук инглиз телен яхшы ук үзләштерүен исемә төшереп, аны уку-укыту шөгыльләре искечәрәк куелган чит телләр факультетына декан итеп чакырдым. Инде гаиләле кешегә фатир мәсьәләсен дә хәл иткәч, бик теләп риза булды һәм милли мәктәпләр институтына директор итеп күчергәнче, бик теләп, яратып, кем әйтмешли, җир җимертеп эшләде, кара алтын табучылар, төзүчеләр, замана дилбегәсен кулларында тотучылар белән уртак тел табып, кызыл үгез тиресен хәтерләткән кирпечтән салынган бинаның дүртенче катын лингофон кабинетлары, заманча җиһазлар белән шыплап тутырды. Хәзер дә алар элеккечә студентларга, укытучыларга хезмәт итә.

Алабугага күчеп килергә ризалашканда ук, үзенең бер шартын калкытып куйды:

– Һәр җәйне берәр айга Себергә экспедициягә чыгып керү кирәк булыр, – диде.

Мин, әлбәттә, ризалаштым, юлын булса да түләргә, ярдәм итәргә дә тырыштым.

Дөрес, Фәриткә Алабугада озак эшләргә ирек бирмәделәр, әүвәл аңа Казанда, аннары Төркиядә ихтыяҗ булды.

Төрек мәмләкәте белән мөнәсәбәтләр җайга салынып, Татарстанда Төрек лицейлары ачылган чорда аны Мәгариф министрлыгына киңәшче итеп җибәрделәр. Анда ул ун ел (үзе алты гына ди) чамасы эшләп, ялга кайтканда да Себерен онытмыйча, шунда барып, халык иҗаты җәүһәрләрен туплауны дәвам итте.

Гаиләсе, хатыны Әлфинур да аның бу мавыгуын аңлады, белүемчә, иренә каршы килмәде.

## Үзеңнеке – үзәктә

Ат дагалаганда, бака ботын кыстырмый калмый дигәндәй, үзем белән бәйле, киләчәгем хәл ителгән, юбилярның турыдан-туры катнашы булган бер истәлекле вакыйганы читләтеп үтә алмыйм. Чөнки бу хатирәдә аның кешелеклелек, дуслыкка тугрылык, халык иҗатын туплаучы өчен иң кирәкле сыйфат – төрле буын кешеләре белән аралашу – җайлый-майлый белү үзенчәлеге тулы көчкә ачыла. Бу вакыйгада аның егетлеге өстенә мәрхәмәтле, ярдәмчел булуы да ачык күренә.

1979 ел иде. Үзебездә докторлык диссертацияләрен яклау советын ачарга Мәскәүдән рөхсәт булмау сәбәпле, 1917 еллар хикмәтенә чаклы кул арбасы белән Әлифба китаплары, хәрефләр тартып йөреп, «әлпи-тиси»гә өйрәткән халыклар галимнәренә баш иеп, тез чүгеп, йөзеңә ясалма елмаю чыгарып барасы була. Мин хезмәтемне Алма-Атада раслатырга йөрим. Кат-кат барып кайтып, бөтен шәкли процедураларны үттем, яклау көннәре якынлаша. Бер катлаулы мәсьәлә ачыкланып җитмәгән. Югары аттестация комиссиясе таләбе буенча, чит төбәктә якласаң, бер бәяләүче (оппонент) һәм өч әгъза советка үз милли әдәбиятыннан белгеч – докторлар кертелү таләбе.

Үзем Казанга кайтып йөри алмыйм, Алма-Атада эшләрем бихисап. Башны кашып, кәпәчем белән киңәшкәннән соң, Фәрит дуска шалтыратып, хәл-әхвәлне аңлатып бирдем, яклау өзелмәсме икән дип, борчылуымны сиздердем. Ул аз гына уйлап торды да: «Хафаланма, мәсьәләне аңладым, үзем оештырып алып килермен», – диде. Мин вәгъдә бирү капчык ташу түгел, җиңел, ә чынлыкта, гамәлдә нәрсә буласын бер Аллаһ кына белә дип уйлап куйдым. Чөнки ул чорда әдәбият белеменнән докторларны санарга бер кул бармаклары җитә иде. Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов вакыт таба алмаячак. Хатип Госман безнең өчен бик югарыда торучы галим иде. Бүлмәсеннән чыгып, безнең якка карап алып, кычкыртып борыннарын чистартып куйса, без – студентлар – уттан курыккан тычканнар мисле төрле почмакларга елыша идек. Ул – хис кешесе, кайсы вакытына туры киләсең. Тәнкыйть мәкаләләре буенча Гали Халит ярларына сыеша алмаган язгы ташуны хәтерләтә иде. Киң күңелле Мөхәмәт ага Гайнуллин гына шик уятмый. Ул – ерак юлга чыгудан да куркып тормый. Юктыр, булмастыр, шундый сәфәргә ризалашмаслар дип өзгәләнеп, үземә урын тапмый йөргән мәлдә кунакханәмдәге телефон телгә килде. Шалтыратучы Фәрит булып чыкты.

– Сәлам, дустым. Дүртесенә дә самолётка билетлар алдым. Иртәгә сәгать унда очабыз. Кунакханәдә урыннар бармы?

– Әйе, аэропортта каршы алыйммы?

– Юк, такси белән алып килермен, шунда көт!

Барысы да төп-төгәл (соңрак, Алма-Атада татар десанты дип көлешеп тә йөрдек) вакытында килеп тә төштеләр, мине яклатып та кайттылар.

Бу очракта Фәритнең ярдәмчеллеге, яшьлек дусларына ихлас тугрылыклыгы гына чагылмый. Ә өлкәннәрне өлкән күреп, яшьләрне үзенчә бәяләп, кешеләр белән сөйләшә-сөйләштерә белү сәләте, зыялылыгы чагыла. Әгәр ул шундый ягымлы, сүзчән һәм кеше холкын сиземләү сәләтенә ия булмаса, биш калын томга кергән халык иҗаты әсәрләрен язып ала алыр идеме? Мин үзем дә фольклорчы, берничә ел Илбарис Надиров белән экспедицияләргә чыккан кеше буларак, берәр җыруны җырлату, әкиятне сөйләтү өчен күпме үгетләп, әүвәл үзең җырлап, сөйләп утырасыңны күз алдына китерәм. Фәрит Юсупов тупланмаларына кергән җыр, бәет, мөнәҗәт, әкият һ.б. әсәрләрне саный, укый башласаң, исләрең китәрлек. Аларны бер кеше язып алганмы, шуңа бер гомер җиткәнме дип уйлыйсың. Аның язмаларына янә бер үзенчәлек хас, алар барысы да нәкъ Себер татарлары шивәсендә язып алынган. Ә бит кайбер фольклорчылар, аларны әдәби телгә күчереп, бөтен тәмен, яңгырашын бетерәләр. Ул – чәчәкне противогаз киеп иснәүгә тиң. Бөтен үзенчәлеге, тәме югала.

Төркиядә хезмәтен тутырып кайтып, шактый вакыт КДУның татар филологиясе факультетында профессор вазифаларын башкарып ятканда, Ф.Юсупов озак еллар өйрәнгән, элгәрләре һәм үзе язып алган әсәрләре тупланган серле сандыктан бикне алсын өчен махсус диярлек, Мәдәният министрлыгы каршында Традицион мәдәниятне үстерү үзәге ачыла, һәм аны әйдәп баручы гыйльми хезмәткәр итеп чакыралар. Шунда эшләгәндә, ул Себер татарлары тарихына, фольклорына мөкиббән галим буларак танылa. 2012–2018 елларда бер-бер артлы саллы-саллы китапларын нәшер итә. Үзенә чаклы язып алынган җәүһәрләрне фәнни күзлектән барлап чыгып, үзе тапкан вариантларны кертеп, Себер халкының рухи мирасын өйрәнүне яңа баскычка күтәрә.

Бу юлда Ф.Юсупов өч принципны маяк итеп ала. Беренчесе – бу юнәлештә хезмәт иткән, аңа чаклы халык иҗатын телдән язып алып, фәнни-гамәли калыпка салуда зур хезмәт куйган шәхесләргә ихтирамлы һәм рәхмәтле булу. Бер мәҗмугасының башында ул өч исемне чәчәк бәйләме уртасына куя: «Себер татарлары халык авыз иҗаты мирасын җыючы һәм фәнни өйрәнүче мәшһүр галимнәр: Василий (Вильгельм) Радлов, Хәмит Ярмөхәммәтов (Хәмит Ярми), Флора Әхмәтова-Урманченең якты истәлекләренә багышлыйм».[1]

## Милләтнең үзаңы – аның иҗатында

Һәр халыкның тарихы, холкы, фикерләү рәвеше, шигъри теле аның авыз иҗатында эзен калдыра. Инглиз, алман, рус һ.б. милләтләрнең дастаннары, сагалары, былиналары, җырлары шуны раслый. Фольклор – һәр халыкның «визит карточкасы». Себер киңлекләрендә яшәүче милләттәшләребезнең үзләренә генә хас тарихи дастаннары, бәетләре, җырлары булса да, «Йосыф-Зөләйха», «Таһир-Зөһрә», «Бүз егет», «Сәйфелмөлек» кебек дастаннар – уртак байлык, «Кузы Көрпә», «Шаһсанәм вә Гариб» кебек сөю-сәгадәт газапларына багышланганнары башка төбәкләрдә дә очрыйлар.

Шул ук вакытта бары тик шул якта туып, шунда яшәгән «Абыл Касыйм», «Бури хан», «Атулы Батыр» кебек тарихи дастаннар шул җирлектә генә туганнар дип уйларга нигез бар.

Героик дастаннардан «Алпамыш»ның әллә ничә төрле нөсхәләре язылып алынуы мәгълүм. («Алып», «Алып-батыр», «Алып кеше» (Алпамша, Алпамыш, Алтмамыш...) Аларның эш-хәрәкәте маҗаралы: гади кешеләрнең башына да кермәслек батырлыклар (дию пәриләрен, җеннәрне, билгесез усал көчләрне җиңә) кылып, хакыйкать тарафдары, уңай зат буларак сурәтләнәләр.

Татар халык иҗатының эпик поэзиясенең, аерым алганда, «Сәйфелмөлек», «Алпамыш», «Кузы Көрпә», «Йелек батыр», «Бүз егет» һ.б. сакланган нөсхәләрен, аларның үсеш-үзгәреш, телдән төшеп калу эволюциясен профессор Ф.Юсупов оештырган сәфәрләр вакытында теркәп калалар[2].

Халык үзенең батырларын, аларның мәнфәгатьләрен кайгырткан затларын сайлап ала белгән. Себер татарларының, аз санлы булсалар да, иркен таралып, җәелеп утыру сәбәпле, ханлыклары да, табигый ки, хакимнәре дә күп булган. Шулар арасыннан ул азатлык өчен көрәшкә гомерен багышлаган Күчүмне аерып алган. Аңа берничә истәлек, риваять багышлаган. «Мең алты йөзләрдә булырга тиеш, Себер татарларының ханы Күчүм булган. Ул үзе көчле, акыллы, хәйләкәр кеше булган».

Ф.Юсупов үзенең тупланмаларында халыкның мәңгелек хыялларын, якты тормыш, яхшы кешеләр турында күзаллавын үзенә кояш нурларыдай җыеп алган әкиятләргә (ул аны себерчә «йомаклар» дип атый) һәм кече жанрларга – мөнәҗәт, бәет, җырларга зур игътибар бирә.

Дастаннарны, әкият-риваятьләрне Ф.Юсупов, нигездә, В.Радлов чыганакларыннан алса, бәетләрне Ф.Әхмәтова язмаларында тапса, соңрак әйләнешкә кергән мөнәҗәтләрне үзе һәм студентлар белән язып алганнарын тәкъдим итә. Экспедициягә үзе белән алып чыккан әгъзаларның исем-фамилияләрен күрсәтеп баруында да, аның акыллы, эчкерсез, кешелекле, намуслы шәхес булуы күренә.

Ислам диненең шигъри юлдашы, халык иҗаты белән язма шигърият бердәмлегендә, әүвәл гарәп-фарсы телләрендә туып, төрки дөньяга (бигрәк тә татарларга, өлешчә башкортларга) тирән үтеп кереп, үз жанры булып киткән мөнәҗәт Себер татарларының рухи-мәдәни мирасында мөһим урын тота. Мөнәҗәтләрнең асылында суфичылык фәлсәфәсе белән баетылган дини лирика ята. «Мөнәҗәт» гарәпчәдән тәрҗемәдә

[1] Сибирские татары: из сокровищницы духовной культуры. Йомаклар-сказки.– Казань: «Магариф-Вакыт», 2016. – С.5

[2] Юсупов Ф.Ю. Себер татарлары. Рухи мәдәният җәүһәрләре. – Казан: КДУ нәшрияты, 2014. – Б.47.

Аллаһка табынуны, таянуны, ярлыкау вә ярдәм сорап мөрәҗәгатьне аңлата. Ислам диненең йогынтысы көчлерәк чорда әүвәл Урта Идел, Урал тарафларында киң таралып, XIV гасырдан, халыкның төп өлеше Исламны кабул иткәч, мөнәҗәтләр Себер татарларының рухи дөньясына да үтеп керә.

Мөнәҗәтләрнең мәгънәви яктан төрле төркемнәргә бүленүе М.Бакиров, К.Миңнуллин, К.Хөснуллин, Ю.Юсупов, Ф.Урманчеев, Р.Ягъфәров, А.Садыйкова һ.б. галимнәр тарафыннан шактый тәфсилле өйрәнелгән. «Ышанам бер Аллага», «Бердер Аллаһым минем», «Ярдәмеңне бир, Аллаһым», «Рәхим-рәхмәтең кыл, Расулуллаһ», кебек мөнәҗәтләр татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә дә табыла. Себер татарлары арасында киңрәк таралган, ешрак әйтелә торган мөнәҗәтләр итеп, Ф.Юсупов ялгыз картлыкка, карыйлыкка, ата-ана белән балаларның аерылышуына багышланганнарын, туган илдән читтә яшәү сагышын, якыннарын сагыну моңын үзәккә алганнарының күплегенә игътибар итә[3]. «Аерылмагыз балалардан», «Аерылдым туганнардан», «Кайттым-җиттем туган илгә...», «Торып, сахраларга чыксам» кебек мөнәҗәтләрнең өстенлек итүе Себер халкының сибелеп яшәве, татарларның үзәге Татарстаннан читтә көн итүләре белән дә аңлатыла торгандыр.

Моң, сагыш, юксыну, югалту җимеше бәетләргә килгәндә, биредә халкыбызны якынлаштырган әсәрләр тагын да күбрәк. Уртак югалту – Тукай үлеме («Тукайга бәет»), төрле сугышларда үлгәннәргә мәрсия («Безне Герман аерды»), ә инде «Хан мәчете бәете», «Суга баткан Гайшә бәете», «Гайшә мескен бәете» һ.б. әсәрләрне милләттәшләребез яшәгән һәр төбәктә ишетә, тыңлый аласың. Минем фикеремчә, безнең якта бик ишетелмәгән «Берсендә – йолдыз, берсендә – кубыз», «Ике ир бала бәете», «Наполеон һәм Миңнулла» бәетләре Себер якларында иҗат ителгәннәр.

Себер татарларының җырларын туплап, сәнгати үзенчәлекләрен өйрәнүгә дә Ф.Юсупов зур әһәмият бирә. Ул элгәрләренең Себер татарлары җырларын бәяләгән хезмәтләрне ихтирам белән телгә ала.

Халык иҗаты әсәрләренең барысында да кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең сафлыгы, садәлеге, явызлыкның җиңелүе, мәхәббәтнең мәңгелеге, ихласлыгы, җилдавылларга бирешмичә шатландыруы алга сөрелә. Халык олы җанлы шәхесләрен, дөреслек, хакыйкать өчен көрәшчеләрен онытмый, дастаннарында, әкиятләрендә, җырларында олылый. Халык иҗаты җәүһәрләре, үз чиратларында, татар халкының характерына, матурлык, тормыш яме турында күзаллавына, үз-үзен тотышын камилләштерүгә, туганлык, милли мөнәсәбәтләрнең ныгуына тәэсир ясаганнар. Шул байлыкны җыеп, туплап, яңа буыннар өчен саклап калу – фидакарьләр бурычы. Күңелләрдә якты уйлар, киләчәккә ышаныч тудырып, рухи мирасны халыкка кайтаручы олы шәхесләрнең берсе – Фәрит Юсупов. Ул – Себер татарларын аерым милләт дип, пычрак суда балык тотарга маташучылардан аермалы буларак, Себердә яшәүче милләттәшләребезне татар халкының аерылмас, тирән тамырлары белән береккән бер өлеше дип бәяли.

Җыеп кына әйткәндә, аның мәҗмугалары күп нәрсә, аеруча безнең катлаулы чорда, төрле төбәкләрдә көн күрүче милләттәшләр арасында бердәмлекне ныгыту ихтыяҗы турында уйландыра. Ошбу китаплар Себер татарлары арасында халыкның үз теленнән язып алынган үрнәкләр белән беррәттән, күпчелек фольклор әсәрләренең бөтен милләтебез өчен уртак икәнлеген, һәр төбәкнең рухи, мәдәни казанышы халкыбызның уртак байлыгы булуын исбатлый.

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,**
*филология фәннәре докторы,*
*Татарстан Республикасының*
*халык язучысы.*

[3] Юсупов Ф.Ю. Себер татарлары. Рухи мәдәният җәүһәрләре. – Казан: КДУ нәшрияты, 2014. – Б.499.

# КАЗАН ЭНЦИКЛОПЕДИСТИКА ФӘННИ МӘКТӘБЕ

*Мансур Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтына – 30 ел*

Башкалабыз Казан илдә һәм дөньяда фәнни ачышлары белән шөһрәт казанган мәшһүр галимнәре, фәнни мәктәпләре белән данлыклы. Чишмә башында – 1804 елда ачылган Казан университеты галимнәре. Беренче Казан геометрия фәнни мәктәбе Н.И.Лобачевский хезмәтләре нәтиҗәсендә барлыкка килә. Алга таба ике гасыр дәвамында Казанда 15 фәнни мәктәп оеша. Алар турында Татар энциклопедиясенең 3 нче томында махсус мәкалә бирелгән.

Һәм менә соңгы 30 елда Татарстан Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтында 16 нчы Казан энциклопедистика фәнни мәктәбе барлыкка килде. Аның оешу тарихы, казанышлары турында галим Гомәр Сабирҗановның 2022 елда нәшер ителгән «Татарская энциклопедия: краткий очерк истории создания» исемле фәнни хезмәтендә тәфсилләп язылган. Укучыларга тәкъдим иткән бу мәкаләмдәге кайбер мәгълүмат автор рөхсәте белән шул китаптан алып бирелде.

Тарихка күз салсак, татар зыялылары инде күптән, ике гасыр дәвамында милли энциклопедия булдыру турында хыялланган. Гыйльми хезмәтләрендә, аның әһәмиятле белем хәзинәсе булачагын нигезләп, зарурлыгын икърар иткәннәр. Әмма бу изге хыяллар төрле сәбәпләр аркасында тормышка ашмаган.

Бу юнәлештә кайбер кыю гамәли адымнар да ясалган. Әйтик, 1927-1928 елларда милләтпәрвәр галим Әхмәтһади Максуди, «Фәнни камус» («Энциклопедик сүзлек») төзеп, беренче китабын (нияте 4 китап) нәшер итүгә ирешә. Әмма 1932 елда репрессиягә дучар була, төрмәдә кыйнап азаплыйлар, 1933 елда Киров өлкәсенә сөргенгә озатыла, хезмәте җыеп алына, тыела. Әдәбият белгече, журналист Исмәгыйль Рәмиев тә 1930 елларда репрессиягә эләгә, бәхеткә, исән кала. Казанда 1969 елда «Әдәби сүзлек» төзи. Рецензентлар бу әһәмиятле хезмәтне ни сәбәптәндер нәшер итүне хупламый. Ни кызганыч, автор шул ук елда вафат була. Аның кулъязмасын әдәбият белгече Рәис Даутов табып ала, редакцияләп, тулыландырып, 2001 елда И.Рәмиев, Р.Даутов авторлыгында китап итеп чыгара. Күренекле язучы Әхмәт Фәйзи 1957 елда матбугатта: «Безгә, татар халкына, үзенең энциклопедия сүзлеген ясарга вакыт җитте» дигән тәкъдим белән чыга.

Әмма КПСС автономияле республикаларга энциклопедия төзергә рөхсәт итми. Үзгәртеп кору чорында мондый мөмкинлек туа. Татарстанның Тел, әдәбият, тарих институты (ИЯЛИ) директоры Мирфатыйх Зәкиев 1989 елның февралендә КПСС Өлкә комитеты үткәргән бер җыелышта беренче секретарь Г.И.Усмановка «Татар энциклопедиясе»н булдыру зарурлыгы турында тәкъдим белән чыга. Март аенда Казан дәүләт мәдәният институтының кафедра мөдире Гомәр Сабирҗанов (ул әлеге мөрәҗәгать турында белмәгән) Өлкә комитетына шул ук мәсьәлә хакында хат яза.

Секретарь бу башлангычны хуплый һәм, ниһаять, 6 сентябрьдә ТАССР Министрлар Советы Рәисе М.Ш.Шәймиев имзасы белән «Татар энциклопедиясен хәзерләү һәм нәшер итү» турында тарихи карар кабул ителә. Шул карар нигезендә Тел, әдәбият, тарих институтында 1990 елда Татар энциклопедиясен хәзерләү фәнни үзәге оештырыла, мөдире итеп Ф.С.Хәкимҗанов раслана.

Аз санлы (16 хезмәткәр) бу коллектив ике ел дәвамында әллә ни эш майтара алмый, чөнки әле тәҗрибә дә юк. Беларусь энциклопедиясен эшләү тәҗрибәсе белән танышу өчен А.Г.Яруллина һәм Г.К.Вайда берничә көн Минск шәһәрендә булып кайталар. Анда штатта 130 хезмәткәр эшләвен сөйләгәч, безнекеләр шакката.



*Татар энциклопедиясе сүзлеген рус һәм татар телләрендә төзеп нәшер иткән өчен 2005 елда институтның бер төркем хезмәткәрләренә Татарстан Республикасының Фән һәм техника өлкәсендә дәүләт премиясе бирелде.*

Энциклопедиячеләр коллективы, 1992 елда Татар энциклопедиясе бүлеге буларак, әле оешып кына килүче Татарстан Фәннәр академиясенә күчерелә, эшен дәвам итә. Аның Президенты, академик Мансур Хәсәнов (25.06.1930 – 13.03.2010) энциклопедия хәзерләүне Академиянең мөһим бурычы дип саный, бүлек эшчәнлеген даими күз уңында тота. Бүлек мөдире вазифасын 1968 елдан танышы, булдыклы, тәҗрибәле галим Гомәр Сабирҗановка йөкли. Алар Мәскәүдә узган КПСС Өлкә комитетлары мәктәпләр һәм уку йортлары бүлекләре мөдирләре семинарында очрашып таныша. Тува республикасыннан килгән яшь галимнең перспективалы зат булуын М.Х.Хәсәнов абайлап ала, аңа Казанга эшкә кайтырга киңәш итә. КПСС Өлкә комитеты беренче секретаре Ф.Ә.Табеев хуплавы белән Г.С.Сабирҗанов ТАССР Министрлар Советы эшләр башкару идарәсенең социаль-мәдәният бүлеген 1971–1980 елларда нәтиҗәле җитәкли. Аннан соң Казан мәдәният институты ректоры чакыруы белән үзе оештырган яңа кафедра мөдире вазифасын 12 ел уңышлы башкара, аның тирән эчтәлекле лекцияләренә студентлар яратып, бик теләп йөри.

Мансур Хәсәнов үзе Казанга чакырып кайтарган хезмәткәрнең эшчәнлеген даими күзәтеп, белеп торган, күрәсең. Фәннәр академиясе составындагы Татар энциклопедиясе бүлеген ул нәкъ Гомәр Сабирҗановка ышанып тапшыра һәм озакка сузмыйча күп томлы энциклопедия хәзерләү бурычын куя. Киңәшләшкәннән соң, башта «Татарский энциклопедический словарь» (Словник) һәм «Татар энциклопедия сүзлеге» (Лөгатьлек) төзеп чыгарырга булалар. Беренчесе – 1994 елның февралендә, икенчесе 1996 елда дөнья күрә. 1997 елда «Татар энциклопедиясенең шәхесләр исемлеге» басылып чыга. Бу басмалар югары уку йортларына, фәнни-тикшеренү институтларына, иҗат берлекләренә, гәҗит-журналлар редакцияләренә тапшырыла, аларның фикерләре сорала. Шактый күп уңай бәяләгән фикерләр, аз санлы искәрмәләр, авторларга таяну ноктасы булып, алдагы эшләргә дәрт-дәрман өсти.

Хәзер коллективка «Татар энциклопедия сүзлеге»н рус һәм татар телләрендә фундаменталь басма итеп хәзерләп нәшер итү бурычы куела. Бу бик дөрес, отышлы карар була, соңрак үзен тулысынча аклый. Башка энциклопедиячеләр сүзлекләрне энциклопедияләр басылып чыкканнан соң гына нәшер итәләр икән. Шулай итеп, безнең бу гыйбрәтле тәҗрибә дөньяда беренче булып чыкты.

Эш күләме гаять зур һәм үзенчәлекле, ә бүлектә нибары 16 хезмәткәр. Мөдирнең нигезле гозерен Татарстан Министрлар Советы Рәисе Мөхәммәт Сабиров уңай хәл итә, бүлек штаты 41 кешегә җиткерелә. Гомәр Сабирҗанов хезмәткәрләрнең эшен оештырып җайга сала, киеренке, нәтиҗәле эш дәвам итә.

Энциклопедия төзү методикасын үзләштерү максатында мөдир Мәскәүгә, Россиянең зур энциклопедиясе (БРЭ) нәшриятына юл тота, 1992–1994 елларда берничә тапкыр барып, башкала энциклопедиячеләре тәҗрибәсен өйрәнә. Соңрак, Татар энциклопедиясе институтын оештыргач, бүлек мөдирләре Р.М.Мөхәммәтшин, Р.В.Шәйдуллин, рәссам Л.Р.Галиеваны да алып бара. Мәскәүдән алып кайткан фәнни-методик кулланмалар, нәшриятта күргән тәҗрибә институт эшчәнлеген камилләштерүгә ярдәм итә.

1994 елның 3 маенда Татарстан Министрлар Кабинетының М.Ш.Шәймиев имзалаган карары «Татар энциклопедиясен хәзерләү һәм нәшер итүдә өстәмә чаралар турында» дип атала. Бу тарихи карар нигезендә Татар энциклопедиясе бүлегенә ТР Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты статусы бирелә. 2014 елдан Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты дип атала, 2024 елда Мансур Хәсәнов исеме бирелде.

Институт директоры итеп 1994 елда ТР Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов раслана, ул бер үк вакытта бик җаваплы ике вазифаны башкара. Рәсми боерык белән урынбасары һәм институтның җаваплы мөхәррире эшен Гомәр Сабирҗановка йөкли.

Фәннәр академиясе 1992–1994 елларда әле оешу, тернәкләнү чоры кичерә, аның колачлы эшчәнлеген җайга салу мәшәкатьләре, республиканың иҗтимагый һәм сәяси тормышында катнашу, аңлашыла ки, академик М.Х.Хәсәновның Татар энциклопедиясе институтын оештыру, аның көндәлек эшчәнлеген якыннан торып идарә итүгә вакыты җитми. Бу эшләр белән аның бердәнбер урынбасары Гомәр Сабирҗанов шөгыльләнә. Беренче чиратта, ул төрле фәннәрне тирәнтен белүче тәҗрибәле кадрлар туплауга керешә. Бу мәсьәлә эзлекле рәвештә, әкренләп, уңышлы хәл ителә. Институтка булдыклы, энтузиаст галимнәр, хезмәткәрләр кабул ителә. Нәтиҗәдә бу үзенчәлекле, җаваплы эштә бердәм, тату, бер-берсенә игелекле затлардан торган 107 кешелек коллектив барлыкка килә. Алар арасында 9 фән докторы, 26 фән кандидаты була, шулардан 10 хезмәткәр Татарстанның атказанган исемнәренә лаек булган.

Гомәр әфәнде институт структурасында 15 фәнни-редакция тармак бүлекләре оештырды, мөдирләре итеп тәҗрибәле галимнәрне билгеләп куйды. Нәшер ителгән басмаларны фәнни яктан тикшерү максатында, Баш фәнни-редакция коллегиясе һәм 35 фәнни тармак редакция коллегияләре оештырылды. Бүлекләр, аларның мөдирләре һәм хезмәткәрләр исемлеге энциклопедиянең һәр томында күрсәтелгән.

Тәҗрибәле, оста оештыручы һәм идарәче, дипломат Гомәр әфәнде Татар энциклопедиясен төзү эшенә Казанның, Татарстанның күренекле галимнәрен, академикларын җәлеп итүгә ирешә. Бәхеткә, алар – Татарстан патриотлары, милләтпәрвәр затлар – аның мөрәҗәгатен намус эше дип кабул итеп, хезмәт хакы белән кызыксынмыйча, гаять зур ярдәм күрсәтәләр. Бу фидакарь галимнәр: филологлар – Мирфатыйх Зәкиев, Хатыйп Миңнегулов, Вахит Хаков, Флёра Сафиуллина; тарихчылар – Миркасыйм Госманов, Индус Таһиров; физиклар – Кев Салихов, Шамиль Чабдаров; археологлар – Альфред Халиков, Евгений Казаков; архитектор – Сәйяр Айдаров; музыкант – Рубин Абдуллин һ.б. Казан дәүләт университеты, фәнни-тикшеренү институтлары, югары уку йортлары галимнәре белән иҗади хезмәттәшлек Татар энциклопедиясен һәм башка фәнни хезмәтләрне сыйфатлы, чынбарлык нигезендә хәзерләп нәшер итү мөмкинлеген тудырды.

Штаттагы урынга дәгъвачыны Гомәр әфәнде, бик җентекләп тикшергәннән соң, өч ай сынау шарты белән кабул итте. Шәхсән минем үземә, 2004 елда эшкә килгәч, бик җитди керү имтиханы тотарга туры килде. Институтның Икътисад һәм халык хуҗалыгы тарихы бүлегендә эшкә мин җиденче, өлкән фәнни хезмәткәр булып килдем, 9 ел тырышып, намуслы хезмәт иттем. Бүлек шактый зур, мәртәбәле, чөнки энциклопедия өчен язылачак мәкаләләрнең темалары киң колачлы. Татарстанның икътисады, халык хуҗалыгының бик күп тармаклары тарихы һәм хәзерге халәте турында тулы, тәфсилле мәгълүмат булырга тиеш. Бүлек мөдире профессиональ тарихчы, КДУны тәмамлагач, күпьеллык хезмәт тәҗрибәсе туплаган урта яшьтәге

Гөлнур ханым Мәүлетова миңа энциклопедия өчен мәкаләләр язу методикасын аңлатты, киңәшләр бирде. Ул инде 1996 елдан биредә эшли, 2003 елдан – бүлек мөдире. Җәмгысы 20 ел әйбәт, нәтиҗәле хезмәт итеп, тәҗрибәле энциклопедияче булып өлгергән. Ул «нәчәлник» булып, безгә әмер биреп кенә утырмады. Күп хезмәт таләп итә торган, катлаулы темаларга – сәнәгать, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалыгы, транспорт, элемтә һ.б. фәнни мәкаләләрне үзе язды. Җитәкчебез хезмәттәшләренә таләпчән, әмма хәерхаһлы, мәрхәмәтле остаз булды.

Бүлектә күренекле галимнәр, белгечләр эшли – Татарстанның атказанган икътисадчысы, язучы, профессор Фарсель Зыятдинов (1937–2021) 1993–2003 елларда шушы бүлектә мөдир вазифасын башкарды, тагын 10 ел өлкән фәнни хезмәткәр иде.

Ветеринария фәннәре докторы, ТАССРның атказанган зоотехнигы профессор Амсар Фазылҗанов (1937–2023) 1996–2013 елларда терлекчелек тармаклары турында тирән эчтәлекле мәкаләләр язды.

Татарстан авыл хуҗалыгы министры урынбасары булып эшләгән, ТАССРның атказанган агрономы Иван Афанасьев 2002–2013 елларда намуслы һәм нәтиҗәле хезмәте белән энциклопедия хәзерләүгә зур өлеш кертте.

Элек КДУның биология факультетында эшләгән Лидия Полякова (1949–2008) 2002–2008 елларда безнең бүлектә үсемлекләр дөньясы турында бай эчтәлекле мәкаләләр язды.

Тарихчы (КДУ тәмамлаган) безнең институт аспиранты Сергей Белов (1979–2022) 21 ел дәвамында төрле мөһим темаларга күләмле камил язмалары белән ихтирам казанды. Фәнни тикшеренүләрен йомгаклап диссертация язды, тик якларга өлгерә алмады, каты авырудан соң, 43 яшендә вафат булды.

2008 елда безнең төркемгә Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтының элекке хезмәткәре, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, арышның мул уңышлы яңа сортын чыгарган селекционер Руфина Асретдинова килеп кушылды. Казан авыл хуҗалыгы институтында (хәзер Аграр университет) 1980 елларда без укыткан студент кыз шундый зур казанышка ирешкән, афәрин! Энциклопедиягә ул Татарстан үсемлекчелеге турында, шул мөһим тармакта күркәм нәтиҗәләргә ирешкән галимнәр, игенчеләр һ.б. темаларга тәфсилле мәкаләләр иҗат итте. Безнең бүлек ябылгач (2013 ел), Төбәкне һәм социаль-мәдәни вазгыятьне өйрәнү бүлегендә әһәмиятле хезмәтен әле дә дәвам итә.

Татар энциклопедиясенә үзем дә шактый күп мәкаләләр яздым, мәгълүмат туплау өчен еш кына архивларда казындым, предприятиеләрдә дә булдым. Бары берничә мисал китерәм. Татарстан икътисады, сәнәгатенең алга киткән эре тармаклары: азык-төлек, сөт һәм сыр, сыра һәм алкогольсез эчемлекләр, спирт, шәраб, аракы җитештерү, җәмәгать туклануы, кулланучылар кооперациясе, «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы, Түбән Кама ГЭСы, Социалистик Хезмәт Геройлары һ.б.

Мин әзерләгән күләмле мәкаләләр уңай бәяләнде, алар күптомлы басмаларда урын алды. Мин чын күңелдән канәгать булдым.

Шушы югары квалификацияле, бердәм коллективтагы хезмәттәшләремә мин ихлас рәхмәтле! Вафат булганнарны юксынабыз, алар һәрчак истә. Исәннәребез – институт ветераннары белән даими элемтәдә, хәл-әхвәл белешеп яшибез, сирәк булса да, данлыклы институтыбызда очрашып куанышабыз!

Институт һәм бүлек тормышында мине шул сокландырды – коллектив даими киеренке иҗади эшчәнлек халәтендә, хезмәткәрләр үзара ягымлы, игелекле мөнәсәбәттә, эшләрен зур җаваплылык белән башкаралар. Минем өчен бу яңа эштә аларга сорауларым күп булды, игътибар белән тыңладылар, иренмичә яхшылап аңлаттылар. Мине гаҗәпләндергәне шул булды – директор урынбасары, җаваплы мөхәррир Гомәр ага Сабирҗанов һәр мәкаләне игътибар белән укып редакцияли, кимчелеккә, хилафлыкка юлыкса, автор белән бергә дустанә, әдәпле генә төзәтәләр. Ә мәкаләләр саны меңнәр, хәтта ун меңнәр.

Институт коллективы 1997 елда «Насёленные пункты Республики Татарстан. Краткий справочник» хәзерләп нәшер итте, укучыларга ошады.

Ниһаять, 1999 елда фундаменталь «Татарский энциклопедический словарь» хәзерләнеп, аз чыгымнар белән Лондонда нәшер ителде, тиражы 30 мең булды. Казан типографияләрендә андый калын басма өчен әле җиһаз юк, ә Мәскәү наширләре бик күп акча сорады. Сүзлек макетын иң башта Мәскәү БРЭ галимнәре укып, югары бәя бирде. Басылып чыккач, Татарстан матбугатында күпсанлы уңай бәяләгән мәкаләләр дөнья күрде, институтка да хатлар килде, кайбер кимчелекләр, хилафлыклар да күрсәтелде.

Казан шәһәре хакимияте (ул вакытта хакимият башлыгы Камил Исхаков) Татар энциклопедиясе институтына 1999 елда Пушкин урамында (56 нчы йорт) ике катлы әйбәт бина бирде. Эш шартлары күпкә уңайланды. 2016 елда бинага капиталь ремонт ясалды, яңа җиһаз, компьютерлар куелды.

«Татар энциклопедиясе сүзлеге» туган телебездә 2002 елда Хельсинки шәһәрендә басылып чыкты. Җентекле тикшеренүләр, архив материалларын туплау нәтиҗәсендә иҗат ителгән энциклопедия сүзлекләре коллективның мәдәният, фән өлкәсендә зур җиңүе булды, киң җәмәгатьчелек аларны җылы кабул итте, матбугатта уңай бәяләгән мәкаләләр чыкты. Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа, Чабаксар, Саранск, Минск, Киев энциклопедиячеләре дә безнең бу сүзлекләргә югары бәя бирде. Сүзлекнең дөньядагы иң затлы 14 телнең берсе булган татар телендә дөнья күрүе куанычлы вакыйга, тарихи әһәмияткә ия казаныш булды! Башта энциклопедик сүзлекләр эшләп чыгару дөрес һәм отышлы адым булды, чөнки алар таләпчән укучылар сынавын узды, Татар энциклопедиясенә төзәтелгәч, тулыландыргач кына кертелде.

Татар энциклопедиясе сүзлеген рус һәм татар телләрендә төзеп нәшер иткән өчен 2005 елда институтның бер төркем хезмәткәрләренә Татарстан Республикасының Фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе бирелде. Лауреатлар исемлегендә М.Х.Хәсәнов, Г.С.Сабирҗанов, В.Г.Абзалова, А.В.Гарзавина, Р.Н.Даутов, Р.И.Мөхәммәтшин, Р.В.Шәйдуллин булды. «Җир ресурсларын файдалану нәтиҗәлелеген күтәрүнең оештыру-икътисади механизмнары» дигән фәнни хезмәтем өчен мин дә, автордаш буларак, 2009 елда шул мәртәбәле премия лауреаты булдым.

Киеренке иҗади эш туктаусыз дәвам итте. Татар энциклопедиясенең рус телендәге 6 томы, 2002–2014 елларда хәзерләнеп, бер-бер артлы басылып чыкты. Энциклопедия басмалары баш мөхәррирләре М.Х.Хәсәнов, аннан соң Н.М.Мазһаров һәм М.Х.Сәлахов, җаваплы мөхәррир Г.С.Сабирҗанов булды. Баш фәнни-редакция коллегиясе составында 37 күренекле галим эшләде. Алты томда җәмгысы 20628 мәкалә, шулардан 9685е күренекле шәхесләр турында иде. Шунысы әһәмиятле: бу саллы басмалар кара-ак һәм төсле фотосурәтләр белән бизәлеп, Казанда «Идел-Пресс» комплексы типографиясендә нәшер ителде. Аның директоры Ислам Әхмәтҗанов Энциклопедия институты мәнфәгатьләрен үтәү өчен 2002 елда типографиягә махсус җиһазлар кайтарткан иде. Нәтиҗәдә Татар энциклопедиясенең 13 томы, (7 том татар телендә) югары сыйфатлы итеп басылып, киң җәмәгатьчелек куллануына тапшырылды.

Энциклопедиягә мәкаләләр хәзерләгәндә, кайбер күңелсез, сәер хәлләр дә очрый. Илебездә, хәтта чит илләрдә билгеле, данлыклы Казан музыка кораллары фабрикасы (анда 500 кеше эшләгән) 1990 елда бөлгенлеккә дучар була һәм эшчәнлеген туктата. Фабрика архивы чүплеккә чыгарып ташлана. Казан Полиграфия-нәшрият комбинаты (элекке Татполиграф) әле эшләсә дә (158 кеше), комбинат архивы «су агып юешләнде» дип, чүплеккә озатыла. Ә канун аларны Милли архивка тапшыруны таләп итә югыйсә!

Татарстанның Кама Тамагы районы, Зур Кармалы авылы тумасы агроном Габдуллаҗан Мәликов (1907–1981) 1946–1978 елларда Грозный шәһәре янындагы совхозда директор булып уңышлы эшләгән. 1966 елда ул Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек була. Аның турында архив мәгълүматларын сорап, мин Ичкерия Президентына хат юлладым. Җавап безне тетрәндерде: «Архив Россия-Чечня сугышы вакытында тар-мар ителде».

Геройның якташы, абруйлы журналист Хәмзә Бәдретдинов, туганы Азат ярдәме белән язып, мәкаләне һәм фотосурәтен 4 нче томда урнаштырдык.

Институт коллективы, кыенлыкларны җиңеп, тарихта беренче күптомлы уникаль, универсаль Татар энциклопедиясен иҗат итте, якты дөньяга чыгарды. Күп хезмәт сорый торган, четерекле һәм җаваплы бу эшне тормышка ашырган хезмәткәрләр мактауга лаек, әлбәттә! Бигрәк тә институт коллективын оештырган, бу изге эшкә 25 еллык титаник хезмәтен кызганмаган, һәрберебезгә укытучы, остаз булган, җаваплы мөхәррир Гомәр ага Сабирҗанов – искиткеч кеше! Тарихчы галим, мәдәният белгече (культуролог), тәҗрибәле энциклопедияче, киң, күпьяклы белемле, әхлаклы инсан.

Халкыбыз өчен бик мөһим эшне ул башыннан алып ахырына тикле җиренә җиткереп башкарып чыкты. Күренекле энциклопедияче, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, «Почёт билгесе», «Буян-Бадыргы» орденнары кавалеры Гомәр Сабирҗанов 2017 елдан лаеклы ялда. Әмма тынгысыз галим кул кушырып утырмый, монография язды, институт җитәкчеләре, коллектив белән тыгыз хезмәттәшлектә яши. Олы хезмәтен югары бәяләп, ТР Фәннәр академиясе президенты Сабирҗанов Гомәр Салих улын 90 яше тулган көнендә (2023 ел, 20 апрель) тантаналы җыелышта Академиянең «Фәнни казанышлары өчен» алтын медале белән бүләкләде.

Татар энциклопедиясе институтында эшләвемне әйткәч, чуваш милләтеннән булган бер танышым – югары белемле юрист – әйтә куйды: «Ничек инде ул энциклопедия татарныкы гына?» Татар энциклопедиясе бары тик татарлар турында гына дип уйлаган икән. Энциклопедиягә кертелгән чуваш милләтеннән булган күренекле шәхесләрне, башка милләт вәкилләрен дә атагач, ул канәгать калды.

Ниһаять, 2008 елда Татар энциклопедиясенең 1 нче томы ана телебездә дөнья күрде. Күптән көтелгән бу тарихи басма 22 октябрьдә Татарстан Фәннәр академиясенең зур залында җәмәгатьчелеккә тантаналы җыелышта тәкъдим ителде, республикабыз һәм татар халкының фәнни, мәдәни тормышында мөһим вакыйга булды.

Бу казаныш белән Татар энциклопедиясе институты хезмәткәрләрен, күпсанлы авторларын, укучыларны ТР ФА президенты Әхмәт Мазһаров, ТР Хөкүмәте рәисе урынбасары, мәдәният министры Зилә Вәлиева, халык шагыйрьләре Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, академик Миркасыйм Госманов, профессор Абдуллаҗан Җәләлов, язучы Адлер Тимергалин кайнар тәбрикләделәр, басма турында уңай фикерләрен әйттеләр, киләчәккә тәкъдимнәрен белдерделәр. Татар энциклопедиясе институты директоры урынбасары, җаваплы мөхәррир Гомәр Сабирҗанов беренче томның кыскача эчтәлеге, аны хәзерләү тарихы, иң күп хезмәт куйган хезмәткәрләр турында сөйләде, аларга рәхмәт әйтте. Республика җитәкчеләренә, аеруча М.Ш.Шәймиевкә рәхмәтен белдерде. Институтның тарих бүлеге мөдире профессор Рафаил Шәйдуллин энциклопедия басмаларын ана телебездә әзерләү бүлеген оештыруны зур казаныш дип бәяләде һәм бу коллективның булдыклы, зыялы хезмәткәрләрен атады. Эшнең тулаем акрын бару сәбәпләреннән гуманитар һәм табигать-техника фәннәренең татар телендә терминнары эшләнмәгәнлеген, рус телендә чыккан томнардагы текстларны яңартып, тулыландырып бирү зарурлыгын әйтте.

Ана телендә иҗат ителгән беренче том Россиядә төрки телләр арасында беренче энциклопедик басма, башка төрки телләрне (башкорт, казакъ, үзбәк, азәрбайҗан, нугай, каракалпак һ.б.) белүче кеше дә оригиналда укып, күпкырлы, бай мәгълүмат алырга мөмкин. Г.Тукай әйтмешли, «чын безнеңчә милли» рухтагы энциклопедия, һичшиксез, татар телен, милләтен саклап калуга уңай йогынты ясаячак, киләчәк буыннарга олы мирас булып калачак.

Энциклопедия гыйльми мәгърифәтче вазифасын да әйбәт башкара. Беренче томны тәкъдим итү җыенындагы чыгышларында милләтпәрвәр зыялыларыбыз бу уникаль басманы югары бәяләделәр. Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин: «Татар энциклопедиясе – халкыбызның зур һәйкәле», – диде. Халык шагыйре Ренат Харис

фикеренчә, «Татар халкының соңгы гасырда ирешкән иң зур казанышы – үзенең энциклопедиясен булдыру». Язучы Адлер Тимергалин: «Энциклопедия – баш маяк, үрнәк өлге, милли казаныш, милли һәйкәл!» – дип бәя бирде. Академик Миркасыйм Госманов: «Энциклопедия халкыбызның милли үзаңын күтәрүгә, телнең үсеше, аның сүз байлыгын арттыруга зур өлеш кертә», – диде.

Татар энциклопедиясен төзү барышында фәнни терминнарны татар телендә булдыру мәсьәләсе хәл ителде. Юриспруденция, нефть чыгару, нефть сәнәгате, очкычлар һәм боралак (вертолёт), автомобиль төзү, төгәл фәннәр, авыл хуҗалыгы, биология, медицина, сәнгать, спорт һ.б. өлкәләргә караган терминнар тарихта беренче тапкыр туган телебездә эшләнде. Бу мөһим юнәлештә күп хезмәт куйган белгечләр: Р.Н.Даутов, А.К.Тимергалин, С.С.Шәмсетдинов (язучы Солтан Шәмси), В.К.Зыятдинов, К.С.Миңнебаев, Л.Х.Хәмидуллин, А.Г.Яруллина, профессорлар В.Х.Хаков, Ф.С.Сафиуллина, М.З.Зәкиев, Т.К.Сиражетдинов, А.А.Җәләлов, биология фәннәре кандидатлары Ф.З.Вәлиев, В.Г.Бакирова, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты Ф.Г.Борһанов, археолог М.И.Әхмәтҗанов, географ Л.Р.Камалиева һәм күп кенә башка хөрмәтле милләттәшләр.

Күптомлы Татар энциклопедиясе дөнья һәм илебез җәмәгатьчелегенә татар халкының һәм Татарстанда яшәүче башка милләтләрнең үзенчәлекле матди һәм рухи мәдәнияте турында бай мәгълүмат бирә. Ул дөньяга карашны киңәйтә, энциклопедик фикер йөртүгә этәрә. Тормышта, хезмәттә җитди казанышларга дәртләндерә, чөнки аның сәхифәләрендә үрнәк алырдай затлар турында язылган. Институтның югары сыйфатлы басмалары китап нәшриятлары өчен үрнәк булып санала.

Энциклопедия сәхифәләрендә төрле фәннәрнең хәзерге заман казанышлары тәфсилле күрсәтелгән. Татар халкы, Татарстан тарихының актуаль мәсьәләләре, җөмһүриятебезнең социаль-мәдәни, иҗтимагый-сәяси тормышы, икътисады киң яктыртылган. Татарстаннан читтәге төбәкләрдә яшәүче татарлар тарихы, аларның бүгенге хәләте турында да мәгълүмат бирелгән.

Энциклопедия мәкаләләре хәзерге фәнни карашка нигезләнеп язылган. Әйтик, татарларның рус тарихчылары бозып язган ясалма «тарихы» чынбарлыкта булган тарихыбыз белән алыштырылды. Чынбарлыкта булмаган, ялган «вакыйгалар» фаш ителеп, дөреслек, гаделлек җиңде. Мәсәлән, Җиңү байрагын 1945 елда Рейхстаг түбәсенә татар егете Гази Заһитов кадаган; Германиядә әсир татарларның фашистларга каршы көрәшкән яшерен оешмасы «Г.Кормаш һәм М.Җәлил төркеме» дип язылды. Советлар Союзы Герое Александр Матросов чынбарлыктагы Шакирҗан Мөхәммәтҗанов (1923–1943) дип кертелде.

Институтта 2000 елда аспирантура ачылды. Анда 67 белгеч укыды, фәнни тикшеренүләр алып барды, 28 аспирант кандидатлык диссертациясе яклады. Аспирантлар Татар энциклопедиясен эшләүдә актив катнашалар. 2024 елда 15 аспирант укый. 3 бүлек мөдире диссертация язып, яклап, фән докторы дәрәҗәсе алды: Р.В.Шәйдуллин (тарих), Р.М.Мөхәммәтшин (сәясәт), Р.Г.Усманов (физика).

Шуны искәртик, бер генә югары уку йорты да энциклопедиячеләр әзерләми. Бу үзенчәлекле һәм бик җаваплы хезмәткә белгечләр Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтында өйрәнәләр. Ә укытучы, остаз вазифасын биредә күпьеллык тәҗрибәле хезмәткәрләр: бүлек мөдирләре, методистлар, мөхәррирләр башкара. Җаваплы мөхәррир Гомәр әфәнде Сабирҗановның, фәнни-редакция коллегиясе әгъзаларының да игелекле ярдәме зур роль уйный. Шуңа күрә 2024 елда Мансур Хәсәнов исеменә лаек булган институтны без Казан энциклопедистика фәнни мәктәбе дип атыйбыз. Моңа институтның Татарстанда, Россиядә энциклопедистика фәнни-методик үзәк вазифасын нәтиҗәле үтәве дә нигезле хокук бирә. Эш шунда: XXI гасыр башлангач, Татарстан шәһәрләре, районнарында үзләренең энциклопедияләрен булдыру хәрәкәте киң колач алды. Бу өлкәдә эле тәҗрибә

булмаганга, аларны төзүчеләр безнең институтка методик ярдәм сорап мөрәҗәгать итәләр. Хәтта ерак Тыва Республикасыннан фәнни-методик ярдәм сорадылар.

Институт җитәкчеләре, җаваплы мөхәррир, фәнни хезмәткәрләр, бу әһәмиятле башлангычны хуплап, аларга җитди методик һәм гамәли ярдәм күрсәтәләр. Мисаллар күп, берничәсен генә атыйм. Гомәр әфәнде Сабирҗанов Болгар шәһәре һәм Спас районы (2 басма), Чүпрәле, Уренхой-Тыва (2 том) энциклопедияләрен әзерләүдә киңәшче, остаз һәм мөхәррир булды. Аның җитәкчелегендә институт хезмәткәрләре Әлмәт, Чистай энциклопедияләрен төзүдә турыдан-туры катнаштылар. Бу мөһим игелекле эшчәнлек дәвам итә.

Институт җитәкчеләре, хезмәткәрләре илнең башка субъектлары энциклопедиячеләре (8 коллектив) белән хезмәттәшлек итә, тәҗрибә уртаклаша. Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа, Чабаксар, Саранск һ.б. шәһәрләрдә, чит илләрдә Кишинёв, Киев, Кютахья (Төркия) шәһәрләрендә фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашып, чыгышлар ясадылар.

Татарстан Җөмһүриятенең 90 еллыгына институт «Республика Татарстан: природа, экономика, история, культура, наука» исемле күп фотосурәтле 1 томлы энциклопедик сувенир басма хәзерләп чыгарды (2010). Ул тиз арада таралып бетте.

2013 елда «Татарстан: иллюстрированная энциклопедия» (1 том) дөнья күрде. Бу басма 2014 елда, Бөтенроссия иң яхшы китап конкурсында (Мәскәү шәһәре) җиңеп, Диплом һәм Гран-при белән бүләкләнде. Бу басмаларны әзерләү һәм нәшер итү Гомәр Сабирҗанов җитәкчелегендә башкарылды, һәр мәкаләне ул редакцияләде.

Гомәр Сабирҗанов җитәкчелегендә һәм редакциясендә ана телебездә берничә ел элек хәзерләнгән Татар энциклопедиясенең 7 нче томы 2021 елда гына дөнья күрде, сәбәбе – финанс булмау. Шулай итеп, күптомлы Татар энциклопедиясен булдыру дәүләт программасы сыйфатлы итеп, тулысынча үтәлде. Шушы тәҗрибәле коллектив энциклопедиянең икенче басмасын хәзерләүгә керешсә, бик вакытлы, дөрес гамәл булыр иде. Мондый тәкъдимне Гомәр әфәнде 2010 еллардан ук әйтә килде. Тик институт директоры Р.М.Вәлиев бу нигезле тәкъдимне хупламады, хакимият алдына бу әһәмиятле мәсьәләне куймады. Хезмәткәрләрнең яртысын, кыскартып, эштән азат иттеләр, эре бүлекләр ябылды. Ә бит дөньяда булган энциклопедияләр тарихы, куллану тәҗрибәсе күрсәткәнчә, аларның камиллегенә өченче басмада гына ирешеп була икән.

Безнең институт 30 ел дәвамындагы эшчәнлеге нәтиҗәсендә милли энциклопедияләр хәзерләп нәшер итүнең үзенчәлекле фәнни методикасын булдырды, энциклопедистика теориясенә һәм төзелешенә зур өлеш кертте. Болар, үз чиратында, Татарстанда һәм башка төбәкләрдә дөнья күргән энциклопедик басмаларның фәнни дәрәҗәсен күтәрде, бу өлкәдә РФнең башка милли субъектлары өчен әйдәп баручы итте.

Хәзер институт коллективы фәнни тикшеренүләрнең яңа юнәлешләрендә эшли. Татар энциклопедиясенең онлайн варианты, электрон энциклопедияләр гамәлгә кертелә. Шулай да милли энциклопедияләрнең китап рәвешендәге басмаларына өстенлек бирелә.

Татарстанның торак пунктлары (3 том) турында кызыклы мәгълүматны «Татарика ворд» сәхифәләрендә табып була, аның беренче чыгарылышы интернетка кертелде. Киләчәккә планнар, В.Маяковский язганча, «громадье» – бик зур һәм гыйбрәтле. «Татарстан халыклары», «Татарстан сәнгате», «Якын чит илләрдәге татарлар», күптомлы Татар энциклопедиясенең яңартылган икенче басмасы, аның электрон варианты, «Татарстан матбугаты һәм журналистикасы», «Казан» сурәтле энциклопедиясе, «Татарстанда спорт һәм физкультура хәрәкәте», Татарстанның һәр районы турында монография нәшер итү, «Тарихи кече шәһәрләрне һәм авылларны саклау» (Кама Фәнни үзәге, Чистай шәһәре) һ.б., һ.б.

Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты (ИТЭР) 2005, 2006,

2017 елларда Казанда Бөтенроссия энциклопедистика фәнни-гамәли конференцияләре үткәрде. 2006 елдагы конференциядә Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа, Чабаксар, Саранск, Воронеж, Рязань, Златоуст энциклопедиячеләре катнашты. 2017 елгы җыенда РФнең 14 республикасы һәм өлкәсе энциклопедиячеләре бу эштә актуаль мәсьәләләрне хәл итү, киләчәккә планнар турында фикер алыштылар. Конференциядә Азәрбайҗан, Казакъстан, Молдова, Украина вәкилләре дә тәҗрибә уртаклашты.

2010–2014 елларда Институт директоры вазифасын тарихчы галим, профессор Р.М.Вәлиев башкарды. 2015 елның февралендә директор итеп Искәндәр Гыйләҗев сайланды. Ул – күренекле тарихчы, абруйлы оештыручы, ТР ФА мөхбир-әгъзасы (2019 елдан академик), Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. Урынбасары булып 2015–2023 елларда педагогика фәннәре докторы, профессор Ф.Г.Ялалов эшләде. Бу вазифаны 2024 елдан тарих фәннәре кандидаты, тәҗрибәле энциклопедияче М.З.Хәбибуллин башкара. 30 ел дәвамында энциклопедистикада теоретик һәм гамәли тәҗрибә туплаган, булдыклы тату коллектив фәнни эшчәнлеген элекке күпьеллык традициягә таянып, уңышлы дәвам итә. 1990 елдан бирле ИЯЛИдә эшләнеп нәшер ителә алмый яткан 2 томлы «Габдулла Тукай» персональ энциклопедиясенең текстларын һәм сурәтләү материалларын безнең институт хезмәткәрләре, сыйфатлы итеп хәзерләп, 2016 елның 3 аенда оригинал-макет эшләп бирде, халкыбыз өчен бик әһәмиятле бу хезмәт 2017 елда дөнья күрде.

Институтта хәзер 62 фәнни хезмәткәр эшли; шулардан фән докторлары – 10, фән кандидатлары – 21, фән һәм техника өлкәсендә Татарстан дәүләт премиясе лауреатлары – 4 кеше. Татарстанда, Россиядә, чит илләрдә шөһрәт казанган институтыбыз хезмәтчәннәренә иминлек, яңа казанышлар юлдаш булсын! Бу үзенчәлекле, тирән белем һәм күп хезмәт таләп итә торган җаваплы фәнни эшкә зур өлеш керткән ветераннар һәм бүгенге хезмәтчәннәр барысы да мактауга һәм хөрмәткә лаек.

Мәкаләнең күләме чикле, барысының да исемнәрен атап булмый. Шулай да, 20-30 ел дәвамында әле дә намуслы һәм нәтиҗәле хезмәт итүчеләрнең беразын ихлас ихтирам белән күрсәтәм, башка иптәшләр үпкәләмәс дип уйлыйм. Менә алар – безнең милләтпәрвәр фидакарь энтузиастлар: Р.В.Шәйдуллин, Л.М.Айнетдинова, И.Р.Вәлиуллин, Р.Р.Сәләхиев, Г.Х.Галимуллина, Г.М.Габделхакова, Ф.А.Ибраһимова, Г.Р.Дәүләтьянова, Р.Ф.Шәрәпова, И.Х.Хәлиуллин, Л.К.Галиева, Л.Р.Әскарова, Ф.Г.Кәлимуллина, Г.И.Каюмова, Ф.Г.Камалетдинова һ.б., һ.б.

Татар энциклопедиясен булдыру зарурлыгын, аның тарихи әһәмиятен аңлап, фәнни нигезле, сыйфатлы итеп бастырып чыгару өчен уңай шартлар тудырган Татарстан җитәкчелегенә без бик рәхмәтле! Г.И.Усманов, М.Г.Сабиров, М.Ш.Шәймиев, Р.Н.Миңнеханов безнең Институт эшчәнлеге белән даими кызыксынып, җитди матди һәм рухи ярдәм иттеләр. Кирәкле мәгълүмати материаллар сорап мөрәҗәгать иткәч, төрле министрлыклар, ведомстволар, оешмалар, предприятиеләр гозерне озакка сузмый, төгәл үтәп, безгә күп булыштылар, энциклопедия төзүгә әһәмиятле өлеш керттеләр. Нәтиҗәдә, ниһаять, без энциклопедияле халык булуга ирештек!

**Марс ГАИТОВ,**
*икътисад фәннәре кандидаты, доцент,*
*Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан*
*дәүләт премиясе лауреаты,*
*Татарстанның атказанган икътисадчысы,*
*ТР ФА Мансур Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе*
*һәм төбәкне өйрәнү институты ветераны*

# ХАТЫЙП МИҢНЕГУЛОВ – ИНСАНИЯТНЕҢ БӨЕК ҮРНӘГЕ

***(Әдәбият галиме Хатыйп Миңнегуловның «Күңелгә якын очрашулар» («Созвучные душе встречи») китабы чыгу уңаеннан)***

Татар сүз сәнгатендә кешелеклелек, аның гадел эш-гамәлләре турында күп язылган һәм язылып тора. Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбиятында ук инсаниятнең матур башлангычын гәүдәләндереп торучы каләм әһелләре шактый булган, һәм аларның шушы рухта теркәп калдырган әсәрләре дә байтак. Бу чор язучылары рухи-әхлакый сыйфатлар аша кешелек җәмгыятендә камил инсан образы тудыру өчен үзләре дә шундый ук яшәү рәвеше алып барганнар: күпчелек үз әсәрләрен автобиографик нигездә язып таратканнар яки үз хыял-максатларын якты образлар җирлегендә баетканнар, тулыландырганнар. Өмет-ышанычлары яктылыгында сюжет корганнар, аларны белем-мәгърифәтле, сабыр-олпат, ышаныч-таяныч булырдай, ихлас-риясыз, садәлек кебек сыйфатларга манып, җете образлар яссылыгында яктырткannнар.




Яңа заман каләм ияләре дә моннан чыгарма булмаган. Алар да моны тойган, аңлаган хәлдә гамәл кыла, әсәрләрен язып бастыра торган. Укучыларына үз әсәрләрен Коръәни-Кәрим үрнәгендә, дини яссылыкта, әхлакый җирлектә бәян иткән, укучыны да шуның рухында тәрбия кылган. Бүгенге көндә дә каләм әһелләре, галим-голәмә үзләре дә барлык вөҗүдләре белән шуңа омтыла. Кайчак ул урынлы һәм үтемле фикер әйтә, кайчак җиһанның гүзәл мәхлукатларына уйланырлык сорау куеп, асылына кайтырга чакыра, кайчакта хәтта таләп итеп, мәйданнарга чыга... Алар яшәү һәм иҗат итү дәверләрендә шулай итеп яшәешнең үзәгенә мәрхәмәт орлыклары чәчә.

Татарның асыл затлары арасында да үзенең эш-гамәлләре белән камил инсан образын тудыручылар шактый. Алар уй-фикерләре, яшәешләрендәге якты эзләре, башкарган игелекле эшчәнлекләре белән дә тоемлана, характерлана. Мондый мөгътәбәр инсаннар кешелек җәмгыятен бары мәрхәмәтлелек, кешелеклелек кенә коткарып калуын ассызыклыйлар. Үзләре дә шуңа омтылалар: яшәү рәвешләре белән шуны раслыйлар, гамәл кылалар.

Татарның олы ихтирамга лаек булган заты – әдәбият галиме Хатыйп Миңнегуловка болар тулаем туры килә. Аның тоткан мәсләге дә, яшәү рәвеше һәм кылган гамәлләре дә шуны раслый, шуны күрсәтә. Ил-көнгә игелек кылып яшәүне үзенең максаты һәм кыйбласы итеп алган Хатыйп абыйның һәр башкарган эше яхшылыкка һәм яктылыкка, күңел халәтенең сафлыгына, олпатлыгына ишарәли. Ул үзе дә язганнарында, катнашкан барлык чараларда: конференция һәм җыеннарда, семинар һәм гамәли кичәләрдә шуны раслый. Кайвакыт шактый үткен чыгышлар да ясый. Ул кешелек дөньясын сафландырырга, рух коесын тазартырга алынган миссиясен үзеннән соң да якты эз калдырырлык итеп эшли, башкара: Хозыр Ильяс кебек юлсызга юл күрсәтә, яралының йөрәген бәйли, хаксызның хакын таләп итә.

Галим һәм әдип Хатыйп Миңнегуловның язганнары байтак. Аларның барысында да гадел инсан үзәккә куела. Фәнни

мәкалә булсынмы, әдәби әсәрме – һәркайсы кешелеклелеккә, аның матур-әхлакый сыйфатларына, гүзәл яшәү үрнәгенә якын килеп аңлатыла, бәян ителә. Автобиографик повестьларында урын алган якты образлары үзләре артыннан ияртә.

Галим Хатыйп Миңнегулов үзенең 85 яшьлек юбилеен өр-яңа китабы белән каршы ала. Моның асылында да шәхеснең фәнни эшчәнлеге белән беррәттән үзенә генә хас булган дөньяны күзаллавы, халкыбызга карата ихтирамы, хөрмәте ята. Китаптагы фәнни бәйләнешләр яссылыгында тудырган байтак язмалары татар сүз сәнгатенең төрле чорларына карый. Соңгы дәвер вәкилләре турындагы мәкаләләре әлеге җыентыгында төпле урын алып тора. Татар поэзиясенең тулыландырылган яңа антологиясе өчен мөһаҗирлектәге шигъриятебезне үз эченә алган материаллары да шактый. Шунысы мөһим: галимнең бу җыентыгында да татар әдәбиятының үткәне һәм бүгенгесе яктыртыла. Үзәккә куелган язмаларның шактый өлешен «Хатыйп Йосыф улы Миңнегулов исемендәге IV Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция материаллары» тәшкил итә. Күпчелеген Хатыйп Миңнегуловның мәкалә-чыгышлары, фәнни эшчәнлеген яктырткан материаллары, мөһаҗирлек әдәбиятына мөнәсәбәтле язмалары алып тора. Китапта шулай ук аерым классик һәм хәзерге әдипләргә, кайбер әсәрләргә, фәнни хезмәтләргә, мөһим проблемаларга багышланган язмалар да бар.

«Шәхесләребез» сериясендә китаплар чыгаруда катнашып килгән галимнең әлеге хезмәтендә диссертацияләрнең, аерым хезмәтләрнең рецензияләре, башкаларның китапларына карата язылган кереш сүзләре, тәкъдимнамәләре урын алган.

Китап ике телдә: татар һәм рус телләрендә нәшер ителгән. «Әлеге җыентыкның мөкаддимәсе урынына» исемле кереш мәкаләсендә автор шактый гына хезмәтләренең язылу тарихына, тегe яки бу нисбәтле бирелүенә, аларның моңарчы кайларда басылуына аңлатмалар аша тәгъбир ителә. Күбрәк өлешне юбилей мөнәсәбәте илә язылганнары алып тора. Автор, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында дөнья күргән алты, сигез томлык татар әдәбиятын язуда катнашып, гаять тә игелекле хезмәт башкара. Аларның барысын да, шулай ук «Татар энциклопедиясе»ндә, «Әдәбият белеме сүзлеге»ндә, «Тукай энциклопедиясе»ндә, «Ислам на европейском Востоке» (2004) кебек белешмәлекләрендәге мәкаләләрен Хатыйп абыйның әлеге китабында күрергә була. Әдәби бәйләнешләргә, аеруча гарәп, фарсы, төрки, рус, борынгы Греция, Рим, шулай ук Һиндстан белән бәйләнешләргә да урын бирелгән. Моңа кадәрге традицияләргә тугры калып, фотоматериаллар, иллюстратив, биобиблиографик материаллар да урын алган.


Китапларга салынган оеткыда укучыга әйтер тәрбияви сүз-фикер булмаса, аның басылып чыгуы да шуның кадәр генә. Рухи ныклык, тәнкыйди эшчәнлек мәсьәләләренең дә кирәклеген ассызыклый автор китабында. Үзенең эшчәнлегенә карата булган мәкаләләргә дә урын бирә, аны кыю яктырта. Димәк, барысы да халык өчен, барысы да милләт өчен дип тырыша ул. Әйе, битараф булмаганнар гына гавам кайгысы белән кайгыра, гавам кайгысы белән яши шул. Бер акыл иясенең: «Дөньяны матурлык коткара», дигәне ничек хак булмасын инде?!

Шулай итеп, галим һәм әдип Хатыйп Миңнегулов хезмәтендә сүзнең көче, җегәре чагыла. Аны тудыручылар, каләм көченең асылын билгеләүчеләр үзәккә алына. Автор инсаниятнең бөек үрнәген – кешелеклелеген җете төсләр аша чагылдыра. Бу исә Хатыйп Миңнегуловның чираттагы табышы. Нәтиҗәле хезмәтенең басмадагы чагылышы. Отышлы һәм шул ук вакытта хәзерге һәм киләчәк буыннар өчен гаять мөһим, дәрәҗәле хезмәте. Шунысы мөһим: авторның ел дәвамындагы тырыш эшчәнлеге чагыла биредә. Һәр язманың юбилей мөнәсәбәтләре белән беркетелүе һәм раслануы матур итеп шәрехләнүе, системалы рәештә үреләп баруы – шуның ачык мисалы.

**Рәҗәп БӘДРЕТДИНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты*

# ТӘЛГАТ ГАЛИУЛЛИННЫҢ 10 ТОМЛЫК «САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР» (2023) БАСМАСЫНА КҮЗӘТҮ

2023 елда Татарстан китап нәшриятында әдәбият галиме, халык язучысы, филология фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, Россиянең, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Тәлгат Нәби улы Галиуллинның «Сайланма әсәрләр» 10 томлыгы (Төзүчесе – Фәүзия Галиуллина) басылды.




Томлыклар «Сәет Сакманов» трилогиясенә кергән «Тәүбә», «Элмәк» романнары белән башлана. Сурәтләнгән болганчык мохиттә вөждан, намус кебек кыйммәтләрне көнчелек, хөсетлек сыйфатлары күмеп китә. Төп герой Сәет Сакманов күчеш чорының төп сыйфатларын үзенә туплаган гомумиләштерелгән образ буларак күз алдына килеп баса.

2 нче томда трилогиянең 90 нчы елларда кеше гомеренең бәясен сурәтләгән «Төнге юллар» романы, Г.Тукай, Дәрдемәнд, Г.Исхакый, Ш.Бабич, М.Җәлил, С.Хәким, И.Юзеев, Г.Сәгыйров, Ш.Галиев, Г.Зәйнашева иҗаты турында тәнкыйть мәкаләләре тупланган. Кереш сүз буларак, галим Азат Әхмәдуллинның «Төнге юлларда ниләр булмас?» мәкаләсе урнаштырылган. Төп өлешне «Олы шәхесләр – шигъриятебезнең йөз аклыгы» бүлеге алып тора.

3 нче томга XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында замана агышын үз кулларына алучы шәхесләр турында публицистик мәкаләләр тупланган. «Тукай әйтмешли, лампада бик тиз май кими, күңел сүрелә... Нәрсәдән башларга бу истәлекләрне?» – дип, язучы хатирәләренә чума. М.Мәһдиевнең ташландык хәлгә килгән бинадагы хастаханәдә ятарга мәҗбүр булуын искә төшерү һәм татар телен укыту, шикаять хатлары, гаделсезлек изүе, яңартып кору чоры, көнчелек, хөсетлек турындагы фикерләр шәхес, милләт бәйсезлеге турында уйланырга мәҗбүр итә. «Теләсә кайсы халыкны нәрсә күтәрә?» дигән сорауга «Фаҗигагә каршы бергәләп дәррәү уяну көче» дигән җавабын да бирә автор. Татар халкын тыйнак, диләр. Моңа карата: «Тыйнаклык – яхшы сыйфат, әмма ул милли мескенлеккә, карусызлыкка әйләнсә, анысы инде фаҗига», – ди Тәлгат Нәби улы.

«Реаль тормыш һәм Джек Лондон егетләре Алабугада», – дип, Тәлгат Галиуллин педагогика институтында эшләү дәверендәге вакыйгалар белән бүлешә. «Милләтебезнең үсешен, туган телебезнең, әдәбиятыбызның киләчәген билгеләүдә иң мөһим кылларны кулларында тотып баручы көчләр – университетлар», – дип, аларның әһәмиятен ассызыклый. Гомумән, бу – җыентыкларның үзәгендә торган темаларның берсе. «Гомер юлымның башында ук поэзиягә каныктым. Аннары ул мине үзе үк җибәрмәс булды. Аяз Гыйләҗевнең ярсулы мәкаләсе белән

башланып киткән проза турында сөйләшү мине дә азындырды», – ди галим үзенең күпкырлы эшчәнлеге хакында.

«Тарихны онытсаң, киләчәгең юк» язмасында тарих дәверләренең әдәбиятта чагылышына, идарәчеләр, халык язмышына кагылышлы уйланулар дәвам итә. «Язучыларның максатлары – Болгарның алга киткән көчле ил булуын күрсәтү һәм болгар-монгол мөнәсәбәтләрен сурәтләү, аларны аеру», – дип яза галим. Бу темалар фән торышы турындагы уйланулар, истәлекләр белән үрелеп, «Замана балалары» дип исемләнгән икенче кисәктә дәвам итә. «Үз халкыңның язмышы кыл өстендә торганда, илдә урнашкан вазгыятькә берни үзгәрмәгәндәй битараф булу җинаять булыр иде», – дип, бу бүлеккә йомгак ясала.

4 нче том фольклор һәм әдәбият арасындагы бәйләнешләрне өйрәнүгә багышланган. Тәлгат Галиуллин буыннан-буынга, телдән-телгә күчеп шомартылган фольклор әсәрләрен шифалы сулы чишмәләр белән чагыштыра, «Шигърият чишмәсенең төбеннән чумырып алучы сүз осталарының исемнәре алтын хәрефләр белән язылып кала», – ди. Язучыларның тормыш фәлсәфәсен ачуда халык иҗаты энҗеләре әһәмиятле роль уйнавын, язма әдәбиятның беренче адымнары өчен алшартлар фольклорда тууын, шулай да фольклорны нигез, ә язма әдәбиятны корылманың өске өлеше итеп күз алдына китерү зур ялгыш булуын искәртә, фольклор мирасы югалу проблемасын күтәрә ул. Беренче бүлектә шагыйрьләребез, алар иҗатында туган якка мәхәббәт чагылышы, җырларда фольклоризм турындагы язмалар урын алган. Хәзерге поэзия үткәннең гүзәл казанышларын кире иҗатка кайтара, сәнгатьлелек көчен арттыра барып, үзе яңа традицияләр тудыра дигән нәтиҗә ясала. Икенче бүлектә чорлар дәвамында поэзиянең форма һәм жанрлар, агымнар, фикер һәм образлар ягыннан үсеше яктыртыла. Өченче бүлектә Г.Тукай, Г.Кандалый, Г.Афзал, Ш.Галиев, З.Нури, Ә.Исхак һ.б. иҗаты мисалында сатирик поэзия үсеше, үзенчәлекләре анализлана. «Бәетләрдә халык язмышы» язмасы, исеменнән күренгәнчә, «кешенең кайгы-хәсрәтен уртаклашу нияте белән иҗатка һәвәс затлар шигъри телгә күчергән кафияле икеюллыклар»га багышланган. Анда «бәет хәтере» гыйбарәсе аңлатыла, «бәет кемгә кирәк?» соравына җавап бирелә. Галим «Татарның миллилеге турында беләсең килсә, бәетләрнең башына чыгарылган исемнәр белән танышу да җитә дип уйлыйм» дигән фикерен җиткерә, бәетләрнең көче аерым шәхеснең фаҗигасендә илнең иҗтимагый-сәяси халәте дә чагылуда булуын раслый. Бу томны йомгаклап, «М.Мәһдиев публицистикасында мифологик катлам чыганак буларак» мәкаләсе урнаштырылган.

5 нче томның күп өлешен «Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы» бүлеге алып тора. Дәреслек битләрендә урын алган «портрет» итеп түгел, аны тулы тормыш кичергән кеше буларак сурәтләүне максат итеп куюын искәртә Тәлгат Галиуллин. Мөрәүвәтле сүз остасының балачагы, яшьлеге, гаиләсе турында мәгълүматлар, аның белән аралашып яшәү турында җылы истәлекләр бирелә. Гаҗәеп төгәл бәяләр остасы икәне искәртелгән М.Мәһдиевнең тормыш сәхифәләренең иҗатында чагылуы күрсәтелә. «Йолдызлык»тагы башка йолдызлар турында да язмалар бар бу томда. Аерым урынны Мөхәммәт аганың хатыны Лилиянең әтисе дә булган Г.Бәширов алып тора. «Гомер тәлгәшләре»ндә Тәлгат Галиуллин үз башыннан узган хәлләр, дуслары, танышлары турында сөйли. Автор «Туган як хикәяләре»ндә тәкъдим ителгән әсәрләрнең дә һәммәсе чынбарлыктан алынып күпертелгән икәнен яза.

6 нчы томда 70-80 нче елларда дөнья күргән әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм публицистик язмалары урын алган. «Яңа үрләр яулаганда» исемле бүлек поэма, балладаларның тематикасы, геройлары, хәзерге поэзиянең сыйфатлары, бу өлкәдәге яңалыклар, Х.Туфан, Р.Мингалим иҗаты турында. «Еллар юлга чакыра» дип аталган икенче бүлек чор сулышы һәм кеше хисләренең хәзерге татар поэзиясендә чагылышы, Ф.Кәрим, И.Юзеев,

Ш.Галиев поэзиясе хакында. «Безнең заман үзе җыр» бүлеге хәзерге укучының фикерләү үзенчәлегенең әдәбиятка тәэсире, андагы фәлсәфи мәсьәләләр, төрле буын шагыйрьләре тормыш тәҗрибәсенең иҗатка йогынтысына һәм С.Хәким, М.Җәлил иҗатына, Х.Туфанның «Ант» поэмасына багышланган.

7 нче томга әдәби тәнкыйть мәкаләләре туплап бирелгән. «Юлдагы маяклар» исемлесе татар совет поэзиясенең үсеш этапларына, «Кайда сез, Нәфисәләр?» бүгенге татар прозасы үсешенә багышланган. Ил язмышы – шигърият язмышы икәне раслана. Бу томда да татар язмышы, фән дөньясы турындагы уйланулар дәвам итә, рецензия, бәяләмәләр һәм ислам дине бишекләренә сәяхәткә багышланган язма бирелә.

8 нче томга «Китек көзге», «Кияү», «Мәкер» бәяннары, хикәяләр, публицистик мәкаләләр тупланган. Автор әйтүенчә, әлеге әсәрләрдә кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр чагылыш таба, әдәп-әхлак мәсьәләләре куела, туган телеңне, халкыңны хөрмәт итү, мәхәббәттә ихласлыкның тулы бәхеткә илтүе ачыклана. Соңгы бүлек публицистик мәкаләләрдән тора. Уены-чыны бергә язылган «Коронавирус – яңа ачылган чирме?», «Хәзерге татар шигъриятендә Гаяз Исхакый образы» дип аталганнары, мөнәҗәт турындагысы да бар.

9 нчы том авторның үз әсәрләреннән башлана. Кыйсса, бәяннары, «Сукыр Гаваз» белән аерым китап буларак чыгарылган һәм укучылар арасында уңыш казанган, яңа заманның әхлакый йөзе турында уйланырга чакырган «Ана корт» повесте урын алган. Алдагы кисәкләргә хас булганча, «Хәтер дәфтәреннән» һәм «Ике гасыр чатында татар сүз сәнгате» бүлекләрендә истәлекләр белән үрелеп, Т.Әйди, Х.Сарьян, К.Җаманаклы, С.Хәким, Г.Афзал, И.Юзеев, Р.Мингалим, Л.Шагыйрьҗан, Р.Аймәт, Л.Лерон, Ф.Солтан, З.Мансуров, Р.Гарифуллина иҗатлары турында әдәби тәнкыйть мәкаләләре бирелә.

10 нчы томда соңгы еллар поэзиясенә, Р.Зәйдулла, Р.Җамал иҗатларына караш, «Казан утлары» – татарның визит карточкасы» мәкаләләре һәм шәхесләребезнең авторга багышланган язмалары урын алган. Китапның соңгы битләрендәге әдәбият исемлеге күбрәк мәгълүмат алырга теләүчеләр өчен файдалы булыр.

Ошбу саллы хезмәтендә галим әдәбиятның җитди һәм катлаулы мәсьәләләрен киң катлау укучылары аңларлык итеп аңлата, күзаллауны тулыландырырга ярдәм итә һәм фән даирәсе пәрдәсенең бер читен ачып күрсәтә. Китаплар татар теле һәм әдәбияты укытучыларына, филология факультеты студентларына гына түгел, әдәбиятны тирәнтен, камилрәк үзләштерергә теләүче һәркем өчен кызыклы. Бер яктан, төрле томнарда урын алган язмаларны тематикалары буенча берләштерү мәгълүматны эзләп табуны уңайлырак итсә, бу басмаларда авторның үз әсәрләре, төрле язучылар иҗатына караган тәнкыйть мәкаләләре һәм истәлекләр үрелеп баруы укучы игътибарын саклау, томнар арасында тыгыз бәйләнеш урнаштыруга хезмәт итә.

**Ралина ХӘБИРОВА,**
*Казан федераль университетының 1 курс студенты, «Рухият» фәнни түгәрәгенең кураторы*

*Марсель Галиев атлы каләмдәшемнең үзенә килгән хатлардан сайлап, берничә сәхифә итеп, журналыбызда бастырып чыгаруы миндә бу онытыла язган бабка – эпистоляр жанрга булган мәхәббәт хисләрен яңадән кузгатып җибәрде. Күпме әдәби кыйммәте булган фактлар, симпатия һәм антипатияләр документы ул хатларда! Әдәбият үсешендәге табигый агымнар, эзләнүләр, үзгәрешләр!.. Тарих!..*

*Миндә дә андый хатлар саклана. Иң күбе – якташларым Наҗар Нәҗмидән, Вазих Исхаковтан, Нурия Измайловадан, мөгаен, чордашларым – Разилдан, Роберттан, Гәрәйдән һ.б. Мин биредә арабыздан киткәннәрне әйтәм. Исәннәрнең хатларын бастыру алар рөхсәте белән генә булыр иде. Ә мәрхүмнәрнең рухлары кичерер дип өметләнәм.*

*Яшьлегемдә зур йогынтысы булган Әнгам Атнабайның кадерле хатлары... Яки өлкән аксакал Сәйфи Кудаш язганнар... Тәнкыйтьтән соң юатып, Сибгат ага Хәкимнең һаман ышаныч белдереп язган хаты... Яисә безнең алсу хыяллар, коммунизм булачагына куаныч белән язган сабакташым Хатыйп Миңнегулов хаты. Күз алдына китерегез: милләтнең олуг галиме булып өлгергәнчегә кадәрге мәртәбәле юл башы, барчабызныкы кебек үк нинди «матур киләчәк» иллюзияләренә бәйле! Йә 1966 елда, минем беренче китап чыккач, Разилның туган якларына – Ташлык, Түбән Кама һәм Иштирәк авылларында әдәби кичәләр, матур танышлык һәм яшьлек хисләре хатирәләренең шаһиты булган хаты («Иштирәк кунагы» исемле мәкалә дә чыккан иде, Чаллы газетасына Г.Метшин исемле әдәбият гашыйгы язган иде. Хатта да ул искә алына. Хәтта Иштирәктә миннән «отып калган» «мияу-мияу» дип шаккатырган гүзәл бер кыз да!)... Мондый эчкерсез дуслык хатын Разил да башкача язмады, ахры: бергә Мәскәүгә киттек, бүтәнчә яшәеш, мәшәкатьләр тулы җитди хатлары саклана.*

*Үземнең мәңгелек кумирым Бабичның сеңлесе, минем бу бөек шагыйрь-агасы турында язганнарымны укып барган Фәсәхәт апаның да, бу темага озын шигыремне шатланып каршылаган Сәйфи ага Кудаш хаты да укучыга кызыклы булыр, шәт: узган гасырның җитмешенче, сиксәненче елларындагы Уфа, Казан мөнәсәбәтләре, уртак борчу-шатлыклар лабаса!*

**Рәдиф ГАТАШ**

# ӘНГАМ АТНАБАЙ ХАТЛАРЫ

*27 октябрь, 1961 ел*
*Уфа*

Рәдиф!

Үпкәләп язган открыткаңны алдым. «Үпкәләргә тик син генә хаклысың». Гафу үтенеп тормыйм. Ирләрнең гафу үтенүе ничектер төчелек кебек.

Тизрәк бер яңалык әйтергә ашыгам. Январь башларында Марат Кәримов белән Казанга барырга җыенам. Наҗар да көнләшеп куйды, мин дә барам, ди. Бәлки аны да алырбыз. Ничек, хуп күрәсеңме? Анысы да монысы, синең каникул кайчан башлана да кайчан бетә? Синең каникул чагына туры килеп куймыйк, дим. Син шул турыда белеп, хат яз әле, яме?

Тагын бер яңалык: 23 декабрьдә ел саен үткәрелә торган поэзия кичәсе булды. Бу юлы Министрлар Советы залында үткәрделәр. Телевидениедән күрсәттеләр, радиодан бирделәр. Бик шәп үтте. Мин «Замандаш»тан өзек һәм берничә шигырь укыдым.

Тагын нәрсә? Ярмәкәй районында булып кайттым. Киң колач белән каршыладылар. Поэманы, авыл халкы да аңлый микән дип, аларга да укып күрсәттем. Аңлыйлар икән, хәтта кайбер әдәбият әһелләренә караганда яхшырак, тирәнрәк аңлыйлар. Шундый әйбәт халкың булганда, язарга да мөмкин дигән фикер белән кайттым.

Берничә яңа шигырь яздым. Ара-тирә пьесага утыргалыйм. Пьеса авыр бара. Ни барып чыгар – куркам.

Тагын? Тагын иң мөһиме калган икән әле. Шигырьләрең турында. «Диңгезгә» дигәнен, диңгезне күрсәң, әйбәтрәк язар идең. «Студент хаты» Гаташны түгел, Хәсән Туфанны хәтерләтә, бик нык хәтерләтә. Әллә, мин әйтәм, фамилияләр буталды микән дип уйладым. Валлаһи!

Ярый, Рәдиф дус, гаташланып маташма, гап-гади генә Гатауллин бул да бик шәп шагыйрь бул. Теләгем – Яңа ел теләгем – шул.

Күрешкәнче бер хатыңны укырга өметләнеп, Әнгам абыең.

***

*28 ноябрь, 1961 ел.*
*Уфа*

Рәдиф!

Хатыңның Казаннан булуына шатландым. Шәп! Бу адымыңны атларга чак кына соңга калсаң, мөгаен, үкенер идең, үзеңне-үзең гафу итмәс идең. Гомумән, молодец! Ә мин синең шагыйрь булачагыңа, чын Казанда кайнатып, менә дигән шигырьләр иҗат итәчәгеңә ышанам. Бәлки бу ышаныч өчен әллә ни зур нигезлекләр дә, материаль сәбәпләр дә юктыр хәзергә, ләкин барыбер ышаныч бар. Ул ышаныч синең үзеңдә, әдәбиятка булган инануыңда, табынуыңда, мөнәсәбәтеңдә. Мәхәббәт кешене шагыйрь ясый ул!..

Бу хатны мин санаторийга китмәс борын башлаган идем. Мәскәү янындагы «Родина» дигән санаторийда айга якын ятып кайттым. Шәп булмады. Барысы да рус та, «Абгам» белән «Сага», татарча сөйләшергә кеше таба алмыйча зарыгыплар булып, урманда берүзем кычкырып, шигырь укып йөрдем дә срокны тутырмыйча кайтып киттем.

Соңгы вакытта әллә ни күп эшләп булмады: пьесаны дәвам итәм, ике-өч шигырь яздым, «Замандаш»ыма үзгәрешләр керттем, бер бүлеген яңадан яздым. Аны русчага тәрҗемә иттеләр, яңа җыентык әзерләргә кушалар, тизрәк, диләр. Әзерлим.

Журналны җибәрә алмыйм әле, Рәдиф. Кул астында гына юк. Аннары үзгәрешләрен дә укытасы килә. Мин аның машинада басылганын җибәрермен. Шунда хатны да озын итеп, әйбәт итеп язармын. Монысы ...-башлы килеп чыкты.

Сау бул. Уңышлар телим. Үзеңнең эшләр ничек? Яңа шигырьләреңне укыйсым килә.

*Әнгам.*

***

*8 ноябрь, 1963 ел*
*Уфа*

Рәдиф!

Уфамны сагынып кайткан идем, менә тагын Казанымны сагына башладым. Бигрәк тә Красная Позициядәге кичә сагындыра. Чын, чын, һәрбер ваклыгы искә төшеп, йөрәкне чеметеп-чеметеп алган төсле була. Кешенең буыннары ката барган саен күңеле нечкәрә бара микән әллә? Мөгаен, шулайдыр.

Уфа бер килеш кенә уфылдап ята. Әллә ни зур үзгәрешләр юк. Халык бәйрәм итә. Урамнар исерек. Урамнар җырлый. Мин аек. Эчәсе килми. Гадәти көннәрдә күбесенчә исерек булгангамы, бәйрәм көннәрендә бөтен кеше бердәм эчкәндә, ял итәсе килә. Шуның аркасында менә өченче көн инде аракы иптәш белән дуслык китеп тора.

Эшкә дә кул бармый, ниндидер төшенке кәеф. Тәрәзәдән ерак горизонтка карап торам да каядыр олагасы килеп куя. Кая? Шайтаным белсенме аны! Менә берничә хат килгән. Шуларга җаваплар язып салырга кирәк, ичмасам. «Хатлар» дигәннән, үч иткәндәй, икесе Татарстаннан. Берсе – Минзәлә районыннан, икенчесе ниндидер Ерыклы авылыннан. Шундый авыл исеме дә була икән – Ерыклы! Ха-ха-ха! Ул авыл кешеләре: «Мин Ерыклыныкы», – дип йөриләр микән?

Рәдиф! Казандагы соңгы көн өчен гафу ит инде, малай?! Шигырьләреңне дә укып булмады. Әллә нинди өермәле сәгатьләр, минутлар булды ул! Иҗади дустымны әллә нишләп хатын-кыз затына алыштырып ташлаганмын. Әлеге күңел йомшаклыгы. Ничава, соңгы очрашу түгелдер. Кышкы каникулга кайтасыңдыр, шәт. Кайтсаң, минем янга килмичә китмәссең дип уйлыйм. Әйеме?

Хат яз. Җавапсыз калдырмам.

Дусларыңа барысына да күп итеп сәлам әйт, рәхмәтемне җиткер. Алар миңа ошадылар.

*Сау бул. Яхшылык теләп, Әнгам.*

***

*18 декабрь, 1963 ел*
*Уфа*

Рәдиф!

Менә хәзер Яңавыл районына әдәбият һәм сәнгать атналыгына китәргә торабыз: язучылар, композиторлар, художниклар, артистлар. Өйдән чыгып китәргә егерме минут калды. Нидер эшләргә кирәк. Кинәт сине, Казанны хәтерләдем, Флора искә төшеп китте. Һәм менә хат язарга булдым.

Моннан бер атна чамасы элек кенә пьесамны төгәлләдем. «Ана хөкеме» дип атала. Кичә театр коллективына укыдым. Яраттылар. Куярга телиләр. Хәзер бер поэма язасы килә. Зур мәхәббәт турында язарга иде. «Мәхәббәт тәүбәсе»ннән дә ким булмасын иде. Планнар күп, өлгереп кенә булмый. Башланып ташланган, яңадан башлап караган күпме нәрсә ята! Ә гомер уза. Вакыт мәңгелек тә, гомер кыска гына бирелә икән бу адәм баласына.

Мин Флорага хат язган идем. Нигә җавап язмады икән? Шулай ярамый инде.

*Дөрес, минем синнән хат көтәргә,*
*Өмет итәргә дә хакым юк.*
*Ләкин йөрәк һаман таләп итә,*
*Таләп итә: нигә хаты юк?*

Шулай дип сора әле, яме?

Үзеңнең рухи яктан күтәренке булуың шәп, әлбәттә. Кәеф яхшы булганда, шигырьләр дә языла ул: бер мәл дөньясына төкереп, борын салындырып аласың да, шатланып, шигырь язасың. Синең дә шулай булсын. Мин синең үсүеңә балаларча шатланам, сөенәм, кайгыңа көенәм. Тфү, тфү, ир кешеләрнең дуслыгы болай төче булмаска тиеш. Ирләр дуслыгы чак кына тупасрак буладыр, мөгаен.

Ярый, мин китим инде. Син миңа яхшы юл телә. Яңа шигырьләр алып кайтырга язсын.

Казандагы барлык дусларга сәлам әйт. Флорага үзенә башка, иң кайнарын тапшыр.

*Эшеңдә, тормышыңда иң гүзәл яхшылыклар теләп, Әнгам.*

***

*1977 ел,*
*Уфа*

Рәдиф!

*Офык артында офыклар,*
*Үрләр артында үрләр...*
*Тарихларда торып калыр*
*Безнең яшәгән көннәр.*

*Йөзгә кызыл килерлек тә,*
*Үкенерлек тә түгел:*
*Ике гомергә торырлык*
*Җыр белән үткән гомер.*

*Октябрьнең 60 еллыгы белән 60 тапкыр ихлас котлап, Ә.Атнабай.*

*Энҗе Мөэминеваның тууына – 100 ел*

# ШИГЫРЬ УЛ – ТЕРЕ ҖАН ИЯСЕ



Шагыйрә, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты Энҗе Һилалетдин кызы Мөэминеваның (1924 – 2009) тууына – 100 ел.

Татарстан Язучылар берлегенең рәсми сайтына мөрәҗәгать итик:

«Энҗе Мөэминева озын иҗат гомерендә олылар өчен дә, балалар өчен дә бердәй актив язган мул җимешле шагыйрьләр җөмләсеннән. Аның «Ефәк яулыгым» исемле беренче шигырь китабы 1961 елда басылып чыга. Шуннан соң «Әниләргә һәм нәниләргә» (1964), «Шигырьләр» (1966), «Синең өчен язам» (1968), «Үрдәгем үпкәләде» (1969), «Бүләгем» (1970) һ.б. китаплары дөнья күрә. Эчтәлек ягыннан аның шигырьләрендә һәм поэмаларында хезмәт кешесенең самими уй-хисләре, хыял-омтылышлары сурәтләнә, тормыш-яшәешнең мөһим шартларыннан булган гаилә кору, бала тәрбияләү, табигатьне саклау, әйләнә-тирәндәге кешеләргә игелек кылу кебек әхлакый проблемалар үзәккә алына».

Шагыйрәнең юбилее уңаеннан Татарстан радиосында берничә тапшыру әзерләнә. Шөкер, бу җәһәттән материал кытлыгы юк, чөнки архивта Э.Мөэминевага кагылышлы кырыкка якын язма саклана. Болар – аның шигырьләренә иҗат ителгән җырлар, әсәрләреннән төзелгән радиокомпозицияләр һәм шагыйрәнең үз тавышы кергән тапшырулар.

Журнал укучылар игътибарына без әнә шундый язмаларның берсен тәкъдим итәбез. 2008 елда, шагыйрәнең вафатына нибары бер ел вакыт калып килгәндә, язучы һәм журналист Дания Гайнетдинова каләмдәше белән әңгәмә үткәргән иде. Биредә Энҗе апабызның күңел хасияте, дөньяга карашы бөтен тулылыгы белән ачылып җитә кебек. Әйтик, «Сез гомерегез буе балаларга математика фәнен укыткансыз, математиканың серле дөньясында яшәгәнсез, шул ук вакытта шагыйрә булып танылдыгыз. Сез бу, беренче карашка, бөтенләй капма-каршы тоелган ике дөньяны ничек саклап килә алдыгыз?» дигән сорауга ул болай дип җавап бирә:

– Әйе, минем 33 ел гомерем укытучылык эше белән үтте. Шигърият белән дә шөгыльләнәм. Үлгәнче шулай булачак инде ул, чөнки шигъристтән пенсиягә китеп булмый. Математика белән поэзиянең капма-каршылыгына килгәндә, ул беренче карашка гына шулай тоела. Алар бер-берсе белән аерылгысыз бәйләнештә, бер-берсен тулыландырып торалар. Математика логик фикер йөртүне таләп итә, математик мәсьәләне чишү өчен билгеле бер закончалыкка нигезләнеп, башыннан ахырына кадәр, җавапка килеп чыкканчы конкрет фикер йөртергә кирәк. Поэзиядә дә шулай ук. Һәр шигырь – билгеле бер фикер җебен хискә төреп аңлату бит ул. Логик фикер җебе булмаган шалтыравык сүз тезмәләре чын шигырь була алмый. Шигырь ул – тере җан иясе кебек, ул туа, яши, үлә, шуңа күрә һәр шигырьнең язылу тарихы, үз биографиясе дә була...

Аннары сүз аерым шигырьләрнең, аларга иҗат ителгән җырларның язылу тарихы, биографиясе турында дәвам итә. Инде QR-код ярдәмендә шушы тапшыруны ачыйк һәм, әлеге кызыклы әңгәмәне тыңлап, яраткан шагыйрәбезнең газиз тавышын ишетик.

*Миркасыйм Госмановның тууына – 90 ел*

# ИМАНЫМ – ХАЛЫККА ХЕЗМӘТ



Шундый затлар була: алар, бу дөньядан киткәч, үзләре белән тулы бер чорны – үз дәверләрен алып китәләр кебек тоела. Ләкин бераз аңга килгәч, шунысы да аңлашыла: юк, алар үз вафатларыннан соң да халыкка, милләткә бер терәк булып хезмәт итәләр. Без аларның әйтеп калдырган фикерләренә, кылган гамәлләренә, әдәби яисә гыйльми мирасларына, васыятьләренә таянабыз. Безгә авыр вакытларда аларның сүзләре көч бирә, фикерләре туры юл күрсәтә. Әнә шундый шәхесләребезнең берсе – тарихчы, археограф, язучы, тарих фәннәре докторы, академик Миркасыйм Госмановның (1934–2010) тууына 90 ел тулды.

Галимнең тормыш юлына һәм гыйльми эшчәнлегенә кагылышлы язмалар журналыбызның киләсе санында дөнья күрер дип көтелә. Ә хәзер без укучыларыбыз игътибарына гаҗәеп кызыклы бер радиотапшыру тәкъдим итәбез. Ул моннан ун ел элек шушы юлларның авторы тарафыннан М.Госмановның тууына 80 ел тулу уңаеннан әзерләнгән иде. Биредә галим белән булган әңгәмәләрдән һәм аны искә алып үткәрелгән кичәләрдән фрагментлар файдаланылды. Тапшыру шагыйрь Гәрәй Рәхимнең Миркасыйм Госмановка атап язган шигыре белән ачылып китә. Аннары Разил Вәлиев галим белән бергәләп «Җыен» фондын оештырып йөргән вакытларын искә алып сөйли (кызганыч, бу ике шәхесебез хәзер инде үзләре дә бакыйлыкта). Шушы чыгышка галимнең үзе белән «Җыен» фондына кагылышлы әңгәмә ялганып китә, һәм ул сүзен болай дип башлый: «Мин үзем бөтен эшне җәмәгатьчелек тәртибендә эшлим, чөнки минем бер иманым бар: үз халкыңа нәрсәнедер, кулыңнан килсә, бушлай эшләргә тиешсең. Мин бит – халыкка хезмәт итәм дип ышанган кеше. Разил Вәлиев, Туфан Миңнуллин – барысы да бу эштә җәмәгатьчелек тәртибендә катнашалар. Әгәр дә без гражданнар җәмгыяте булсын дип телибез икән, халыкта менә шундый аң да булырга тиеш. Гражданнар җәмгыяте ул ихтыяри, фидакарьләрчә эшләгәндә генә барлыкка килә...»

Биредә шулай ук Татарстан Фәннәр академиясенең элеккеге президенты, Миркасыйм ага белән иңгә-иң торып эшләгән кешеләрнең берсе – академик Әхмәт Мазһаров, Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллин чыгышлары урын алган.


Миркасыйм Госмановның тагын бер хезмәтен искә алмый мөмкин түгел: тарих фәнен милләткә хезмәт иттерүнең ачык бер мисалы – Казаныбызның меңъеллык тарихы булуын исбатлау, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары Людмила Андреева аның шушы юнәлештәге эшчәнлеген ачып бирә.

Тапшыруда сез шулай ук күренекле галим Искәндәр Гыйләҗевның остазына кагылышлы фикерләрен ишетерсез.

Миркасыйм Госманов турында сүз барганда, «югалту» сүзе килешеп җитмәс кебек, аның хезмәтләренә мөрәҗәгать иткән саен, без аны әле таба гына барабыз. Аның XX гасырның икенче яртысы һәм XXI гасыр башында иң күренекле милләттәшләребезнең беренче бишлегенә кергән зат икәнлеге яшәгән саен аңлашыла бара. Ул бик күпләр өчен остаз булып кала, шәкертләр тәрбияләвен дәвам иттерә.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

# ӘДӘБИ СКАНВОРД

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
|  | | | | | | | | Шәрык поэзиясендә дүртьюллык шигырь | | Татар шагыйре |
| | | | | Әхәт Гаффар повесте | | ... Прилепин (рус язучысы) | | | | |
| | | | | | | | | ... Мандельштам / Француз язучысы | | Борынгы салым |
| | | | | ... Урайский | | Юнысова, Минһаҗева | | | | |
| | Әдәби әсәр төре | | | | | ... Христиан Андерсен | | | | |
| | | | | Эльмира Шәрифуллина поэмасы | ... Нәҗми | | | | Кылыч савыты | |
| | | | | XIX йөз француз композиторы | | | | | | |
| Эт токымы / Кыйммәтле таш | | ...-Жак Руссо | | Әдәби әсәрнең тәмамлану өлеше | Украин язучысы, фольклорчы | | «... Скала» (Милан опера театры) | Эстон рәссамы | | Хәким Хәйруллин романы |
| | Марсель Галиев китабы | | Кәрим Тинчурин драмасы | | | | | | | ... Юзиев |
| | | | | | Әбҗәлилов, Мәхмүтов | Казакъларда халык җырчысы, шагыйре | | | | |
| | ... Мөхәммәд хан | | | | | Михаил Лермонтов поэмасы | ... Карнай (башкорт язучысы) | | | |
| | | | Шагыйрь ... Әмирханова | | | | | | Немец язучысы | |
| Корабта аш пешерүче | | Рус шагыйре | | | | | |  | | |
| | | | | | | Очкыч | | | | |
| Язучы, галим ... Поварисов | | | | Сагыш, моң белән сугарылган шигырь | | Даниил ... (рус язучысы) | | | | |
| Актёр Ричард ... | Язучы Алексис Кивиның милләте | | Шекспир короле / Рус сатиригы | | | | | | | |

**Рәис ГАБДУЛЛА** *төзеде*

***Үткән санда чыккан сканворд җаваплары. Султан уңга:*** *Газиз, яхта, Фәнил, граф, «Гарасат», Таир, Роза, Анри, Павел, дәфнә, Нәкый, Разим, Яна, Әнәс, Шакир, Әюп, Киров, каю, титр, Инна, Аль, Рәми.* ***Өстән аска:*** *тип, Ахир, Агата, Агиев, Гаффар, Еники, әләм, Ркаил, «Зиндан», июнь, «Адымнар», Зөлкарнәй, Отар, торф, Ясәви, Зинин, Том, ампир.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман З.ХАКИМА «Таинственная монета», повести И.ДИНДАРОВА «Чёрные дни белых ночей», Л.ЛЕРОНА «Обруч»; стихи Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ, Р.РАХМАНИ, Д.ГАРИФУЛЛИНА.*
*«Новые имена»: стихи Э.МИННУЛИНОЙ.*
*Литературный конкурс «Нравы отчего дома...»: рассказ Р.БАТУЛЛЫ «Родинка».*
*«Литература родственных народов»: стихи И.ТЮРКОГЛУ в переводе Ф.ГИЛЯЗОВА, С.РАУФА в переводе Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ.*
*«Юбилеи»: фотоархив, посвящённый 90-летию образования Союза писателей РТ; статья Т.ГАЛИУЛЛИНА, посвящённая 85-летию Ф.Юсупова; статья М.ГАИТОВА, посвящённая 30-летию Института татарской энциклопедии и регионоведения Академии наук РТ.*
*«Обзор книги»: статьи Р.БАДРУТДИНОВА, Р.ХАБИРОВОЙ.*
*«Памятные письма»: письма А.Атнабаева Р.Гаташу.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 100-летию Э.МУКМИНОВОЙ и 90-летию М.УСМАНОВА. Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*Литературный сканворд. Составил Р.АБДУЛЛА.*
*На наших обложках: здание Союза писателей РТ. Фото И.АБРАМОВОЙ; кандидат исторических наук, общественный деятель Т.БИКТИМЕРОВА.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and Poetry»: novel by Z.KHAKIM «The Mysterious Coin», stories by I.DINDAROV «Black Days of White Nights», by L.LERON «Hoop»; poems by F.ZAMALETDINOVA, R.RAKHMANI, D.GARIFULLIN.*
*«New names»: poems by E.MINNULLINA.*
*Literary contest «Morals of the Father's House...»: story by R.BATULLA «The Birthmark».*
*«Literature of kindred peoples»: poems by I.TURKOGLU translated by F.GILYAZOV, S.RAUF translated by F.ZAMALETDINOVA.*
*«Anniversaries»: photo archive dedicated to the 90th anniversary of the formation of the Union of Writers of the Republic of Tatarstan; article by T.GALIULLIN, dedicated to the 85th anniversary of F.Yusupov; article by M.GAITOV dedicated to the 30th anniversary of the Institute of Tatar Encyclopedia and Regional Studies of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan.*
*«Book review»: articles by R.BADRUTDINOV, R.KHABIROVA.*
*«Memorable letters»: letters by A.Atnabaev to R.Gatash.*
*«Priceless voices»: articles for the 100th anniversary of E.MUKMINOVA and the 90th anniversary of M.GUSMANOV. The column is led by N.AKMAL.*
*Literary crossword puzzle. Compiled by R.ABDULLA.*
*On our covers: the building of the Union of Writers of the Republic of Tatarstan. Photo by I.ABRAMOVA;*
*Candidate of Historical Sciences, social activist T.BIKTIMEROVA.*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* Татарстан Язучылар берлеге бинасы. *И.АБРАМОВА фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* тарихчы Тәэминә БИКТИМЕРОВА.

***Төзәтү.*** *Апрель санының 184 нче битендә «24 ноябрь, 1999 ел» дигәнне «24 февраль, 1999 ел»; «Йортта 5 ноябрьдә» дигәнне «Йортта 5 февральдә» дип укырга.*